تخلص

# ЛИТЕРАТУРНАЯ МАСКА
# ПСЕВДОНИМ
# ТӘХӘЛЛҮС
# ΨΕΥΔΏΝΥΜΟΣ
# ЯШЕРЕН ИМЗА

**РУХИ МИРАС**

ЭЗЛӘНҮЛӘР ҺӘМ ТАБЫШЛАР

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ТӘХӘЛЛҮСЛӘР

МИРАСХАНӘ

**РУХИ МИРАС**

ЭЗЛӘНҮЛӘР ҺӘМ ТАБЫШЛАР

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ТӘХӘЛЛҮСЛӘР

**10**

МИРАСХАНӘ

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

Казан • Казань
2021

# РУХИ МИРАС

## Эзләнүләр һәм табышлар

**Татар әдәбиятында тәхәллүсләр**

# ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ

## Поиски и открытия

**Псевдонимы
в татарской литературе**

УДК 94 (093)
ББК 63.2
Р 82

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

Проект «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024)»
ТР Дәүләт программасы кысаларында
ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият
һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге
тарафыннан гамәлгә ашырыла

**Редколлегия:**
***И. Г. Гомәров*** *(проект җитәкчесе һәм җаваплы мөхәррир),*
***Ә. М. Закирҗанов, А. М. Ахунов***

**Төзүчеләр:**
***Л. Ш. Гарипова, Г. Н. Зәйниева***

**Р 82** **Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбиятында тәхәллүсләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Псевдонимы в татарской литературе** / редкол.: И. Г. Гомәров (проект җит. һәм җавап. мөх.), Ә. М. Закирҗанов, А.М. Ахунов; төз.: Л. Ш. Гарипова, Г. Н. Зәйниева. – Казан: ТӘһСИ, 2021. – 10 нчы чыг. – 300 б.
ISBN 978-5-93091-404-7

Җыентык татар халкының рухи мирасын барлау, билгесез яки аз билгеле язма чыганакларны бастырып чыгару, татар текстларын өйрәнү барышындагы яңа фәнни тикшеренүләр белән укучыларны таныштыру традициясен дәвам итә.

Әлеге чыгарылышта татар сүз сәнгатендә псевдонимнарны өйрәнүгә багышланган язмалар, фәнни мәкаләләр һәм хезмәтләр тупланды. Төп урын журналист, язучы, җәмәгать эшлеклесе Мәхмүт Бәдәйлинең «Псевдонимнар сүзлеге»нә бирелде. Гарәп язулы кульязмада сакланган бу хезмәт гамәлдәге татар язуына күчерелеп, укучылар игътибарына беренче тапкыр тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-93091-404-7

© ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать нституты, 2021

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫНДА ПСЕВДОНИМНАР

Псевдоним – грек сүзе, «яшерен имза, кушамат» мәгънәсендә. Урта гасырлар шәрык, шул исәптән татар әдәбиятында язучылар үз иҗатлары өчен сайлап алган әдәби исем гарәп теленнән кергән *тәхәллүс* («нәрсәдән дә булса арыну, азат ителү» мәгънәсендә) сүзе белән дә билгеләнгән. Күпчелек очракта тәхәллүсләр әдипнең сәнгати осталыгына, тормышта башкарган һөнәренә, туган яки иҗат иткән урынына һ.б.га символик ишарә булып тора. Шәрык классикларыннан Сәгъди «бәхетле», Нәваи «аһәңле», Гаттар «ислемай белән сәүдә итүче» дигәнне аңлата, татар әдипләреннән Сәйф Сараи «Сарай шәһәрендә иҗат итүче», Хисам Кятиб «язучы Хисам» дигән мәгънәне белдерә.

Татар әдәбиятының «алтын дәвере» саналган XX йөз башында тәхәллүсләр кулланып язу аеруча активлашып китә. Бу иң беренче чиратта татар телендә вакытлы матбугат чыга башлау, мәгърифәт һәм иҗат иреге киңәю нәтиҗәсендә әдәбият мәйданына килүче «каләм тибрәтүчеләр»нең арта баруы кебек күренешләр белән бәйле. Болардан тыш, әлеге чорда патша хөкүмәтенең эзәрлекләвеннән, цензура күзәтүеннән яшерену өчен дә, аерым бер әдипләр, сәяси эшлеклеләр үзләренә төрле яшерен имзалар алырга мәҗбүр булганнар. Шулай ук кайбер башлап язучылар, беренче әсәрләрен бастырганда, чын исем-шәрифләрен куярга кыюлыклары җитмичә, тәхәллүсләр кулланганнар. Яки киресенчә дә булган: танылган язучылар, һәр көн саен басылып чыккан язмалары белән укучыны ялыктырмас өчен, яшерен имзалар алу юлын сайлаганнар. XX гасыр башында

актив иҗат иткән Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Фатих Кәримиләрнең псевдонимнары күп булуы шуның белән дә аңлатыла.

Язучы һәм әдәбият галиме М. Мәһдиев, яшерен имзалар белән язуның тагын бер сәбәбен күрсәтеп, болай ди: «Псевдонимнар алуның татар әдәбиятында үзенчәлеге дә бар. Мондый үзенчәлек бигрәк тә мөлкәтле катлаудан чыккан авторларда күзгә ташлана. Аларның мохите өчен язучылык дәрәҗәле эш түгел. Г. Камалның этисе, мәсәлән, улының язучы булып китүенә риза булмаган. Казанның зур сәүдәгәре Мөхәммәтшакир Габдрәхимовның улы[1] да, этисе теләгенә каршы килеп, кибет-сәүдә эшенә кул селти һәм язучылык эшенә керешә. Әнә шулай итеп, мөлкәтле катлаудан чыккан каләм әһелләре псевдоним куллануга барганнар». Шул ук вакытта XX гасыр башында тәхәллүсләрдән файдаланып язуның активлашуын аерым бер очракларда Европа, рус, төрек әдәбиятларының тәэсире, алардан күчкән «модага иярү» дип тә билгеләргә мөмкин.

Татар әдәбият белемендә яшерен имзалар белән язу күренеше тиешле дәрәҗәдә барланган, фәнни җәһәттән тулысынча өйрәнелгән дип әйтеп булмый әле. Бу темага язылган диссертацияләр, монографияләр дә юк диярлек. Шулай булуга карамастан, М. Бурнашева, М. Мөхәррәмов, Р. Нәфыйгов, И. Нуруллин, М. Мәһдиев, Ә. Кәримуллин, А. Әхмәдуллин, З. Рәмиев кебек әдәбият галимнәре һәм тарихчыларның фәнни мәкаләләрендә XX йөз башында иҗат иткән аерым бер әдипләрнең нинди псевдоним-тәхәллүсләр куллануы турында кайбер мәгълүматлар китерелә. Галимнәрнең бу язмалары арасында язучы һәм журналист Мәхмүт Бөдәйлинең (1895 – 1975) «Псевдонимнар сүзлеге» әлеге өлкәне максатчан өйрәнүгә багышланган булуы белән аерым игътибарга лаек.

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең бу чыгарылышында татар сүз сәнгатендә тәхәллүсләр мәсьәләсен яктырт-

[1] Биредә сүз XX гасыр башы татар әдәбиятының күренекле вәкиле, язучы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Гали Рәхим (1892–1943) турында бара.

кан язмалар, фәнни мәкаләләр һәм хезмәтләр җыеп бирелде. Китапның беренче бүлегендә М. Бөдәйлинең югарыда искә алынган сүзлеге белән танышырга мөмкин. Аның төп нөсхәсе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондларында саклана. Сүзлекне авторның яшерен имзаларны җыю, туплау, ачыклау өстендә озак елларга сузылган эш нәтиҗәсе дияргә мөмкин. Бу хакта аңлатма рәвешендә язылган өлештә ул үзе дә: «Псевдонимнарның авторларын ачыклау – шактый авыр хезмәт. Кайсы язучының нинди стильдә язуын, уйлау һәм җөмлә төзү алымнарын, үзенең чыгышы ягыннан кайсы төбәкнеке икәнлеген, ул җирлектә нинди сүз-тәгъбирләр кулланылуын һәм башка бик күп моментларны ачыклагач кына, дөрес нәтиҗәгә килергә мөмкин», – дип искәртеп уза. Бирелә меңгә якын әдип һәм журналист, сәнгать әһелләренең яшерен имзалары ачыклана. Алар арасында татарлардан тыш үзбәк, казакъ, башкорт мәдәниятләре вәкилләренең дә булуы хезмәтнең актуальлеген һәм кулланылыш чикләрен тагын да киңәйтә төшә.

Шул ук вакытта әлеге сүзлектәге мәгълүматларны чорлар узу белән үзгәрмәслек иң соңгы хакыйкать дип карау дөрес булмас иде. Аерым бер урыннарда Совет чоры идеологиясе тәэсире, авторның теге яки бу шәхескә, иҗатына мөнәсәбәтле субъектив фикерләре дә үзен нык сиздерә. Әйтик, Октябрь инкыйлабына кадәрге аерым бер әдипләрне «иске карашлы», «кадимче мулла» дип билгеләү, кайбер шәхесләргә бернинди дәлилсез «провокатор», «доносчы» дигән мөһер сугу очраклары да күренгәли. Басмага әзерләгәндә, сүзлекнең мондый урыннары берникадәр кыскартылып, күп нокта белән билгеләнеп куелды. Шәхесләрнең туган-үлгән елларында һәм урыннарында төгәлсезлекләр булган очракта, астөшермәләр белән дөресләп барылды, шулай ук текстка тел-стиль җәһәтеннән дә кайбер төзәтмәләр кертелде.

Җыентыкның икенче өлешендә татар әдәбиятында псевдонимнар кулланылышына караган төрле фәнни мәкаләләр тупланды. Тәхәллүсләрне өйрәнү юлларын күрсәткән, аның аерым бер

фән тармагы булып күтәрелергә тиешлеген беренче урынга куйган М. Бурнашева, «Псевдонимнар турында» дигән мәкаләсендә, «эш дөрес барсын, фактик материал, текстлар анык булсын өчен», яшерен имзаларны ачуның мөһимлеген билгели. «XX йөз башы татар әдәбиятында псевдонимнар» язмасында исә күренекле язучы М. Мәһдиев псевдономастиканың татар әдәбияты тарихында тиешенчә өйрәнелмәвен күрсәтә, тәхәллүсләр сүзлеген төзү әдәбият тарихын теоретик яктан өйрәнгәндә төп чыганак булып торачагын ассызыклый. Бу өлкәдә зур көч куйган әдәбиятчы-текстолог З. Рәмиев фикеренчә дә, әдәби мирасыбызны тулырак күзаллау өчен, псевдонимлы әсәрләргә игътибар итәргә, авторларын ачарга омтылырга кирәк. Галим бик күп тәхәллүсләрне «чишүгә» ирешә, мәсәлән, тәкъдим ителгән «Дамелла, Марксист, Ташмөхәммәд» мәкаләсендә татар әдәбияты классигы Фатих Әмирхан имзалары ачыклана.

Кушымтада М. Бөдәйли сүзлегендә урын алган тәхәллүсләрнең әлифбага нигезләнеп төзелгән күрсәткече урнаштырылды.

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең әлеге китабында укучылар игътибарына тәкъдим ителгән язмалар алга таба әдәбият тарихында авторлык мәсьәләләрен ачыкларга, андагы «ак таплар»ны бетерергә ярдәм итәр дип уйлыйбыз.

*филология фәннәре кандидаты Л. Гарипова,*
*филология фәннәре кандидаты И. Гомәров*

# I
# бүлек

Мәхмүт Бөдәйли

## ТӘХӘЛЛҮСЛӘР СҮЗЛЕГЕ

Псевдонимнар (мөстәгар исем, кушамат) куллану әдәбият, сәнгать өлкәсендә эшләүчеләр тарафыннан киң файдаланылган. Безнең татар әдәбияты дөньясында да псевдонимнар гаять күп. Аларның беришләре, танылган билгеле язучыларныкы булып, күпләргә мәгълүм. Икенчеләре, кайчандыр киң җәмәгатьчелеккә анык булып та, хәзерге көндә бик аз кешеләргә билгеле. Ә өченчеләре исә бөтенләй онытылган, аларның чын авторларын ачыклау мөмкин дә түгел диярлек.

Псевдонимнарны ачу, ягъни кушаматлар артына яшеренгән авторларның кем икәнлекләрен билгеләү – әдәбият фәне өчен ифрат кирәкле эш. Газета-журнал битләрендә, гомумән вакытлы матбугатта кайчандыр псевдонимнар белән генә басылып чыккан күп кенә әдәби әсәрләрнең, эшлекле тәнкыйть мәкаләләренең, эпиграммаларның авторлары күпчелек очракта әдәбиятка олы өлеш керткән зур әдипләр һәм язучылар булганга күрә, ул әдәби материалларның чыннан да фәлән язучыныкы икәнен билгеләү белгечләр өчен дә, киң катлау укучылар өчен дә кызыксыз булмас дип уйлыйм. Дөрес, биредә китерелә торган барлык псевдонимнар да танылган зур язучыларга гына карамыйлар. Азмы-күпме әдәби хәрәкәткә катнашкан, заманында татар мәдәниятенә тегеләйме-болаймы тәэсир иткән кайбер билгесезрәк кешеләрнең псевдонимнары да бирелә. Ахыргы чиктә, ул псевдонимнарны бүтәннәрнеке белән бутамау өчен генә булса да, аларны да белеп тору кирәк саналды.

Мин псевдонимнар җыю һәм ачу белән кече яшьтән үк шөгыльләнәм. Мәдәни һәм әдәби үсеш үзәгендә торган күп кенә язучылар һәм җәмәгать эшлеклеләре белән шәхси таныш булуым да бу эштә күп ярдәм итте. Заманында Ф. Әмирхан, Г. Камал, Ш. Камал, Г. Ибраһимов һәм башка олы язучылар, эшемне хуплап, булышлык күрсәтеп килделәр.

Псевдонимнарның авторларын ачыклау, – алда әйткәнемчә, шактый авыр хезмәт. Аның белән җитди шөгыльләнер өчен, бик күп казынырга һәм актарынырга кирәк. Кайсы язучының нинди стильдә язуын, уйлау һәм җөмлә төзү алымнарын, үзенең туган ягы кайсы төбәктән икәнлеген, ул җирлектә нинди сүз-тәгъбирләр кулланылуын һәм башка бик күп моментларны ачыклагач кына, дөрес

бер нәтиҗәгә килергә мөмкин. Бу эштә япа-ялгыз булу сәбәпле, мин, әлбәттә, мәсьәләне фәнни югарылыкта ук башкарып чыктым дип әйтә алмыйм. Мин бары тик үземә билгеле булган кешеләрнең псевдонимнарын гына теркәдем һәм алар турында, белгән кадәремчә, кыскача биографик мәгълүматлар китердем. Шуңа күрә татар әдәбиятында булган бөтен псевдонимнарны җыйдым дип дәгъва кылмыйм. Әгәр журнал укучылар үзләренә мәгълүм теге яки бу псевдонимның кемнеке икәнен ачуда булышсалар, авторлары турында белгәннәрен язып җибәрсәләр, мин аларга чиксез рәхмәтләр укыр идем.

Псевдонимнар сүзлеге алфавит тәртибендә төзелде. Башта шәхесләрнең чын исем-фамилияләре һәм алар турында кыскача мәгълүмат бирелде, соңыннан псевдонимнары санап чыгылды.

*Мәхмүт Һади Бөдәйли*

*Казан (Идел буе) федераль университеты*
*Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең*
*Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге, Ф. 2501*

## ТӘХӘЛЛҮСЛӘР СҮЗЛЕГЕ[1]

**1. АБЛЕЕВ Мөхәммәт Шәриф улы.**

***Тәхәллүсләре:*** М. Аблаев, Аблай М.

1902 елның 13 июлендә Лаешта туа[2]. 1918 елда комсомолга керә. Казанда Коммунистлар университетында[3] укый. 1922 елдан башлап яза һәм бастыра башлый. «Минем сугыштагы дустым»[4], «Кем баласы?», «Ике туй», «Шәмсекамәр», «Лейтенант» исемле хикәя әсәрләре авторы.

**2. АБРАМОВ Кыям Галимбик улы** (1898–1937)[5].

***Тәхәллүсләре:*** К. Абрамов, Кыям А.

Казанда Коммунистлар университетын бетергәч, райком секретаре була. Соңыннан Татарстан министрлар советы рәисе була. Вакытлы матбугатта язышa.

**3. АБЫЗГИЛЬДИН Җиһангир.**

***Тәхәллүсе:*** Җ. Абызгильдин.

Уфа мулласы. Иске карашлы. Октябрь революциясенә чаклы.

---

[1] Әлеге сүзлекнең керешендә автор тарафыннан аның язылу тарихы, максатбурычлары турында түбәндәгечә искәртелә: «Бу әсәр – бик күп еллар буена җыеп килгән материаллар нәтиҗәсе, күп эзләнү, күп хезмәт җимеше. Бу әсәргә XIX гасырдан башлап бүгенгә кадәр татар, башкорт, үзбәк, казакъ кебек тугандаш халыкларның әдәбият мәйданына чыккан 1150 дән артык кеше кертелде. Бу кешеләрнең күп өлеше псевдонимнар белән язганнар яки шундый кушаматлар белән аталып йөртелгәннәр.

Арада кушаматлары булмаганнары да керде. Алары турындагы мәгълүматлар «белешмә» булып хезмәт итүгә ярарлар дип уйлыйбыз. Һәрхәлдә, бу халыкларның әдәбият тарихы белән кызыксынучы әдәбият галимнәре, әдәбият тарихчылары өчен ул белешмәләрнең дә кирәге, әһәмияте булачак, әлбәттә.

Ачылмаган псевдонимнар булган кебек, монда кертелгән кайбер кешеләрнең биографиясе турында тулы мәгълүмат бирелмәгәннәре дә бар. Шулай булуга карамастан, мин аларны монда кертергә кыюлык иттем. Мин белмәсәм, бәлки тарих белән, әдәбият белән шөгыльләнүчеләр белерләр дә кимчелекне тулыландырырлар дип өмет иттем. 1973, май, Казан. Мәхмүт Бөдәйли».

[2] Татар энциклопедиясе: Мөхәммәт Әблиев 1900 елның 15 июлендә Тәтеш өязе (хәзерге Кама Тамагы районы) Даныш авылында туган.

[3] Коммунистлар университеты – Татар коммунистлар университеты.

[4] Төгәлрәк: «Минем дустым сугышта».

[5] Татар энциклопедиясе: 1897–1938 еллар.

**4. АГЗАМОВ Әюп.**

***Тәхәллүсе:*** Чыгтай.

Үзбәк язучысы. Журналист.

**5. АГИЕВ Әмрулла Нигъмәтулла улы** (1885–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Әмрулла А., Агиев Ә.

Пенза өлкәсендә Тенишево авылында туа. Мулла Фәхрелислам Агиевнең агасы. Аклар белән 1920 елда китеп, Харбин шәһәрендә «Ерак шәрык» журналы, Милли идарә исеменнән «Ерак шәрык» газетасын һәм ислам динен кабул итү көненә багышлап, бер көнлек «Мең ел» исемле газета чыгаручыларның берсе. Иске карашлы мулла була. Читтә үлә.

**6. АГИЕВ Фәхрелислам Нигъмәтулла улы** (1887–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Ф. Агиев, Фәхри, Ф. А.[1]

Пенза өлкәсе Краснослободск өязе Усть-Рохманская волосте Тенишево авылында туа. Элек авылда укый. 1906 елда Казан шәһәренә килеп, Г. Тукай, Ф. Әмирханнар белән танышып, алар өндәве буенча русча учительлеккә имтихан тота. Вакытлы матбугатта языша. 1913 елда Казанда балалар өчен «Ак юл» исемле журнал чыгара башлый. 1921 еллардан «Зур сугыш», «Куяннар», «Сукыр Ильяс», «Кыйраәте ибтидаийә», «Әлифба», «Кызганыч үлем», «Балалык вакыты», «Кызыл йолдыз», «Кәкре аяклы тавык» дигән әсәрләре, «Хикәяләр җыентыгы» китабы бар. 1934 һәм 1937 елларда кулга алына.

**7. АГИШЕВ Сәгыйть Ишмөхәммәт улы.**

***Тәхәллүсләре:*** С. Агиш, Сакалтай.

1905 елның 19 гыйнварында Оренбург өлкәсе Шарлык районы Исәнгилде авылында мулла гаиләсендә туа. Оренбург шәһәрендә «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. 1921 елда югары уку мәктәпләрендә укый. Төрле газета, журналларда редактор була. Талантлы журналист, юморист, танылган әдип. Башкорт, татар, рус телләрендә 50 гә якын әсәре бар.

[1] Казан (Идел буе) федераль университеты Н.И. Лобачевский исем. Фәнни китапханәнең Сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлегендә сакланган кульъязмадан өстәлгән тәхәллүсләр * белән билгеләнеп барачак.

**8. АГИШЕВ Якуб Хәлил улы** (1899–1972).

***Тәхәллүсләре:*** Я. Агиш, Я. А., Каләм, Тутыя Якубы.

Пенза өлкәсендә Кузнецк районы Пәлдәнге авылында крестьян гаиләсендә туа. Мәдрәсәдә татарча укый. Хосусый рәвештә бер поптан русча өйрәнә. 1930 елда Казанга килеп, педагогия институтының тел, әдәбият факультетын тәмамлый. 1941–1951 елларда шул институтның кафедра җитәкчесе була. Күренекле әдәбиятчы һәм укытучы, Г. Тукайчы[1].

**9. АДАКОВ Габдрахман** (1894–1918).

***Тәхәллүсе:*** Г. Адак.

Әстерханда сәүдәгәр гаиләсендә туа. Шундагы мәктәптә белем алып, артист була.

**10. АЙДАРОВ Кәраматулла Хәррас улы[2].**

***Тәхәллүсе:*** Айдаров Кәрамәт.

Пермь шәһәре мулласы. Вакытлы матбугатта язышып каләм тибрәткән яшь фикерле кеше. Аның турында шагыйрь Шәехзадә Бабич болай дип яза:

> Күпне сайлап, юкны каулыйсың, Кәрамәт Айдаров,
> Әй, печән чабам диеп, комлыкта Чалгы Кайраров.

**11[3]. –**

**12. АЙДАРОВ Ситдыйк Хәнәфи улы** (1895–1938).

***Тәхәллүсе:*** С. Айдар.

Вакытында танылган татар җырчысы. Артист. Сара Садыйкованың тормыш иптәше[4]. Талантлы драма артисты, җырчы һәм гармунчы. Ул Казанда һөнәрче гаиләсендә туа. 1912 елда «Сәйяр» труппасына алына. 1933 елда Мәскәү консерваториясе янындагы Опера студиясенә җибәрелә. 1938 елда укуын тәмамлап, Казанга кайта. Тамашачылар аны бик яратып каршы алалар. Шул елны ул каты

[1] 1946 елда Габдулла Тукай иҗаты буенча Мәскәүдә кандидатлык диссертациясе яклый, аннан соң да Г. Тукай иҗаты белән бәйле хезмәтләре басыла.

[2] Татар энциклопедиясе: Әхмәди улы.

[3] 11 нче номерда текст юк. Чыганакның тәртип санын саклау максатыннан алга таба да тексты булмаган номерлар үзгәрешсез бирелде

[4] Дөресе: тормыш иптәшләре Әшрәф Синәева (драма актрисасы) һәм Галия Кайбицкая (җырчы).

авырып үлә. Казанда Ленин районында[1] аның исеменә бер матур урам бар.

**13. АЙДАРОВ Харрас (ишан).**

Оренбург Каргалысы дигән бистәдә мулла. Вакытлы матбугатта язгалый иде. «Рөэя (төш күрү)» исемле әсәре бар. Ул ишаннардан көлә. Ш. Бабич:

Юп-юаш Харрас ишан Айдар түгел, Алдар ишан,
Төлкедәй алдар ишанга эт кебек һаулар ишан, –

дип яза.

**14. АЙДАРОВ Әсгать Харрас улы[2]** (1906–1959).

***Тәхәллүсләре:*** Әсгать Айдар, Ә. Айдар, Алтайлы, Ә. А.*.

Оренбург өлкәсе Иске Сорочино авылында туа. Стәрлетамакта урта һәм партия мәктәбен 1923 елда тәмамлагач, 1927 елда Казанга килеп, радио комитетында эшли. 1941 елда фронтка китә. Аннан кайткач, радио комитетында эшли. Ул әдәбиятка шигырьләре белән килеп керә. «Ташбай», «Наводчик Фәхретдин», «Солдат хикәяләре», «Ватан өчен», «Көтәм сине» кебек шигырь, повесть һәм драма әсәрләре авторы.

**15. АЙМАНОВ Якуб.**

***Тәхәллүсләре:*** Якуб Айманов, Я. Айман Капаллы, Якуб Алтайлы, Айман Алтайлы*, Я. А.*.

Уфада Галия мәдрәсәсендә укыган казакъ шагыйре. «Шура» журналында күп яза. 1913 елда «Табигать», 1915 елда «Саман» исемле поэмалары дөнья күрә. Ш. Бабич аның турында болай яза:

Айманов Якуб, синең зиһенеңдә илһам көрсисе,
Көрсине ватсаң, пешәр аркаң, зобани гөрзисе.

**16. АЙНУЛОВ Сөнгать Ибраһим улы** (1880–1953).

***Тәхәллүсе:*** С. Айнулов.

Буа өязе Иске Чокалы авылында туа. Баку шәһәрендә «Икъбаль» (Благоденствие) журналының редакторы.

**17. АИТОВ Гани Шаһиәхмәт улы** (1898–1944).

***Тәхәллүсләре:*** Гай, Аит бай, Гает-бану.

---

[1] 1934–1994 елларда гамәлдә булган район.

[2] Татар энциклопедиясе: Харис улы.

Апас районы Кызылтау авылында[1] туа. 1942 елда сугышка китеп, 1944 елда Николаев шәһәре янында[2] үлеп кала. Ул Апас районы газетасында секретарь була. «Чаян», «Сәнәк» журналларында күп яза.

**18. АЙТУГАНОВ Гайнулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Айтуганов, А. Гайнулла.

Тәтештә укытучы була. Исхак Казаков белән җәнҗаллашып та йөри. Соңгы елларда Казанда инструктор булып эшли. Партия әгъзасы. 1937 елны кулга алына. Вакытлы матбугатта язгалый.

**19. АЛУШАЕВА Фәрхәнә** (1886–1958).

***Тәхәллүсләре:*** Ф. Алушаева, А. Фәрхәнә.

Себердә хезмәткәр гаиләсендә туа. Фатих Әмирханның дусты. Ризван Алушаевның тормыш иптәше. Бик күп еллар Ачинск шәһәрендә, совет чорында Башкортстанда укытучы була. «Фикер» газетасында үткен мәкаләләр язып, хатын-кызларны хөрлек-ирек өчен көрәшкә өнди. Уфада үлә.

**20. АКБИРДИН Лотфи** (1895–1958).

***Тәхәллүсләре:*** А. Лотфи, Акбирдин Л.

Революциядән соң Ташкентка китеп, Татар мәгариф институтында укыта. Матбугатта язышa.

**21. АКМУЛЛА – Камалетдинов Мифтахетдин Мөхәммәдьяр улы** (1831–1895).

***Тәхәллүсе:*** Акмулла.

Башкортстанның Бәләбәй өязе Җилем волосте[3] Туксанбай авылында туа. Яшьтән ятим кала. Стәрлебашта Шәмсетдин Зәки дигән шагыйрьдән дәрес ала. Атасы – казакъ, анасы – татар. Троицк шәһәрендә шактый вакыт төрмәдә утырып чыга. Туры сүзле булганга, «Акмулла» дип йөртәләр. Троицк шәһәрендә аның исемендә «Акмулла» дигән көлке журналы чыгарыла. Шиһап Мәрҗани иҗатына гашыйк булып, Мәрҗани турында бик тәэсирле шигырьләре бар.

1895 елда Гафиятулла Баймуратов һәм Дәүләтша исемле башкортлар тарафыннан үтерелә.

---

[1] Коллар авылы исеме белән дә билгеле.

[2] Төгәлрәге: Херсон өлкәсе Высокопольский районы Наталино авылын азат иткәндә вафат була.

[3] Төгәлрәге: Кульиль-Минск волосте.

**22. АКЧУРИН Галимҗан Кәлимулла улы** (1895–1933).

***Тәхәллүсләре:*** Г. Акчурин, Галимҗан Акчурин, Г. А.*.

Пенза өлкәсе Краснослободск өязе Усть-Рохмановка авылында туа. Кышкар авылында укый. Соңра Казанга килеп, 1910 елда «Касыймия» мәдрәсәсендә укый. 1912 елда шәкертләрне оештырып, забастовка ясый һәм укыту ысулыннан разый булмыйча чыгып китә. Шул чорда Г. Тукайлар, Ямашевлар белән очрашып, сәяси юнәлеш ала. 1914 елда Төркестанга китеп, мамык чистарту заводына эшкә керә. Шул чорда «Шура», «Сөембикә» журналларына шигырьләр яза. 1917 елда Коммунистлар партиясе сафына кереп, Ташкент, Бохара, Хива, Дүшәнбе шәһәрләрендә һәм шул республикаларның җаваплы эшчеләре булып, Урта Азиядә Совет властен төзү, ныгыту, партия сафларын көчәйтү һәм күбәйтү эшләрендә күп эшли. 1926 елда Казанга килеп, Татарстан наркомфин[1] урынбасары. 1930 елда чирләп Ташкентка китеп, анда партия тарихы буенча фәнни тикшеренү институтының гыйльми хезмәткәре булып тора. 1933 елда Мәскәүдә туберкулездан үлә. Хәзер Бохарада аның исеменә урам һәм колхозлар бар.

**23. АКЧУРИН Галимҗан** (1892–1937).

***Тәхәллүсе:*** Г. Акчура.

Петропавел шәһәрендә бай Акчурин малае. Революциягә чаклы студент. Революциядән соң Уфада Милләт мәҗлесенең секретаре була. Вакытлы матбугатка язышкалый. Татарчадан русчага тәрҗемә ясый. «Восточный сборник» дигән әсәрендә байтак татарча әсәрләрне русчага тәрҗемә итеп, русларны таныштыра.

**24. АКЧУРИН Йосыф Хәсән улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Ай, Й. Акчура, Й. Акчурин.

Акчурин Йосыф Хәсән улы 1905 елда «Казан мөхбире» газетасында редактор була. 1906 елдан башлап «Вакыт» газетасында, «Шура» журналында языша. Соңра Төркиягә китеп, хәрби академия бетереп, төрек офицеры, парламент әгъзасы булып тора. «Мөселманнар берләшмәсе»нең җитәкчесе. Кадет партиясе әгъзасы.

[1] Наркомфин – ТАССР финанс халык комиссары (народный комиссар финансов).

**25. АКЧУРИНА Мәхубҗамал** (1896–1948).

***Тәхәллүсләре:*** М. Акчурина, Мәхубҗамал[1] Акчурина, А. М-җ*.

Кузнецк өязе Димау авылында туа. 1909–1910 елларда әдәбиятка килә. 1914 елда «Мишәрләр тормышыннан бер ләүхә[2]», «Шәфкатьсез ата» исемле хикәяләре басыла.

Хосусый рәвештә русча укып, рус әдәбияты белән таныш мәгърифәтче бер журналист була. Хатын-кызлар мәсьәләсендә аларга хөрлек-ирек таләп итә, балалар тәрбиясенә бик зур әһәмият бирә иде. «Шура», «Сөембикә» журналларында актив язышa.

**26. АКЪЕГЕТ – Муса Мөхәммәтҗан улы Алтынбай-Акъегет** (1864–1923).

***Тәхәллүсләре:*** Акъегетзадә, Муса Акъегетзадә, Муса Алтынбай, Акъегет Муса*, Алтынбай*.

Пенза өлкәсендә Чамбар (хәзер Белинский) шәһәрендә урта дәрәҗәле чиновник гаиләсендә туа. Пензада гимназия бетергәч, Кырымда «Тәрҗеман» газетасында эшли. Соңра Төркиягә китеп, Истанбулда Мөлкия мәктәбен[3] тәмамлап, шунда рус теле укытучысы булып кала. 1908 елда хөррият булгач, «Мәтин» дигән газета чыгара. «Мәтин» туктагач, Анатулыда бер өяздә исправник була.

**27. АЛИЕВ Кәрим.**

***Тәхәллүсе:*** Шәүкый.

Ташкентта үзбәк шагыйре.

**28. АЛИЕВ Камил.**

***Тәхәллүсләре:*** Какра, Ташкент Шамали, Ташкентлы.

Ташкентта үзбәк шагыйре һәм язучысы.

**29. АЛИЕВ Җиһанша.**

***Тәхәллүсе:*** Афиил.

Татар шагыйре.

---

[1] Мәхбүбҗамал.

[2] Ләүхә – күренеш.

[3] Мөлкия мәктәбендә дәүләт учреждениеләрендә эшләүче хезмәткәрләр әзерләгәннәр.

**30. АЛИМОВ Мирсәгать.**

***Тәхәллүсе:*** Җигәй.

Үзбәк шагыйре.

**31. АЛИМҖАН Хәмит.**

***Тәхәллүсе:*** Очкын.

Үзбәк язучысы.

**32. АЛИШЕВ Габдулла Бари улы** (1908–1944).

***Тәхәллүсләре:*** Абдулла Алиш, А. Алиш.

Татарстанның Куйбышев районы Көек авылында туа. 1927–1930 елларда Казанда җир төз[елеше]ү техникумын тәмамлап, мелиоратор булып эшли. Соңра журналларда секретарь була. Казан педагогия институтында укый. 1941 елда Ватан сугышына китә. Брянск янындагы каты сугышта пленга төшә. Фашистлар аны концлагерьга озаталар. Шунда ул дусты Муса Җәлил белән очраша. 1944 елда аларны җәзалап үтерәләр.

**33. АЛКИН Ильяс Сәетгәрәй улы.**

***Тәхәллүсе:*** Алкин И.

Казанда[1] алпавыт гаиләсендә туган. Югары мәктәп бетергән офицер. Казанда «Болак арты республикасы» дип аталган буржуаз оешманың җитәкчесе. Кәрим Әмири аның турында болай диде:

> Алкин Ильяс – тол офицер һәм Болакның тол ханы,
> Шәп кеше иде. Инде хәзер иске башмак олтаны.

**34. АЛКИН Сәетгәрәй Шаһиәхмәт улы.**

***Тәхәллүсе:*** Алкин С.

Алпавыт, адвокат, Дәүләт думасы әгъзасы, кадет, Милли буржуаз хәрәкәт җитәкчесе. 1906 елда «Казан мөхбире» газетасының редакторы.

**35. АЛЛАБИРДИЕВ Габдрахман Хаҗимөхәммәт улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Габдрахман Минский, Г. Минский, Г. М, Гамь, М. Тимербулат, Әптери.

1906 елның 29 сентябрендә Әстерханда туа. Мәктәптә башлангыч белем алгач, 1926–1928 елларда Казанга килеп, театр техникумында

---

[1] Төгәлрәге: Казан губернасы Мамадыш өязе Кече Кирмән волосте Алкин авылында туган.

укый. 1936–1938 елларда Мәскәүдә Бөтенсоюз дәүләт кинематография институтында белем ала. Бакуда киностудиядә, Казанга килгәч, «Чаян» редакциясендә эшли. 1928 елда әдәбиятка килә. Хәзер татар әдәбият дөньясында танылган әдип, юмористик хикәяләр остасы. Хикәя җыентыклары, балалар һәм зурлар өчен язган пьесалар авторы.

**36. АЛЛАЯРОВ Сафа.**

***Тәхәллүсе:*** Мөганни.

Ташкентлы. Үзбәк язучысы.

**37. АЛМАЕВ Габдерәүф.**

***Тәхәллүсе:*** Г. Алмай.

1918 елларда Казанда наркомпроста эшләде. Укытучы. «Париж коммунасы» исемле 2 пәрдәлек пьеса авторы. К. Әмири аның турында болай язды:

Алмаев Габдерәүф тә йөрде борчак сипкәләп,
Нарком итеп куймаганга, чыкты сафтан үпкәләп.

**38. АЛМАЕВ Әхмәтҗан.**

***Тәхәллүсләре:*** Алмай Ә., Әхмәтҗан, Ә. Алай.

Гражданнар сугышы елларында «Кызыл армия» газетасында редактор. 1917 елда Псковта «Сугыш сафы» газетасында эшли. 1929–1930 елларда Мәскәүдә ГПУда Шәрык бүлеге мөдире иде. 1938 елда кулга алына.

**39. АЛПАРОВ Гыйбадулла Хәбибулла улы** (1888–1936).

***Тәхәллүсләре:*** Авыргазый, Г. Алпар, Габдебари, Алпир, Г. А*, А. Авыргазый*.

Уфа губернасы Эстәрлетамак өязе Курманай авылында туа. Күренекле тел галиме, профессор, филология фәннәре докторы, талантлы язучы һәм педагог. Бик күп әдәби, фәнни әсәрләр авторы.

**40. АЛИКОВ Габдрахман.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Аликов, Алик.

1911 елның 20 маенда Әстерханда туа. 1937 елда Казанда театр техникумын тәмамлый. 1943–1946 елларда сугыш мәйданында була. Вакытлы матбугатта язгалый.

**41. АМАНТАЙ – Габдулла Сахипгәрәй улы Амантаев.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Амантай, Г. А.

1907 елның 23 февралендә Оренбург өлкәсе Югары Кунакбай авылында укытучы гаиләсендә туа. 1920 елда комсомолга, 1926 елда партия сафына керә. Татарча һәм русча башлангыч белемне атасыннан ала. 1926–1928 елларда «Яшь юксыл», «Башкортстан яшьләре» газеталарының редакторы. 1928–1931 елларда Ленинградта Шәрык телләре институтында укый. Уфага кайткач, М. Гафури исемендәге Тел, әдәбият институтының директоры булып тора. Татар, башкорт телләрендә язган хикәя, шигырь, балалар өчен һәм фольклордан 10 нан артык әсәр калдыра. 1939 елда шәхес культы корбаны була.

**42. АПАКОВ Шәймәрдән.**

***Тәхәллүсләре:*** Апак, Аппак.

Иж-Бубый авылы мулласы. [...]

**43. АППАКОВА Дәрҗия Сәйфулла кызы** (1898–1948).

***Тәхәллүсләре:*** Д. Аппакова, Дәрҗия А., Дәрҗия Аппакова.

Татарстанның Ширәмәт районы[1] Байгол авылында туа. 1914–1917 елларда Казанда керәшеннәр өчен ачылган Учительская школаны[2] бетереп укытучы була. 1917–1925 елларда «Кызыл әләм» газетасының хәбәрчесе. Шул ук елларда совпартшколада һәм театр техникумында укый. 1928–1943 елларда Урта Азиядә хатын-кыз азатлыгы өчен күп көч сарыф итә.

Балалар дөньясын бик яхшы белә һәм алар тормышын сурәтләүдә бик оста каләм иясе санала. Шактый әсәрләр иҗат итә.

**44. АРАПОВА Нәфига Галим кызы** (1902–1943).

***Тәхәллүсе:*** Н. Арапова.

Казанда туа. «Сәйяр»дә уйный башлый. Татарстанның атказанган артисткасы исемен яулый. Шагыйрь К. Әмири аның турында:

> Арапова – түп-түгәрәк, бәп-бәләкәй, кап-кара.
> Ул дулап китсә, кызып китсә, бөтен эш таптала, – ди.

---

[1] Хәзерге Түбән Кама районы.

[2] Татар укытучылар мәктәбе.

**45. АРАБЛИНСКИЙ Хәсән[1] Хәләф улы** (1881–1919).

***Тәхәллүсе:*** Х. Араблинский.

Бакуда туа. Азәрбайҗан театрында күп хезмәт күрсәтә. Татар театрында режиссер була. 1919 елда Бакуда мөсаватчеләр[2] тарафыннан атып үтерелә.

**46. АРСЛАНОВ Нуретдин Миргазиз улы.**

***Тәхәллүсләре*** **:** Нури Арслан, Н. Арслан.

1912 елның 19 сентябрендә Петропавел шәһәрендә эшче гаиләсендә туа. 1928 елда «җидееллыкны» бетергәч, Казанда художниклар техникумында укый. 1931–1934 елларда рәссамлык укытучысы булып эшли. 1939–1946 елларда армия сафында фашистларга каршы сугышта була. 1948 елда марксизм-ленинизм университетын тәмамлый. Татарстанның танылган шагыйре. Шактый шигъри әсәрләре бар.

**47. АРСЛАНОВ Тимер Гәрәй улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Тимер Арслан, Т. Арслан.

Башкортстанның Туймазы районы Кәкребаш авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1953 елдан партия әгъзасы. Ватан сугышында катнаша. Башкорт, рус телләрендә 10 лап әсәре бар. Башкорт шагыйре.

**48. АСАНБАЕВ Нәҗип** (Николай Васильевич Асанбаев).

***Тәхәллүсләре:*** Н. Асанбай, Нәҗип Асанбаев.

1921 елда Башкортстанның Бакалы районы Акманово авылында крестьян гаиләсендә туа. 1944 елда партия сафына керә. Язган китаплары 10 нан артык. 1937 елда финанс техникумын бетергәч, башкорт growинститутында укый. Ватан сугышында катнаша. Уфада танылган прозаик.

**49. АСЯНОВ Фәнил Габделһади улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Фәнил Асянов, Ф. Асянов.

1929 елның 30 декабрендә Башкортстанның Бозаяз авылында (Кырмыскалы районы) колхозчы гаиләсендә туа. 1953 елда партия

[1] Дөресрәге: Хөсәен.

[2] Мөсаватчеләр – бердәмлек тарафдарлары.

сафына керә. 1955–1959 елларда югары партия мәктәбен бетереп, редакция хезмәткәре була. 5–6 хикәяләр җыентыгы авторы.

**50. АТАЕВ Хәсәнморат Мөхәммәтәмин улы.**
***Тәхәллүсләре:*** Лаппаси, Х. Атаев.
Үзбәк язучысы.

**51. АТАҖАНОВА Анна Бибикарый.**
***Тәхәллүсе:*** Гаҗизә.
Үзбәк язучысы. Хатын-кыз һәм балалар язучысы.

**52. АТАКУЗИЕВ Рәхмәтулла.**
***Тәхәллүсе:*** Уйгун.
Ташкентта үзбәк шагыйре.

**53. АТЛАСИ Мөхәммәтһади.**
***Тәхәллүсләре:*** Һ. Атласи, М-Һ Атласи, Һади Атласи.
Дәүләт думасы әгъзасы. Дума газетасы нашире. Бөгелмә техникумында укыта. «Казан ханлыгы», «Сибирия тарихы», «Сөембикә» исемле тарихи әсәрләр авторы. 1929 елда һәм 1937 елларда кулга алына. Буржуаз милләтче.

**54. АТЛАШИ – Хөсәен Абушаев[1].**
***Тәхәллүсләре:*** Хөсәен Атлаши, Х. Атлаши, Х. Абушаев.
Хвалынь өязе[ндә туган]. Шагыйрь һәм җырчы, «Шура», «Аң» журналларында шигырьләр яза. Җырчы буларак пластинкалары да бар.

**55. АТНАБАЕВ Әнгам Касыйм улы.**
***Тәхәллүсләре:*** Ә. Атнабаев, Атнабай.
1928 елның 23 февралендә Башкортстанның Тәтеш районы Иске Күрдем авылында крестьян гаиләсендә туа. Танылган татар һәм башкорт шагыйре. Башкортча, татарча, русча язган шигырь җыентыклары бар.

**56. АТНАГУЛОВ Сәлахетдин Садретдин улы** (1893–1937).
***Тәхәллүсләре:*** С. Атнагул, Сәлах Атнагулов, Азамат, Сәләй, Кара малай, Азамат С.А.
Башкорт Республикасы Бәләбәй районы Суккул авылында туа. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укый. Күренекле әдип, шактый

[1] Татар энциклопедиясе: Хөсәен Абушаев-Атлаши.

газеталарда редактор. Казанда пединститутта доцент. Байтак әдәби, фәнни әсәрләр авторы.

**57. АФЗАЛОВ Гамил[1] Гыймадетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Афзал, Гамил Афзал.

1921 елның 23 маенда[2] Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылында туа (крестьян). 1931–1934 елларда Магнитогорскида яши. Шунда җидееллык мәктәп тәмамлый. 1940–1953 елларда производствода эшли. Башкортстанда Калтас авылында яши. Шигырь җыентыклары бар. Шагыйрь-юморист. «Чаян», «Казан утлары» журналларында яза.

**58. АХУНОВ Гариф Ахун улы (Ахунҗанов).**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Галимов, Г. Ахунов.

1926 елның 18 сентябрендә Арча районы Өчиле авылында туа. 1947 елда Арча педучилищесын бетергәч, 1952 елда Казан университетының тел, әдәбият бүлеген тәмамлый. Татар әдәбият дөньясында танылган прозаик. Талантлы журналист һәм әдип. «Казан утлары» журналында редактор.

**59. –**

**60. АХУНОВ Фатих Галимирза.**

***Тәхәллүсләре:*** Ахунов Ф.

Тифлис шәһәрендә журнал чыгарып, телебезгә хезмәт иткән галим.

**61. АХУНБАБАЕВ Юлдашбай** (1885–1943).

***Тәхәллүсләре:*** Ю. Ахунбабаев, Юлдаш А.

Төркестанда партия җәмәгать эшлеклесе. Төркестан Үзәк башкарма комитеты рәисе. Вакытлы матбугатта актив катнаша.

**62. АЮХАНОВ Закир.**

***Тәхәллүсе:*** З. Аюхан.

«Шура» журналында бик актив язышкан галим. 1911 елда Томск шәһәрендә «Тум сүзе» газетасының редакторы, нашире Нурулла Карпов була.

---

[1] Чыганакта: Галим дип бирелгән.

[2] Чыганакта: гыйнварында диелгән.

**63. АЯГУЗИ Сабирҗан хаҗи Гарәпша улы.**

***Тәхәллүсләре:*** С. Аягузи, Сәйях Аягузи, С. Хаҗи Аягуз.

Вакытлы матбугатта языша. 1919 елда Казанда мөгаллимәләр курсы ача.

**64. БАБАҖАНБИКОВ Мәдйосыф.**

***Тәхәллүсе:*** Баян.

Ташкентлы. Үзбәк язучысы.

**65. БАБИЧ Шәехзадә Мөхәммәдзакир улы** (1895–1919).

***Тәхәллүсләре:*** Шөпшә, Бәбәйчүп, Чытырман, Таулы башкорт, Каракүз, Башкорт.

1895 елның 2 гыйнварында Башкортстанның Бөре районы Әсән авылында мулла гаиләсендә туа. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укый. Троицк шәһәрендә укытучы, Оренбургта «Кармак» журналында секретарь була. Башкортстанның халык шагыйре. Көчле юморист, сатирик.

**66. БАГБОСТАН ханым Вилдан кызы Мөэминова** (1884–1963).

***Тәхәллүсләре:*** Багбостан, Б. Мөэминова.

Татарстанның Сарман районы Мәндәй авылында туа. 1908 елда Оренбург шәһәрендә яңача ысул белән укытучылар әзерләүче кызлар мәктәбе ачып, 1918 елга чаклы дәвам иттерә. Заманында ачык фикерле, тырыш мәгърифәтче, «Шура», «Сөембикә» журналларында, «Вакыт» вә башка газеталарда тәгълим-тәрбия турында мәкаләләр яза.

**67. БОГДАНОВ[1] Гариф Вагыйз улы** (1890–1955).

***Тәхәллүсләре:*** Г. Богданов, Богдан Г.

Казанда танылган педагогларның берсе, дәреслек китаплары һәм тәрбия турында хикәя китаплары язган автор.

**68. БОГДАНОВ[2] Идрис.**

***Тәхәллүсләре:*** И. Богданов, Богдан.

Революциягә чаклы Троицк шәһәрендә Яушев дигән байларның управляющие булып эшләде. Мәгърифәтле, русча яхшы белүче, рус әдәбияты белән яхшы таныш кеше. 1913 елларда Толстойның

[1] Багданов варианты да бар.

[2] Багданов варианты да бар.

«Крейцерова соната»сын татарчага тәрҗемә итә. «Югалган хатын», «Зөләйха белән Фатыйма», «Таш кунак», «Помада мәсьәләсе» әсәрләренең авторы.

**69. БАЕМБӘТОВ Гыйлемдар Солтан улы** (1886–1932[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Г. Баембәт, Г. Б., Чакмагыш.

Башкортстанның Бәләбәй өязе Чакмагыш авылында туа. Башкорт учительский школасында укый. 1918 елда Уфада «Көрәш» редакторы. Оста тәрҗемәче.

«Патша төшерәләр», «Асылган» исемле пьесалар авторы. Троцкийчылыкта гаепләнә.

**70. БАЕМБИТ – Зөһрә Әхмәт кызы Мөслимова.**

***Тәхәллүсе:*** Баембит Зөһрә.

1899 елда Уфада туа. 1918 елдан КПСС әгъзасы. Революция ветераны. Атасы – татар, анасы – башкорт. Вакытлы матбугатта языша.

**71. БАДАМШИН Борһан Гыйззәтулла улы** (1897–1970).

***Тәхәллүсләре:*** Б. Бадамшин, Б. Б., Бадамша.

Саратов өлкәсе Балаково районы Яңа Рязань авылында крестьян гаиләсендә туа. Авыл мәктәбен бетергәч, Әстерхандагы әбибабаларына килеп, Ибраһим Абилов һәм Наримановлар ярдәме белән училищены тәмамлый. 1917 елда Мәскәүдә экономик факультетның юридик бүлеген бетерә. 1929 елда кулга алына. Аннан котылгач, 1933 елда балык хуҗалыгы институтына кече хезмәткәр булып эшкә керә. Ихтиолог буларак, Каспий диңгезендәге эт балыгы, тюленьнәр «хуҗасы» булып әверелә. Гыйльми, фәнни хезмәтләре бар. Вакытлы матбугатта языша. Казакъстан фәннәр академиясенең член-корреспонденты. 1970 елда Әстерханда үлә.

**72. БАЙБИКОВ Хәсән** (1902–1943).

***Тәхәллүсе:*** Х. Байбиков.

Әстерханда туа. 1921 елда Самара театр техникумын бетереп, артист була, Ватан сугышында үлә.

---

[1] Татар энциклопедиясе: үлгән елы – 1933 ел.

**73. БАЙБУРИН Габдулла Гыйндулла улы.**

***Тәхәллүсе:*** Г. Байбурин.

1925 елның 1 мартында Башкортстанда Чишмә районы Сәфәр авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Авылда 1942 елда мәктәпне бетерә. 1943–1948 елларда Совет армиясендә хезмәт итә. 1948–1952 елларда Уфада techinstitутта укый. 1954 елда редакциягә чакырыла. 1958–1959 елларда нәшриятта редактор. 1967–1969 елларда Мәскәүдә югары әдәбият курсларында укый. 10 га якын шигырь, поэма, хикәя, пьеса җыентыклары авторы.

**74. БАЙГИЛДИЕВ Шәриф Камалетдин улы** (1884–1942).

***Тәхәллүсләре:*** Ш. К., Шәриф Камал, Ш. Камал.

1884 елның 28 февралендә Мордва республикасы Рузаев районы Пешлә авылында мулла гаиләсендә туа. Аңар Чехов, Горькийларның тәэсире зур була. Ул – татар әдәбиятының классигы. Ленин ордены белән бүләкләнгән, рәссамлык остасы булып санала.

**75. БАЙГИЛЬДИН Гыймад Камалетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гыймад Байгилде, Фагыйл.

Армавир мулласы, Шәриф Камалның абыйсы. [...]

**76. БАЙДИЛДЕ Габдрахман.**

***Тәхәллүсе:*** Г. Байдилде.

Казакъ язучысы, казакъ җәмәгать эшлеклесе. Революциянең башлангыч елларында Колчакта, Бүкәйхановта адъютант була. Соңрак партиягә кереп, чиктә яшерен хезмәткәр булып эшләгән. 1929 елда Мәскәү Бутыркасында аталар. Хәзер акланган.

**77. БАЙКИН Зөлкарнәй** (1888–1936).

***Тәхәллүсләре:*** Б. Зөлкарнәй, З. Байкин, Грачев.

Пенза өлкәсе Качкаров[1] авылында туа. Әстерханда мәдрәсәдә белем ала. Башта укытучы була. Агасы Җ. Байкин[2] кебек яшьтән театрга тартыла. Пенза ягында Байкиннар гаиләсенә «карга» кушаматы бирелгән була. Сәхнәдә Байкиннардан артистлар күбәя башлагач, ул сәхнәдә үзен Грачев (Карга) дип йөртә. 1921 елда Әстерхан театрында, аннан соң хатыны Г. Байкина белән Ташкент, Сәмәрканд

[1] Пенза өлкәсендәге Кошкарово авылы булса кирәк.

[2] Җәләл Байкин хакында сүз бара.

якларына китә. Шунда эшли. 1931 елда Әстерханга кире кайтып, театрда эшли. 1936 елда Әстерханда үлә.

**78. БАЙКИНА Сара (Әхмәтшина)** (1895–1972).

***Тәхәллүсе:*** С. Байкина.

1895 елның 14 декабрендә Әстерханда тегүче гаиләсендә туа. Ире Байкин ярдәмендә 1912 елда профессиональ артистка булып китә. Шагыйрь Кәрим Әмири аны болай шаярта:

Байкина нечкә тавыштан җырласа, тешкә тия,
Черки тавышын яңгыратып сәхнәдә, «чең-чең» килә.

**79. БАЙКИН Җәмил**[1] (1886–1954).

***Тәхәллүсләре:*** Җ. Байкин, Б. Җәмил.

Пенза өлкәсе Качкаров авылында крестьян гаиләсендә туа. Алар 1897 елда Әстерханга күчеп киләләр. Җәләл[2] башлап Казанда «Касыймия» мәдрәсәсендә, аннан соң ике ел Истанбулда укып кайта. Әстерханда татар театрын башлап оештыручыларның берсе. 1954 елда Әндиҗан шәһәрендә вафат була (хатыны – Сара).

**80. БАЙКИН Габдрахман** (1905–1944).

***Тәхәллүсе:*** Г. Байкин.

Әстерханда туа. Ул скрипкачы һәм композитор буларак мәгълүм. Сугышта һәлак була.

**81. БАЙКИНА Фатыйма Мөхәммәдҗан кызы** (Асаева, 1897–1925).

***Тәхәллүсләре:*** Ф. Асаева, Ф. Байкина.

Әстерханда туа. 1914 елда абыйсы Җәләл[3] Байкин кул астында сәхнәгә чыга. Ул Әстерхан театрында эшли. 1925 елның феврalendә Әстерханда вафат була.

**82. БАЙКИНА Гөлчәһрә Заһидова.**

***Тәхәллүсләре:*** Гөлчәһрә Байкина, Г. Заһидова.

1903 ел[ның] 1 октябрендә Әстерханда эшче гаиләсендә дөньяга килә. Театр артисты, 1919 елда Симферополь, Ташкент якларында уйный. 1931 елда Әстерханга кайта. 1939 елда Г. Юсупов белән

[1] Дөресрәге: Җәләл Байкин.
[2] Чыганакта: Җәлил.
[3] Чыганакта: Җәлил.

Әстерханнан китә. 1945 елда Казан академия театрына чакырыла. 1957 елда атказанган артистка исеме ала.

**83. БӘЙРӘМОВ Әхнәф Арслан улы.**

***Тәхәллүсе:*** Ә. Бәйрәмов.

1923 елның 30 сентябрендә Башкортстанның Чакмагыш районы Чиялекүл авылында крестьян гаиләсендә туа. Башкорт журналисты. 1945 елдан КПСС әгъзасы. Башкорт телендә язган әсәрләре бар.

**84. БАЙТУРСУНОВ Әхмәт.**

***Тәхәллүсләре:*** Ә. Байтурсун, Аккобай.

Казакъларның күренекле шагыйре һәм тел галиме. Казакъ мәктәпләре өчен язган дәреслекләре һәм шигырь җыентыклары бар. 1929 елда кулга алына. Соловки утравында була. Котылып кайткач, 1937 елда яңадан утырталар һәм юк итәләр[1].

**85. БАИШЕВ Әхмәт.**

***Тәхәллүсләре:*** Баиш, Булат.

Ташкентлы. Үзбәк язучысы, журналист. Үзбәк телендә язган әсәрләре бар.

**86. БАЙЧУРИНА Заһирә Гали кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** З. Байчурина, Татар хатыны.

1890 елның 27 маенда Татарстанда Әгерҗе районы Тирсә авылында мулла гаиләсендә туа. Иж-Бубый авылында укый. Укытучы. 1922 елда шигырьләр җыентыгы басылып чыга. 1935–1939 елларда райсовет депутаты була. Ул – Каюм Рахманкулов хатыны.

**87. БАЙЧУРА Шәриф Хәсән улы** (1892–1972).

***Тәхәллүсләре:*** Ш. Байчура, Кызыл солдат, К. Армиец, Ш. Б*.

Татарстанның Буа районы Ташкичү авылында туа. Революциягә чаклы да, аннан соң да төрле газета редакцияләрендә эшләп йөргән журналист.

**88. БАКИРОВ Госман (Усман) Фәтхулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Усман Бакир, Усбак, Г. Б*.

1896 елның 13 мартында Арча районы Югары Курса авылында крестьян гаиләсендә туа. Авылда укытучы була. 1922 елда Казанга

[1] Кулга алынып ике ай үтүгә атыла.

килеп, җир төзү техникумында укый. Соңра укытучы һәм инспектор булып эшли.1936–1940 елларда Казан педагогия институтында тел, әдәбият бүлеген тәмамлый, 1941–1945 елларда фронтта командир була. КПСС әгъзасы. Танылган балалар язучысы. Язган хикәя, әсәрләре бар.

**89. БАКИРОВ Фатих Салих улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Ф. Бакир, Ф. Бакиров, Күгәй, Ил улы, Гай-у, Мәңгелек юлчы.

1898 елның 24 декабрендә Казан шәһәрендә туа. Революциягә кадәр «Шура», «Аң», «Сөембикә» журналларында языша. Казанда артист була. Революциядән соң юридик факультет тәмамлап, Ташкент университетында юридик факультет җитәкчесе. Профессор. Әдәби, фәнни әсәрләр авторы.

**90. БАЛТАНОВ Гобәйдулла** (1892–1930).

***Тәхәллүсе:*** Балтан Гобәй.

Укытучы, Наркомпрос хезмәткәре.

**91. БАКЫЙ Сафа** (1892–1940).

***Тәхәллүсләре:*** Сафа Бакый, Авылдан.

Татарстанда вакытлы матбугатта актив катнашкан журналист. «Искедән яңалыкка» һәм «Хуҗалыклары артта калган крестьяннарга хөкем» пьесаларының авторы. 1929 елда кулга алына. Шуннан кайтмый.

**92. БАРУДИ – Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Галиев** (1857–1922[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Галимҗан Баруди, Г. Баруди.

Казан өязе Кече Кавал авылында туа. Бохарада укып кайтып, Казанда мулла була. «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» исемле зур мәдрәсә белән идарә итә. Күп галимнәр җитештерә. 1906 елда «Әд-дин вәл-әдәп»[2] журналын чыгара. Мәгариф өлкәсендә уку-укыту методикаларын яңача үзгәртеп кору буенча шактый эшли. Тел, әдәбият, гарәп теле фәннәреннән берничә дәреслек авторы. 1920 елда бай көтепханәсен[3] фәнни көтепханәгә тапшыра (4288 китап). «Китабе сүлүс» – өч

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1921 ел.

[2] «Дин вә әхлак».

[3] Көтепханәсен – китапханәсен.

тел[1] (гарәп, фарсы, татар теленең) сүзлекчәсе 1893 елда басыла. Баруди Уфада Мәхкәмәи шәргыядә[2] мөфти була. Бервакыт Пороховой бистәсендә торганга, үзен Баруди дип атый. Баруд – порох дигән сүз.

**93. БАСЫЙРОВ Мияссәр Мәгъсүм улы.**

***Тәхәллүсе:*** М. Басыйров.

1930 елның 25 ноябрендә Башкортстанның Бакалы районы Иске Балыклы авылында колхозчы гаиләсендә туа. Башкортстанның Тарих, тел, әдәбият институтын 1959 елда тәмамлый. Шагыйрь һәм язучы.

**94. БАСЫЙРОВ Фәхразый Хәбибрахман улы** (1893–1932).

***Тәхәллүсләре:*** Ф. Басыйр, Ф. Б.

Башкортстанның Дүртөйле районы Үткен авылында крестьян гаиләсендә туа. Башлангыч белем алгач, Уфада учительская семинария бетереп, Казанга килә. Анда медицина факультетын тәмамлап, врач була. Вакытлы матбугатта актив языша. Медицинадан язган әсәрләре дә бар.

**95. БАТТАЛОВ Габделбари.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Баттал, Муса Габдулла, Уйгыр, Таймас.

1874 елда туган[3]. Революциягә чаклы Мисырда Әзһәрия институтында[4] укып кайтып, Троицкида Яушевлар мәдрәсәсендә укытучы булып эшли. «Йолдыз» газетасының хәбәрчесе һәм редактор. «Ислам философлары», «Сөембикә манарасы хакында», «Нәзарияты әдәбият» (Галимҗан Ибраһимов белән бергә), «Мәгыйшәт юллар», «Сөймәк вә сөелмәк», «Будда» исемле әсәрләр авторы. 1920 елда чит илгә чыгып китеп, ак эмигрант була.

**96. БАТТАЛОВ Салих Вазыйх улы.**

***Тәхәллүсләре:*** С. Баттал, Баттал Салих.

1905 елның 5 августында Татарстан[ның] Биләр районы[5] Олы Тигәнәле авылында крестьян гаиләсендә туа. Төрле фабрикаларда эшче вазифасын башкара. Фронтта очучы булып хезмәт итә.

---

[1] «Ләгать сәләс: өч тел» хезмәте булса кирәк.

[2] Диния нәзарәтендә.

[3] Татар энциклопедиясе: 1880–1969 еллар.

[4] Каһирәдәге Әл-Әзһәр университеты.

[5] Спас өязе.

1951 елда марксизм-ленинизм университетын тәмамлый. Юмористик шигырьләрен халык яратып укый.

**97. БАХУЛЗАДӘ Корбан.**
***Тәхәллүсләре:*** Бахул, Бахулзадә.
Үзбәк шагыйре һәм язучысы.

**98. БӘХТИЕВ Фаикъ.**
***Тәхәллүсе:*** Бәхтиевский.
Укытучы, «Кызыл ил» газетасында журналист.

**99. БАШКУРОВ Рөстәм Шакир улы** (1927–1967).
***Тәхәллүсләре:*** Р. Башкур, Рөстәм Башкуров.
Тарихчы, Татарстанның гыйльми хезмәткәре. Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институты[1] галиме.

**100. БАШМАКОВ Ибраһим Йосыф улы** (1893–1913).
***Тәхәллүсләре:*** И. Башмаков, И. Б-к, Бикморза.
Пенза өлкәсе Инсар өязе Өрләдем авылында туа. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укый. Оренбургта «Шура», «Вакыт» идарәләрендә эшли. 1911 елдан «Шура»да шигырьләр яза башлый.

**101.** *Кара:* 189.

**102. БАҺМАНИ Габделкаюм Әлҗулбатый.**
***Тәхәллүсләре:*** Каюм Җулбатый. К. Баһман.
Мамадыш өязе Сатыш мөгаллиме, Җулбат[2] авылында мулла була. «Шура» журналында бик күп языша.

**103. БАҺАВЕТДИНОВ Гыймаз** (1897–1937).
***Тәхәллүсләре:*** Г. Баһаветдинов.
Бондюг заводында туа. Эшче. Казан университетын бетергәч, химия-технология институтын оештырып, аның җитәкчесе була. Аннан элек Татарстанның наркомюст[3] иде. «Татарстан» газетасында редактор. Шәхес культы корбаны.

---

[1] Бүген ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты.
[2] Хәзерге Саба районы Юлбат авылы.
[3] Юстиция халык комиссары (Народный комиссар юстиции).

**104. БАЯЗИТОВ Сафа Гатаулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** С. Баязитов, Баязит С.

Петербургта мулла гаиләсендә туган. Атасы урынына Петербургта мулла булып тора. «Нур» исемле газетаның редакторы. Революция алдыннан мөфти итеп билгеләнә. Иске карашлы иде. Шагыйрь Шәехзадә Бабич ул мөфти булгач, шундый эпиграмма яза:

Юк сафа, бетте «сафа», менгәч татарның тәхетенә,
Якты күрмәссең татар иблис төкергәч бәхетеңә.

**105. БАЯЗИТСКИЙ Зәки.**

***Тәхәллүсе:*** З. Баязитский.

Татарстанда танылган артист. Татар театрының директоры да булып тора. Үзе дә пьеса язгалый.

**106. БАЯНОВ Нур Галим улы** (1905–1945).

***Тәхәллүсләре:*** Нур Баян, Н. Баян, Гөләндәм.

Татарстанның Калинин районы[1] Әнәк авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1923 нче елда Казанга килеп, татар-башкорт хәрби мәктәбен тәмамлый. Баянов һәртөрле редакцияләрдә журналист булып эшли. Татар нәшриятының җаваплы редакторы. 1941 елда сугышка китеп, 1945 елда батырларча һәлак була. Аның шигырьләрен яратып укыйлар. Байтак шигырь-поэма җыентыклары бастыра.

**107. БАЯНОВ Әхсән Фәтхелбаян улы.**

***Тәхәллүсе:*** Әхсән Баян.

Шагыйрь һәм прозаик.

**108. БЕЛОУСОВ Бәкер Җәббар улы.**

***Тәхәллүсе:*** Бәкер Белоус.

Сембер өлкәсе Акчуриннар фабрикасында эшче. Революциянең башлангыч елларында бригада комиссары була. Хивада Җүнәйд хан белән сугышканда, басмачылар тарафыннан үтерелә.

**109. БИИШЕВА Зәйнәп Габдулла кызы.**

***Тәхәллүсе:*** З. Биишева.

Башкортстанның Күгәрчен районы Туембетово авылында крестьян гаиләсендә туа. 1924 елда мәктәп бетергәч, Оренбург педагогия

[1] Минзәлә өязе.

техникумына җибәрелә. Ул аны 1929 елда тәмамлап, комсомол ячейкасы секретаре була. Аннан соң төрле редакцияләрдә әдәбият бүлекләрендә эшли. 1941 елдан КПСС әгъзасы. Башкорт, рус телләрендә шигырь, поэма, хикәя, повесть, роман җыентыклары – 15 ләп китабы бар. Яхшы тәрҗемәче. «Юлаев» исемендәге бүләккә лаек.

**110. БИГИЕВ Мөхәммәдзаһир Ярулла ахун улы** (1870–1902).

***Тәхәллүсләре:*** Заһир Биги, З. Биги.

Ростов-Дон шәһәрендә туа. Атасы – Ярулла Габделкәрим улы – Пенза губернасы Чамбар өязе Кикин авылыннан Ростовка күчеп килә. Заһир русча укый. Аннан Казанга килеп, Күлбуе мәдрәсәсендә белем ала. 1891 елда Ростовта мулла була. «Гөнаһе кәбаир», «Гүзәл кыз Хәдичә», «Мавәраэннәһердә сәяхәт» повестьларының авторы. «Мөртәд», «Катилә» исемле әсәрләрен энесе Муса Ярулла бастырмаган.

**111. БИГИЕВ Муса Ярулла ахун улы** (1873–1949).

***Тәхәллүсләре:*** Муса Бигиев, М. Биги, Муса Җарулла, Муса Габдулла.

Пенза губернасы Алты авылында[1] [туа]. Ростовта 5 яшьтән укый башлый. Петербургта ирекле тыңлаучы булып университетта укый. Әхмәт Исхак белән Мисырга барып, белем эстиләр. Шәрык телләре галиме профессор Крачковский – аның дусты. Әнисе Фатыйма ханым 28 бала тапкан. Муса – 27 нче бала. Революциядән соң чит илләр[гә] чыгып китә. 1918 елда Петербургта «Әл-минбар» газетасы чыгара. «Мәгыйшәт юллары», «Рәхмәте иляһия борһанларга», «Озын көннәрдә руза», «Исляхәт әсаслары», «Әл-лүзүмият тәрҗемәсе» дигән әсәрләре бар.

**112. БИКБАЕВ Равил Төхфәт улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Р. Бикбай, Равил Бикбай.

Оренбург өлкәсе Покров районы Югары Кунакбай авылында туа. 1938 елдан Башкортстан педагогия институтында гыйльми хезмәткәр булып эшли.

**113. БИКБАЕВ Баязит Гаяз улы** (1909–1968).

***Тәхәллүсләре:*** Б. Бикбаев, Баязит Бикбай, Б. Б.

---

[1] Кикино авылында.

Башкортстанның Куергазы районы Калта авылында туа. 1923 елда Оренбургта һәм Уфада педагогия техникумында укый. Төрле редакцияләрдә әдәбият буенча эшли. Башкортстан укучыларының мәхәббәтен яулый. Башкортча язган шигырь, поэма, роман китаплары 20 дән артык. Шулардан байтагы рус һәм татар теленә тәрҗемә ителгәннәр.

**114. БИКБУЛАТОВ Мөхәммәт** (1899–1961).

***Тәхәллүсе:*** М. Бикбулат.

Башкорт язучысы. Уфада «Яңа авыл» газетасында редактор булып тора.

**115. БИКБУЛАТОВ Сөнгатулла Нигъмәтулла улы** (1886–1954).

***Тәхәллүсләре:*** С. Бикбулат, С. Б.

Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә гарәп нәхүе[1], соңгы елларда Казан университетында гарәп теле укыта. Шәрык телләре галиме. Дәһрилеккә тартым галим. «Хәзрәти Мөхәммәд», «Мәбдә әл-кыйраәт», «Мәбдә әс-сарыф» әсәрләре [авторы]. «Коръән»не саф татарга әйләндерә башлаган. Тәмам итү-итмәве билгеле түгел. Ш. Бабич аның турында болай яза:

> Бикбулат – ул бер «улак»тан су агызып тик ята,
> Кылдый-былдый боргаланмый, сатмый артык сафсата.

**116. БИККИНИН Мөхәммәтгариф Мирзазариф улы.**

***Тәхәллүсләре:*** М. Биккинин, Гариф Биккинин.

1907 елда Казанда «Тавыш» газетасы чыгара. «Таңчы» иде («Таң» газетасын чыгарган социалист-революционерларны «таңчы» дип йөртәләр иде). 1916 елның 18 маенда вафат була.

**117. БИККОЛОВ Ибраһим Җамалетдин улы** (1884–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Ибраһимов Биккол, И. Б., Әкмәли.

Татарстанның Буа районы Яңа Тинчәле авылында туган. Укытучы. Революциягә кадәр Сибириядә укытучы була. «Йолдыз», «Кояш» газеталарында, «Шура», «Аң» журналларында актив язышa. Ф. Әмирханның дусты. 1917 елда Сембердә «Җөмһүрият»

---

[1] Нәхүе – синтаксисы.

редакторы. Ярдәмчесе – Габдерәүф Шаһиди. Шагыйрь Кәрим Әмири аның турында болай яза:

> Бикколов Ибрай да бик күп гизде Себер илләрен,
> Капчык аскач кайтты монда, сагынып үскән җирләрен.

**118. БИККОЛОВ Касыйм Җамалетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Касыйм Биккол, К. Биккол.

Буа районы Яңа Тинчәле авылында туа. Язган әсәрләре:
«Нәмүнәи тәрәккый», 1904 елда Казанда;
«Гайнел-тәрәккый», 1907 елда (балалар өчен);
«Алтынбай агай», 1908 елда Казанда;
«Төркестан», 1908 елда Казанда;
«Бәдәлче»;
«Сабирҗан агай», 1910 елда Казанда;
«Ат караклары»;
«Хаҗи»;
«Гыйльме хәл»;
«Балалар кыйраәте»;
«Татар ханнары»;
«Кыйраәт вә зирагать»;
«Әхлак»;
«Канун вә низамлар», 1913 елда.

**119. БИККОЛОВ Шакир Сәлим улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Бикколов Шакир, Шакир Б.

1932 елның 15 гыйнварында Башкортстанның Абзали районы[1] Хәлил авылында туа. 1951 елда Башкортстан педагогия институтында укый. Аны бетергәч, гаскәри хезмәткә алына. 1958 елда башкорт нәшриятында редактор була. 1962 елдан КПСС әгъзасы. Язган шигырь җыентыклары бар.

**120. БИККОЛОВ Шәриф Сәгадәтулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Шәриф Биккол, Ш. Биккол, Ш. Б.

1924 елның 28 маенда Башкортстанның Кырмыскалы районы Карлыман авылында крестьян гаиләсендә туа. Ватан сугышында зенитчик булып катнаша. 1944 елда коммунистлар партиясе сафына

[1] Әбҗәлил районы.

керә. 1945–1949 елларда Башкортстан педагогия институтын тәмамлый. 1952 елда Уфа театр техникумында укыта. 1962–1968 елларда Язучылар союзының җаваплы секретаре. 15 тән артык шигырь, поэма җыентыклары бар.

**121. БИКЧӘНТӘЕВ Әнвәр Һади улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Әнвәр Бикчәнтәй, Ә. Бикчәнтәй.

1913 елның 4 ноябрендә Уфа шәһәрендә туа. 1928–1930 елларда Оренбург педагогия техникумында укый. 1931–1932 елларда Архангельск шәһәрендә укытучы. Ватан сугышында комиссар һәм командир була. 1942 елда партия сафына керә. 15 ләп башкорт, татар, рус телендә хикәя, роман җыентыклары бар.

**122. БИКМИЕВ Әхмәтҗан.**

***Тәхәллүсләре:*** Охранкада: «Султанов», Бикмиев Ә.

Буа шәһәрендә китап белән сәүдә итә. 1911 елдан башлап Февраль революциясенә чаклы «охранка»да «Султанов» исеме белән хезмәт итә.

**123. БИКМӨХӘММӘДЕВ Бикмулла.**

***Тәхәллүсе:*** Бикморатов.

1873 елда Арча районы Дөбьяз авылында крестьян гаиләсендә туа. 15 яшендә Алафузов заводына эшкә керә. 1925 елдан Хезмәт батыры. 39 ел хезмәт итә. Революционер.

**124. БИКТИМИРИЯ Галимәтелбәнат Лотфулла кызы** (1876–1906).

***Тәхәллүсләре:*** Галимәтелбәнат, Г. Биктимирия.

Казан өязе Кышлау авылында мулла гаиләсендә туа. Русча хисап, җәгърафия[1] өйрәнә. Хатын-кызга ирек бирү турында күп әсәрләр яза. 1892–1903 елларда «Тәргыйбел-бәнат»[2], «Хөснелвасия»[3], «Мәгашәрәт әдәбе»[4] исемле әсәрләре басылып чыга. 1895 елда Касыйм өязе Яубаш авыл мулласы Гарифкә кияүгә чыга.

[1] Җәгърафия – география.

[2] «Кыз балаларда укуга дәрт уяту».

[3] «Опекунлыкта гаделлек».

[4] «Аралашу кагыйдәләре».

**125. БИКЧУРИН Исхак.**

***Тәхәллүсе:*** Борис.

Чистайдан. «Бәянел-хак», «Кояш» газеталарында тәрҗемәче булып эшли. Шигырьләр яза. [...] Ул «эсер» таңчылардан. [...]

**126. БИКЧӘНТӘЕВА Әминә Әхмәт кызы.**

***Тәхәллүсе:*** Ә. Бикчәнтәева.

1913 елның 26 гыйнварында Казанда туа. 1938 елда Казанда педагогия институтын тәмамлый. Укытучы, Татар нәшриятында редактор була. Күбрәк балалар өчен язучы шагыйрә һәм тәрҗемәче. «Бүләк», «Дачада», «Бакча гөлләре», «Дәү әнием», «Бүген һәм иртәгә» исемле шигырь вә хикәя җыентыклары бар.

**127. БОЛГАРСКИЙ Барый Фәйзуллин** (1885–1927).

***Тәхәллүсе:*** Б. Болгарский.

Казанда ярлы итек тегүче гаиләсендә туа. 6 айлык чакта ятим кала. «Сәйяр»гә кушылып, данлыклы артист булып китә.

**128. БОЛГАРСКАЯ Гөлсем (1891–1968).**

***Тәхәллүсләре:*** Гөлсем Болгарская, Г. Болгарская.

Гомер буе сәхнәдә уйнап, «Атказанган артистка» исемен яулауга ирешә.

**129. БОРЫНДЫКОВ[1] Микъдәт Юныс улы** (1898–1965)[2].

***Тәхәллүсләре:*** М. Борындыков, Б. Микъдәт.

Кузнецк өязе [Дөмавыл] авылында туа. Казанда Учительская школаны бетерә. Беренче бөтендөнья сугышында офицер була. 1918 елда коммунистлар партиясе сафына керә. 1922 елда Татарстанның наркомпросы[3] була. Вакытлы матбугатта языша. «Безнең юл» журналының редакторы була. 1929 елда һәм 1937 елда кулга алына.

**130. БУБИ – Габдулла Габделгалләм улы Нигъмәтуллин** (1871–1922).

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Буби, Г. Буби.

[1] рус. Брундуков.

[2] Татар энциклопедиясе: 1896–1965 еллар.

[3] Мәгариф халык комиссары (народный комиссар просвещения).

Иж-Бубый авылында яңа ысул белән укытучылар җитештерүче гали[1] мәдрәсә ачып, «җәдит» укытучылар әзерләде. Донос буенча 1912 елда патша хөкүмәте мәдрәсәне ябып, укытучыларын кулга алды. Төрмәдән котылгач, Габдулла Буби 1913–1917 елларда Кытай, Голҗа шәһәрләрендә мәгариф эшендә була. Вакытлы матбугатта актив катнаша. Ислам фәлсәфәсенә багышланган берничә китабы бар.

**131. БУБИ – Гобәйдулла Габделгаллəм улы Нигъмәтуллин.**

***Тәхәллүсләре:*** Гобәй Буби, Фәйзи әфәнде.

Габдулла Бубиның бертуганы. Тәкъдирләре икәвенең дә бер.

**132. БУБИ – Мөхлисә Габделгаллəм кызы Нигъмәтуллина.**

***Тәхәллүсләре:*** Мөхлисә Буби, М. Буби.

Габдулла Бубинең сеңлесе, укытучы. Вакытлы матбугатта хатын-кыз иреге турында күп яза, революциядән соң Мәхкәмәи-шәргыядә казый була.

**133. БИКМӨХӘММӘДЕВ Исмәгыйль.**

***Тәхәллүсе:*** И. Бикмөхәммәдев.

Һиндстанга бара. Аның юл истәлеге 1862 елда Казанда басылып чыга.

**134. БУБИ Фәйзулла Тәрзимөхәммәдев.**

***Тәхәллүсе:*** Фәезбәк.

Бубый укытучысы. Төркиядә яшәүче тегүче татар малае. Иж-Бубый мәдрәсәсе ябылгач, аны кулга алалар. Төрмәдән котылгач, Истанбулга китеп, анда «Сабах» газетасының редакторы була. Бохара әмиренең каенесе. Иж-Бубый мәдрәсәсендә укый. Садри Җәләл Фәйзулла турында: «Ул безгә исторический материализм укыткан икән», – дип хәтерли. Шагыйрь Шәехзадә Бабич аның турында болай яза:

Буби Фәйзулла – тырышлыктан яралган җан, – ди ул.
Бер каралганнан, агарганнан яңарган җан, – ди ул.

**135. БҮКӘЙХАНОВ Галихан.**

***Тәхәллүсе:*** Г. Бүкәйхан.

[1] Гали – югары.

Казакъ адвокаты. Патша вакытында Дәүләт думасы әгъзасы. Андагы «Мөселман фракциясе»нең эшлеклесе, русча яхшы речь сөйләүче депутаты.

Ш. Бабич аның турында:

Галихан мескен казакъның бер генә ак йолдызы
Һәр колакка яңгырый ялгыз Галиханның сүзе, –
дип язды.

**136. БУЛАТОВ Сәет** (1898–1970).

***Тәхәллүсе:*** С. Булат.

Ульяновск шәһәрендә туа. 1916 елда Сембер труппасында катнаша. Башкорт һәм үзбәк театрларында уйный, 1925 елда Казанга чакыралар. Мәскәүгә китеп, режиссерлыкка укый. Яхшы режиссер, талантлы оештыручы, педагог. Казанда үлә.

**137. БУЛАТОВ Фатих Гариф улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Ф. Булатов, Фәтхи.

1902 елда Татарстанның Азнакай районы Түбән Сукаеш авылында туа. 1922–1926 елларда Казанда Татар-башкорт хәрби мәктәбендә укый. Гомер буе гаскәри хезмәттә була. Ватан сугышында генерал дәрәҗәсенә менә. Вакытлы матбугатта языша. «Генерал язмалары» исемле татарча һәм русча зур күләмле китаплар авторы.

**138. БУЛАТОВ Әхмәт (Шакир) Баһаутдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Әхмәт Булатов, Ә. Булатов.

1901 елда крестьян гаиләсендә туа. 1907–1917 елларда мәктәптә укый. 1910–1912 елларда рус мәктәбендә белем ала. 1918 елда Буа шәһәрендә Дарел-мөгаллиминдә (укытучылар институты) укый. Укытучы була. 1920–1923 елларда Кызыл армия сафында хезмәт итә. 1924–1931 елларда Хивада өлкә судында секретарь. 1928–1931 елларда Харәзем өлкә суды хозурындагы яклаучылар (адвокатлар) рәисе. 1931–1932 елларда Мәскәүдә укый, төрле гали уку йортларында гыйльми хезмәткәр. Казанда китаплар палатасында мөдир булып эшли.

**139. БУРАНГОЛОВ Мөхәммәдша** (1888–1966).

***Тәхәллүсләре:*** М. Бурангол, Мөхәммәдша Б.

Самара өлкәсендә Бозаулык районы Югары Ильяс авылында туа. Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Аннан соң укытучы

була. 1938 елдан Тел, әдәбият институтында[1] фольклорчы булып эшли. Фольклор җыючы һәм берничә драма әсәрләре авторы.

**140. БУРАНБАЙ.**

***Тәхәллүсе:*** Буранбай.

«Кармак» журналында күп язган журналист, юморист. Көчле сатирик. Кара диңгез якларыннан яза.

**141. БОРНАШЕВ А.А.**

***Тәхәллүсе:*** А. Борнашев.

Лейб-гвардия – Финляндия бүлегенең подпоручигы. 1825 елның 14 декабрендә булачак декабристлар восстаниесе булганчы бер көн элек К. Рылеев уздырган киңәш мәҗлесендә катнашкан кеше.

**142. БОРНАШЕВ Ибраһим Рәхмәтулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** И. Борнаш, Ибраһим Борнашев.

Ташкентта гимназия тәмамлый. 1920 елда «Кызыл шәрык» исемле агитбюрода хуҗалык җитәкчесе. Аннан соң Татарстанга килеп, наркомфин, журналист булып эшли. Җаваплы эшләрдә катнаша.

**143. БОРНАШЕВА Заһидә Хөсәен кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гыйффәт туташ, З. Хибия, Заһидә Борнаш.

1895 елда Пенза өлкәсе Әҗе авылында туа. Авыл мәктәбен бетергәч, үзлегеннән әдәбият белән кызыксына башлый. Рус шагыйрьләрен укый. 1912 елда шигырьләр яза башлый. 1915 елда, иске тормыш рамкасына чыдый алмыйча, протест йөзеннән өен ташлап кача. Шул чордагы вакытлы матбугатта шигырьләр бастыра башлый. Ниһаять, «Гыйффәт туташ шигырьләре» исемле җыентыгы чыга. Революциядән соң Коммунистлар партиясе сафына керә. Урта Азиягa китеп, шәрык хатын-кызларының азатлыгы өчен көрәш башлый. 1922 елда Сәмәркандта «Михнәттәшләр тавышы» газетасының редакторы була. 1971 елда «Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан» дигән гыйльми әсәрен бастыра.

**144. БОРНАШЕВ Мөхәммәдҗан Сәйфулла улы.**

***Тәхәллүсе:*** М. Борнашев.

1918 елда Бөтенрусия мөселман коммунистларының беренче съездында делегат, журналист.

[1] Тарих, тел һәм әдәбият институты (Уфа).

**145. БОРНАШЕВ Фәтхелислам Закир улы** (1898–1946[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Ф. Борнаш, Буф, Мишәр, Закир улы, Закир, Иген игүче, Номерсыз урындык, Фаш (?).

Чувашия республикасы Батыр районы Бикшек авылында мулла гаиләсендә туа. 9 яшендә Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә биреп укыталар. 1915 елда ул мәдрәсәне ташлап чыгып, үзлегеннән укытучылыкка имтихан тота. 1917–1918 елларда «Яшь йөрәкләр», «Таһир – Зөһрә» пьесаларын яза. 1919 елда Коммунистлар партиясе сафына керә. 1921–1924 елларда «Кызыл Татарстан», «Безнең юл», «Кызыл дәфтәр», «Чаян» журналларында редактор була. Күп кенә шигырь, поэма җыентыклары һәм драма әсәрләренең авторы.

**146. БОРНАШЕВ Хөсәен Хәсән улы.**

***Тәхәллүсе:*** Х. Борнаш.

Кызыл армиядә комиссар, акгвардияләр белән барган сугышта һәлак була. Хәрби матбугатта язышкан.

**147. БОРҺАНОВ Сафа Вафа улы** (1901–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Сафа Борһан, Сабур, Танай, Ләйләтин, Ләлин.

Татарстанның танылган журналисты.

1920–1937 елларда вакытлы матбугатта журналист һәм редактор буларак та күп эшли. Эрудицияле, талантлы, гадел язучы иде. 1927 елда (Ишимголов белән) «Канлы якшәмбе», «Февраль революциясе», 1928 елда «Октябрь революциясе», «Урожай көне» исемле әсәрләр яза.

**148. БӘДИГОВ Хуҗа Габделбәдигъ улы** (1887–1947[2]).

***Тәхәллүсләре:*** Х. Бәдигый, Хуҗа Бәдигъ.

Казанда туа. Танылган укытучы, профессор, фольклорчы.

**149. БАКИРОВ Кәбир** (1880–1941[3]).

***Тәхәллүсләре:*** Кәбир Бәкер, К. Б., Әбү Тозгыт.

Оренбург казачийларыннан. Революциягә кадәр танылган журналист. «Вакыт», «Шура» редакциясендә эшли. 1909 елда «Чөн тамь», «Ахун хәзрәтнең вафаты», 1912–1913 елларда «Бәйрәм

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1898–1942 еллар.

[2] Татар энциклопедиясе: 1887–1940 еллар.

[3] Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. 2 томда. 1 т. / Төз.: Р.Н. Даутов һәм Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. Б. 184.

хатирәләре», «Кара тап», «Тарихи пьеса», «Җанлы кабер ташы», «Башсыз хикәя», «Җанлы курчаклар», «Минем уйлануым», 1914 елда «Тукай Петербургта» әсәрләрен бастыра, 1918–1919 елларда Ташкентта «Олуг Төркестан» газетасы чыгара. 1921 елда «алтын» эше белән кулга алына.

**150. БАКИРОВ Хәнәфи.**

***Тәхәллүсләре:*** Х. Бакири, Хәнәфи Бакири.

Уфада яши. Уфага килгәнче Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. Төркиядә укып кайтып, төрекчә белгәнлеген күрсәтергә тырышкандай, «эвет, әфәндем», «белмәзем»... дигән булып кылана иде. Ш. Бабич аның турында язган эпиграммында болай ди:

Хәнәфиел-Бакиригә нә дияргә белмәзем,
Чөнки анда мәгънәсезлек, мөстәбидлек[1] күрмәзем!

**151. БӘХЕТГӘРӘЕВ Бәхтияр.**

***Тәхәллүсләре:*** Б. Бәхетгәрәй, Б. Бәхтияр.

Язучы. 1915–1916 елларда «Җир сату» әсәрен язган.

**152. БӘХТИЯРОВ Нәкыйп** (1899–1941).

***Тәхәллүсләре:*** Н. Бәхтияров, Җамали.

Журналист. 1924–25 елларда «Чаян» журналында җаваплы секретарь булган кеше.

**153. БӘХТИЯРОВ Вафа** (1884–1960[2]).

***Тәхәллүсләре:*** В. Бәхтияр, Вафа Бәхтияров.

Казанда туган. Казанда «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»дә укыган. 1906–1907 елларда Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан белән бергә «Әлислах» газетасы чыгарган мәгърифәтче-демократларның берсе.

**154. БӘШИРОВ Зариф Шәрәфетдин мулла улы** (1888–1964)[3].

***Тәхәллүсләре:*** З. Бәшири, Зариф Бәшири, Фираз, Сөрүҗе *(революциягә чаклы).*

Чувашстанда Чүти авылында туа (Зөя өязе). 1902 елга кадәр Буада Нургали ахун мәдрәсәсендә укый. 1907 елда Казанга килеп,

[1] Мөстәбидлек – изүче, залимлек.

[2] Татар энциклопедиясе: 1881–1960.

[3] Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. 2 томда. 1 т. / Төз.: Р.Н. Даутов һәм Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. Б. 188: 1888–1962.

Печән базары мәхәлләсендә укый. «Йолдыз»да шигырьләр яза башлый. 1909–1913 елларда Пенза якларында укытучы була. Аннан соң Капалга барып, 1917 [елга] чаклы укытучы була. Революциядән соң Алма-Атага килеп, газета-журнал чыгара башлый. Күп кенә шигырь-поэма, хикәя-әсәрләр җыентыгы авторы.

**155. БӘШИРОВА Зәйнәп Хуҗаҗан кызы**

***Тәхәллүсләре:*** Зәйнәп Бәширова, З. Бәширова, Фурия.

1903 елда Лаеш өязе Балтач авылында туа. 1917–1918 елларда хатын-кызлар өчен ачылган Укытучылар семинариясенә керә. Аннан соң Казан рабфагында укый, 1924–1925 елларда Мәскәү дәүләт журналистика институтын тәмамлый. Аннан кайткач, төрле редакцияләрдә җаваплы эшләрдә эшли. Шигырь җыентыклары бастыра. 1930 елда Коммунистлар партиясе сафына керә. Кәрим Әмири аның турында мондый эпиграмма яза:

«Бәширова» – «Өй кибарым»[1] дип түгәрәк төзеде,
Тик членнар артмый бер дә, ул һаман да берүзе.

**156. БӘШИРОВ-РАЗИН Гомәр Бәшир улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гомәр Бәшири, Г. Бәшир, Г. Разин.

1901 елның 1 гыйнварында[2] Арча районы Яңасала авылында крестьян гаиләсендә туа. Яшьли атадан ятим калып, тормыш авырлыгын татый. Гражданнар сугышында гади солдат булып катнаша. Марксизм-ленинизм институтында белем ала. КПСС әгъзасы. 1930 елларда яза башлый. 1951 елда «Намус» романы өчен Сталин премиясе бирәләр. Танылган әдип. Татар әдәбияты классикларыннан берсе. Күп телләргә тәрҗемә ителде.

**157. БӨДӘЙЛИ Кәшфеләсрар Кәшфелһади улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Кәшфи Бөдәйли, К. Бөдәйли, Кәбүли, Дулкын, Тутай II.

1905 елда Мамадыш районы Ямашев исемендәге авылда туа. Казанга килеп, рабфакта укый. Казанда финанс-экономика институтын тәмамлый. Экономист булып эшли. Вакытлы матбугатта шигырьләр, мәкаләләр яза.

---

[1] Өй кибарым – өйләнмәүчеләр һәм кияүгә бармаучылар оешмасы.

[2] Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. 2 томда. 1 т. / Төз.: Р.Н. Даутов һәм Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. Б. 192: 7 гыйнварда.

**158. БӨДӘЙЛИ Мәхмүт Кәшфелһади улы.**

***Тәхәллүсләре:*** М. Бөдәйли, Кигәвен, Философ, Габкаһар, Әйтмим, М. Б.: Мб, Без, Кәшфизадә, Большевик, Әйтермен әле, Чаянчы, Шәрык кигәвен, Чебен, Тукай түгел, Мин түгел, Мөхбир, Карт студент, Тире трест, Авталиф, Таттеатр трест, Мәһмүт Һади, М. Һади, Мулла-монтагай һәм сәүдәгәр кулаклар оешмасы, Дәһри.

1895 елның 3 апрелендә Мамадыш өязе Ямаш авылында туа. 1907 елда Троицк шәһәренә китеп, «Хуҗаҗания» мәдрәсәсен тәмамлый. Ике класслы рус-татар мәктәбендә укый. Типографиядә наборщик булып тора. 1914 елда Ташкентта «Садаи-Төркестан» газетасында эшли. «Акмулла», «Шура» журналларының, «Вакыт» газетасының хәбәрчесе. 1914 елда бер мәкалә өчен Ташкентта кулга алына. 1915 елда солдатка алына. Аннан кайткач, Мамадышта хәрби комиссар була. 1918 елда «Мамадыш тавышы» газетасын чыгара. 1920 елда ВЦИК партия «Кызыл шәрык» агитбюросы белән Төркестанга җибәрелә. Анда горкомнацта урынбасар. Хивага фәүкылгадә[1] посол итеп билгеләнә. Бохарада матбугат вәзире була. 1922 елда Казанга кайтып, наркомздрав вазифасын башкара. Университетның физматында укый. «Татарстан»да редактор булып тора. «Чаян»да беренче редактор. Язган нәрсәләре бар: «Окоп тавышы», «Тормыш төенчекләре», «Замана көлкеләре», «Көлке теориясе», «Коммунистның беренче әлифбасы», «Коммунистлар манифесты» (сөальлеҗаваплы тәрҗемә), «Иптәш, үзеңне сынап кара», «Саз бизгәге», «Иҗтимагый авырулар», «Миллионнар саклау наменә», «Юмор һәм сатира» җыентыгы...

Ш. Бабич аның турында болай ди:

Кигәвен дуст, көчәнмә, угың юк бит кадарга,
Безелдәвеңнән бозау гына тотына куркып чабарга.

Шагыйрь Калмаери болай яза:

Һәм Бөдәйли, һәм директор, һәм язучы, һәм һәме
Һәм дә җырчы, һәм дә комик... һәммәләреңнән дә юк шәбе.

**159. БӨДӘЙЛИ Мисбахетдин Кәшфелһади улы** (1906–1970).

***Тәхәллүсләре:*** М. Бөдәйли, Мисбөдәл.

Татарстанның Мамадыш районы Ямаш авылында туа. Сарман районы Карамалы авылында үсә. Балалар йортында коммуна

[1] Фәүкылгадә – гадәттән тыш.

мәктәбен тәмамлый. Комсомолда секретарь булып һәм җаваплы эшләрдә эшли. Пушнина белгече буларак, Урта Азиядә шактый эш башкара. «Татарстан» һәм «Татария» газеталарының корреспонденты. Бөтенсоз коммунистларының журналистлар союзы әгъзасы.

**160. ВАҺАПОВ Габдулла Әхмәт улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Габдүш Вагапов, Вагапов Г, Габдийүш.

1814 елда Казан губернасында туа. 1835 елда Казан гимназиясен тәмамлаганнан соң, университет физматында укый. Казан кадетлар курсында укыта. Русчадан татарчага, татарчадан русчага тәрҗемә итә. Яхшы тәрҗемәче санала. Ибраһим Хәлфин эшен дәвам иттерә. Гарәп, фарсы, төрек, татар телләрен яхшы белә. 1850 елда дәреслекләр бастыра. 1860 елда университетта укыта, русларга татарча, татарларга русча өйрәнү өчен «Самоучитель» китабын яза. Ул 1852 елдан 1911 елга кадәр 12 тапкыр басыла. Аңа татар һәм төрек җыр вә мәкальләрен кертә. 1875 елда «Русча-татарча азбука» дигән әсәре беренче тапкыр басыла. «Тимернең Болгарны алуы» әсәрен бастыра. Русчадан бик күп тәрҗемә итә.

**161. ВӘЛИЕВ Фәйзи** (1892–1941).

***Тәхәллүсләре:*** Ф. Вәлиев, Фәйзи, Фәйзи Чаган, Вәлиев Фәйзи.

Шагыйрь, прозаик. Ул Башкортстанның Кушнаренко районы Шәрип авылында туа. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укый. 1912 елда андагы укыту ысулыннан разый булмыйча, ташлап чыгып китә. Төрле заводларда эшче һәм укытучы булып йөреп, үзлегеннән белем ала, «Шура», «Аң», «Чәчән»дә шигырьләр, хикәяләр белән чыгыш ясый. Ул төрле псевдонимнар астында шактый матур әдәби хикәяләр иҗат итә. Ләкин бүгенгә кадәр аның әдәби яктан җитлеккән әсәрләре укучыларга әле җиткерелмәде.

**162. ВӘЛИЕВ Әкрәм Мөхәррәм улы** (1908–1963).

***Тәхәллүсләре:*** Әкрәм Вәли, В. Әкрәм, Әбләйский.

Башкортстанның Чакмагыш районы Әбләй авылында туа. Башкортның танылган шагыйрь һәм әдибе. Башкорт, рус телләрендә 30 дан артык роман, хикәя, повесть һәм шигырь җыентыклары бар.

**163. ВӘЛИЕВ Габдулла Вәли улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Вәли, Г. Вәлиев.

1904 елның 5 маенда Татарстанның Ютазы районы Бәйрәкә авылында туа. 1925–1926 елларда Бөгелмәдә педагогика курсларын бетерә. 1930–1932 елларда Әлмәт мәгариф бүлегенең баш методисты булып эшли. 1934 елда хәбәрче-журналист, 1952 елда «Үсү юлы» пьесасын, 1953 елда «Алтын орлык» драмасын, 1954 елда «Өермә» һәм «Күңелсез мәхәббәт» комедияләрен яза.

**164. ВӘЛИЕВ Ярулла Носратулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Ярулла Вәли (*революциядән соң*).

1921 елның 10 мартында Нуриман районы Бикморза авылында туа. Башкорт язучысы, журналист, төрле редакцияләрдә эшли. Язган хикәя-повесть җыентыклары бар.

**165. ВӘЛИДОВ Батыр Хаҗиәхмәт улы.**

***Тәхәллүсе:*** Батыр Вәлит.

1905 елның 20 апрелендә Башкортстанның Баймак районы Туктагол авылында туа, башкорт язучысы һәм шагыйре. Башкорт телендә уннан артык шигырь җыентыклары бар.

**166. ВӘЛИХАНОВ Чокан.**

***Тәхәллүсләре:*** Вәлихан Чакан, В. Чакан.

Казакъ мәгърифәтчесе. 1835 елда туа. Хөсәен Фәезханов һәм Шиһаб Мәрҗанинең дусты. Казакъ сүзлеге өчен материаллар җыйган кеше. Әбләй хан оныгы.

**167. ВАФИН Нури Зариф улы.**

***Тәхәллүсе:*** Нури Вафин.

1919 елда Казанда туа. 1935–1938 елларда сәнгать техникумында укый. 1939 елда «Шатлык дулкыннары» исемле беренче шигырь китабы басылып чыга. Ватан сугышында катнаша. Кайткач, Казанда мех комбинатында рәссам булып эшли.

**168. ВӘЛИДОВ Габдрахман.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Вәлид, Габдрахман Вәлиди, Гуд.

1894 елның 15 декабрендә Казан өязе Өшкәтә волосте Большая Шухата[1] авылында мулла гаиләсендә туа. Казанда «Мөхәммәдия»дә

[1] Хәзерге Әтнә районы Олы Өшкәтә авылы.

укый. Революциядән соң Мәскәүдә Крупская исемендәге академияне бетерә. Академиянең вак милләтләр мәктәбе бүлегендә баш гыйльми хезмәткәр булып эшли.

**169. –**

**170. ВӘЛИЕВ Хәйретдин Вәли улы** (1893–1969).

***Тәхәллүсләре:*** В. Х., Хәйретдин Вәли, Күпкински-Чүпкински.

Укытучы, әдәбиятчы, тәнкыйтьче.

**171. –**

**172. ВӘЛИЕВ Ярулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Ярулла Вәли, В. Ярулла.

Татарстанда Буа өязе Бикмураз авылында туа. Бозаулыкта үлә. Оренбургта укый. Махсус русча өйрәнә. «Шура», «Вакыт» идарәсендә эшләп, Закир Рәмиев кызына өйләнә. 1901–1912 елларда «Җанлы җеназа», «Ачлык кушты», «Мәңгелек мәсҗет», «Йолдыз» (шивәләр мәҗмугасы), «Оят, яки күз яше», «Үзеңә кайта», «Ахырзаман бәласе», «Урман әүлиясе», «Әфьюн», «Ялтыравыклы күз», «Җәйге таңда көтү куганда» әсәрләренең авторы.

**173. ВӘЛИДОВА Айсылу Габдрахман кызы.**

***Тәхәллүсе:*** Айсылу Вәлиди.

Тел, әдәбият институтын тәмамлап, филология фәннәре доценты булган кеше, Мәскәүдә яши.

**174. ВӘЛИДОВ Зәки.**

***Тәхәллүсе:*** Зәки Вәлиди.

1886 елда Ишембай районы Көзән авылында туа. Яшьли ятим кала. 1890 елдан Хәбибеннаҗар хәзрәттә тәрбияләнә. 1919 елда Башкортстанда буржуаз хөкүмәт төзеп, соңра Төркиягә качып китә. Эмигрант.

**175. ВӘЛИДОВА Кояш Гыйльфан кызы.**

***Тәхәллүсе:*** Шахтер кызы.

1895 елда февральдә Рәмиевләрнең алтын приискасында тора. Революциядән соң укытучы була. Хатын-кыз ирege турында мәкаләләр яза, партияле.

**176. ВӘЛИДОВ Мөхәммәдсалих Борһанетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Сәлим Вәлиди, Сәвәл.

1908 елда Апас районы Дәвеш авылында туа. Революциянең баш елларында «Кызыл шәрык яшьләре» журналында языша. Китап сәүдәсе мөдире.

**177. ВӘЛИДОВА Йолдыз Габдрахман кызы.**

***Тәхәллүсе:*** Йолдыз Вәлиди.

Мәскәүдә институт бетереп, филология фәннәре кандидаты була.

**178. ВӘЛИДОВ Садрелислам Хәйретдин улы** (1891–1943).

***Тәхәллүсләре:*** Садри Җәлал, Тимер ага баласы, Әфләтун, Тиктормас, Ирдәс Садри, С. Җәлал, С. Җ.

Татарстанның Апас районы Апас авылында туа. «Буби» мәдрәсәсендә укый. Беренче Герман сугышында офицер була. 1917 елда «Безнең тавыш» газетасын чыгара. Язучы, көчле юморист, 1923 елда «Чаян»да җаваплы секретарь. 1914 елда «Алга» нәшрияты Садри Җәләл хикәяләре җыентыгында 5 әсәрен бастыра: «Дим буе», «Андрей, мин сиңа рәнҗемим», «Бишек янында», «Йолдыз», «Нигә син мине сөясең». 1929 елда һәм 1937 елда кулга алынып сукырая, төрмәдән чыгып, иректә үлә.

**179. ВӘЛИДИ Җамалетдин Җәлалетдин улы** (1887–1932).

***Тәхәллүсләре:*** Җамал Вәлиди, Җәләй, Җ. Вәлиди.

Татарстанның Апас районы Апас авылында туа. «Буби» мәдрәсәсендә укый. Оренбургта «Хөсәения»дә укыта. «Шура», «Вакыт» идарәсендә эшли. Революциядән соң Казанга килеп укытучы була. Зур галим, талантлы язучы, гадел укытучы. «Татар теленең имля, сарыф, нәхү кагыйдәләре», «Милләт вә миллият», «Камус» әсәрләренең авторы. 1932 елда кулга алынып, төрмә полициясенең 3 нче этажыннан ташланып үлә.

**180. ВӘЛИШИНА (НИГЪМӘТУЛЛИНА) Камилә.**

***Тәхәллүсләре:*** Камилә Валиуллина, Вәлишина К.

1908 елда Казанда эшче гаиләсендә туа. 1924 елда Казан рабфагында укый. 1926 елда Әстерханда, 1927 елда Казанда күчмә театрда эшли. 1948 елда Әстерханга кайтып, пенсиягә чыга.

**181. ВӘЛИШИН Якуб.**

***Тәхәллүсләре:*** Вәлишин Якуб, В. Якуб.

1899 елның 26 декабрендә Татарстанда эшче гаиләсендә туа. Рус-татар мәктәбендә укый. Гражданнар сугышында катнаша. 1922 елда Әстерханга кайтып, клуб мөдире була. 1926 елда партия сафына керә. Ватан сугышына катнаша. Әстерханда пенсиягә чыга.

**182. ВАХИДОВ Габделхәй Каюм улы.**

***Тәхәллүсе:*** Хәй Вахит.

1918 елның 20 декабрендә Татарстанның Дөбьяз районы Мәмдәл авылында туа. 1941–1945 елларда Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң Казан дәүләт консерваториясен тәмамлый. Балалар өчен шигырьләр яза башлый. 1939 елда «Дулкыннар» исемле беренче әсәре басыла. Әкиятләр, «Безнең авылда», «Якты юл» китапларын бастыра. «Самат» операсына либретто яза. Танылган язучы, көчле драматург.

**183. ВАХИТОВ Касыйм Мисбах улы** (1916–1942).

***Тәхәллүсләре:*** Касыйм Вахитов, Вахитов К.

Башкортстанның Әлшәй районы Нигъмәтулла авылында туа. 1935 елда дәүләт педагогика техникумын бетергәч, укытучы була. 1937–1941 елларда Казан педагогика институтын тәмамлый. 1938 елда яза башлый. «Чаян», «Совет әдәбияты», «Азат хатын» журналларында шигырьләр бастыра. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1942 елда Смоленск янындагы каты сугышларда батырларча һәлак була.

**184. ВАХИТОВ Миңнулла Вәли улы** (1879–1927)[1].

***Тәхәллүсләре:*** Миңнулла Вахитов, Габдуллаев Төхфәтулла.

Казанда эшче гаиләсендә туа. Чыгышы Лаеш өязе Наласа авылыннан. 12 яшеннән Алафузов заводында, Октябрь революциясеннән соң типографиядә эшли, Обком контроль комиссиясендә әгъза була.

**185. ВАХИТОВ Әнүр Хисмәт улы.**

***Тәхәллүсе:*** Әнвәр Вахитов.

[1] Татар энциклопедиясе: 1872–1927 еллар.

1932 елның 20 декабрендә Башкортстанның Гафури районы Тугай авылында туа. Башкорт язучысы. Башкорт телендә дүрт-биш хикәя китабы басыла.

**186. ВАХИТОВ Мулланур Муллаҗан улы** (1885–1918).

***Тәхәллүсләре:*** Вахитов Мулланур, М. Вахитов, М-нур Вахитов*, Нур В*.

Пермь өлкәсе Кунгур шәһәрендә туа. Революциягә чаклы төрле урта һәм югары мәктәпләрдә укый. Революциядән соң бөек революционер, милли республикалар оештыручы, партия җитәкчесе булып эшли. 1917 елда Мәскәүдә һәм Казанда Мөселман комиссариаты оештыра. «Кызыл байрак», «Игенче» газеталары чыгара. 1918 елда Пләтән төрмәсенә ябыла. Аклар аны 6 елга каторгага хөкем итәләр.

**187. ВАХИТОВ Шакир Габделгани улы Шамильский** (1892–1945).

***Тәхәллүсләре:*** Шакир Шамильский, Ш. Шамильский.

Лаеш өязе Юеш Көрнәле авылында туа. Татарның талантлы артисты.

**188.** [...]

**189. ВАҺАПОВА Фатыйма.**

***Тәхәллүсе:*** «Гөлҗамал» (*бер кыз исеме түгел, шартлы исем*).

Петроградтагы генерал Ваһапов кызы. Казанда 4 нче кызлар гимназиясендә укып йөргәндә, Артибашев дигән бер рус алпавытына кияүгә чыгып чукына. Шул чорларда Сара Нәхимова дигән укымышлы татар кызы Бугишпан исемле бер еврейга кияүгә чыгып, лютеран динен кабул итә. Ш. Бабич, шуларга ишарә итеп:

Милләтеңнән читкә качтың, гимназистка «Гөлҗамал»
Сезгә ләгънәт, әй укыган һәм чукынган марҗалар, –

диде.

**190. ВАГАЗОВА Фатима.**

***Тәхәллүсе:*** Ф. Вагазова.

Казанда республика музеенда гыйльми хезмәткәр булып эшләп пенсиягә чыккан белемле ханым.

**191. ГАБДУЛЛА САБИР.**

***Тәхәллүсләре:*** Мәмә Сабир, Иҗикбатыр.

Ташкентта үзбәк шагыйре һәм язучысы. Язган әсәрләре бар.

**192. ГАБДУЛЛАЕВ Габдерәхим.**

***Тәхәллүсе:*** Гайрәти.

Үзбәк шагыйре һәм язучысы.

**193. ГАБДУЛЛАЕВ Маннан.**

***Тәхәллүсе:*** Рамир.

Үзбәк язучысы.

**194. ГАБДУЛЛАҖАН.**

***Тәхәллүсе:*** Нәсими.

Үзбәк шагыйре. Фольклорчы.

**195. ГАБДУЛЛИН Ибраһим Әхмәт улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Габдуллин И, И. Габдуллин.

1920 елның 20 октябрендә Башкортстанда Шаран районы Җирекле авылында крестьян гаиләсендә туа. 1939 елда Уфада Геология техникумын тәмамлый. 1940 елда Совет армиясе сафына алына. 1942 елдан фронтта. 1945 елдан журналист-хәбәрче. 1954–1955 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы хозурындагы югары әдәбият курсларында укый. Шул ук вакытта М. Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый. 1947 елда партия сафына керә. 1938 елда «Ал яулык» пьесасын, 1940 елда «Ерак чиктә» пьесасын, 1946–1947 елларда «Тирәнтен сулау» драмасын, «Роза», «Йөрәк ялкынсыз яна», «Хатыннан аерылам» комедияләрен, «Урман кызы», «Йөрәк белән шаярмыйлар», «Бер мәхәббәт тарихы», «Онытылган ант» драмаларын яза. Вакытлы матбугатта катнаша.

**196. ГАБДЕЛҖАББАРОВ Габдерәшит.**

***Тәхәллүсе:*** Уйгур.

Үзбәк шагыйре һәм язучысы.

**197. ГАБДРАХМАНОВ Рөстәм.**

***Тәхәллүсе:*** Кинҗәтай.

Үзбәк журналисты һәм язучысы.

**198. ГАБДЕЛҖӘЛИЛ Габделмәннан улы** (1832–1925).

***Тәхәллүсләре:*** Җәлалетдин Мәннани, Габделҗәлил.

Бу кеше 1844–1856 елларда Тирсә мәдрәсәсендә укыганда, халык арасында күп таралган мәшһүр шигырен язган:

Каләм үгрән, каләм изгегә тартыр,
Каләм белгән кешенең кадере артыр.

**199. ГАБДРАХМАНОВ Котдус.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Котдус, Г. К.

Рөшди сыйныфы өчен «Әхлак» исемле дәреслек язган кеше.

**200. ГАБДРАХМАНОВ Хәбибрахман** (1914–1942).

***Тәхәллүсләре:*** Хәбра Рахман, Х. Рахман.

Татарстанның Балтач районы Яңгул авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1936 елда Х. Рахман Казан педагогия институтын тәмамлап, Алабуга педагогика мәктәбендә укыта. 1938 елда Совет армиясе сафына алына. Халхин-Гол сугышында катнаша. Кайткач, тагын Алабугада укыта, шундагы район газетасында языша һәм редактор булып тора. Аның «Чәчәк ява» исемле беренче шигырь җыентыгы 1937 елда басыла. Х. Рәхман Мәскәү янындагы каты сугышларда 1942 елның ноябрендә батырларча һәлак була.

**201. ГАБДРАХМАНОВ Мансур Ибраһим улы** (1912–1972).

***Тәхәллүсләре:*** Мансур Габдрахманов, М. Габдрахманов.

Казанда туа, яшьли әти-әнисез ятим кала. 12 яшьтән мөстәкыйль хезмәт юлына керә. 1939 елда педагогия институтында укый. Аннан Фин сугышына китә. Ватан сугышында башыннан ук катнаша. 1944 елда каты яраланып кайтып, университетка аспиратурага керә. 1958–1965 елларда университетның фәнни эшләре буенча проректоры була. Партия һәм совет съездларында катнаша. Верховный совет әгъзасы, профессор, «Кызыл байрак», «Кызыл йолдыз» орденнары белән бүләкләнә.

**202. ГАБДРАХМАНОВ Рәис Бикмөхәммәт улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Рәис Габдрахманов, Г. Рәис.

1918 елның 3 гыйнварында[1] Башкортстанның Благовар районы Күчәрбай авылында туа. Күренекле башкорт язучысы.

[1] Дөресе: октябрь.

Башкорт телендә 15 ләп хикәя, повесть китаплары бастырган кеше.

**203. ГАБДЕССӘЛАМОВ Әбелмәних Әбелгазиз[1] улы** (1782–1826 (һиҗри 1200–1240)).

*Кара:* 453.

**204. ГАБДУЛЛАЕВ Кәрим.**

***Тәхәллүсе:*** Тулкын.

Үзбәк язучысы.

**205. ГАБДУЛЛИН Басыйр.**

***Тәхәллүсләре:*** Б. Габдуллин, Басыйр Габдуллин.

1917 елда Әстерханда «Солдат ялкыны» газетасын чыгара.

**206. ГАБДУЛЛИН Ришат Мокыйм улы.**

***Тәхәллүсе:*** Габдуллин Рәшит.

1916 елның март аенда Усть-Каменогорск шәһәрендә шахтер гаиләсендә туа. Әтиләре кебек яшьтән шахтер хезмәтенә керә. 1935 елда Мәскәүгә консерваториягә җибәрелә. Казакъ операсы җырчысы булып китә. Йомшак тембрлы баритон тавышлы җырчы.

**207. ГАБДУЛЛИН Мөслим Мокыйм улы.**

***Тәхәллүсе:*** Габдуллин Мөслим.

1916 елның мартында Усть-Каменогорскта шахтер гаиләсендә туа. 1936 елда Мәскәүгә консерваториягә җибәрелә. Аннан өйрәнеп кайткач, казакъ операсының күренекле җырчысы булып китә. Көмешсыман лирик тенор тавышлы җырчы.

Ришат белән Мөслим икәве Мокыймның игезәк балалары.

**208. ГАБДУШЕВ Хәким.**

***Тәхәллүсе:*** Х. Габдушев, Х. Г.

Революциягә чаклы «Кармак» журналында языша. 1920 елда аклар белән китеп, Харбин шәһәрендә «Ерак шәрык» журналы, милли идарә исеменнән «Ерак шәрык» исемле газета чыгара.

---

[1] Дөресе: Әбелфәез.

**209. ГАБИДУЛЛИН Исмәгыйль.**

***Тәхәллүсләре:*** И. Габиди, Габиди Исмәгыйль.

Казанда Бишбалтада мулла булган кеше. «Шура» журналында дөньяви шигырьләр яза. 1918 елда Казанда Садыйк мулла Иманкольй белән «Иттифак» газетасы чыгаралар. Садыйк та – шагыйрь. Аның турында Бабич болай яза:

Мулла Исмәгыйль Габит ул өч йөрәкме, берме – я?
Ул йөрәктә нәрсәдер кайный – шигырьме, динме – я?

**210. ГАБДЕРӘШИТОВ Мөнәвәр карый.**

***Тәхәллүсләре:*** Мөнәвәр карый, М. Рәшиди.

Үзбәк укытучысы һәм язучысы. 1909 елда «Хөршид» исемле газетаның нашире һәм мөхәррире. 1914 елда «Садаи Төркестан» газетасының редакторларыннан. 1929 елда кулга алына.

**211. ГАБИДУЛЛИН Әзһәр.**

***Тәхәллүсе:*** Ә. Габиди.

Язган әсәрләре бар.

**212. ГАБИДУЛЛИН Рифгать Мөхәммәджан улы.**

***Тәхәллүсе:*** Р. Габидуллин.

1912 елның 20 декабрендә Уфада туа. Консерватория бетергән композитор.

**213. ГАБИДУЛЛИН Хаҗи Заһидулла улы** (1896–1940)[1].

***Тәхәллүсләре:*** Хаҗи Габдуллин, Х. Габдуллин.

Пермь губернасында (Көңгердә булса кирәк) туа. Башлангыч мәктәпне бетергәч, Көңгер шәһәрендә тимерьюлчылар мәктәбенә укырга керә. 1915 елда аны тәмамлап, тимерьюлда канторщик булып эшли. 1916 елда патша армиясенә алына. Анда прапорщиклык мәктәбен бетереп, прапорщик була. Февраль революциясеннән соң аны солдатлар Көңгер советына депутат итеп алалар. 1917 елда Коммунистлар партиясе сафына керә. Гражданнар сугышында полкта хәрби комиссар. 1920 елда Татарстанда милиция башлыгы була. 1925 елда – Татарстан министрлар советы рәисе. 1927 елда Мәскәүгә алына һәм анда Мәгариф министрлыгында гыйльми

[1] Татар энциклопедиясе: 1897–1940 еллар.

җитәкче була. 1931–1933 елларда ул КУТВда[1] укыта. Кандидатлык диссертациясен шунда яклый. 1933 елда профессорлык дәрәҗәсен ала. «Россиядә панисламизм һәм пантюркизм турында очерклар» дигән әсәре басылып чыга. 1934 елда Истанбулда үткәрелгән Бөтендөнья конгрессында совет делегациясенең җитәкчесе. 1937 елда кулга алынып, шәхес культы корбаны була.

**214. ГАБИТОВ Хәбибулла** (1886–1939).

***Тәхәллүсләре:*** Х. Габиди, Габидов Хәбибулла.

Башкортстанда Хәбибулла районы Габделкәрим авылында туа. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укый. Байтак еллар Иркутскида мөгаллим була. 1913 елда яза башлый. 1918 елда «Башкорт моңнары», 1923 елда «Курай җырлары», 1937 елда «Энҗекәй һәм йолдызкай» пьесасы, 1928 елда «Кечкенәләргә җырларым», 1929 елда «Типкән» исемле шигырь һәм хикәя әсәрләре иҗат итә. Башкортча дәреслекләр, фольклор турында хезмәтләре бар.

**215. ГАБДУЛЛИН Гыйззулла.**

***Тәхәллүсе:*** Габделгабит.

Оренбургта туа. Укытучы, шагыйрь. 1955 елда Карши шәһәрендә үлә.

**216. ГАБДУЛЛИН Әфтәхетдин.**

***Тәхәллүсләре:*** Ә. Габдуллин, Әфтәх Габдул, Г. Әфтах.

1918 елда «Идел-Урал өлкәсе» дигән газета чыгарды.

**217. ГАБӘШИ Солтанәхмәт Хәсәнгата улы** (1891–1938)[2].

***Тәхәллүсләре:*** С. Габәши, Г. Солтанәхмәт.

Казан арты Кече Солабаш авылында туа. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. 1915 елда Уфада реальный училищены тәмамлый. Аннан Казанга килеп, юридическийга керергә тырыша[3]. Революциядән соң Солтанәхмәт татар халкының беренче һәм танылган композиторы була. Соңгы елларда музыка мәктәбендә укыта. 1937 елда кулга алынып, шәхес культы корбаны була.

[1] Көнчыгыш хезмәт ияләренең коммунистик университеты.

[2] Татар энциклопедиясе: 1891–1942 еллар.

[3] 1915–1917 елларда Казан университетының юридик факультетында укый.

**218. ГАБӘШИ Хәсәнгата Мөхәммәт улы** (1863–1930[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Х. Г. Габәши, Хәсәнгата Г.

Казан арты Кече Солабаш авылында укый. Күп еллар Уфада Дини нәзарәтендә казый булып тора. Төрле аң-белем тарату җәмгыятьләрендә актив эшли. Берничә тарих китапларының авторы. Музыка-җырның шәригать тарафыннан дөреслеге турында фәтва яза. Иске муллалар аңар каршы зур тавыш куптаралар. 1. «Мөфассал тарихе гомуми», 2. «Мохтасар кауме төрки», 3. «Земствода мөселманнар», 4. «Төрек ырулары», 5. «Чахотка», 6. «Мәктәп балалары өчен мөнәҗәтләр җыентыгы» исемле әсәрләр яза.

**219. ГАДЕЛЕВ.**

***Тәхәллүсе:*** «Гаделев».

Муравьев-Апостол идеясе белән таныш прапорщик, декабрист. Җәзага тартыла.

**220. ГАДЕЛЕВ Шаһморат.**

***Тәхәллүсе:*** Гадел.

Бөгелмә өязе Тымытык авылының мулласы һәм укытучысы. [...]

**221. ГАДЕЛЕВ Лотфулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Лотфи Гадел (*революциядән соң*).

Уфада яшәүче язучы, журналист. 1894 елда туган. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укыта. Татарның беренче дипломаты Кәрим Хәкимов турында китап язып бастырган язучы. Хәкимов сеңлесе Мәгъниянең тормыш иптәше.

**222. ГАЗИЗЗАДӘ Ләзиз.**

***Тәхәллүсләре:*** Газиззадә, Татлы.

Үзбәкнең карт язучыларыннан. Ташкентта укытучы һәм гыйльми эшләр алып баручы.

**223. ГАЗИЗОВ Габдулла Кәлимулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Газиз, Г. Сакмари, С. Г., Г. Газиз Сакмари.

Оренбург янында Саракташ авылында туа. Мисырга китеп, Бәйрутта американ көллиясен бетереп кайткач, Троицк шәһәрендә миллионер Яушевлар кызына өйләнә. Яушевлар мәдрәсәсендә

[1] Татар энциклопедиясе: 1863–1933 еллар.

укытучы була. Революциягә чаклы татарның вакытлы матбугатында актив языша. Революциядән соң аклар белән китеп, Харбин шәһәрендә «Мең ел» дигән бер көнлек газета чыгаруда катнаша. Журналист. Ш. Бабич аңар телеграмма язып, болай характерлый:

Хәлфә Габдулла Газиз – ул бергә – алтын, меңгә – җиз,
Шунда да алтын аталганнар Газиздән күп гаҗиз.

**224. ГАЗИЗОВ Лотфулла Кәлимулла улы.**

***Тәхәллүсе:*** Газизов Лотфулла.

Оренбург янындагы Саракташ авылында туа. Г. Сакмариның абыйсы. Учительская семинария тәмамлагач, Троицк шәһәрендә татарлар өчен ачылган 2 класслы рус-татар мәктәбенең директоры булып күп еллар эшли. Гаять көчле педагог. Белемле, талантлы укытучы. Шәһәрдәге иҗтимагый эшләргә актив катнаша. Бик тырыш, гадел, тугрылыклы мәгърифәтче. Туберкулездан үлә.

**225. ГАЙНУЛЛИН Мөхәммәд Хәйрулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Мөхәммәт Гайнуллин, М. Гайнуллин.

1903 елның 13 августында Татарстанның Апас районы Кызыл Тау авылында туа. 1925–1931 елларда Казанда Шәрык педагогия институтында студент һәм аспирант. 1931–1947 елларда Казан дәүләт педагогика институтында өлкән укытучы. 1947–1950 елларда Казан университетының тел, әдәбият кафедрасы доценты. 1944–1955 елларда Фәннәр академиясе филиалының Тел, тарих, әдәбият институтының директоры. Коммунистлар партиясенең әгъзасы. 40–50 ләп фәнни хезмәтләре бар. Гыйльми кадрлар җитештерүгә зур әһәмият бирүче профессор.

**226. ГАЙНЕТДИНОВ Мәсгуть Вәлиәхмәт улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Мәсгуть Гайнетдинов, М. Гайнетдин.

1920 елда[1] Ульяновск өлкәсендә Яңа Малыклы районы Лабит авылында туа. СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторында эшли.

[1] Татар энциклопедиясе: 1929 ел.

**227. ГАЙНУЛЛИН Мидхәт Фазулла улы.**

***Тәхәллүсе:*** М. Гайнуллин.

1925 елның 13 ноябрендә Башкортстанның Бүздәк районы Кече Үстүбә авылында туа. Башкорт язучысы, тел галиме. Дәүләт университетында җитәкче. Башкорт, рус телләрендә дәреслекләр һәм фәнни әсәрләр авторы.

**228. ГАЙНАН Кадыйри.**

***Тәхәллүсе:*** Кадыйр Гайнан.

Татар язучысы, шагыйрь. 1925 елларда «Үсәбез» әсәрен язган шагыйрь.

**229. ГАЙНАН Садретдин.**

***Тәхәллүсләре:*** С. Гайни, Садретдин Айни.

Бохаралы. Таҗик шагыйре һәм әдибе. Революциягә чаклы Бохарада мәгърифәтчелек нигезен таратуда гаепләнеп, Бохара әмире Әлихан тарафыннан 65 камчы суктырылган инкыйлабчы. Урта Азиядә классик хисапланган әдип. Күп телләргә тәрҗемә ителгән кеше.

**230. ГАЙСИН Нурулла Әхъяр улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Нур Гайсин, Н. Гайсин.

1914 елның 2 ноябрендә Башкортстанның Чакмагыш районы Әхмәт авылында батрак гаиләсендә туа. Кече яшьтән үк ятим калып, кеше тәрбиясендә үсә. 1933 елда Казанга килә. Анда педагогика институтын тәмамлагач, урта мәктәптә тел, әдәбият укыта. Нур Гайсин 1934 елда яза башлый, 1937 елда «Ватаным өчен», «Яшьлек таңы», «Зәңгәр күктә», «Түтәлләр» исемле шигырь китаплары басылып чыга. Ватан сугышында зенитчик булып хезмәт итә. Солдаттан кайткач, «Безнең мәктәп», «Минем әнием», «Безнең дуслар» һәм башка лирик һәм юмористик шигырьләр җыентыгы басылып чыга.

**231. ГАЙФИ Сәхи.**

***Тәхәллүсләре:*** Гайфи Сәхи, С. Гайфи.

1917 елда Оренбургта «Безнең теләк» газетасын чыгара.

**232. ГАЛЛӘМОВ Насыйр.**

***Тәхәллүсе:*** Батыр.

Үзбәк язучысы, балалар өчен яза.

**233. ГАЛИ.**

***Тәхәллүсе:*** Гали.

XII йөзнең азагы – XIII йөз башы. Болгар чорында «Йосыф вә Зөләйха» поэмасы авторы.

**234. ГАЛИ РӘХИМ** (1892–1938)[1].

***Тәхәллүсләре:*** Г. Рәхим, Гали Рәхим, Р. Гали, Р. Габдрахманов, Мөхәммәдгали Рәхим, Гөлгыйзар, Бикчәнтәй улы, Г. Р.

Габдрахманов Мөхәммәтгали Шакир улы. Казан өязе Мәңгәр авылында туа (анасы Гайшә Исхак кызы Айтуганова). Казанга килеп, русча һәм татарча белем алгач, вакытлы матбугатта актив языша башлый. Татар халкының талантлы әдибе, танылган тәнкыйтьчесе, әдәбият тарихчысы булып әверелә. Аның язганнары арасында: «Татар әдәбияты тарихы», «Идел», «Гыйшык», «Миләүшәләр арасында», «Әбүсәгыйть», «Сабирҗан хәзрәт», «Баллада», «Тынлык», «Шәрык шагыйрьләре» җыентыгы һ.б. күп кенә әсәрләр.

**235. ГАЛИЕВ Габдулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Перс, Галиев Габдулла.

Чистай шәһәрендә Бадамшин дигән байларда приказчик булып эшләгән кеше. [...]

**236. ГАЛИЕВ Гариф Закир улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гариф Галиев, Г. Гали.

1903 елның 10 маенда Азнакай районы Урманай авылында туа. 1928–1941 елларда Бөгелмәдә чыккан «Сабанчы» газетасында, Казанда «Колхоз» газетасында, «Колхоз бригадасы» журналларында эшли. Партия әгъзасы. 22 ләп китабы чыккан.

**237. ГАЛИЕВ Гомәр Билал улы** (1900–1954).

***Тәхәллүсләре:*** Гомәр Гали, Г. Гали, Гали Гомәр, Г. Гомәр, Рәмог.

Татарстанның Буденный районы Иске Тинчәле авылында туа. Көчле журналист. Зур эрудицияле әдип, гадел, үткен каләмле тәнкыйтьче. Беренче герман сугышында катнаша. 1925–1927 елларда «Безнең юл» журналында редактор һәм нәшриятта баш редактор. 1929–1934 елларда Казан дәүләт медицина институтында татар

[1] Дөресе: 1892–1943 еллар.

теле филологиясе доценты. Шәхес культы корбаны. Язган гыйльми, фәнни әсәрләре бар...

[...][1]

**266. ...**

Шул көннән башлап, ул гомер буе шигырьләр яза, Бөек Октябрь революциясен ялкынлы революцион шигырьләр белән каршы ала. Шигырьдән башка аның «Кара йөзләр» драмасы, «Кызыл йолдыз» комедиясе бар. Мәҗит Гафури Совет иленең патриоты, Совет халкының яраткан шагыйре буларак, «Халык шагыйре» исемен яулап алды. Мәҗит Гафури алтын приискасында эшчеләрне җәфалауларын фаш итеп язып чыккач, прииск хуҗасы шагыйрь Закир Рәмиев (Дәрдемәнд), ачуына чыдый алмый, Мәҗит Гафури турында болай яза:

Мөгезе бар куйның, бары кучкар түгел,
Очар кошның барысы да шоңкар түгел,
Кемнәр әйтмәс шигырьне, әйтер берүк
Чукаңлаган аксак ишәк тулпар түгел.

Шагыйрь Шаехзадә Бабич Мәҗит Гафури турында болай дип яза:

Ул Гафури язмаса, тормыш юлында изеләчәк,
Акрын-акрын аксый торса, алгы сафка тезеләчәк.

**267. ГАФУРОВ Голәм.**

***Тәхәллүсләре:*** Гафур Голәм, Голәм, Уртай, Шалпанколак, Күсә, Илгәр, Күсә ирсакал.

Үзбәкстанның классик шагыйре. Күп телләргә тәрҗемә ителгән шагыйрь. Язган әсәрләре күп.

**268. ГАФУРОВ Голәмназар.**

***Тәхәллүсе:*** Найза.

Ташкентта үзбәк шагыйре.

**269. ГАФУРОВА Гөлчәһрә Заһир кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Гөлчәһрә, Гөлчәһрә Гафурова.

1901 елда Татарстанның Апас районы Бортас авылында туа. Вакытлы матбугатта актив катнашып, хатын-кызлар хөрлеге өчен көрәштә күп көч куйган ханым.

[1] Кульъязмада 238 дән 265 нче номерга кадәрге шәхесләр турындагы мәгълүматлар сакланмаган.

**270. ГАФУРОВ Сибгат.**

***Тәхәллүсләре:*** Сибгат Гафуров, С. Гафуров.

Баку эшчесе. Октябрь революциясенә чаклы ук коммунист большевиклар сафына кергән кеше. Казанда җаваплы эшләр башкара, 1937 елда кулга алынганчы, Татарстан өлкә партия контроль комиссиясендә әгъза булып тора.

**271. ГАФУРОВ Галиәсгарь Могыйнетдин углы.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Гафуров, Галиәсгарь Гафури, Чыгтай, Г. Ч.

Бозаулык шәһәрендә мулла булып торган вакытында 1910 елда ислам диненең хаталарын фаш итеп, «Исабәт» исемле китап язган кеше. Аңар каршы динчеләр, кадимчеләр бик зур шау-шу куптаралар. Патша хөкүмәтенә һәм Диния нәзарәтенә гаризалар язып, Чыгтайны тәүбә итәргә мәҗбүр итәләр. Указын алып, муллалыктан төшерәләр. Чыгтай фанатизмының бик көчле чагында хаклыкны турыдан-туры әйтергә батырчылык итсә дә, үз карашында нык тормый, икеләнә. Шуңа күрә 1921 елда яңадан мулла була. 1923–1924 елларда дингә каршы ачык көрәш башлагач, муллалыгын ташлап, дәһригә әйләнә һәм 1925 елда Мәскәүдә «Фән һәм дин» исемле журнал чыгара башлый. Аның «Ачлык корбаннары» исемле 3 пәрдәлек пьесасы һәм «Им-том» дигән 2 пәрдәлек пьесасы басыла. Болардан башка «Фатыйма вә аның тәкәммеле», «Су ташыганда» дип аталган әсәрләре бар. «Әлгасрелҗәдид»тә «Тутам» әсәре басыла. Г. Тукайның «Указ бәласе» шигыре Чыгтайга төбәлгән.

**272. ГАФУРОВ Ибраһим Нури улы** (1910–1972).

***Тәхәллүсе:*** Ибраһим Гафури.

Казанда туа. 1934 елда татар театры техникумын тәмамлаганнан соң, артист булып китә. 1937 елдан Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты. Ул гаять сәләтле актер булып санала.

**273. ГАЯЗОВ Мансур Гаяз улы** (1917–1943).

***Тәхәллүсләре:*** Гаязов Мансур, М. Гаяз.

Мари республикасы Бәрәңге районы Бәрәңге авылында туа. Педагогия мәктәбен бетергәч, үз авылында укытучы. Беренче шигырьләре «Совет әдәбияты», «Пионер каләме» журналларында басыла, Ватан сугышында алдынгы сызыкта була. Фронтта Коммунистлар партиясе сафына керә, шул сугышта батырларча һәлак була.

**274. ГАУНИ – Шәһит Рәҗәпов.**

***Тәхәллүсе:*** Ш. Гауни.

Саратов губернасы Кузнецк өязе Колчура авылында туа. Вакытлы матбугатта язышa. Календарьлар чыгара. «Фәнни тәҗвид» китабын яза. Тукай шуңа ишарә итеп шигырьләр иҗат итә.

**275. ГАБИДУЛЛИН Кашшафетдин Шаһимәрдан улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Кашшафетдин Каркаралы, К. Габидуллин Минзәләви, Минзәләви, әл-Каркаралы.

Минзәләдән китеп, Каркаралыда мулла булган кеше. Шиһаб Мәрҗани шәкерте. 1897 елда «Кыйссаи-Бәдәр» исемле китап язып бастыра.

**276. ГАБИДУЛЛИН Мөхәммәди Габидулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Мөхәммәди Габидуллин.

1905 елда туа. Башкорт язучысы. Шәриф Манатов турында әсәр язучы.

**277. ГИЗЛӘВИ И.С.**

***Тәхәллүсе:*** Гизләви И.С.

«Күз яшьләре» исемле әсәр язган кеше.

**278. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН Ибраһим Гыйззәтулла улы.**

***Тәхәллүсе:*** И. Гыйззәтуллин.

1918 елның 15 октябрендә Башкортстанның Ишембай районы Түбән Әрмит авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1935–1939 елларда Стәрлетамак педагогия мәктәбен тәмамлый. 1941 елда Казан университетына барырга торганда сугышка алып китәләр. Анда яраланып, эшкә яраксыз инвалид булып кала. 1944 елда хәбәрче буларак яза башлый. Аннан соң очерк һәм хикәяләре дөнья күрә. 1960 елда «Яңадан сафта» китабы басыла. Моннан башка «Тормыш матурлыгы», «Юлга чыкканда» дигән әсәрләр авторы.

**279. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН Илдус Габделхәй улы.**

***Тәхәллүсләре:*** И. Гыйззәтуллин, Илдус Гыйззәтуллин.

1935 елда Татарстанның Актаныш районы Әҗәкүл авылында туа. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында (Тел, әдәбият һәм тарих институтында) аспирант була. Диссертация темасы: «Үзәк мөселман хәрби коллегиясе (1918–1920 еллар)».

**280. ГЫЙЛЬФАНОВ Ибраһим Гыйльфан улы** (1905–1969).

***Тәхәллүсләре:*** Дәһри Ибрай, Ибраһим Гыйльфанов, Балканлы.

Уралда Балкан приискасында туа. Урта мәктәп бетергәч, төрле курсларда укый. Редакцияләрдә эшли, обком хозурындагы белем оешмасының гыйльми әгъзасы, дәһриләр секторы башлыгы була. Нәшриятта редактор. «Ислам дине» әсәренең авторы.

**281. ГЫЙЛЬМАНОВ Ләбиб Гыйльман улы** (1906–1938).

***Тәхәллүсе:*** Ялкавайлы.

Башкортстанда Ялкау иле авылында туа[1]. Революциягә кадәр вакытлы матбугатта катнаша. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укып, зуррак белем алыр өчен, Төркиягә, Истанбул гали мәктәп йортына китә. Ш. Бабич аны болай тасвирлый:

> Ул Ләбиб – кызгылт егет, лап-лоп басып гайрәтләнеп,
> Әй, йөри торгандыр инде фәс киеп дуракланып.

**282. ГЫЙЛӘҖЕВ Локманхәким Габдрахман улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Локман Хәким, Локман Гыйләҗев.

1923 елның 1 мартында Башкортстанның Бүздәк районы Каңлы Төркәй авылында туа. 1945–1949 елларда Башкортстан педагогия институтында укый. Танылган әдип һәм тәнкыйтьче. 1968 елдан Язучылар союзы башлыгы.

**283. ГЫЙМРАНОВ Зәки Закир улы** (1898–1938).

***Тәхәллүсе:*** Зәки Гыймранов.

Татарстанда Алабуга районы Бәзәкә авылында туа. Урта мәктәп бетергәч, педагогия курсларында укып, җаваплы эшләр башкара башлый. Казанга киткәч, обкомда агитпропаганда башлыгы булып эшли. Вакытлы матбугатта язышa. 1937 елда кулга алынып юкка чыга.

**284. ГЫЙНИЯТОВ Хәмит Шәрәфи улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Хәмит Шәрәф, Гыйниятов Х.

Үзбәкстанның өлкән язучыларыннан, танылган галим. «Олуг Октябрь революциясенең Үзбәкстанда галәбә кылышы[2]» дигән тарихи әсәр язып ятучы галим.

---

[1] Дөресе: Татарстанның Әлмәт районы Иске Баграҗ авылында (хәзерге исеме – Елхово) туа.

[2] Галәбә кылышы – җиңүе.

**285. ГОБӘЙДУЛЛИН Газиз Сәлих улы** (1887–1938[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Г. Газиз, Г. Г., Г. Сәлман, Әбү Сәлман, Габделгазиз, Газиз Салих улы, Г. Салих улы*, Г. Гобәйдуллин*.

Казанда бай сәүдәгәр гаиләсендә туа. Казанда мәдрәсә тәмамлагач, учитель Гафур Коләхмәтовтан өлгергәнлек таныклыгына әзерләнә. 1916 елда Казан университетының тарих, филология факультетын тәмамлый. Революциягә чаклы «Аң», «Сөембикә», «Шура» журналларында язышa. Революциядән соң «Мәгариф» журналында һәм шул чордагы матбугатта бик актив катнаша. Казанда Гыйльми үзәктә эшли һәм укыта. Бик эшлекле галим, талантлы язучы, күренекле әдип, әдәбият тарихчысы исемен алган профессор.

Революциягә кадәр демократик язучылар Гафур Коләхмәтов, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Габдулла Тукайлар белән якын дуслык мөнәсәбәтендә тора. Габдулла Гыйсмәти әйтүенчә, Г. Тукайны кымызга җибәрүдә матди ярдәм бирүче дә ул булган. Профессор Газиз Гобәйдуллин һәрвакыт шат күңелле, юморга бай, көләргә оста, мәҗлесе күңелле кеше. Ул күп әдәби мирас калдыра. «Татар әдәбияты тарихы», «Тарихе әдъян», «Сәгать», «Милләтчелекнең бәгъзе әсаслары», «Олуг кешеләр һәм аларның эшләре» (Нәҗип Хәлфин белән бергә), «Г. Газиз хикәяләре» исемле хикәяләр җыентыкларының авторы. 1920 елларда Казанда кулга алынып, төрмәдә хурлыклар күргәч һәм иреккә чыккач та, Казанда кала алмый. Бакуга китеп, 1937 елгы шәхес культы шаукымына кадәр Баку университетында профессор була.

**286. ГОБӘЙДИ – Давыт бине Гобәйдуллин әл-Кыдырлы** (1873–1919).

***Тәхәллүсләре:*** Г. Д, Г. Гобәйди әл-Кыдырлы, Г. Гобәйди.

Татарстанда Кыдырлы авылында туа. 1907 елда А.В. Вишневскийдан тәрҗемә итеп, «Хифзыссыйхәт»не бастыра. Моннан башка Г. Д. имзалары белән [язылган] «Шүрәле каргаган авыл», «Башкорт кызы Маһинур», «Ике мәхәббәт», «Авыл кызы», «Төлкенең яңа хәйләсе» әсәрләре дә әл-Кыдырлыныкы булырга кирәк.

**287. ГОБӘЙДУЛЛИН Әзһәр.**

***Тәхәллүсе:*** Әзһәр Гобәйди.

Үзбәк язучысы.

[1] Татар энциклопедиясе: 1887–1937 еллар.

**288. ГОБӘЙДУЛЛИН Гариф Шакир улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гариф Гобәй, Г. Гобәй.

1907 елның 26 августында Казанда Бишбалта бистәсендә эшче гаиләсендә туа. 1927–1930 елларда Татарстан рабфагында белем ала. 1932 елларда Казан дәүләт педагогия институтында укый. Аны бетергәч, 1940 елга чаклы Татглавлитта, 1941 елдан 1946 елга кадәр Татарстан радиокомитетында эшли. 1950–1952 елларда Татарстан Язучылар союзы рәисе була. Партияле. Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләнә. 20 дән артык китабы чыга. Русчага тәрҗемә ителеп, чит халыклар арасында да танылган әдип. Соңгы елларда дөнья шаулаткан китабы – «Коръән серләре».

**289. ГОМӘРОВ Габдулла Закир улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Гомәров, А. Гомәров.

1906 елның 15 июнендә Оренбург шәһәрендә туа. 1925 елда Казанга килеп, югары мәктәпләргә әзерли торган курсларда укый. Аны бетергәч, Казан университетының физика-математика факультетына керә. 1928 елдан ул «Яңалиф» журналында, «Совет әдәбияты» журналы һәм нәшрият редакциясендә эшли башлый. Коммунистлар партиясе әгъзасы. Тәрҗемәчеләр секциясендә җитәкче. Байтак вакыт «Совет әдәбияты» журналында редактор була.

**290. ГОМӘРЕВ Габдрахман.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Гомәрев, Габдрахман Гомәрев.

1907 елда Әстерханда «Идел» исемле газета чыгара.

**291. ГОМӘРЕВ Латыйф Габдрахман улы**

***Тәхәллүсләре:*** Л. Гомәрев, Латыйф Гомәрев, Аяз.

1895 елның 20 февралендә Татарстанның Саба районы Арташ авылында туа. Сатыш мәдрәсәсен тәмамлагач, Мамадышта укытучылар курсында укый. Революциядән соң Мәскәүдә Коммунистик университетта. Татарстанда обкомның матбугат бүлегендә эшли. 1937 елда кулга алалар. Котылып кайткач, пенсиягә чыга. 1927 елда «Үлек тә түгел, терек тә түгел» дигән фантастик хикәя бастыра.

**292. ГОМӘРЗАДӘ Хәбибулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Х. Г., Хәбибулла Гомәрзадә, Х. Гомәрзадә.

1906 елда Әстерханда «Туп» дигән журнал чыгара. Ул редактор, нашире – Корбангали Илембетов. Гомәрзадә 1917 елда Әстерханда «Азат халык» газетасы чыгара.

**293. ГОМӘРЕВ Ибраһим.**

***Тәхәллүсе:*** Ибраһим Гомәрев.

1896 елның 5 апрелендә Мордва республикасында Кече Салмовка авылында крестьян гаиләсендә туа. 1919–1936 һәм 1941–1947 елларда Әстерхан театрында эшли. 1957 елда Казанда Татарстанның атказанган артисты исеме бирелә. Әлмәттә яши.

**294. ГОМӘРЕВ Әхмәт.**

***Тәхәллүсләре:*** Әхмәт Гомәрев, Ә. Гомәрев, Ә. Г.

1894 елда Әстерханда туа. 1918 елда партия сафына керә. 1919 елда Мәскәүдә «Шәрык халыклары коммунистларының икенче съезды»нда делегат булып катнаша. Яхшы белемле журналист. Вакытлы матбугатта «марксизм» темасына күп мәкаләләр, «Көннәр көнендә» исемле 4 пәрдәлек пьеса яза.

**295. ГОСМАНОВ Хатип Госман улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Х. Усманов, Госманов Хатип, Сулмаш.

1908 елның 21 маенда Пермь өлкәсе Чернушка районы Сулмаш авылында туа. Үз авылында татар мәктәбе, күрше авылда рус башлангыч мәктәпләрен бетерә. Казанга килеп, 1939 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый, шуннан соң төрле редакцияләрдә эшли. Алабугада педагогия мәктәбендә һәм Казан педагогия институтында укыта. 194..[1]–1946 елларда Бөек Ватан сугышы фронтында фашистларга каршы сугыша. 1951 елда ул галимлек дәрәҗәсенә, аннан соң докторлыкка диссертация яклап, профессор була.

**296. ГОСМАНОВ Шамил Хәйрулла улы** (1898–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Шамил Госманов, Ш. Усманов, Тарикъ, Батырша, Рәисә, Исрафил.

1898 елның 26 декабрендә Самара өлкәсе Пәндәлкә авылында туа. 1918 елдан партия әгъзасы. Татарстанда обком һәм хөкүмәт әгъзалары булган җаваплы эшче, көчле журналист. Талантлы, ялкынлы язучы, совет чорында революциянең башлангыч елларында

[1] Чыганакта язылып бетмәгән.

булган вакыйгаларны, Гражданнар сугышын, Кызыл армияне оештыру эшләрен, татар хезмәт ияләре арасында революцион большевиклык хәрәкәте ничек таралуларны беренче буларак матур сурәтләүче рәссам. Ул – хәрәкәтчән, һәр эшкә, һәр яңалыкка башлап тотынучы зур оештыручы.

**297. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА Сәхибҗамал Күлекче Гыйззәтулла кызы –** Хәмидуллина-Волжская.

***Тәхәллүсләре:*** Сахибҗамал Гыйззәтуллина, Волжская Русина.

1892 елның 26 маенда Казанда туа. Татар кызларыннан беренче буларак татар театры оештыручыларыннан һәм «Сәйяр» труппасы оештыручыларыннан берсе. Татар театрының анасы.

**298. ГЫЙЗЗӘТОВ Таҗи Кәлимулла улы** (1895–1955).

***Тәхәллүсләре:*** Таҗи Гыйззәт, Т. Гыйззәт.

1895 елның 15 октябрендә Татарстанда Красный Бор районы Барҗы Умга авылында туа. Башлангыч белемне авыл мәктәбендә ала. 1912 елдан 1918 елга кадәр Ижевск заводында эшли. Казанга килгәч, Кәрим Тинчурин, Зәйни Солтаннар ярдәмендә яхшы артист һәм драматург булып китә. Иҗат иткән рольләре, язган драма әсәрләре бик күп һәм тамашачылар тарафыннан яратып каралалар. 37 пьеса яза, русчага да байтагы тәрҗемә ителә.

**299. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН Төхфәтулла Гыйззәт улы** (1893–1959).

***Тәхәллүсләре:*** Ченәкәй, Төхфәт Ченәкәй, Сәмави, Күрәзә, Авылчы, Якәнч, Кечкенәкәй, Бәләкәй, Кечкентәй, Т. Гыйззәт*.

Танылган татар шагыйре, юморист, тапкыр сатирик. Революциягә кадәр һәм революциядән соң газета-журналларда актив языша. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укып, Галимҗан Ибраһимов һәм Шәехзадә Бабичлар белән якын дуслык мөнәсәбәтендә була. Язып бастырган нәрсәләре күп.

**300. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН Фәтхелбәян Нурлыгаян улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Бәян Гыйззәт, Г. Бәян, Б. Гыйззәт, Б. Г.

1918 елның 29 июлендә Башкортстанда Кушнаренко районы Талбазы авылында крестьян гаиләсендә туа. 1934–1936 елларда Уфада медицина рабфагында укый. Комсомолга керә. 1937–1940 елларда Казанда педагогия институтының тарих, тел, әдәбият факультетын

тәмамлый. 1941 елны армиягә алынып, Ватан сугышында илне фашистлардан коткаруга булыша, партия сафына керә. Сугыштан кайткач, Казанда 1946–1950 елларда Татар академия театрының әдәбият бүлеге башлыгы була. 1953 елдан Тарих, тел, әдәбият институтында[1] өлкән гыйльми хезмәткәр булып эшли. Иҗтимагый эшләрдә дә актив катнаша. Фәннәр кандидаты.

**301. ГЫЙРФАНОВ Габдулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Г., Гыйрфанов Г., Г. Г.

1912–1914 елларда Троицк шәһәрендә «Акмулла» журналында, Оренбургта «Шура» журналында языша.

**302. ГЫЙРФАН ахун Рәхманкулов.**

***Тәхәллүсе:*** Гыйрфан ахун.

Революциягә кадәр Екатеринбург (Свердловск) шәһәрендә мулла һәм ахун. «Шура», «Дин вә мәгыйшәт» журналларында языша. Бабич аның турында:

> Гыйрфан абзый бер шәһәрдә гыйрфаны юк бер ахун.
> Анда истибдад[2] – хәзинә, анда гайбәт ун вагон.

**303. ГЫЙСМӘТУЛИН Габдулла Төхфәтулла улы** (1883–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Г. Гыйсмәти, Гыйсмәти, Габдулла Гыйсмәти, Гыйсмәтуллин Г.

Казакъстанда Кустанай шәһәрендә туа. Атасы – Каргалы башкорты, анасы – казакъ. Яшьтән анасы үлеп, үги ана кулында үсә. 12 яшенә чаклы Кустанайда укый. Соңра Троицк шәһәренә килеп, Яушевлар мәдрәсәсендә укый. 1907 елда Казанга килеп, Тукай, Коләхмәтов вә башка демократик яшьләр белән аралаша. Соңра Петербургка китеп, психо-неврология институтының юридик бүлегенә керә. Дәүләт думасы мөселман фракциясендәге сул канаттагы депутатлар белән аралаша, Финляндия яшьләре арасында демократик фикер тарату эшен алып бара, андагы татарлар арасында культура-агарту эшләрен оештыра. 1916 елга чаклы Габдулла институтта укый. Тимерьюл идарәсендә эшли. Февраль революциясеннән соң рабочийлар район съездына, Петербург шәһәре съездына делегат итеп сайлана. Октябрь революциясеннән соң Петроградта

[1] Хәзер ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты.

[2] Истибдад – деспотизм.

мөселманнар комиссариатында эшли. 1920 елда Коммунистлар партиясе сафына керә. Соңра Уфага килеп, 1924–1925 елларда Госплан [оешмасы] рәис[е] урынбасары, 1926–1928 елларда халык мәгариф комиссары, аннан соң халык хуҗалык киңәшенең рәисе була һәм 1937 елгы шәхес культы касавәтенә[1] чаклы шунда эшли.

**304. ГЫЙМАДИЕВ Минһаҗ** (1903–1970).

***Тәхәллүсләре:*** Гыймадиев М., Минһаҗ Гыймадиев.

1903 елның 27 октябрендә Татарстанның Саба районы Оет авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Үз авылында берничә ел укыганнан соң, бәхет эзләп, Урал, Себер якларына чыгып китә, анда эшче булып йөри. Җәмәгать эшләренә актив катнаша. 1927 елда Коммунистлар партиясе сафына керә. Партия җибәрүе буенча Казанга килеп, Коммунистлар университетын тәмамлый. Журналист булып китә. Нәшрияттта редактор, Ватан сугышы вакытында фронт газеталарында редактор була. Өлкән журналист, җәмәгать эшлеклесе, подполковник Минһаҗ 1970 елда үлә.

**305. ГЫЙЛЬМУШИН Галәветдин.**

***Тәхәллүсләре:*** Гыг, Г. Г., Гыйлмуҗ.

Чистай шәһәрендә ахун булган кеше. Революциягә чаклы вакытлы матбугатта «Йолдыз», «Кояш» газеталарында актив язышa.

**306. ГЫЙРФАНОВ Галәветдин.**

***Тәхәллүсе:*** Галәветдин Гыйрфанов.

1915 елда «Хәят вә сәгадәт» дигән китап бастыра. «Шура»да язышa.

**307. ГЫЙРФАНОВ Касыйм Гыйрфан улы.**

***Тәхәллүсләре:*** К. Гыйрфанов, Гыйрк, Квилд, Камил.

1891 елның мартында Татарстанның Чирмешән районы Иске Үтәмеш авылында туа. Авыл мәдрәсәсен тәмамлагач, Чистай мәдрәсәсендә укый. 1912–1913 елларда шул мәктәптә укытучы була. Аннан соң Уфага килеп, «Галия» мәдрәсәсендә укый. 1916 елдан башлап 1922 елга кадәр Чиләбе шәһәрендә укыта. Казанда Татревкомда эшли. Аннан Мәскәүгә китеп, аспирантураны тәмамлый. 1925–1926 елларда Уфага эшкә кайта. 1937 елгы шәхес культы шау-

[1] Касавәтенә – рәхимсезлегенә.

кымы белән партиядән чыгартыла. Урта Азиягә китеп, анда укыта. Шуннан Уфа[га] кайтып, гомер буе укытучы була. Вакытлы матбугатта фәнни мәкаләләр белән актив языша. Язган әсәрләре бар.

**308. ДАВИДОВ Мирза.**

***Тәхәллүсләре:*** Мирза Давидов, М. Давидов.

1895 елда Самарада туа. 1918 елда Самарада «Яңа көч» газетасы чыгара, 1919 елда Самарада «Кызыл Идел» газетасының редакторы, 1921 елда Харьков шәһәрендә «Тау эшчесе» газетасы редакторы була. Татарстанда төрле редакцияләрдә эшли, революциягә кадәр дә язгалый.

**309. ДАЛИМОВ Усманбик.**

***Тәхәллүсе:*** Субукай.

Үзбәк язучысы.

**310. ДАСАЕВ Исхак** (1907–1958).

***Тәхәллүсе:*** Дасаев И.

1907 елда Әстерхан шәһәрендә эшче гаиләсендә туа. 1930–1936 елларда Әстерханда, 1936–1941 елларда Мамадыш театрында, 1944–1948 елларда Минзәлә һәм Буа театрларында директор була. 1948 елда Әстерханга кайта, эшли һәм 1958 елда шунда үлә.

**311. ДАСАЕВА – (Садрина) Сылухан.**

***Тәхәллүсе:*** Сылухан Дасаева.

1910 елда Әстерханда туа. 1929 елда Казан театр техникумын тәмамлый һәм Мәскәү эшче театрына чакырыла. 1933–1936 елларда Әстерхан, аннан Мамадыш, Минзәлә, Буа театрларында эшли. 1948 елда яңадан Әстерханга кайта. Шунда театрда эшләп пенсиягә чыга.

**312. ДАУТОВА (ӘДҺӘМОВА) Марзия** (1901–1964)[1].

***Тәхәллүсе:*** Марзия Даутова.

Әстерханда сәүдәгәр гаиләсендә туа. Шунда кызлар мәктәбендә белем ала. Балалар укыта. Шул ук вакытта спектакльләрдә дә катнаша. 1920 елда Бакуга чакыртыла, шунда Азәрбайҗан театрын юлга салу өчен бөтен көчен сарыф итә. 1932 елда Бакуда «Хезмәт батыры», 1936 елда Әстерханда «Халык артисткасы» исемен яулый.

[1] Татар энциклопедиясе: 1901–1962 еллар.

1948 елда Сталин премиясенә лаек була. Күп еллар Азәрбайҗан Югары Советы әгъзасы була. 1964 елда Бакуда үлә.

**313. ДАШКИН Әбүбәкер.**

***Тәхәллүсе:*** Әбүбәкер Дашкин.

Революциягә кадәр язучы булган журналист. 1905 елда Әстерханда «Ислам» журналының нашире һәм редакторы.

**314. ДОМОЛАЗОВ Степан Василий улы** (1885–1937).

***Тәхәллүсе:*** Домолазов Степан.

Керәшен татары. Мамадыш өязе Албай[1] авылында туа. 1918 елда Мамадыш өязе хәрби комиссариатында военрук. Коммунистлар отрядының командиры булып китеп, Колчакны тар-мар итүдә күрсәткән батырлыклары өчен полковник дәрәҗәсенә менә, Казанга кайткач, республика хәрби комиссары булып та тора. 1937 елда юкка чыга. Керәшен матбугатында язгалый.

**315. ДОНСКОЙ Гали** (1894–1957).

***Тәхәллүсе:*** Г. Донской.

Әстерхан шәһәрендә туа, 1921 елга кадәр Әстерхан театрында эшли. Аннан соң эстрада артисты булып китә. 1967 елда Түбән Тагил шәһәрендә үлә.

**316. ДИБЕРДЕЕВ Мөхәммәтйосыф Мөхәммәтәмин улы.**

***Тәхәллүсе:*** Йосыф Дибердеев.

Милләтне кайгырту турында күп сөйләнеп, мәктәп, мәгариф эшләренә бер тиен дә ярдәм итми торган шапырынчак саран бай. Ш. Бабич аның турында:

> Әй, Йосыф бай! Тел беләν милләт «дөбердәт», абзыкай!
> Буш калайның өстенә яңгыр шыбырдат, абзыкай! –

дип, матур характеристика бирә.

**317. ДИМ Баязит** (1909–1945**).**

***Тәхәллүсләре:*** Баязит Дим, Дим Баязит.

Баязит Фәхрелислам улы Баянов Башкортстанның Дәүләкән районы Иске Аюхан авылында крестьян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне үз авыл мәктәбендә ала. Аннан соң комсомолга кереп,

[1] Чыганакта авыл исеме күрсәтелмәгән.

1924 елда Бәләбәй педагогик мәктәбенә керә. Аны 1928 елда бик яхшыга тәмамлап, 1928–1929 елларда газета редакциясендә эшли. 1931 елда партия сафына керә, 1932 елда армиягә алына. Шул көннән башлап ахыр гомеренә кадәр армия хезмәтендә була. 1945 елны үлә. Басылган хикәя җыентыклары бар.

**318. ДИНМӨХӘММӘТОВ Габделхәй Ишмөхәммәт улы** (1891–1922).

***Тәхәллүсләре:*** Габделхәй Динмөхәммәтов, Г. Динмөхәммәтов, Г. Д., Гадел, Сюрприз, Шимали, Фәлән.

Киров өлкәсе Малмыж районы Түнтәр авылында Ишми ишан гаиләсендә туа. Мәшһүр Ишми ишанның малае.

Габделхәй атасының киресенә ачык фикерле, мәгълүматлы, халыкны кайгыртучан, революцион идеяләр белән сугарылган журналист иде. Малмыжда хосусый рәвештә русча укып, рус әдәбияты белән таныш. Үз чорында чыккан «Таң», «Ялт-Йолт», «Шура» журналларына язып тора. Белемле укытучы, демократ фикерле кеше. Революциядән соң Малмыжда «Якын юл», «Мәгариф» журналларында тәгълим-тәрбия турында мәкаләләр яза. Атасы тормышыннан алып язган «Җинаять» әсәре бар.

**319. ДИНМӨХӘММӘТОВ Гаян.**

***Тәхәллүсе:*** Әлмансур.

**320. ДИНМӨХӘММӘТОВ Ишмөхәммәт ишан.**

***Тәхәллүсләре:*** Ишми ишан, Кушмый ишан дип дә йөртәләр, имеш.

Киров өлкәсендә Малмыж өязе Түнтәр авылында ишанлык кылучы мулла. Бөтен яңалыкка каршы, искедән иске, киредән кире. Бөтен яңа фикердә булган кешеләр белән көрәшеп, жандармерияга донос, яңа ысул белән укыта торган мәктәпләрне яптырып йөргән кеше. 1919 елда революция таләбе буенча атып үтерелә. 1912 елда Бубиларга суд ясатып, дөнья шаулата. Шиһаб Мәрҗани өстеннән донос язып йөри. Мәрҗани «русчаны белү кирәк һәм файдалы» дигәч, шуңар каршы гарәпчә китап язып, Диния нәзарәтенә җибәрә.

**321. ДӘҮЛӘТАЛИЕВ Мәхмүт Вахит улы** (1889–1920).

***Тәхәллүсләре:*** Мәхмүт Дәүләтали, Дәүләтали М., М. Д.

Казанда Яңа Бистәдә мәзин гаиләсендә туа. Хөсәен Ямашевның кардәше һәм дусты. Коммунистлар партиясе әгъзасы, 1907 елдан Казанда «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» шәкерте, «Әлислах»та языша. Герман сугышында катнаша. Революциядән соң Мулланур Вахитов белән бергә «Чулпан» газетасында языша. Казанда мөселман бюросын идарә итә. 1919 елда Башкортстан Совнархозында бүлек мөдире була. Казанда вакытта «Сабан туе»н оештыручыларының берсе. 5 нче армиядә чыккан «Сугыш сафы» газетасында редактор. 1920 елда Башкортстанда Баймак авылында баш күтәргән анархист-кулаклар атып үтерә.

**322. ДУЛАТОВ Мирьякуп.**

***Тәхәллүсләре:*** Мирьякуп Д., Дулатов М., Мирьякуп Дулатов.

Танылган казакъ шагыйре. 1920–1921 елларда Оренбургта чыккан «Казакъ» газетасында һәм Ташкентта чыккан «Иңбәкчел казакъ» газетасында җаваплы хезмәткәр булып эшли. Казакъ телендә «Уян, казакъ», «Бәхетсез Җамал» исемле шигырь җыентыклары һәм «Кыйраәт китабы», «Исәп коралы» исемле дәреслекләр авторы, 1929 елда кулга алына. 1934 елда[1] лагерьда Беломор шәһәре янында Сосновец станциясендә грудная жабадан үлеп кала.

**323. ДӘЛИЛ Әсгарь.**

***Тәхәллүсләре:*** Дәлил Әсгарь, Д. Ә., А. Дәл.

Сәяхәтче журналист, Искәндәриядән шактый язды.

**324. ДӘМИН.**

***Тәхәллүсе:*** Дәмин.

Язучы. «Каннар акканда» (1 пәрдәдә), «Авыл серләре» (1 пәрдәдә) исемле пьесалар авторы.

**325. ДӘҮЛӘТОВ Галим Габдулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Дәүләтов, Г.Г. Дәүләт.

1936 елда Башкортстанның Мәләвез районы Сергеева[2] авылында колхозчы гаиләсендә туа. Интернатта укып белем алгач, Тарих, тел, әдәбият факультеты студенты була. Башкортстанның Тел, әдәбият, сәнгать институтында эшли.

[1] Дөресе: 1935 елда.

[2] Дөресе: Сергеевка (Саргай) авылы.

**326. ДӘҮЛӘТШИН Гобәй (Гобәйдула Әхмәтгәрәй улы Дәүләтшин)** (1893–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Дәүләтшин Гобәй, Г. Дәүләтшин.

Самара өлкәсе Ташбулат авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Авыл мәдрәсәсендә белем ала. 1914 елда аны солдатка алалар. Февраль революциясеннән соң 1917 елда Мәскәүдә җыелган беренче мөселманнар съездына делегат булып килә. Шул елны Коммунистлар партиясенә кабул ителә. 1922 елда партия мәркәз комитеты хозурындагы татар-башкорт бюросына әгъза итеп сайлана. Озакламый башкорт обкомы чакыруы буенча Уфага кайта. Башкортстанда төрле җаваплы эшләр башкара. Мәгариф министры була. Ул – күренекле җәмәгать эшлеклесе. Башкорт телендә язган берничә хикәя, повесть җыентыклары бар.

**327. ДӘҮЛӘТШИН Габделгалләм** (1880–1922).

***Тәхәллүсе:*** Галләм Дәүләтшин.

Оренбург мулласы. Әхмәт бай мөтәвәллисе. «Хөсәения» мәдрәсәсенең мөдире.

**328. ДӘҮЛӘТШИН Фәррах** (1887–1955).

***Тәхәллүсе:*** Фәррах Дәүләтшин.

Башкортстанның Бөре кантоны Иске Уртай авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1913–1916 елларда Ак Чишмә кәгазь фабрикасында эшли. Инвалид булып авылга кайткач, бәетләр яза башлый. Революциядән соң аңар киң юл ачыла: аны халык җырчысы, бәетче дип таныйлар һәм бәетләрен бастырып та чыгара башлыйлар. Дүртбиш китабы чыга.

**329. ДӘҮЛӘТШИНА Һәдия Лотфулла кызы** (1905–1954).

***Тәхәллүсе:*** Һәдия Дәүләтшина.

Самара өлкәсе Пугач өязе Хәсән авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1919 елда авылда кызлар мәктәбендә укый. 1921 елда ул Самарадагы (Куйбышев) татар-башкорт педагогия техникумында белем ала. Гобәй Дәүләтшин Мәскәүгә китү аркасында, Һәдия дә Мәскәүгә китә. 1924 елда Уфага кайтып, башкорт педагогия рабфагында укый. 1935–1937 елга кадәр шунда укуны дәвам иттерә. 1937 елда шәхес культы корбаны була. Язган китаплары бар.

**330. ДАВЫДОВ Әнвәр Мортаза улы** (1919–1968).

***Тәхәллүсләре:*** Әнвәр Давыдов, Ә. Давыдов, Ә. Д.

Самара өлкәсе Камышлы авылында туа. 1930 елда Авыл хуҗалыгы техникумында укый, аннан соң колхозларда хисапчы, Себердә журналист, Фирганәдә газета хезмәткәре, аннан соң Мордва республикасында укытучы.

1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышында илне фашистлардан саклый. Аннан Казанга кайтып, 1952 елда нәшриятта редактор, 1953 елда Язучылар союзы секретаре. Шигырь һәм поэма җыентыклары бар. 1912 елдан партияле.

**331. ДАУДОВ Фәезхан.**

***Тәхәллүсе:*** Фәезхан Даудов.

Оренбургта чыккан «Дин вә мәгыйшәт» журналында редактор. Ул элек Оренбургта Хөсәеновлар конторында хезмәт итә. Аннан соң Буби мәктәбенә гарәп теле укытучысы булып китә. [...] Бабич аны болай характерлый:

> «Дин-мәгыйшәт»нең зәвыксыз саесканы Фәезхан Дауд,
> Әүвәле саткан махорка, инде муллалык зәүкъ[1].

**332. ДӘҮЛӘТШИН Нәбиулла Хәсән улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Нәби Дәүли, Н. Дәүли.

1910 елның 1 июнендә Татарстанның Әлки районы Яңа Камка авылында крестьян гаиләсендә туа. 1922 елда Нәбине балалар йортына урнаштыралар. Ул анда һөнәр мәктәбен тәмамлый. 1931–1933 елларда Донбасста «Пролетар» газетасы хәбәрчесе. 1941 елда Ватан сугышына китә. Анда пленга төшә. 1945 елда пленнан котыла. Казанда берничә шигырь һәм поэма җыентыклары басылып чыга. Танылган шагыйрь һәм прозаик.

**333. ДАЯН – Кадыйр Хәким улы Даянов** (1910).

***Тәхәллүсләре:*** Даян Кадыйр, К. Даян.

Чиләбе өлкәсендә Кунашаков[2] районы Кунашаков авылында крестьян гаиләсендә туа. Авылда урта мәктәп тәмамлагач, 1927 елда Укытучылар курсында укый. 1930 елда укытучы була. 1930–1933 елларда Уфага килеп, Башкортстан педагогия институтында

[1] Зәүкъ – тәм табу.

[2] Дөресе: Коншак районы.

укый. Аны бетергәч, нәшрият редакторы була. 1936–1941 елларда Уфа педагогия институтында филология кафедрасы башлыгы була. Башкорт, рус телләрендә шигырьләр, поэмалар, хикәяләр җыентыгы, 25 тән артык китап авторы.

**334. ДӘҮЛӘТШИН –** Т. Үзбәк.
**ИШМОРАТОВ** – Таң.
**ИШМАЕВ** – Туран.
**ГЫЙЛӘҖИЕВ К.** – Галиев.

***Тәхәллүсләре:*** Т. Үзбәк, Таң, Туран, Галиев.

Болар барысы да «Идел-Урал» исемле эмигрантлар газетасының редакторлары. Алар [Бөек] Ватан сугышы чорында Германиядә, Советлар Союзына каршы оештырылган «Идел-Урал» комитеты тарафыннан чыгартыла торган пропаганда газетасы һәм журналында актив катнашалар.

**335. ГАБИТОВ Камал.**

***Тәхәллүсләре:*** Габитов Камал, Г. Камал.

Революциягә кадәр Троицк шәһәрендә Яушевларда хезмәт иткән укымышлы кеше, «Акмулла» көлке журналында редактор да булып торды. Троицкидагы приказчиклар оешмасының председателе, демократ.

**336. ЕМЕЛЬЯНОВ Яков** (1848–1893).

***Тәхәллүсе:*** Емельянов Я.

Казан губернасы Лаеш өязе (Кызыл Йолдыз районы) Алан исемле керәшен татар авылында туган керәшен татар шагыйре. 1864–1969 елларда керәшен татар мәктәбендә укый. 1879 елда «Керәшен татар телендә» дигән әсәре басыла. Шигырьләре яратып укыла.

**337. ЕНИКЕЕВ Гайсә Мирза.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Еники, Гайсә Еникеев.

Уфа мирзаларыннан, 1906–1907 елларда Дәүләт думасына сайланган укытучы. Думада артык әллә ни эшләмәсә дә, татар-башкорт көйләренә гашыйк. Үзе дә матур гына җырлый. Аларны мөмкин кадәр оныттырмаска тырыша һәм иренми җыя. Фольклорчыларга шактый бай мирас калдыра. Ш. Бабич аның турында болай дип яза:

Еникеев кыйммәтен тик хәлфәләр аз-маз белер,
Юкса ул бер сазда йөргән бер кыйкылдак каз ирер.

Ул мулла булырга әзерләнгән хәлфәләрне русча имтиханга әзерли, Бабич шуңар ишарәт итә.

**338. ЕНИКЕЕВ Исхак.**

***Тәхәллүсләре:*** И. Еникеев, Исхак Е.

1920 елларда Казанда «Татарстан» газетасында берничә вакыт редактор булып эшли. Белемле журналист.

**339. ЕНИКЕЕВ Нигъмәт Сәлимгәрәй улы** (1893–1971).

***Тәхәллүсләре:*** Еникеев Нигъмәт, Н. Еники.

Бәләбәй өязе Яңа Каргалы авылында крестьян гаиләсендә туа. Гражданнар сугышы чорында күренекле сәяси эшлекле, сәяси кадрлар тәрбияләп үстерү эшендә талантлы оештыручы һәм педагог. 1919 елда шәрык фронтында «Кызыл йолдыз» газетасы чыгара, Пермь шәһәрендә «Кызыл Урал» газетасын оештыруда күп эшли, Бәләбәй шәһәрендә өяз советы рәисе һәм хәрби комиссар урынбасары. 1919 елда май аенда коммунистлар партиясенә кабул ителә Татар бригадасының сәяси бүлек башлыгы була. 1920 елда Бохара халык хөкүмәтенең сәяси бүлек башлыгы итеп билгеләнә. 1922 елда халык хуҗалыгы институтында укый. 1923 елда Казанда мәркәз төрек-татар хәрби мәктәп комиссары итеп билгеләнә. Казанда обком һәм үзәк башкарма комитеты әгъзасы була.

**340. ЕНИКЕЕВ Габдессаттар Мөхәммәтхан улы** (1885–1939).

***Тәхәллүсләре:*** С. Еники, Раттас, Е. Саттар, Озын, С. Е.

Гурьев шәһәрендә туа. 17 яшендә Әстерханга килеп, Ваһапов хәзрәт мәдрәсәсендә укый. 1917 елда Әстерханда партия сафына кереп, Наримановлар белән бергә вак милләтләр комиссариатында эшли. 1920 елда Мәскәүгә килә. 1921 елда Казанга килеп, обкомда эшли. Тәэминат наркомы һәм «Татарстан» газетасы редакторы. 1937 елда кулга алынып, шәхес культы корбаны була.

**341. ЕНИКЕЕВ Әмирхан Нигъмәтҗан улы** (1909 ел, 2 март).

***Тәхәллүсләре:*** Әмирхан Еники, Ә. Еники.

Башкортстанның Благовар районы Яңа Каргалы авылында крестьян гаиләсендә туа. 1916–1924 елларда мәктәптә укый. 1925 елда Казанга килеп, курьер булып эшли. 1926–1927 елларда татар рабфагында укый. 1928–1934 елларда хезмәтне фәнни оештыру институтында укый. 1939–1941 елларда Үзбәкстанда Мар-

гелан шәһәрендә укыта. Бөек Ватан сугышы елларында фронтта була. 1950 елда кайткач, Казанда радиокомитетта эшли. Шул елдан башлап профессиональ язучы. Хәзер танылган прозаик, талантлы язучы. Язган әсәрләре күп.

**342. ЕРИКЕЕВ Әхмәт Фазыл улы** (1902–1967).

***Тәхәллүсләре:*** Әхмәт Ерикәй, Ә. Ерикәй.

Башкортстанның Дуван районы Өлкенде[1] авылында туа. 1924 елда партия сафына керә. 1927 елда Мәскәүдә Журналистлар институтында укый. Казанга килгәч, төрле редакцияләрдә эшли. Яхшы журналист. Белемле шагыйрь, җырлар язучы. Татарстанда Язучылар союзында рәис була. Бөтенсоюз Югары совет әгъзасы.

**343. ЗӘБИРОВ Хәбибрахман Габдулла улы** (1882–1930).

***Тәхәллүсләре:*** Х. Зәбири, Хәбибрахман Зәбири, Х. З. әл-Чистайлы.

Чистайлы. Гомер буе укытучы була. Бик күп дини вә дөньяви дәреслекләр яза.

**344. ЗӘБИРОВ Миргаяз[2] Каюм улы** (1884–1947).

***Тәхәллүсләре:*** Миргазиз Укмасый, Газиз әл-Укмасый, М. Укмасый, Миргазизел Укмасый*, Укмасый М. Г*.

Татарстанның Балык Бистәсе районы Укмас авылында туа. 1903 елда яза башлаган шагыйрь. Күп кенә шигырь вә хикәяләре бар. Мәсәлән, «Өмид йолдызым», «Алданма кызыл алмага», «Кырмыскалар тормышыннан», «Хәлифәлек өчен сугыш» исемле китаплар авторы. Шагыйрь Бабич аның турында болай ди:

*(Укмаси мулла булгач*):

Укмаси Миргай Газизгә ук та үтмәстер хәзер,
Инде ул язган шигырьне кем дә укымастыр хәзер.

**345. ЗӘЙНАШЕВА Гөлшат Хисам кызы** (1928 ел, 13 гыйнвар).

***Тәхәллүсләре:*** Гөлшат Зәйнашева, Г. Зәйнашева, Гөлшат.

Татарстанда Ворошилов районы[3] Иске Теләнче авылында туа. 1942 елда Минзәлә педагогия техникумында укый. 1945–1949 ел-

---

[1] Кирилл хәрефләре белән бирелгән.

[2] Дөресе: Миргазиз.

[3] Хәзерге Тукай районы.

ларда Казан педагогия институтында тарих, тел, әдәбият бүлегендә укый. 1952 елда нәшриятта редактор була. Шигырьләр, җырлар яза. Җырлары радиолардан тапшырыла. Шигырь җыентыклары бар.

**346. ЗӘЙНИ Хәбиб Хәлил улы** (1891–1967).

***Тәхәллүсләре:*** Д. Зәйни, Хәбиб Зәйни, З. Хәбиб.

Троицк шәһәрендә туа. Троицк мәдрәсәсендә («Рәсүлия»дә) белем алгач, Төркиягә китеп, анда физкультура институтында укый. Аннан кайткач, Уфада «Галия» мәдрәсәсендә физкультура укыта. Урта һәм югары мәктәпләрдә 40 еллап җәгърафия, биология фәннәре укыта. Мәктәпләр өчен чыгарылган дәреслекләр, методик кулланмалар һәм мәктәпләрдә укыту-тәрбия мәсьәләләре турында язылган күп кенә мәкаләләр авторы.

**347. ЗАКИРОВ Тура.**

***Тәхәллүсе:*** Җасур.

Үзбәк журналисты. Шагыйрь.

**348. ЗАКИР Һади** (1863–1933).

***Тәхәллүсләре:*** З. Һади, Закир Һади.

Уфа губернасы Бәләбәй өязе Ярамка[1] авылында умартачы гаиләсендә туа. Атасы хәлфәлек иткән крестьян умартачы. 1903 елда [язылган] «Бәхетле кыз», «Официант», 1905 елларда «Хәер-дога», «Бәхетсез кыз», «Җиһанша хәзрәт» исемле әсәрләрнең авторы.

**349. ЗАКИРОВ Зәки** (1897–1937).

***Тәхәллүсе:*** Зәки Закиров.

Туган җире билгесез. Язган нәрсәләре бар.

**350. ЗАКИРИ Исмәгыйль.**

***Тәхәллүсләре:*** Авыл егете, Эрә егете, З. И.

1920 һәм 1926 еллардагы «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан» газеталарына авылдан шигырьләр язып, җырлар җыеп йөргән авыл шагыйре.

**351. ЗАКИРОВ Исхак** (1911–1941).

***Тәхәллүсләре:*** И. Закиров, Исхак Закиров.

Казанда туа. 1939 елда Казанда финанс-экономика институтын тәмамлый. 1929 елдан Казан журналларында языша башлый.

[1] Ярмәкәй авылы.

1934 елдан башлап нәшриятта бухгалтер булып эшли. 1941 елда Бөек Ватан сугышына китә. 1944 елның 14 июлендә геройларча һәлак була.

**352. ЗАРИПОВ Нур Талип улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Нур Зарипов, Н. Зарипов.

Башкортстан Фәннәр академиясе филиалының Тарих, тел, әдәбият институтында гыйльми хезмәткәр. 1972 елда башкорт телендә «Бүз егет» китабы өстендә эшли.

**353. ЗӨЛКАРНӘЕВ Гали Камал улы** (1905 ел, 20 февраль).

***Тәхәллүсе:*** Гали Зөлкарнәй.

Чиләбе өлкәсе Аргаяш районы. 1931 елда Уфадагы Башкорт коммунистлар югары мәктәбендә укый. 1940–1945 елларда «Кызыл Башкортстан» газетасында редактор. «Октябрь» журналында редактор. Прозаик, яхшы тәрбияче.

**354. ЗӨЛКАРНӘЕВ Имангали Мөхәммәтдин улы**[1] (1904–1943).

***Тәхәллүсе:*** Али Зөлкарнәй.

Башкортстанның Бөре өязе Зур Шады авылында крестьян гаиләсендә туа. 1924 елдан Мәскәү, Ленинград югары уку йортларында укый. 1941 елдан Ватан сугышында «Кызыл атлылар» газетасы редакторы. 1943 елда батырларча һәлак була.

**355. ЗӨЛФӘКАРЫЙ Кыям.**

***Тәхәллүсе:*** Зөлфәкарый К.

Революциягә кадәр Казанда мәдрәсәдә шәмаилләр ясый.

**356. ЗЫЯТДИНОВ Вакыйф** (1891–1944).

***Тәхәллүсе:*** Вакыйф Зыя.

Революциягә чаклы һәм аннан соңгы вакытлы матбугатта актив язышкан шагыйрь һәм язучы.

**357. ИБРАҺИМОВ Габдулла.**

***Тәхәллүсе:*** Кыпчак.

Башкорт журналисты һәм әдибе.

**358. ИБРАҺИМОВ Бәһрәм.**

***Тәхәллүсе:*** Юксыл.

---

[1] Күп чыганакларда: Зөлкарнәев Имамгали Мөхәммәтдин улы.

Үзбәк язучысы, революциядән соң матбугат мәйданына чыккан язучы.

**359. ИБРАҺИМОВ Габдрәшит казый Гомәр улы** (1857–1922[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Рәшит казый, Р. Ибраһим.

Иртыш буендагы Тара шәһәрендә туа.

Татарча мәдрәсә тәмамлагач, русча да укып мәгълүмат алган кеше. Сәяхәтче, мөселман миссионеры. Бик күп газета-журналларның редакторы, дин галиме, Диния нәзарәтендә казый булып тора. Япониягә барып, японнарны дингә өндәп йөргән кеше. Патша хөкүмәте панисламизмда гаепләде. Ул үлгәч, 1922 елда Галимҗан Ибраһимов: «Тарихи кыңгырау өзелде», – дип язды[2]. Бабич аның турында:

> Әй, кызу Габдеррәшит казый, кадерле, дәртле карт!
> Күргәнеңне сөйләр идең. Бик сагындык, өйгә кайт!–

дип яза.

**360. ИБРАҺИМОВ Габдулла Габдессабур улы** (1885– 1937).

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Шөнаси, Габдулла Ибраһимов, Шөнаси.

Гали белем алып, профессор дәрәҗәсенә ирешкән тәҗрибәле укытучы, физика (гыйльме әшья), химия укыта, «Тәгълимдә тәрбия тарихы» исемле гыйльми әсәр авторы.

**361. ИБРАҺИМОВ Галимҗан Гыйрфан улы** (1887–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Г. Ибраһимов, Г. И., Г-җан Ибраһим, Габди, Гыйрфанзадә, Гыйрфан улы, Г-җан И*.

Башкортстанның Авыргазы районы Солтанморат авылында туа. Авылда мәдрәсә тәмамлагач, Казанга килеп, Күлбуе мәдрәсәсендә укый. Хосусый рәвештә русча өлгергәнлеккә имтихан тотарга әзерләнә. Революциягә кадәр Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укыта. Революциягә чаклы Казанга килеп, «Таң» журналында сәркатип була. «Шура» журналында вә башка газета-журналларда актив языша. Революциядән соң, 1917 елда Уфада «Ирек», «Безнең юл» газеталары чыгара. 1918 елда Петроградта Мулланур Вахитов, Шәриф

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1857–1944 еллар.

[2] Г. Ибраһимов әлеге мәкаләсен 1922 елда Габдрәшит Ибраһимов вафат булган дигән ялгыш хәбәрне ишеткәч яза.

Манатов, Исхак Казаковлар белән бергә Мөселман комиссариаты төзиләр. «Чулпан» газетасы чыгара. Казанда Гыйльми үзәк рәисе була. Төрле газета-журналлар оештыра, гали мәктәпләрдә укыта. Фәннәр академиясенең гыйльми хезмәткәре. 1928 елда Галимҗан Ибраһимовның 20 еллык әдәби, гыйльми, сәяси-иҗтимагый хезмәтенә юбилей уңае белән Мөхәммәт Таһиров, Габдрахман Сәгъди, Сафа Борһан, Галимҗан Нигъмәтиләр тарафыннан редакторлык итеп нәшер ителгән гыйльми, тәнкыйди җыентык чыга. 1938 елны кулга алынып, шәхес культы корбаны була. Татар үзенең зур галимен, танылган әдибен, гадел тәнкыйтьчесен, җәмәгать эшлеклесен югалта.

Казанда һәм Уфада аның исемендә урамнар бар.

**362. ИБРАҺИМОВ Ваһаб.**

***Тәхәллүсе:*** Дәврани.

Үзбәк язучысы.

**363. ИБРАҺИМОВ Мирза.**

***Тәхәллүсләре:*** И. Мирза, И. М., Мөрәттиб, М. И*.

Чыгышы белән азәрбайҗанлы карт революционер. Казанда күп еллар хәреф җыючы. Соңгы елларны обком контроль комиссиясендә әгъза булды. Вакытлы матбугатта язышты.

**364. ИБРАҺИМОВ Гали Гыйззәтулла улы** (1919 ел, 16 гыйнвар).

***Тәхәллүсләре:*** Гали Ибраһим, Г. Ибраһимов.

Башкортстанда Стәрлетамак шәһәрендә эшче гаиләсендә туа. 1937–1939 елларда педагогия рабфагында укый. 1942 елда партия сафына керә. Ватан сугышында катнаша.

1959 елда «Агыйдел» журналында редактор урынбасары була. Башкорт, рус телләрендә 10 нан артык китап авторы.

**365. ИБРАҺИМОВ Мадамин.**

***Тәхәллүсе:*** Бишәрык.

Үзбәк язучысы.

**366. ИБРАҺИМОВ Мөнир Әхмәдрәшид улы.**

***Тәхәллүсе:*** Мөнир Ибраһимов.

Рәшит казыйның улы. Тара шәһәрендә туа. Ул да, әтисе кебек, японнарны дингә өндәп йөри.

**367. ИБРАҺИМОВ Ризван.**

***Тәхәллүсләре:*** Алпуш, Г. И.

Журналист, вакытлы матбугатта язышa.

**368. ИБРАҺИМОВ Николай Мисаил улы.**

***Тәхәллүсе:*** Николай Ибраһимов.

Казан университеты мөдире Н.И. Лобачевскийның укытучысы, Мәскәү университетында укыткан кеше.

**369. ИБРАҺИМОВ Фатих Исхак улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Фатих Ибраһимов, Ф. Ибраһим, Ф. Туйкин (Чаян) *(Фазыл Туйкин белән бутамаска кирәк).*

1916 елда Татарстанның Лениногорск районы Кирлегәч авылында туа. Казанда гали мәктәп бетереп, журналист була. «Чаян» журналында һәм «Мәктәп» журналында редактор. 1969 елны кандидатлыкка диссертация яклый. Педагог һәм әдип.

**370. ИБРАҺИМОВ Фәрид Таҗетдин улы** (1893–1937[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Ибраһимов Фәрид, И. Фәрид, Фәрид Ыргалы, Ибраһим Ф*, Фәрид И*.

Татарстанның Лаеш өязе Түбән Ырга авылында дөньяга килә. Мәдрәсә бетергәч, укытучы һәм язучы, шагыйрь була, 1912 елда «Уйларым», «Өмидемнең нурлары» исемле шигырь, поэма җыентыклары басылып чыга. 1915 елда «Төш» поэмасы, «Таң аткач», «Иртән» шигырьләре, 1921 елда Ташкентта «Үч» поэмасы, 1922 елда Каракүл шәһәрендә «Азгын» исемле музыкаль драмасы, 1924 елда Каракүлдә «Гармун тавышы» һәм башка шигырьләр, поэма җыентыклары дөнья күрә.

Революциядән соң институт бетергәч, Ташкент, Сәмәрканд, Каракүл кебек төрле шәһәрләрдә укыта.

1937 елларда Сәмәрканд педагогия институтының профессоры булып эшләгән җирдә кулга алынып, шәхес культы корбаны була.

**371. ИБРАҺИМОВ Хәбибулла Кәлимулла улы** (1894–1959).

***Тәхәллүсләре:*** Ибраһимов Хәбиб, Ибраһимов.

Оренбург шәһәрендә йөкче гаиләсендә туа. Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. 1915 елда солдатка алына. Аннан кайт-

[1] Татар энциклопедиясе: 1893–1943 еллар.

кач, музыка укытучысы була. 1922 елда аны Ленинградка, музыка белеме институтына укырга җибәрәләр. Аны яхшы билгеләренә тәмамлап кайта. Башкортстанның сәнгать эшлеклесе, талантлы композитор, мәшһүр драматург. «Мостафа хәзрәт», «Башмагым», «Зөлхәбирә», «Пианино мәсьәләсе» дигән пьесалар авторы.

**372. ИБРАҺИМОВ Йосыф Ибраһим улы** (1895–1962).

***Тәхәллүсе:*** Йосыф Ибраһимов.

Гражданнар һәм [Бөек] Ватан сугышы ветераны. Вакытлы матбугатта язгалады.

**373. ИБРАҺИМОВ Шәймәрдан Нуриман улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Ибраһимов Шәймәрдан, Ш. Ибраһимов.

Мәскәүдә туа. 15 яшендә революция эшенә катнаша. 1918 елда Коммунистлар партиясе Үзәк комитеты хозурындагы Шәрык халкы коммунистлары бюросында эшли. Шәрык коммунистларының II съездында делегат. Һәрвакыт Мәскәүдә җаваплы партия эшләрендә катнаша. Шәхес культы корбаны. Хәзер Мәскәүдә аның исемендәге урам бар.

**374. ИБРАҺИМОВА Һаҗәр.**

***Тәхәллүсе:*** Һаҗәр Ибраһимова.

«Тырыш бала» дигән китап яза. Кайдан икәнен белә алмадым. Китабын Троицкида укыдым.

**375. ИГЕБАЕВ Габделхак Хаҗимөхәммәд улы** (1930 ел, 2 июль).

***Тәхәллүсләре:*** Игебай Габделхак, Габделхак Игебаев, Г. Игебаев.

Башкортстанның Баймак районы Күсәй авылында колхозчы гаиләсендә туа. Яшьтән ятим калып, балалар йортында үсә. 1946 елда педагогия мәктәбен тәмамлый. 1946–1950 елларда Башкортстан педагогия институтының тел, әдәбият факультетын тәмамлый. Башкортстанның танылган шагыйре. Уннан артык шигырь, поэма җыентыклары бар.

**376. ИДРИСИ Галимҗан.**

***Тәхәллүсләре:*** Галимҗан Идриси, Г. Идриси, Г. И*.

Сәяхәтче журналист. Революциягә кадәр вакытлы матбугатта актив язышa. Беренче герман сугышы чорында пленга төшеп, мөселман әсирләренә мулла булган һәм чит илдән аларны вербовать

итәргә килгән маклерларга бирмәүчеләрнең берсе (Баязид Бурнаев сөйләде). Ул Германиядә торып кала. Германиядән кайтып, күп кенә үзбәк яшьләрен Германиягә укырга алып китә.

Яңадан Русиягә кайткач, шөбһәләнеп аны кулга алалар. Шуны ишетү белән, студентлар, Ленинның секретаре Фотиевага мөрәҗәгать итеп, аны коткаралар. Германиягә кайтып, шунда гаиләсе белән яши. Аның агасын Петропавел шәһәрендә чехлар атып үтерә. Ул Муса Җәлилләргә ярдәм итә.

1925 елларда Идриси, «Татарстан» газетасының махсус хәбәрчесе буларак, Берлиннан язып тора. [...] Берлинга баргач, ике тапкыр Чичерин белән сөйләшеп интервью ала. 1943 елда Финляндиягә профессор булып килгән һәм Финляндия татарларына лекцияләр укып киткән (Финляндия язучысы Хәсән Хәмиди сүзләре).

**377. ИДЕЛЛЕ – Газиз Салих улы Госманов** (1905 ел, 25 декабрь).

***Тәхәллүсләре:*** Иделле, Зизаг, Фонамсог, Шәй агайның секретаре, Газиз Иделле.

Әстерханда эшче гаиләсендә туа. 1923 елда Свердлов шәһәрендә индустрия техникумын тәмамлый. 1925–1926 елларда Свердловск шәһәрендә «Сабан һәм чүкеч» газетасы редакторы. 1926 елда Казанга килеп, берничә еллар «Безнең юл» журналында секретарь була. 1930–1940 елларда армия сафында хезмәт итә. Аннан кайткач, Казанда төрле редакцияләрдә эшли. Ул – шагыйрь дә, танылган әдип тә, тәнкыйтьче дә.

**378. ИДИЯТУЛЛИН Мәгъсүм Насыйбулла улы.**

***Тәхәллүсе:*** Мәсгуд Идиятуллин.

1928 елда Татарстанның Апас районы Бакырчы авылында крестьян гаиләсендә туа. Казанда институт бетергәч, журналист һәм «Чаян» журналында җаваплы секретарь булып эшли.

**379. ИЗМАЙЛОВ Шакир Сафиулла улы** (1844–1939).

***Тәхәллүсләре:*** Шакир Измайлов, Ш. Измайлов.

1918 елда Сембер шәһәрендә «Таң» газетасы чыгара. 1919 елда Мәскәүдә Бөтеншәрык халыклары коммунистларының II съездында делегат. 1924 елларда Татарстанда наркомтруд була. Журналист.

**380. ИЗМАЙЛОВА Асия Сафиулла кызы.**

*Тәхәллүсе:* Асия Измайлова.

1903 нче елда августта Сембер шәһәрендә тимерьюл машинисты гаиләсендә туа. 1917 елда педагогия курсларында укый. 1918 елда аны эшчеләр театрына алалар. 1920–1922 елларда Сембер шәһәрендә губерна комитеты әгъзасы һәм мәгариф инструкторы булып эшли, шул елда комсомолга керә һәм Мәскәүгә күчә. Анда педагогия курсларында укый. КУТВга керә. Анда партия сафына кабул ителә. Шул чакта ук музыка техникумында дәресләр тыңлый. Аны бетергәч, төрле шәһәрләргә гастрольгә йөри. 1927 елда Казанга күчә. 1928 елда М. Горький белән очраша. Совет оешмаларында депутат була. «Халык артисткасы» исемен ала. Кандидатлыкка диссертация яклый.

**381. ИКРАМОВ Әкмал.**

*Тәхәллүсләре:* Икрамов Әкмал, Эзче.

Үзбәк язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе.

**382. ИКРАМОВ Хәтәм.**

*Тәхәллүсе:* Батрак.

Үзбәк язучысы.

**383. ИЛЬЯСИ Габдрахман Мөхәммәтәмин улы** (1856–1895).

*Тәхәллүсе:* Г. Ильяси.

Казанда сәүдәгәр гаиләсендә туа. Казанда Күлбуе мәдрәсәсендә укый. Хосусый рәвештә русча өйрәнә. Каюм Насыйри белән бергә төрле фәннәр өйрәнү белән шөгыльләнә. 1870 елда «Бичара кыз» һәм «Яшь кыз вә хатыннарга һәдия» исемле әсәрләр авторы. Археология оешмасында әгъза була. Анда докладлар ясый.

**384. ИЛЬЯСИ Габдрахман Вәкил улы** (1908–1943).

*Тәхәллүсләре:* Рахман Ильяс, Р. Ильяс.

Татарстанның Кайбыч районы Карамасар авылында туа. 1925–1927 елларда ФЗӨ[1]дә укый. 1929 елда партия сафларына керә. 1930 елларда әдәбиятка килә, 1936 елда армия сафына алына. 1934–1936 елларда марксизм-ленинизм институтында укый. «Зәйнүш»,

[1] Фабрика-завод өйрәнчеклеге.

«Фонтан», «Горизонт», «Танышлар», «Таулар арасында», «Кавказ хикәяләре» исемле әсәрләрнең авторы.

**385. ИЛЯЛОВ Исмәгыйль Гобәйдулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Исмәгыйль Һилалов, И. Һилал.

1898 елда Троицк шәһәрендә туа. Татар мәдрәсәсеннән соң, рус-татар мәктәбен тәмам иткәч, үзлегеннән музыка өйрәнеп, Троицкидагы театр оешмасына кереп, яшьтән үк артист, музыкант була. Мандолинада виртуоз.

**386. ИЛЬСКАЯ – Фатыйма Салих кызы Хуҗасәедова** (1902 ел, 13 гыйнвар).

***Тәхәллүсе:*** Ильская Фатыйма.

Оренбург шәһәрендә туа. 1915 елда «Сәйяр» труппасына кушылып, артистка булып китә. Татарстанның атказанган артисткасы исемен яулый. Ул чыннан да татарлар өчен ил кызы, ил сөеклесе булып калды.

**387. ИМАМЕТДИНОВ Сабир Фәхретдин улы** (1908–1963).

***Тәхәллүсе:*** Сабир Имаметдинов.

Татарстанның Мамадыш [районында] туа. Ул Мамадышта Укытучылар семинариясен бетерә. Партия сафына керә. Казанга килгәч, җаваплы эшләр башкара. Вакытлы матбугатта мәкаләләр яза.

**388. ИМАМЕТДИНОВ Төхфәт.**

***Тәхәллүсе:*** Димский.

Вакытлы матбугатта «Димский» имзасы белән мәкаләләр язган журналист.

**389. ИМАНАЕВ Миргаяз** (1870–1927).

***Тәхәллүсләре:*** Иманаев Миргаяз, М. Иманаев.

Татарстанда Минзәлә өязе Карамалы волосте Олы Чакма[к] авылында крестьян гаиләсендә туа. 1890 елда Учительская школа бетереп, укытучы була. 8 яшендә ятим кала. 13 яшендә абыйсы русча укыта. Татар телен укыту турында мәкаләләр яза.

**390. ИМАНАЕВ Шәехгаттар.**

***Тәхәллүсләре:*** Иманаев Шәехгаттар, Ш. Иманаев.

Университетның хокук факультетын бетереп, адвокат була һәм укытучылык итә. 1913 елда «Хокук вә хәят» исемле журнал чыгара.

**391. ИМАНКОЛЫЙ Мөхәммәтсадыйк Шаһиәхмәт улы** (1870–1932).

***Тәхәллүсләре:*** Иманколый Садыйк, Садыйк, Мөхәммәт Садыйк, С. Иманколый*.

Бохарада укып кайтып, 1893 елда Казанда Яңа Бистәдә мулла була. «Әд-дин вәл-әдәп», «Шура» журналларында шигырьләр яза. 30 нчы елларда кулга алынып, төрмәдә үлә. Ш. Бабич аның турында болай яза:

Әл-Иманколый Садыйк әшгарь язарга башламыш.
Әй, кыямәт купмасын, дим, мулла чалма ташламыш.

**392. ИСӘНКУЛОВ Фәрид Әхмәдулла улы** (1928 ел, 6 март).

***Тәхәллүсләре:*** Фәрид Исәнкулов, Ф. Исәнкулов.

Башкортстанның Кырмыскалы районы Корманбай[1] авылында крестьян гаиләсендә туа. 1951 елда Уфада нәшрияттта баш редактор була.

«Агыйдел» журналында редактор урынбасары. 1954 елдан партия сафына керә. Балалар әдәбияты остасы. Башкорт, рус телләрендә 20 гә якын хикәя, повестьлар җыентыгы авторы.

**393. ИСКӘНДӘРОВ Габдрахман Идрис улы** (1897–1937)[2].

***Тәхәллүсләре:*** –

Татарстанның Дөбьяз районы Рәс авылында дворник гаиләсендә туа. Укытучылар курсын бетереп, укытучы була. Партия сафына керә. Мамадыш, Кукмара районнарында район башкарма комитеты башлыгы. Казанга килгәч, Наркомзем (Җир эшләре халык комиссары) була.

**394. ИСКӘНДӘРОВ Хәлим Фәттах улы** (1888–1958).

***Тәхәллүсләре:*** Айваз, Х. Искәндәров, Астыртын, И. Хәлим*, Наразый*.

Чиләбе өлкәсе Златоуст өязе Арслан авылында туа. Мәдрәсә бетергәч, Троицк шәһәрендә «Рәсүлия», Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укый. Революциягә кадәр Троицкида Яушевлар мәдрәсәсендә укыта. 1918 елда Уфада «Ил теле» исемле газета чыгара. Свердловск шәһәрендә газета чыгара. Омскида мәгариф мөдире була. 1929 –

[1] Дөресе: Карлыманбаш авылы.
[2] Татар энциклопедиясе: 1898–1938 еллар.

1941 елларда Мәскәүдә укыта. «Белек йорты» дигән хрестоматия авторы. 1958 елда Бөгелмәдә үлә.

**395. ИСЛАМОВ Данис Фәтхи улы** (1921 ел, 15 декабрь).

***Тәхәллүсләре:*** Данис Исламов, Д. Исламов.

Башкортстанның Чишмә районы Яңа Мусино[1] авылында крестьян гаиләсендә туа. Ватан сугышында катнаша. Кайткач, Уфада «Кызыл Таң» газетасында эшли. Унлап хикәя-повесть җыентыклары авторы.

**396. ИСЛАМХАНОВ Галләмхан.**

***Тәхәллүсләре:*** Галләмхан Ислами, Г. Исламханов.

Оренбургта «Дин вә мәгыйшәт» журналында редактор. 1910 елда «Хөррият сәмәрәләре»[2] дигән әсәр авторы.

**397. ИСМӘГЫЙЛЕВ Мостафа Лотфый Ширванский.**

***Тәхәллүсләре:*** Исмәгыйль Ширванский, Исмәгыйль Лотфый, И. Ширванский, Ширванский*, Мостафа Лотфи*.

Әстерханда туа. Төркиягә барып, гали белем ала. Аннан кайткач, Әстерханда төрле кыска гомерле газеталар чыгара. 1906 елда «Борһане тәрәккый», 1907 елда «Хәмият», 1911 елда «Хак» исемле газеталар чыгара. Г. Тукайның «Мостафа» дигән шигыре шуңа багышланган.

**398. ИСМӘГЫЙЛЕВ Сәед Әхмәт улы** (1884 ел, 29 октябрь).

***Тәхәллүсләре:*** Сәед Исмәгыйлев, Сәед.

Башкортстанның Чишмә районы Ярми авылында крестьян гаиләсендә туа. 1944 елда халык бәетчесе, җырчысы дигән исем яулый. Уфада биш-алты җыр китабы басылып чыга.

**399. ИСБОЛОВ Морза казый** (1890–1940).

***Тәхәллүсе:*** Исболдов Морза Казый.

Казакъ журналисты. Укытучы. Соловкида Анзерда лагерьда була.

**400. ИСХАКОВ Гата** (1890–1937).

***Тәхәллүсләре:*** –

[1] Яңа Муса авылы.
[2] «Хөррият җимешләре».

Башкортстанда Бөре өязендә туа. Укытучы, фольклорчы. Уфада «Галия»дә укый һәм укытучы булып гомер итә. Урта мәктәпләр өчен «Әдәбият юллары» исемле хрестоматия төзегән кеше.

**401. ИСХАКОВ Мөхәммәтгаяз Гыйләҗетдин улы** (1878–1954).

***Тәхәллүсләре:*** Г. Исхакый, Чыңгыз, Таңчы, Иблис, Гаяз*.

Чистай өязе Яуширмә авылында туа. Казанда Күлбуе мәдрәсәсендә укый. Революциягә кадәр «Ил», «Сүз» газеталарын чыгара. «Тормышмы бу?», «Очрашу яки Гөлгыйзар», «Бай улы», «Кәләпүшче кыз», «Кияү», «Фамилия сәгадәте», «Җәмгыять», «Өч хатын белән тормыш», «Алдым-бирдем», «Теләнче кызы», «Мулла бабай», «Ике гашыйк», «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Солдат», «Җыентык», «Мөгаллим», «Мөгаллимә», «Сөннәтче бабай», «Кыямәт», «Ул икеләнә иде», «Остазбикә», «Зиндан», «Тәгаллемдә сәгадәт», «Ул әле өйләнмәгән иде», «Зөләйха» һ.б. әсәрләр авторы.

**402. ИСХАКОВ Вәли Исхак улы** (1891–1957).

***Тәхәллүсләре:*** Вәли Исхаков, В. Исхакый.

Татарстанның Арча районы Наласа авылында крестьян гаиләсендә туа. Байларда приказчик булган кеше. Революциядән соң 1918 елда партия сафына керә. Татарстанда нарком рабкоры[1] һәм Госплан рәисе булып эшли. Журналларга языша.

**403. ИСХАКОВ Вазыйх Мөхәммәдша улы** (1927 ел, 7 октябрь).

***Тәхәллүсе:*** Вазыйх Исхаков.

Башкортстанның Чакмагыш районы Тайнаш авылында туа. 7 еллык мәктәпне тәмамлагач, ат караучы булып эшли. Аннан соң МТС[2]та шофер. 1948–1958 елларда армия сафында, 1964 елда Башкортстан дәүләт университетын тәмамлый. Аны шунда ук әдәбият кафедрасына укытучы итеп калдыралар. Ул революционерлар биографиясеннән шактый әсәрләр бастыра. Башкорт, татар, рус телләрендә 10 лап әсәре бар.

**404. ИСХАКОВ Голәм.**

***Тәхәллүсе:*** Юксыл.

Үзбәк шагыйре.

---

[1] Рабочий корреспондент.

[2] Машина-трактор станциясе.

**405. ИСХАК Хантурә.**

***Тәхәллүсе:*** Гыйбрәт.

Үзбәк язучысы.

**406. ИСХАКОВ Рәхмәтулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Мусинский, Мим.

Вакытлы матбугатта язган кеше.

**407. ИСХАКОВ Фазыл.**

***Тәхәллүсе:*** Ф. Исхаков.

Фәннәр академиясе филиалында эшли.

**408. ИСХАКОВ Әхмәт Габдулла улы** (1905 ел, 1 май).

***Тәхәллүсләре:*** Әхмәт Исхак, Карәхмәт, Кисекбаш, Кырыкбаш Имәни*, Кырыкбаш Имәнлесенең бер туганы*, Габделтатар Камбальск*.

Казанда туа. Мәдрәсә бетергәч, 1922 елда педагогия техникумы тәмамлый, Татарстан комсомол обкомында, 1925–1928 елларда Мәскәүдә «Эшче» газетасында эшли. 1923 елдан башлап шигырьләр яза. Ватан сугышында катнаша. Кайткач, Казанда күп җырлар һәм мәсәлләр яза. «Чаян» журналында редактор була. «Намус» операсына либретто яза. 1955 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә, татар халкының яраткан шагыйре, танылган әдибе, тәҗрибәле редакторы, үткен каләмле юморист, сатирик, белемле тәрҗемәче.

**409. ИСХАКОВ Хәбиб Исхак улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Х. Исхакый, Хәбиб*, Исхак малае*, Хис*.

1905–1907 еллардан соң «Шура», «Таң», «Школа» журналларына яза. Казандагы «Мөхәммәдия» шәкерте. 1912 елда «Гөл бакчасы», «Патша һәм таз хикәяләре», «Хәбиб шигырьләре», «Милләт бакчасы» әсәрләренең авторы. Революция алдыннан вафат була.

**410. ИСХАКОВ Һади.**

***Тәхәллүсе:*** Һади Исхаков.

Уфада кооператив техникумы директоры булып эшләгән журналист.

**411. ИСХАКЫЙ Әхмәт.**

***Тәхәллүсе:*** Әхмәт Исхакый.

Фатих Кәрим белән Төркиядә Истанбулда белем алган язучы. Орск шәһәрендә китап белән сәүдә итә һәм нашир дә була.

**412. ИСӘНБИРДЕ Газизетдин.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Исәнбирдин, Г. Исәнбирде.

Революциягә кадәр «Шура» журналында һәм башка вакытлы матбугатта актив язышкан шагыйрь һәм педагог.

**413. ИСӘНБАЕВ Мөхәммәтсәгыйд Гыйльметдин улы** (1895–1972).

***Тәхәллүсләре:*** Сәгыйть Исәнбай, С. Исәнбай.

Татарстан Фәннәр академиясе филиалында Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләгән гыйльми хезмәткәр, «Тукай замандашлары» дигән әсәр һәм Тукай альбомының авторы.

**414. ИСӘНБӘТ Нәкый Сиражетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Нәкый Исәнбәт, Н. Исәнбәт, Карасакал, Каплан, Мәргән, Мәлгунь, Күкташ, Башы бозык, Аллаяр, Талпан, Дамулла, Коры философ, Кабан.

1899 елның 27 ноябрендә Башкортстанның Салават районы Малаяз авылында туа. 1914 елда «Агыйдел» журналында яза башлый. Татар әдәбият дөньясында зур хөрмәт казанган галим, зур әдип, шагыйрь, танылган драматург, белемле, гадел тәнкыйтьче.

**415. ИХСАНОВА Ләбибә Фәйзулла кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Ләбибә Ихсанова, Ихсанова Ләбибә.

1923 елның 23 августында Вятская Полянада хезмәткәр гаиләсендә туа. Урта мәктәп тәмамлагач, Казанга килеп, университетның география факультетын бетергәч, төрле редакцияләрдә эшли. «Яшь сталинчы» газетасында, «Пионер» журналында редактор була. Коммунистлар партиясе әгъзасы, аның хикәяләрен балалар яратып укыйлар. «Якты хыяллар», «Җир астында җиде көн», «Канатлы яшьлек» вә башка әсәрләрнең авторы.

**416. ИХСАНОВ Әхмәт Сөләйман улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Ихсанов Әхмәт, Рәтмир.

1908 елда Башкортстанның Күгәрчен районында Акман Ибрай авылында крестьян гаиләсендә туа. 1929–1930 елларда педагогия институтында укый. Бөек Ватан сугышында катнаша.

Башкортстанның танылган язучысы һәм шагыйре. Берничә шигырь, хикәя җыентыкларының авторы.

**417. ИШӘЕВ Нуретдин.**

***Тәхәллүсләре:*** Робтый, Н. Ишаев, Н. Робтый*.

Бәләбәй өязе Рабит авылында туа. 1912 елда «Өчбүлә мулласы Фәйзрахман» белән «Төркиягә сәяхәт турында», «Шура» журналында мәкаләләр яза. «Тыңлап карагыз, җырламакчы булам», «Кызык сүз» шигырь җыентыклары, «Авыл тормышы» исемле 4 пәрдәле пьесаның авторы.

**418. ИШБУЛАТОВ Х.**

***Тәхәллүсе:*** Х. Ишбулат.

1919 елда Вятка шәһәрендә «Сабан-чүкеч», 1920 елда Уфада «Яңа хәбәрләр» газеталарын чыгара.

**419. ИШМӨХӘММӘТОВ Гаяз.**

***Тәхәллүсе:*** Г. Ишимов.

Мисырда гарәпчә укып кайткан гарәп теле белгече. Казанда университетта гарәп теле укыта. Казанда үлә.

**420. ИШЕМГУЛОВ Булат** (1900–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Ишемгулов Булат, Таң, Г. Закир улы.

Габдрахман Закир улы Габдрахманов. Башкортстанның Зианчура районы Яңа Чебенле авылында крестьян гаиләсендә туа. 1916 елда Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укый. 1919 елда армия сафына алына. Комсомол, партиядә җаваплы эшләр алып бара. 1925 елда Уфада нәшрият редакторы була. Башкортча, татарча, русча 20 дән артык шигырь, поэма, хикәя җыентыклары авторы.

**421. ИШМОРАТОВ Ризаэтдин Фәхретдин улы.**

***Тәхәллүсе:*** Риза Ишморат.

1903 елның 1 ноябрендә Башкортстанның Яңавыл районы Бәдрәш авылында крестьян гаиләсендә туа. 1914 елда Татарстанның Актаныш районы Уразай авылына күчеп киләләр. 1911–1915 елларда авыл һәм Минзәлә мәктәпләрендә укый. 1917–1918 елларда Уфада «Госмания» мәдрәсәсендә укый. 1919–1922 елларда Уфада педагогия техникумында, 1923–1926 елларда татар театр техникумында, 1927–1930 елларда Ленинград сәнгать институтында белем

ала. Казанга кайткач, сәнгать эшендәге җаваплы эшләрдә эшли. Ватан сугышында фронт газетасы редакторы була. Татарстанның күренекле язучысы, драматург.

**422. ИШМОРАТ – Рания Гыйниятулла кызы Чаптарова.**

***Тәхәллүсе:*** Рания Ишморатова.

1917 елның 20 июлендә Чистай шәһәрендә туа. Рабфак бетергәч, Мәскәүгә китеп, тегермәнчелек мәктәбендә укый. Партия сафына керә. Ватан сугышы вакытында госпитальдә эшли. 1952 елда язу эшенә тотына. 1956 елдан башлап, аның берничә пьесасы һәм хикәяләре җыентыгы чыга.

**423. КАДЕРМӘТИ Минһаҗ Йосыф улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Һинди Минһаҗ, М. Кадермәти, Минһаҗ Кадермәти, М. Һинди*.

Төркиядә укып кайтып, Уфада «Мәдрәсәи Галия» салдырам дип, халыктан акча җыеп йөргән кеше. Укытучы була. Матбугатка язышa. Кайчан, кайда туганын белә алмадым. Тукай дәверендәге кеше. Тукай аның турында болай дип яза:

Таш ташыйлар, анда Минһаҗ «Галия» нигезен сала.
Туй ясыйлар, монда Минһаҗ гаилә нигезен сала.
Ала карга, кара козгын әрсезләнә, тук була.
Һинди мәдрәсә салганда, Рәшид мәчет Токиода.

«Дөньяда җәннәт вә аның хурлары», «Мөшавәрәт» календаре авторы.

**424. КАДЫЙРИ Арам.**

***Тәхәллүсләре:*** Баба Равшан, Фидани.

Үзбәк язучысы.

**425. КАДЫЙРИ Габдулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Алимов, Җолканбай, Иркәбай, Шаши, Аусар, Думбылбай, Думбыл дивана, Ләкләк мәхзүм, Шалгай, Калвак мәхзүм-Шаши, Чичарә, Җиян, Мөштем, Юлаучы, Кәмпер.

Үзбәкләрнең карт әдибе. 1914 елда Ташкентта «Садаи Төркестан» газетасында «Чолгынбай» имзасы белән яза.

**426. КАДЫЙРОВ Закир.**

***Тәхәллүсләре:*** З. Кадыйр, Закир әл-Кадыйр.

Гарәпстанда укып, гарәпчә яхшы белгән укытучы һәм тәрҗемәче, революциягә кадәр Себердә, аннан соң Уфада «Тормыш» газетасы редакторы.

**427. КАДЫЙРОВ Әхәт Сәлими.**

***Тәхәллүсе:*** Әхкәм.

Татарстанда төрле урыннарда эшләп, төрле газеталарга язгалаган пенсионер.

**428. КАЗАКОВ Исхак Мостафа улы** (1876–1938).

***Тәхәллүсләре:*** И. Казаков, Исхак Казаков, К. Исхак*, Учитель-Тәтешле*, Ик*.

Казанда туа. Революциягә кадәр Тәтеш шәһәрендә укытучы була. Татар халкының «уяну» чорында укытучы буларак та, язучы буларак та күп хезмәт күрсәтә. Культура хәрәкәтенең үзәгендә торган фигураларның берсе. 1911 елны патша хөкүмәте тарафыннан төрмәгә ябыла. 1917 елда коммунист большевиклар сафына кереп, Мулланур Вахитов, Шәриф Манатовлар белән бергә Мәскәүдә җитәкче органнар төзеп, революцион хәрәкәт белән җитәкчелек итә. «Казанга сәяхәт» пьесасы һәм «Миллионнар саклау намына», Мәхмүд Бөдәйли белән бергә язган әсәрләрнең авторы. Аның иҗтимагый-политик вакыйгаларга бәйле, фәнни-гыйльми эшләргә карата язган монографияләре бар иде. Татарстанда партия һәм совет эшләрендә җаваплы урыннарда эшли.

**429. –**

**430. КАЗИМБЕК Мирза Александр Касыйм улы (Мирза Мөхәммәтгали).**

***Тәхәллүсе:*** А. Казембек.

Иранлы. 1827 елдан Казан университетының Көнчыгыш телләре кафедрасы профессоры һәм цензор. 1849 елда Петербург университетына күчерелә. Төрек-татар телендә язган әсәрләре бар.

**431. КАЙБЫШЕВ Мөхәммәтхәнәфи Сәет улы.**

***Тәхәллүсләре:*** М. Хәнәфи, Хәнәфи Кайбышев, «Теоретик»[1], Х. Кайбышев*, Хәнәфи*.

---

[1] Кирилл хәрефләре белән бирелгән.

Революциягә кадәр университет бетереп, врач була. Көчле журналист, «Таң» журналында күп матур әсәрләр яза. Чыгышы белән Уфа губернасы Бөре өязеннән. Казанда күз клиникасында ординатор булып эшли. 1913 елда ул хатыны белән Истанбулга китә, аннан «Кояш» газетасына мәкаләләр язып тора. [...]

**432. КӘЛИМУЛЛИН Илгиз.**

***Тәхәллүсләре:*** Кәлимуллин И., Илгиз Кәлимуллин.

1929 елның 20 мартында Татарстанның Апас районы Болын-Балыкчы авылында эшчеләр гаиләсендә туа. Аның гәүдәсенең түбән ягын паралич суга һәм ул урынга ята. Анасы бәләкәй чана-арбага күтәреп, аны мәктәпкә йөртә.

Илгиз дуслары ярдәме белән җидееллык мәктәпне тәмамлый. Аннан соң әдәбият белән кызыксына. Үзе дә шигырьләр яза башлый. 1950 елда аның берничә шигъри әсәре матбугатка чыга. Язучылар союзына керә. Русчаны яхшы белә. Аның шигырьләре рус телендә языла. Татар шагыйрьләренең әсәрләрен русчага тәрҗемә итә.

**433. КАМАЛЕТДИНОВ Әгъзам Камал улы** (1918–1943).

***Тәхәллүсләре:*** Ә. Камал, Камал Әгъзам.

Татарстанның Апас районы Үтәмеш авылында туа. Авылда мәктәп бетергәч, Казанга килеп, финанс-экономика техникумына керә. 1937 елны техникумны тәмамлый. Аннан соң укытучы була, 1938–1939 елларда «Чаян» һәм «Кызыл Татарстан» редакцияләрендә эшли. 1939 елда гаскәри хезмәткә алалар, Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак була. Язган берничә җыентыгы бар.

**434. КАМАЛОВ Барлас Хәмит улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Б. Хәмит, Х. Вәгыйз, Х. Канзәфәр, Барлас Камал.

1930 елның 17 гыйнварында Чистай шәһәрендә туа. Казанда югары белем алган журналист. Танылган язучы, радио комитетында эшли. Язган әсәрләре бар.

**435. КАМАЛОВ Габделбар.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. А., Атави, Алатавый*.

Татарстанда Алабуга өязе Юбраш авылында туа. Революциягә чаклы «Кызлар шулай кызык итәләр» пьесасын язган автор.

**436. КАМАЛЕТДИНОВ Габдулла Галиәкбәр улы** (1893–1933).
***Тәхәллүсе:*** Камал I.

Казанда сәүдәгәр гаиләсендә туа. 1910 елдан профессиональ артист була. «Сәйяр» труппасында эшли. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. 1924–1931 елларда үзбәк, төрекмән театрларында режиссер булып эшли. 1926 елда Үзбәкстан аңар «Хезмәт батыры» исемен бирә. 1932 елда Кузбасста театр оештырып, режиссер була. 1933 елда Казанда туберкулездан үлә.

**437. КАМАЛ III – Камал Ситдыйк улы Сәлахетдинов** (1899–1968).
***Тәхәллүсе:*** Камал III.

Әстерхан шәһәрендә туа. 1918–1924 елларда Әстерханда дәүләт театрында эшли. Ул Татарстанга килгәч, «Атказанган» һәм «Халык артисты» исемнәрен ала. Казанда үлә.

**438. КАМАЛЕТДИНОВ Габдрахман Галиәкбәр улы** (1901–1948).
***Тәхәллүсе:*** Камал II.

Казанда танылган артист, «Сулган чәчәкләр» пьесасында уйный.

**439. КАМАЛЕТДИНОВ Галиәсгәр Галиәкбәр улы** (1879–1933).
***Тәхәллүсләре:*** Г. Камал, Ишан, Ишангали, Кызыл, Һади, Зәйнәп Камалетдинова, Саип, Г. Казани, Сәгыйка, Яшенче, Азад, Алты бармак, Г. Мамай, Г. К., Г. К-ва, Г. Камалетдинова, Бадика.

Казанда сәүдәгәр гаиләсендә туа. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Аталары аны мулла итәселәре килеп, 20 яшенә чаклы укыталар. Русча укып, рус әдәбияты белән таныша һәм рус театрларына йөреп, сәнгатькә гашыйк була. Ул үзе пьесалар язарга тели башлый. Мәдрәсәне тәмамлагач, аталары аны 1900 елда Казанда «Җиңги Садыйк» дигән исем белән сәүдә итүче байның кызына өйләндерәләр һәм сәүдәгәр итәргә тырышалар. Галиәсгар, шул иректән файдаланып, «Мәгариф» исемле китап кибете ача. 1900 елда «Казани» имзасы белән «Өч бәдбәхет» исемле әсәрен бастыра. «Азат хатын» исемле газета чыгара башлый. Патша хөкүмәте ул газетаны япкач, Галиәсгар, Тукай белән берләшеп, «Яшен» сатирик журналын чыгара. Аны да туктаталар. Аннан соң Камал «Йолдыз» газетасында эшли. Ул берсе артыннан берсе чыгып торган драма әсәрләре яза башлый. Ниһаять, ул татар халкының яраткан шагыйре-әдибе, танылган драматургы, классик язучысы булып танылa.

**440. КАМАЛЕТДИНОВ Пәрвәзетдин Җамалетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Зыя Камал, Пәрвәз Камали.

Гарәпстанда укып кайтып, Уфа шәһәрендә «Галия» мәдрәсәсенең мөдире һәм укытучысы. «Галия»дән күп журналистлар, әдип, шагыйрьләр, революционерлар чыга. Гарәп теле галиме, дини китаплары бар. Белемле педагог, ачык фикерле зыялыларның берсе.

**441. КАМАЛЕТДИНОВ Сәлахетдин Камалетдин улы** (1885–1954).

***Тәхәллүсләре:*** Сәлах Камал, С. Камал.

Буа районы Иске Шәйморза авылында укый. Төркиядә рәссамлыкка укып кайтып, Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. Соңгы елларында Казанда университет көтепханәсенең мөдире. «Бухгалтер Фатыйх» дигән әсәр авторы.

**442. КАМАЛОВ Хисам Нуретдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Хисам Камалов, Х. Камалов.

1926 елның 14 апрелендә Татарстанның Әлмәт районы Кама-Исмәгыйль авылында туа. 1946–1950 елларда Бөгелмә педагогия техникумында, 1950 елдан Казан педагогия институтында [укый]. «Яңадан сафта» һәм «Чияле тау» исемле җыентыклар авторы.

**443. КАМАЛОВА Фатыйма.**

***Тәхәллүсе:*** Камалова Фатыйма.

1903 елда Оренбургта эшче гаиләсендә туа. Башта үзешчән драма коллективына катнаша. 1918 елда Оренбург профессиональ труппасына кушыла. 1919 елда Камал I белән фронт театрында эшли. 1922 елда Казанга килә. 1923–1924 елларда Әстерханда, аннан соң Үзбәкстанда һәм Таҗикстанда эшли. 1939 елда Казанга килеп, академия театрына керә. Казанда Татарстанның һәм РСФСР-ның атказанган артисткасы исемен ала.

**444. КАМАЛЕТДИНОВ Әгъзам** (1918–1943).

***Тәхәллүсләре:*** Әгъзам Камал, Камалетдинов Әгъзам.

Татарстанның Апас районы Үтәмеш авылында туа. 1937 елда финанс-экономика техникумын тәмамлый. «Чаян», «Социалистик Татарстан»да языша. 1943 елда Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак була.

**445. КАМАЛОВ Әнәс Галиәсгәр улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Әнәс Камал, Камали, Камали малае, Ә. Галиәкбәров, Шаркүз, Төкәмсез әкәм, Ә. Камал*, Әнәс К*, Кәли*.

1908 елның 20 февралендә Казанда язучы гаиләсендә туа. Мәктәп бетергәч, 1927 елдан башлап атасыннан күрмәкче яза башлый. Казанда театр техникумын тәмамлагач, редакцияләрдә эшли. Пьесалар яза. Байтак пьесаларның авторы. Яхшы тәрҗемәче.

**446. КАНДАЛЫЙ Габделҗаббар Габделмәҗит улы** (1797–1860).

***Тәхәллүсләре:*** Г. Кандалый, Габделҗаббар Кандалый.

Ульяновск өлкәсендә Кече Кандал районы Иске Кандал авылында туган мәшһүр шагыйрь. 17 ел буена иске мәдрәсәләрдә укып йөргәннән соң, 1824 елда үз авылына мулла була. Кандалый яшь чагыннан ук ул чордагы уку-укыту тәртипләренә риза булмый. Ул вакыттагы шигырьләр суфилык, динчелек рухында язылалар. Кандалый, шигырьләрендә реаль тормыш сурәтләрен кертеп, замана шагыйре булып китә.

**447. КАНЗАФАРОВ Локман Хәким.**

***Тәхәллүсләре:*** Локман Хәким, Канзафаров Локман.

1911 елда Уфада «Мәгълүмате җәдидә» журналында эшли.

**448. КАПКАЕВА Маһруй.**

***Тәхәллүсләре:*** Сания Гыйффәт, Кадрия.

Вакытлы матбугатта язгалый.

**449. КАПКАЕВ Габдулла** (1897–1946).

***Тәхәллүсләре:*** Капкаев Г., Габдулла Капкаев.

Әстерханда туа. Беренче татар театры студиясен тәмамлый, 1918–1921 елларда Әстерхан дәүләт театры артисты була. Аннан соң Баскынчак, Әстерхан, Саратов һәм Казан юридик органнарында эшли. 1919 елда партиягә керә. 1946 елда Казанда үлә.

**450. КАПКАЕВА (Кайбилова) Таибә.**

***Тәхәллүсе:*** Таибә Капкаева.

1903 елның 15 гыйнварында Әстерханда туа. Яшьтән үк сәхнәгә тартыла. 1919–1933 елларда Әстерханда эшли. Матур тавышлы җырчы. Соңгы елларда Казанда Академия театрында артистка була. Хәзер пенсиядә.

**451. КАПКАЕВ Гыйниятулла казый.**

***Тәхәллүсе:*** Капкаев Г.

Уфа шәһәрендә Диния нәзарәтендә революциягә кадәр бик күп еллар казый булып тора. Шәехзадә Бабич аның турында менә нәрсә яза:

И Гыйният! Сал җинаятьтән ниһаять зур бина!
Капкасына «Капкаев капкан» диеп яз зур гына!

**452. КАРАШ Гомәр.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Караш, Габдулла Мөштак, Мулла Казакаев, әл-Караши, Гомәр Караш баласы, Г. Караш улы, Казакъ Г. К.

Революциягә кадәр Уфада «Галия» мәдрәсәсен тәмамлый. «Шура» журналында актив языша. Казакъча язган әсәрләр: «Үрнәк», «Уйга килгән фикерләрем», «Көмеш», «Карлыгач», «Бәдәле хаҗ», «Ага тулпар», «Торымтай», «Шигырь», «Күкчеләр», «Уразакай», «Бала тулпар» вә башкалар. Революциядән соң Коммунистлар партиясе сафына керә. Казакъ контрлары аны ат койрыгына тагып өстерәтеп үтерәләр.

**453. КАРГАЛЫЙ – Әбелмәних Әбелфәез улы Габдессәламов** (1782–1826).

***Тәхәллүсләре:*** Әбелмәних, Ә. Каргалый, Әбелмәних әл-Бистәви.

Каргалы бистәсендә туа. Бохарада Ниязколый Төрекмәни шәкерте. «Таҗетдин[1] хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» әсәре 1889 елда[2] басыла.

**454. КАРИЕВ Багис Габделвахит улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Алтай, Багис, Карыйзадә, Телче, Ишетүче, Каләм каш.

Үзбәкнең карт язучы-әдипләреннән, фольклорчы, тәнкыйтьче. Кушаматлар җыючы.

**455. КАРИЕВ Габдеррәзак.**

***Тәхәллүсләре:*** Пиннати, Фикри.

Үзбәк язучысы.

**456. КАРИЕВ Әнәс Кари улы** (1920–1954).

***Тәхәллүсләре:*** Әнәс Кари, Ә. Уразай*.

---

[1] Дөресе: Тәрҗемәи.

[2] Дөресе: 1845 елда.

Татарстанның Азнакай районы Уразай авылында туа. 1939 елда Үзбәкстанның Үргәнеч шәһәрендә педагогия институтында укый. Аны бетергәч, шунда укыта. Аннан кайткач, Азнакайда укытучы була. Балалар шагыйре булып танылa. Шигырь, поэма җыентыклары бар.

**457. КАРИЕВ Габдулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Кариев, Г. Кариев, Г. Кари*.

Татарстанда Чистай өязе Мораса авылында туа. 1886–1920 елларда Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Коръәнне яттан белгән хафиз. «Сәйяр» татар театр труппасын оештыручы танылган артист. «Артист» исемле 2 пәрдәлек пьеса яза.

**458. КӘРИМОВ Газим.**

***Тәхәллүсе:*** Бөек.

Үзбәк язучысы.

**459. КӘРИМОВ Сәлим.**

***Тәхәллүсе:*** Хисрави.

Үзбәк язучысы.

**460. КАРИПОВ Кәшфеләсрар Мәгъдәнур улы** (1892–1918).

***Тәхәллүсләре:*** Татар, К. Карипов, К. Карип*, Кәшфи К*.

Башкортстанның Кушнаренко районы Байталлы авылында мулла гаиләсендә туа. Уфада «Госмания» мәдрәсәсендә укый һәм укыта. 1917 елда партия сафына керә. Шул ук елны Уфада «Алга» газетасында язышa. Революциягә кадәр «Акмулла», «Кармак» журналларында «Татар» имзасы белән иҗат итә.

**461. КАРИПОВ Низам** (1905–1942).

***Тәхәллүсләре:*** Н. Карипов, Низам Карипов.

Башкортстанның Мәчетле районы Иске Хәлил авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Авыл мәктәбен тәмамлагач, комсомолда эшли. 1927–1929 елларда Совет армиясендә була. Шунда партия сафына керә. 1929 елдан Казан рабфагында укый. Аннан соң ТКУны[1] бетерә. Аннары төрле редакцияләрдә эшли.

**462. КӘРИПОВ Голүм Мәгъдәнур улы.**

***Тәхәллүсе:*** Илгизәр.

[1] ТКУ – Татар коммунистлар университеты.

1897 елда Башкортстанның Кушнаренко районы Байталлы авылында туа. Свердлов шәһәрендә чыккан «Шәпи агай» журналында язышa.

**463. КАСЫЙМОВ Газим** (1891–1941) .

***Тәхәллүсләре:*** Үзбәк, Корыч, Касыймов Газим, Г. Касыймов.

Революциягә чаклы укытучы була. Революциядән соң партия сафына кереп, төрле шәһәрләрдә төрле эштә катнаша, газета чыгара. 1926 елларда Казанга килеп, обком аппаратында эшли. 1937 елда кулга алына. Язган әсәрләре бар.

**464. КАСЫЙМОВ Гали** (1893–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Гали Касыймов, Г. Касыймов.

Мәдрәсә бетергәч, русча укып фикере ачылган зыялы. Революциядән соң партия сафына кереп, революциянең башлангыч елларында большевиклык хәрәкәтен башлап йөрүчеләрнең берсе. Вакытлы матбугатка язышa, митингларда яхшы сөйли. Кызыл гаскәрдә командир. 1937 елда кулга алынып, шәхес культы корбаны була.

**465. КАСИМОВ Мөхәммәдйосыф.**

***Тәхәллүсе:*** Касыймов Йосыф.

1666 елда Федор Алексеевич патша вакытында рус дәүләт сәүдә илчесе булып, Һиндстанга барган дипломат.

**466. КАСЫЙМОВ Шамил.**

***Тәхәллүсләре:*** Касыйм Шамил, К. Шамил.

Татарстанның танылган артисты, күп шәһәрләрдә татар театры оештырып, күп кенә театр мәктәпләрендә укытып йөргән, тәҗрибәле педагог, «Җәмил» исемле 3 пәрдәлек, «Тычканга үлем, мәчегә күңел» исемле 2 пәрдәлек пьесалар авторы.

**467. КАШШАФЕТДИНОВ Миргази Солтан улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гази Кашшаф, Кашшаф Гази, Г. К., Кредо, Тайфун.

1907 елның 15 апрелендә Башкортстанның Кандыр районы Яңа Арслан[1] авылында туа. Авылда мәктәп тәмамлагач, 1925 елда Казанга килә. 1926–1929 елларда педагогия институтын тәмамлый. Партия сафына керә. 1947 елдан Казан университетының татар

[1] Дөресе: Яңа Арсланбәк авылы.

теле, әдәбияты кафедрасы мөдире. Белемле журналистлар җитештерде. Татар классиклары турында күп кенә әсәрләр язды. Туры сүзле тәнкыйтьче.

**468. КИЛБӘТОВ Зиннәтулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Килбәтов Зиннәт, З. Килбәти.

Революциягә кадәр Эстәрледә укытучы, «Шура» журналында язгалый. Бабич аны болай тасвирлый:

> Зиннәтулла килбәтең юк, хезмәтең юк дингә дә, милләткә дә.

**469. КАҺҺАР Габдулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Көләр**,** Иш**,** Яланаяк**,** Мәүләнгафур.

Үзбәк язучысы.

**470. КИЕКБАЕВ Җәлил Гыйниятулла улы** (1911–1968).

***Тәхәллүсләре:*** Киекбаев Җәлил, Д. Киекбай.

Башкортстанның Гафури районы Каран-Елга авылында крестьян гаиләсендә туа. 1935–1937 елларда Мәскәү педагогия институтының чит ил телләре (Германская филология) бүлегендә укый. 1946–1949 елларда Уфада авиация институтында немец теле укыта. Аннан соң офицер буларак Башкортстан университетының проректоры вазифасын башкара.

**471. КИЛДЕБӘКОВ Һади Нурмөхәммәт улы** (1887–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Һади Килдебәк, Һ. Килдебәк.

Революциягә кадәр мәдрәсәне тәмамлагач, бер авылда мулла була. Соңыннан патша хөкүмәте тарафыннан кулга алына. Төрмәдән котылгач, журналист, педагог була, вакытлы матбугатта языша. Революция булыр алдыннан Минзәлә земствосында башлык. Революциядән соң партия сафына кереп, җаваплы эшләр башкара. Көчле дәһри, белемле оратор. Бабич аның турында:

> Килдебәккә килде бит михнәт – мәшәкатьләр җиле,
> Җил белән ут сүнде бит. Кабынырмы ул утлар кире?, –

дип язды.

**472. КИЛДЕЕВ Абдрахман.**

***Тәхәллүсе:*** Маруз.

«Маруз» имзасы белән язган мишәр. Язучы.

**473. КИНЬЯБУЛАТОВА Катибә Кәрим кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** К. Катибә, Катибә Киньябулатова.

1920 елның 15 апрелендә Чиләбе өлкәсе Мәүлүт авылында туа. Авыл мәктәбен бетергәч, 1936–1939 елларда Уфага килеп, рабфакта укый. Аннан соң Башкортстан педагогия институтының тарих, тел, әдәбият факультетын тәмамлый, укытучы. 1961–1963 елларда Мәскәүдә югары әдәбият курсларында укып, Уфада «Башкорт кызы» журналының редакторы була.

**474. КИРЕЕВ Әхнәф Нури улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Кирәй Мәргән, Әхнәф Кирәй.

1912 елда Башкортстанның Мишкин районы Кыйгазы[1] авылында укытучы гаиләсендә туа. 1941 елда партия сафына керә. 1932 елда Уфага килеп, төрле редакцияләрдә эшли. 1946 елда Башкортстан педагогия институтында фольклор бүлеген бетерә. 1951–1954 елларда партия үзәге комитеты хозурындагы иҗтимагый фәннәр академиясендә аспирантура тәмамлый. 1963 елда докторлык диссертациясен яклап, профессор була. Башкортстан университетының татар теле кафедрасы башлыгы.

**475. КОЛӘХМӘТОВ Габделгафур Юныс улы** (1881–1918).

***Тәхәллүсләре:*** Г. К., Гафур Коләхмәтов, Татарин театрал, Г. Коләхмәтов*.

Пенза шәһәрендә сабын кайнату заводы тоткан кеше гаиләсендә туа. Казанда Учительская школаны бетергәч, Бишбалта бистәсендә укытучы. Татар яшьләре арасында демократик хәрәкәтнең җитәкчеләреннән. Язган әсәрләре: «Яшь гомер», «Ике фикер» (3 пәрдәдә), «Ник уйгандым», «Тарих сәхифәләре» китабы. Бабич аңа болай ди:

> Таҗ көлтәләп ник төяндең? Ник, уянгач, йокладың?
> Ник уянгач алга алган эшне әйдәп китмәдең?

**476. КОНОВ Минһаҗ Гайнетдин улы** (1892–1937)[2].

***Тәхәллүсләре:*** Минһаҗ Конов, М. Конов.

Татарстанның Питрәч районы Күн авылында туа. Авыл мәктәбендә русча өйрәнә, укытучы була. Язгалый. 1917 елда партия

[1] Дөресе: Кыйгазытамак.
[2] Татар энциклопедиясе: 1894–1934 еллар.

сафына кереп, җаваплы җәмәгать эшләрендә эшли. Дингә каршы язган әсәре бар.

**477. КОРБАНГАЛИЕВ Мөхетдин Хафиз улы** (1873–1941).

***Тәхәллүсләре:*** М. Корбангалиев, Корбангалиев Мөхетдин, М. Х.

Татарстанда Алабуга өязе Биектау авылында туа. Авыл мәдрәсәсен бетергәч, Казанда Учительская школаны тәмамлап, укытучы була. Тел, әдәбият турында дәреслекләр яза. Революциядән соң югары мәктәпләрдә укытып, профессор дәрәҗәсен яулый.

**478. КОРБАНГАЛИЕВ Нәҗип.**

***Тәхәллүсе:*** Нәҗип Корбангали.

Революциягә кадәр Чиләбе шәһәрендә ахун иде. Үз чорындагы журналларга мәкаләләр яза. Революциядән соң Токио шәһәренә – Япониягә эмиграция ясый.

**479. КОРБАНГАЛИЕВ Салих Мөхетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Салих Корбангалиев, С. Корбангалиев.

1900 елда[1] Казанда укытучы гаиләсендә туа. Мәдрәсә бетергәч, Казанда медицина факультеты тәмамлап, врач [була]. 20 нче елларда Татарстанда Наркомздрав (сәламәтлек саклау халык комиссары) булып тора. Ватан сугышы вакытында фронтта була. Аннан Ленинград шәһәренә кайтып, институтның хирургия бүлегендә эшли. Хәзер шул институтның җитәкче профессоры.

**480. КОРБАНГАЛИЕВ Харис.**

***Тәхәллүсе:*** Х. Корбангали.

Революциягә чаклы Троицк шәһәрендә укытучы. Вакытлы матбугатка язгалый.

**481. КОТЛЫ.**

***Тәхәллүсе:*** Котлы.

Котлы дигән имза белән «Мәктүп» исемле әсәр язган кеше.

**482. КРОТОВА (Әхсәнова) Бибинур.**

***Тәхәллүсе:*** Бибинур Кротова.

1913 елда Әстерханда туа. Җыр-биюгә сәләтле. Сүзгә оста. 1932 елда профессиональ театр артисткасы булып китә. 1968 елга чаклы шунда эшләп пенсиягә чыга.

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1901 елда.

**483. КРОТОВ Рамазан.**

***Тәхәллүсе:*** Кротов Рамазан.

1909 елда Әстерханда туа. 1931 елда артист булып эшли башлый. Ватан сугышына катнаша. Аннан кайткач, тагын артист булып эшли. 1965–1971 елларда Әстерхан театрында режиссер һәм художество җитәкчесе була. Хәзер пенсиядә.

**484. КРЫЙМОВ Миргазиян Галиулла улы** (1892–1945)[1].

***Тәхәллүсләре:*** Крыймов Миргазиян, М. Крыймов.

Сарман районы Мәндәл[2] авылында мулла гаиләсендә туа. Татарча мәктәпне бетергәч, русча өйрәнеп, рус әдәбияты белән таныша. Шигырьләр яза. Ватан сугышында гвардия полковнигы чинында һәлак була.

**485. КРЫЙМОВ Мансур.**

***Тәхәллүсләре:*** Крыймов Мансур, М. Крыйм*.

Революциягә кадәр, аннан соң да шигырьләр язган шагыйрь-журналист.

**486. КУГУШЕВ Исмәгыйль** (1897–1968).

***Тәхәллүсе:*** Исмәгыйль Кугушев.

Пенза губернасы Инсар өязе Салмуш[3] авылында туа. 1900 елда Әстерханга күчеп киләләр. Ул шунда мәктәптә белем ала. Беренче Герман сугышына алалар. Февраль революциясеннән соң Әстерханга кайта. 1921–1927 елларда Казан һәм Буа театрларында эшли.

**487. КУДАШЕВ Ильяс-Ашказарский** (1885–1928).

***Тәхәллүсләре:*** Ашказарский, Кудашев.

Танылган артист. Төрле шәһәрләрдә театр оештырып йөри.

**488. КУДАШЕВ Сәйфи Фәттахетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** С. Кудашев, С. Кудаш*, Кылыч, Вөҗдан, Кылычбай, Акбилет.

1895 елның[4] 3 ноябрендә Башкортстанның Акманай авылында[5] туа. Анасы – Шәмсебәдәр Гыйләҗетдин кызы. Уфада «Галия»

[1] Татар энциклопедиясе: 1891–1945 еллар.
[2] Дөресе: Мөэмин-Каратай авылы.
[3] Дөресе: Латышовка.
[4] Татар энциклопедиясе: 1893–1894 еллар.
[5] Татар энциклопедиясе: Келәш авылында.

мәдрәсәсен тәмамлый. Русча өйрәнә. 1925–1930 елларда Уфада «Октябрь» редакциясендә эшли. Революциягә кадәр үк төрле журналларда яза башлый. Хәзер бөтен төрки халыкларга танылган халык шагыйре.

**489. КУДАШЕВ Афзал.**

***Тәхәллүсләре:*** А. Кудашев, Афзал Кудашев.

1899 елда Башкортстан җирендә туган журналист һәм әдип.

**489а. КОРБАНОВ Таһир Яхъя улы.**

***Тәхәллүсе:*** Корбанов Таһир.

1910 елда Оренбург өлкәсе Кустанай авылында туа. Педагогия институтын тәмамлый. Хәзер педагогик фәннәр доценты.

**490. КУКЛЯШЕВ Салихҗан Бикташ улы.**

***Тәхәллүсе:*** Салихҗан Кукляшев.

1811 елда Бөгелмә өязендә туа. 1830 елда Оренбургта Неплюев исемендәге кадетский корпусны тамамлый. Рус, гарәп, фарсы телләрен яхшы белә. Пограничный комиссиягә тылмач итеп билгеләнә. Неплюев мәктәбендә үзе белән бергә укыган сабакташлары: Бикарслан Сөбханкулов, Мөхәммәтдин Мөслимов, Хәлил Әриповлар белән бергә Казанга киләләр. Анда гимназиядә шәрык телләре, университетта медицина фәннәре өйрәнәләр. Ул шәрык телләре бүлегенә күчә. 1836 елда, татарлардан беренче буларак, кандидатлык дәрәҗәсен яулый. Оренбургта Неплюев мәктәбендә укытучы һәм 1850 елда кыргыз (казакъ) мәктәбендә «смотритель» була. Казакъ галиме Ибраһим Алтынсарин Кукляшевта тәрбияләнә.

Кукляшев 1845 елда «Диване хикәяте татар» исемле әсәр, 1859 елда «Татар хрестоматиясе» һәм «Словарь к татарской хрестоматии» әсәрләрен бастыра. Ул мәгърифәтчеләрнең иң активы була.

**491. КУЛАЛАЕВ – Әхмәт Ишморатов.**

***Тәхәллүсе:*** Кулалаев.

«Сәйяр» труппасының танылган артисты.

**492. КОЛМӨХӘММӘТОВ Якуб Хәйрулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Якуб Колмөхәмматов, Колмөхәмматов Я.

1918 елның 7 октябрендә Башкортстанның Ишембай районы Канакаево[1] авылында крестьян гаиләсендә туа. Башкортстан шагыйре. Төрле редакцияләрдә эшли. Шигырь, поэма җыентыклары бар.

**493. КУЛИБАЕВ Сәләх Габит улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Сәләх Кулибай, С. Кулибай.

1910 елда Башкортстанның Әбҗәлилев районы Таһиров[2] авылында крестьян гаиләсендә туа, «Октябрь» журналында эшли. Танылган шагыйрь. Башкорт, татар, рус телләрендә шактый санда шигырь җыентыклары бар.

**494. КУЛИЕВ Ибраһим Габделвахит улы** (1885–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Ибрай Кули, ИК, Арамантов, И. Кули, Алтынбаев.

Тукаев, Фатих Әмирхановларның дусты, «Кояш» газетасының зур язучыларыннан, белемле журналист. «Җир байлыгы» исемле әсәрнең авторларыннан берсе.

**495. КУЛАТКЫЙ Каюм Гобәйдулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** К. К., К. Кулаткый, К. Гобәй.

Сембер өлкәсендә Кулаткы авылында туа. 1905–1917 елларга кадәр «Ил», «Йолдыз» газеталарында актив языша. 1914 елда Әстерханда «Халык» газетасы чыгара (нашире Шакир Баһаветдинов иде).

**496. КУНАКБАЕВ Хөсәен Әхмәтҗан улы** (1912–1943).

***Тәхәллүсе:*** Х. Кунакбаев.

Башкортстанның Әбҗәлил районы Таһир авылында крестьян гаиләсендә туа.

Башкорт шагыйрьләреннән берсе. Шигырь җыентыклары бар. 1937 елда кулга алына. Аннан котылгач, үз иреге белән фронтка китә. 1943 елда Ватан саклау юлында геройларча һәлак була.

**497. КУРМИЕВ Мөхәммәт Мирсаяф улы.**

***Тәхәллүсе:*** М. Курми.

1897 елның 2 маенда Башкортстанның Слак авылында туа, иске мәдрәсәдә укып, Коръән ятлый. Революциядән соң 1918 елда

---

[1] Канакай авылы.

[2] Таһир авылы.

партиягә керә. Ике мәртәбә кулга алынып, исән-сау кайта. Хәзер пенсионер. Уфада яши.

**498. КОРМАШИ Кәшиф.**

***Тәхәллүсләре:*** Кәшиф Кормаши, К. Кормаши*.

Туган елы, туган җире мәгълүм түгел. «Күңелемә», «Җәйге күл», «Кәшиф Кормаши шигырьләре», «Болында», «Ялгызлыкта», «Мәктәп» исемле әсәрләрнең авторы.

**499. КОРМАШИЛАР Сабирҗан һәм Зариф.**

***Тәхәллүсләре:*** Кормашилар.

«Шура» журналына Алма-Атадан мәкаләләр язып торучы ике туган укытучылар.

**500. КОРМАШИ – Әхмәт Мөхәммәтзариф улы Уразаев.**

***Тәхәллүсләре:*** Әхмәт Кормаши, Ә. Кормаши, Ә. Уразаев.

Курган өлкәсе Звериноголовск шәһәрендә туа. Бабалары – Татарстанның Әтнә районы Күшәр авылыннан. Туган елы билгесез. 1874 елда «Бүз егет», 1876 елда «Таһир – Зөһрә»не яза.

**501. КОРМАШИ Әхсәншәех.**

***Тәхәллүсләре:*** Кормаши Әхсән, Ә. Кормаши, Әхсән К.*, Хәсән К.*

Революциягә кадәр «Шура», «Таң» журналларында язышкан шагыйрь. «Ялгыз каен», «Күңелем», «Кыз балаларга нәсыйхәт», «Ай», «Әхсән Шәех Кормаши шигырьләре» исемле әсәрләр авторы.

**502. КУЗЕЕВ Рамазан Усман улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Р. Кузеев, Рамазан Кузеев.

Башкортстанның күренекле галиме. Фәнни әсәрләр авторы.

**503. КОРБАНОВ Гомәр.**

***Тәхәллүсләре:*** Әфләтун, Мулла Хайратый.

Үзбәк язучысы.

**504. КУРСАВИ Габденнасыйр** (1776–1818[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Габденнасыйр, Г. Курсави.

[1] Татар энциклопедиясе: 1776–1812 еллар.

Казан губернасы Корса авылында туа. Башта Мәчкәрә мәдрәсәсендә укый, аннан соң Бохарага барып, күп еллар укытучы була. Дини хорафат белән килешә алмый. «Әл-иршад лил-гыйбад» («Туры юлга өнләү») исемле гарәпчә китап язып, кыю фикерләр әйтә. Аның өчен Бохара әмире җәзалауга хөкем итә. Курсави аннан кача. Хаҗга китеп барганда, Истанбулда вабадан үлә.

**505. КУТУЕВ Гадешшәкүр Мөхәммәт улы**[1] (1903–1945).

***Тәхәллүсләре:*** Гадел Кутуй, Казбек, Ут малай, Һималай, Руслан, Тимерче малае, Әкәлим, Гөләй, Г. Кутуй.

Саратов өлкәсе Кузнецк районы Татар Кынадысы авылында туа. 1920 еллар башында Казанга килеп, педагогия институтында укый. Шигырьләр яза башлый. Футурист булып хаталанып та йөри. «Казан», «Әнкә җан», «Шатлык җырлары», 1939 елда[2] «Тапшырылмаган хатлар» исемле әсәрләр яза. Бөек Ватан сугышына үзе теләп китеп, 1945 елда батырларча һәлак була. Татарның яраткан шагыйре, танылган драматургы.

**506. КУШАЕВ Гобәйдулла Габидулла улы** (1902–1939)[3]**.**

***Тәхәллүсе:*** Г. Кушай.

«Кызыл кичәләр» исемле сәхнә әсәрен яза.

**507. КУШАЕВ Ибраһим Йосыф улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Кушаев Ибраһим, Ибраһим Йосфый*, И. Йосфи*, Йосыф солдат*, Солдат Йосфый*.

1896 елда Казанда туа. 1917 елда «Кызыл көрәшче» газетасында языша. 1918 елда партия сафына керә. 1914–1919 елларда сәхнәгә катнаша. Укытучы. 1919–1920 елларда Казанда гаскәри курсларда укый, «Кызыл армия» газетасында языша. Курсларны бетергәч, Урта Азиягә басмачлар белән көрәшкә китә. Анда бизгәк белән авырып, госпитальгә керә. Шуннан хәбәре юк.

**508. КӘРИМ Рәхим.**

***Тәхәллүсе:*** Кәрим Рәхим.

Тугыз пәрдәлек «Бүз егет» трагедиясен язган.

[1] Татар энциклопедиясе: Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев.

[2] Дөресе: 1935 ел.

[3] Татар энциклопедиясе: 1902–1937 еллар.

**509. КӘРИМОВ Габдулла Әхмәтвәли улы** (1901–1936)[1].

***Тәхәллүсе:*** Ярлы Кәрим.

Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында мулла гаиләсендә туа. 1916 елда Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. 1919 елда партия сафына керә. Төркестан фронтында «Кызыл маяк» газетасында басыла башлый. 1921–1922 елларда Казанда Коммунистлар университетында укый. 1936 елда Уфада үлә. Ает авылында музее эшли.

**510. КӘРИМОВ Камил Гыйльман улы** (1892–1949).

***Тәхәллүсләре:*** Камил Кәримов, К. Кәримов.

Татарстанда Миңнебай авылында туа. 7 яшендә Оренбургка килеп, «Хөсәения», аннан соң реальное училищеда укый. 1913 елда юридик факультет тәмамлый. Революциядән соң Оренбургта өч еллык тәгълим-тәрбия курсларында директор булган. Казанга 1926 елда килә. Институтта тарих укыта. Шәрык әдәбияты белән яхшы таныш укытучы. Казанда Дәүләт арбитраж судында юрист булып эшли.

**511. КӘРИМОВ Марат Нәби улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Марат Кәрим, М. Кәрим.

1930 елның 9 гыйнварында Башкортстанның Зианчура районы Күгәрчен авылында укытучы гаиләсендә туа. Авыл мәктәбен тәмамлагач, Оренбург өлкәсе Сары авылындагы татар-башкорт педагогия техникумын тәмамлый. Төрле редакцияләрдә эшли. 1954–1956 елларда Мәскәүдә комсомол мәктәбендә укый, андагы журналистлык факультетын тәмамлый. 1961–1964 елларда «Сәнәк» редакциясендә эшли. Башкорт телендә 6 шигырь җыентыгы басылып чыга.

**512. КӘРИМОВ Мостафа Сафа улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Мостай Кәрим, М. Кәримов.

1919 елның 20 ноябрендә Башкортстанның Чишмә районы Келәш авылында крестьян гаиләсендә туа. Мәктәпне тәмамлагач, Уфада рабфакта укый. Бөек Ватан сугышы башлану белән, Мостай Кәрим фронтка китә. 1942 елда каты җәрәхәтләнә. Аннан кайткач, бөтенләй иҗат эшенә бирелә. 1951–1962 елларда Башкортстанның

---

[1] Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда. 2 т. / төз.: Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. Б. 716.

Язучылар союзы рәисе була. 1955 елда Бөтенроссия югары совет депутаты итеп сайлана. Башкортның «Халык шагыйре» исеме алган данлыклы шагыйрь. Язган әсәрләре күп.

**513. КӘРИМОВ Фатих Гыйльман улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Фатих Кәрими, Ф. К., Каләм, Карт эшче, Вәкилә, Озын колак, Мөхәммәтфатих Кәрими, Выборщик, Кәрими М-фатих*.

Бөгелмә өязе Миңнебай авылында туа. [Атасы] – Гыйльман бине Ибраһим Юмәт бине Габделкәрим (1870–1937). [Фатих] Чистай шәһәрендә Закир хәзрәт мәдрәсәсендә укый. Беркадәр русча укыгач, Төркиягә барып белем ала. Аннан соң Оренбургка килеп, матбага ача. «Вакыт» исемле газета чыгара. Гаять көчле язучы, үткен каләмле, тәҗрибәле журналист, зур эрудицияле әдип. Язган әсәрләре: «Мөгаллим әфәнде, кашыма башыңны», «Бер шәкерт илә бер студент», «Җиһангир мәхзүмнең авыл мәктәбендә укуы», «Кайнана», «Салих бабайның өйләнүе», «Тәрбияле мужик», «Безнең кидеш», «Аннан-моннан», «Мирза кызы Фатыйма», «Хыялмы, хакыйкатьме», «Өмет пароходында», «Күңелсез көннәр» вә башкалар.

**514. КӘРИМОВ Фатих Әхмәтвәли улы** (1909–1945).

***Тәхәллүсләре:*** Фатих Кәрим, Рим, Дим, Ф. К., Мирәк, Фамирәк.

Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында мулла гаиләсендә туа. Авыл мәктәбен бетергәч, 1925 елда Казанга килеп, Җир эшләре техникумында укый. 1929 елда тәмамлый. 1931– 1933 елларда Совет армиясенә алына. 1941 елда Бөек Ватан сугышына китә. Шигырь һәм поэма җыентыклары бастырган данлыклы шагыйрь.

**515. КӘРИМОВ Хәниф Кәрим улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Кәримов Хәниф, Хәниф Кәрим.

1910 елның 25 июлендә Башкортстанның Кыйгы районы Югары Киги[1] авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1929 елда Уфага килеп, анда халык мәгарифе институтында укый. 1932–1934 елларда Совет армиясе сафында була. 1937 елда «Октябрь» журналының редакторы. Ватан сугышында башыннан ахырына кадәр фронтта була.

[1] Югары Кыйгы авылы.

1946–1959 елларда Язучылар союзының җаваплы секретаре. 25 ләп шигырь-поэма җыентыклары. Башкортстанның танылган шагыйре.

**516. КӘРИМОВ Хөснетдин Минһаҗетдин улы** (1887–1965).

***Тәхәллүсләре:*** Хөсни Кәрим, Х. Кәрим, Х. К., Күзәтүче, Кайгыртучы.

Бөре өязе Туймазы авылында туа. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә белем ала. Аннан соң русча укып, учитель була. Вакытлы матбугатта шигырьләр яза. Революциядән соң партия сафына керә. 1919 елны аклар аны кулга алалар. Ул аннан Кызыл армия ярдәмендә котыла. Казанга килгәч, төрле җаваплы урыннарда эшли. Язган әсәрләре бар.

**517. КӘРИПОВ Низам Кәрип улы** (1905–1942).

***Тәхәллүсләре:*** Низам Кәрипов, Н. Кәрипов.

Башкортстанның Мәчетле районы Иске Хәлил авылында крестьян гаиләсендә туа. 1929 елда Казанга китеп, рабфакта укый. Аннан соң Казан университетының журналистика бүлеген бетерә. 1939 елда Уфада Язучылар союзы секретаре. Ватан сугышында батырларча һәлак була.

**518. КӘРАМ Габдрахман Хәбибулла улы (Рәхмәтуллин)** (1878–1947).

***Тәхәллүсләре:*** Г. Кәрам, Габдрахман Кәрам, Г. Рәхмәтуллин.

Яшьтән ятим калып, Мифтах Иманкулов тәрбиясендә үсә. Мәктәп бетергәч, Истанбулга китеп, гали мәктәпне тәмамлый. Журналист, белемле язучы. Герман Вамбериның биографиясен яза. Солтан Рахманкулов белән русча-татарча лөгать төзиләр. «Аулакта көрешү» исемле әсәре бар.

**519. КӨЕКОВ Мөхәммәтгали Габдессалих улы Чокрый** (1826–1886[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Гали Чокрый, Гали Бирскәви, Г. Чокрый.

Башкортстанның Тәтеш районы Иске Чокыр авылында туа. 1883 елда «Шәмгыз-зыя»исемле әсәрен, 1889 елда «Мәдхе Казан» әсәрен бастыра. Аның 100 ләп әсәре була. Шуның унбере генә басыла. 1872 елда «Хаҗнамә»не яза, шул кульязма булып кала.

[1] Татар энциклопедиясе: 1826–1889 еллар.

**520. КҮЛТӘСИ – Шәмсетдин Мөхәммәт бине Нурмөхәммәт әт-Таһири** (1856–1932)[1].

***Тәхәллүсе:*** Шәмсетдин Күлтәси.

Арча районы Күлтәс авылында мулла гаиләсендә туа. Атасыннан укып, русча да өйрәнә. «Һәйяте җәдидә», «Хикмәте җәвидә» исемле әсәрләре бар.

**521. ЛАТЫЙПОВ Галимҗан Шакирҗан улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Галимҗан Латыйпов, Г. Латыйф, Г. Л*.

1912 елның 20 гыйнварында Башкортстанның Чакмагыш районы Яңа Дөмәй авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Рабфак бетергәч Казанга килеп, финанс-экономика институтында укый. 1939 елны институтны тәмамлый. 1936–1937 елларда беренче шигырьләре басылып чыга. 1939 елда «Юл буйлап», «Хезмәт иртәсе», «Якты көннәр», «Яз башлана», «Учак янында» исемле шигырь җыентыклары дөнья күрә. Аның шигырьләрен балалар да яратып укыйлар. Русчага аударылганнары да бар.

**522. ЛАТЫЙПОВ Әхмәтгариф Насыйбетдин улы** (1886–1962).

***Тәхәллүсләре:*** Гариф Латыйпов, Г. Латыйпов, Г. Л.

Татарстанның Питрәч районы Шәле авылында туа. Казанда яши. Гомер буе корреспондент, революциягә кадәр «Йолдыз», «Кояш» вә башка газеталарда, революциядән соң «Татарстан» газетасының хәбәрчесе була.

**523. ЛИМАНОВ Исмәгыйль.**

***Тәхәллүсләре:*** И. Лиманов.

1914 елда Петербургта «Милләт» исемле газета чыгара. Башка газеталарга да язып тора. Үз чорының җәмәгать эшлеклесе.

**524. ЛОТФУЛЛИН Гадел.**

***Тәхәллүсе:*** Лотфи Гадел.

1913 елда «Йолдыз», «Кояш» газеталарында татар әлифбасы хакында, тәрбияләр турында тәнкыйди мәкаләләр белән чыга. 1915 елда «Яшьлек искә төшәр» исемле әсәрен Казанда «Мәгариф»тә бастыра. Беренче Герман сугышында катнаша. Кайтуы билгеле түгел.

[1] Татар энциклопедиясе: 1856–1930 еллар.

**525. ЛОТФУЛИН Гасыйм Фатыйх улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Лотфый, Гасыйм Лотфый.

1900 елның 16 февралендә Арча районы Иске Өҗем авылында туа. 1918 елга кадәр мәдрәсәдә укый. 1924 елга кадәр авылда укыта. Аннан соң югары белем алыр өчен Казанга килеп, башта Казан педагогия институтын, аннан соң университетның география факультетын тәмамлый. 1941 елда Ватан сугышына китә. Кайткач, техникумнарда укытучы була. Язган дәреслекләре һәм хикәя җыентыклары бар.

**526. ЛЬВОВ Михаил (Рифгать Дәүләтша улы Габитов).**

***Тәхәллүсләре:*** Р.Г. Габитов, М. Львов, Львов Михаил.

Башкортстанда Нәсибаш авылында туа. Хәзер Мәскәүдә яши. Русча шигырьләр яза. Яратып укыйлар. Татар-башкорт язучыларының шигырьләрен дә, башка әсәрләрен дә русчага тәрҗемә итә.

**527. МАЗУНОВ Мөнир Хәсән улы** (1918–1969[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Мөнир Мазунов, М. Мазунов.

Пенза өлкәсе Лопатин районы Иске Карлыган авылында туа. «Җидееллыкны» бетергәч, Әстерханда педагогия мәктәбен тәмамлый. 1939–1946 елларда Совет армиясендә хезмәт итә. Сугыштан кайткач, иҗат эшенә тотына. «Безнең тавыш», «Яшьлек җыры», «Син дә белергә тиеш» исемле шигырь китаплары басылып чыга. Танылган шагыйрь.

**528. МӘДЬЯКУП – Диванов Мәдьйосыф.**

***Тәхәллүсе:*** Чакар.

Үзбәк язучысы.

**529. МАКСУДОВ Баһаветдин Җәлалетдин улы.**

***Тәхәллүсе:*** Баһаветдин Максудов.

Казый улы. Уфада яши. Һәр эшкә сәләтле, оста кеше була. Мәктәпләргә күргәзмә әсбаплары, агачтан кырып, төрле җиһазлар ясый. Типографиядә эшли.

**530. МАКСУДОВ Гаяз Гыйсам улы** (1897–1940[2]).

***Тәхәллүсләре:*** Г. Максудов, Гаяз Максуди, Г. М.

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1918–1987 еллар.

[2] Татар энциклопедиясе: 1891–1942 еллар.

Казан губернасы Лаеш өязе Югары Кибәхуҗа авылында туа. Мәдрәсә тәмамлагач, Гарәбстанга китеп, америкaн көллиятенең математик факультетын тәмамлый. Гарәпчә, французча, русча, төрекчә телләр галиме иде. 1921 елда Казанда «Мәгариф» һәм «Безнең юл» журналларында редактор иде. Шәхес культы корбаны булды.

**531. МАКСУДОВ Мәхмүд Гыйсам улы** (1900–1963[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Мәхмүд Максуд, М. Максуд, Нур, Тәлгать, Кызыл солдат, Макс, Әптери малай, Мим, М., М. М*.

Казан губернасы Лаеш өязе Югары Кибәхуҗа авылында туа. Малмыжда башлангыч, урта мәктәпне тәмамлый. 1919 елда Коммунистлар партиясе сафына керә. Мәскәүдә университетның әдәбият бүлеген тәмамлый. 1926–1928 елларда Казанда нәшрият редакторы. 1941 елда Бөек Ватан сугышына китә. Анда политрук була. Язган шигырьләре һәм хикәя җыентыклары бар.

**532. МАКСУДОВ Мөхәммәдгалим Рәхим улы.**

***Тәхәллүсе:*** Галим Максудов.

Ханкирмәнле[2]. 1897 елда Петербургта матбага ачкан кеше.

**533. МАКСУДОВ Ниязколый** (1887–1970).

***Тәхәллүсләре:*** Нияз Колый, Нияз Максуди.

Мисырда Америка көллиясен тәмамлап кайта. Революциягә кадәр Троицк шәһәрендәге Яушевлар мәдрәсәсендә укытучы һәм мөдир. 1920 елны Харбинга китеп, аннан Америкага бара. Петербург университетында профессор һәм шунда мулла була. (Америкадан килгән татарлар сөйләгән сүз.)

**534. МАКСУДОВ Садретдин Низаметдин улы** (1873–1945[3]).

***Тәхәллүсләре:*** Садри Максуди, С. Максуди, Җанбай, Ди-ди.

Казан өязе Суыксу[4] авылында туа. Казанга килеп, Галләм хәзрәт мәдрәсәсендә укый. Аны бетергәч, Учительская школаны тәмамлый. Соңра Парижга китеп, дүрт ел буена французча өйрәнә. Казанга кайткач, 1906 елда Дәүләт думасына депутат итеп сайлана. Думада кадетлар партиясе яклы була. Бөек Октябрь революциясеннән

[1] Татар энциклопедиясе: 1900–1962 еллар.

[2] Ханкирмәнле – Касыйм шәһәреннән.

[3] Татар энциклопедиясе: 1878–1957 еллар.

[4] Дөресе: Ташсу авылы.

соң татар милләтчеләренең җитәкчеләреннән берсе. Аклар белән чит илләргә китеп, ак эмигрант була.

**535. МАКСУДОВ Садыйк Мөбин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Максуд Сөндекле, М. Сөндекле, Сөндекле М.

1904 елның 15 сентябрендә Татарстанның Олы Тархан районы Сөндек авылында крестьян гаиләсендә туа. 1924 елда Донбасста эшли. 1930 елда партия сафына керә. Шул ук елны «Күмер тавышы» исемле шигырьләр җыентыгы басыла. Бөек Ватан сугышында катнаша. Иллегә якын шигырь-поэма җыентыклары авторы. Уфада яши.

**536. МАКСУДОВ Әхмәтһади Низаметдин улы** (1868 – 1941).

***Тәхәллүсләре:*** Әхмәтһади Максуди, Һади Максуди, Һ. М., Һәмзәви, Кәүкәб, Хәерби.

Казан өязе Суыксу[1] авылында туа. Казанда мәдрәсә бетергәч, Төркиягә китеп, дәрелфөнүндә укый. Яңа ысул белән укыту эшен өйрәнә. Төрекчә, гарәпчә, рус телләрен яхшы белә, кайткач, Кырымда Бакчасарайда яңача мәктәп ачып, яңа ысул (җәдидчә) белән укыта, дәреслекләр яза. 1908 елда Казанга кайтып, «Йолдыз» исемле газета чыгара.

**537. МАКСУДОВА Зәйнәп Габделҗәмил кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Зәйнәп Максудова, З. Максудова, З. Газизова.

Биографик фән галимәсе. Әгерҗе районы Уразай авылында туа. «Буби» мәдрәсәсендә укый. Аннан соң Ташкентка китеп, анда университетта шәрык телләре, тарих факультетында укый.

**538. МАЛИКОВ Дөлфәт Госман улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Зөлфәт, З. Маликов, Буран.

1947 елның 3 гыйнварында Татарстанның Мөслим районы Яңа Сәет авылында туа. «Чаян» редакциясендә эшли. Шигырьләр яза.

**539. МАЛИКОВ Зыя.**

***Тәхәллүсләре:*** Зыя Маликов, З. Маликов.

1918 елда Никола Березовкада сул эсэрлар газетасы – «Хәбәрләр» чыгара. Нашире – Мәхмүт Тимербаев.

---

[1] Ташсу авылы.

**540. МӘРЬЯМ Кугушева.**

***Тәхәллүсе:*** Мәрьям Кугушева.

1916 елда «Алаш» исемле казакъча газета чыгара.

**541. МАЛИКОВ Һади Кәрим улы** (1894–1973).

***Тәхәллүсе:*** Һади Маликов.

Татарстанда Тәтеш өязе Кариле авылында туа. 1905–1907 елларда Тәтеш шәһәрендә учитель Исхак Казаковта русча укый. Соңра Казанга килеп, сәүдә мәктәбен тәмамлый. 1917 елда Коммунистлар партиясе сафына керә. 1918 елда Мулланур Вахитов белән бергә эшли. Казанда буржуаз республиканы бетерүдә катнаша. Татарлардан гаскәри бүлек төзү эшенә катнаша. Мәскәүдә хәрби академияне тәмамлый. 1921 елда дипломат булып китә. Төркиядә, Иранда, Кытайда хәрби атташе була.

**542. МАЛИКОВ Әдип Малик улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Әдип Маликов, Маликов Әдип.

1921 елда Башкортстанның Яңавыл районы Югары Чат авылында туа. 1939 елда Пермь педагогия мәктәбен тәмамлый. Армиягә алына. Армиядән кайткач, Мәскәүдә институтның әдәбият бүлеген бетерә. Язган шигырь җыентыклары бар. Танылган шагыйрь.

**543. МАМИН Хәсән.**

***Тәхәллүсләре:*** Хәсән Мамин, Х. Мамин.

1914 елда Ташкентта Яушевларда эшли. Приказчиклар оешмасы башлыгы. 1917 елда Оренбургта «Эшче» газетасы чыгара.

**544. МАМИШЕВ Якуб.**

***Тәхәллүсе:*** Якуб Мамишев.

Революциягә кадәр «Минем дә бар язганнарым» исемле әсәр яза.

**545. МӘМЛИЕВ Нурмөхәммәт казый.**

***Тәхәллүсе:*** Н. Мәмлиев.

Революциягә чаклы Уфада Диния нәзарәтендә казый булып тора. «Мәгълүмат», «Дин вә мәгыйшәт» журналларында язышa.

**546. МӘМЛИЕВ Төхфәтулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Т. Мамлин, Житель, Учитель, Мамли.

Уфа мирзаларыннан. Казанда Учительская школаны тәмамлый. 1905–1906 елларда социалист революционер (эсер) «таңчылар»ның берсе, «Таң йолдызы»нда шигырьләр, мәкаләләр яза. [...]

**547. МАНАТОВ Шәриф Әхмәтҗан улы** (1892–1936).

***Тәхәллүсләре:*** Шәриф Манатов, Ш. Манатов, Гайнетдин, Ш. Әхмәтҗанов.

Башкортстанның Учалы районы Манат авылында (Ялан кантоны) урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Учительская школаны бетергәч, Швейцариягә китеп, гали[1] белем ала. 1920 елда Бәхетгәрәй Шәфиев белән Төркиягә делегат итеп җибәрәләр.

Революциядән соң 1918 елда партия сафына керә. Мәскәүдә Мулланур Вахитов, Исхак Казаковлар белән бергә совет, партия оешмалары төзешендә актив эшли. 1936 елда Башкортстанның Учалы районы Көчек авылында туберкулездан үлә.

**548. МАНГУШЕВ Габдерахман.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Мангуш, Бикморза.

Язган әсәрләре: «Килен», «Мөхәррир», «Бәхет эзләгәндә».

**549. МАННАПОВ Минһаҗ Низаметдин улы** (1893–1940).

***Тәхәллүсләре:*** М. Маннапов, М. М.

Троицк шәһәрендә бүрек тегүче гаиләсендә туа. «Акмулла» журналында шигырьләр яза.

**550. МАННУРОВ Шәйхи Фәрмулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Шәйхи Маннур, Ш. Маннур, Шиһап солдат.

1905 елның 15 гыйнварында Татарстанның Мамадыш районы Тулбай авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1921 елда Себергә күчәләр. «Коммунист», «Урак-чүкеч» газеталарында языша. 1922–1923 елларда укытучы була. 1928 елда «Тайга төбеннән», «Чиккән сөлге», «Елмаюлы кояш турында», «Чуен ташкыннары» җыентыклары чыгара. 1937 [елда] педагогия институтын тәмамлый. 1939 елда «Хезмәт Кызыл байрагы» белән бүләкләнә. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Еллар моңы», «Кайнар йөрәкләр», «Җиңүчеләргә сәлам», «Җир ананың сылу кызы», «Муса Җәлил» китапларын язып бастыра.

[1] Гали – югары.

**551. МАНСУРОВ Борһан Хөснетдин углы** (1889–1942).

***Тәхәллүсләре:*** Борһан Мансуров, Б. Мансур, Б. М., Хөснетдин малае.

Саратов губернасы Хвалынь өязе Иске Зеленай авылында туа. Әстерхан шәһәрендә «Низамия» мәдрәсәсендә укый. Революциягә кадәр вакытлы матбугатта язгалый. 1918 елда партия сафына керә. 1919 елда Мәскәүдә җыелган Шәрык халкы коммунистларының 2 нче съездында делегат. 1921 елда Казанда Татарстан Үзәк башкарма комитеты рәисе була. Төрле журнал һәм газеталарда язышa һәм редакторы була.

**552. МАНСУРОВ Гасыйм Мөхәммәдгатау улы** (1894–1957[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Г. Мансуров, Г. М., Гата малае.

Әгерҗе районы Песса авылында мулла гаиләсендә туа. «Буби» мәдрәсәсендә укый, 1918 елда партия сафына керә. Иҗтимагый-сәяси эшләрдә, җаваплы урыннарда эшли. Журналист һәм чекист. Язган китаплары бар.

**553. МАНСУР Гаяз** (1917–1943).

***Тәхәллүсе:*** Мансур Гаяз.

Мари республикасы Бәрәңге районы Бәрәңге авылында туа. Педагогия мәктәбен тәмамлап, укытучы булып эшли. Бөек Ватан сугышында фронтта партия сафына керә. 1943 елда батырларча һәлак була.

**554. МАНСУРОВ Зыя Мансур улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Зыя Мансур, З. Мансур*, З. Заманов*.

1916 елда Башкортстанның Дүртөйле районы Җитмәк[2] авылында крестьян гаиләсендә туа. 1950 елда беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыга. 1939–1946 елларда фронтта була.

**555. МӘХМҮДОВ Мөхәммәтгали** (1824–1891).

***Тәхәллүсләре:*** Мәхмүдов Гали, Г. Мәхмүдов.

Казан губернасы Казан өязе Мәмдәл волосте Шөләнгер авылында крестьян гаиләсендә туа. Казанда Хәйрулла хәзрәт мәдрәсәсендә

[1] Татар энциклопедиясе: 1894–1955 еллар.

[2] Дөресе: Җитембәк авылы.

укый. Александр Казембек, аның кабилиятен[1] белеп, матур язуына игътибар итә. Аны университетта каллиграфия һәм бүтән фәннәр укытучысы итеп билгелиләр. Парадный окладтан азат ителә. Алтын медаль белән бүләкләнә. Шәрык телләрен яхшы белә. 1857 елда «Татар телен өйрәнүдә гамәли кулланма» әсәрен яза.

**556. МӘХМҮТОВ Һәнүз Котдус углы.**

***Тәхәллүсе:*** Һәнүз Мәхмүтов.

1933 елның 15 июлендә Башкортстанның Яңавыл районы Таш Елга авылында туа. 1963 елда Казан дәүләт университетының тарих, тел, филология факультетын тәмамлый. Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтында аспирантура бетерә.

**557. МӘХМҮДОВ Хөҗҗәтелхәким Давыт улы** (1885–1930).

***Тәхәллүсләре:*** Х. Мәхмүт, Сибирияле, Х.Д. Мәхмүдов, Хөҗҗәтелхәким*.

Себерле. Революциягә чаклы Уфада Диния нәзаратендә казый була. 1913 елда Оренбургта «Ислам көтебханәсе» исемле журнал чыгара. «Вакыт», «Йолдыз» газеталарында еш язышып тора. Яшь табигатьле, яшь фикерле кеше.

**558. МИДХӘТ Әхмәт Ситдыйк улы.**

***Тәхәллүсе:*** Әхмәт Мидхәт.

1890 елда Казанда туа. Мәдрәсә бетергәч, төрле мәктәпләрдә укытучы була. Революциядән соң радиода эшли.

**559. МИЛЛЕБАЕВ Ганиҗан.**

***Тәхәллүсләре:*** Әмили Гали, Сурати, Инҗик.

Үзбәк язучысы.

**560. МИНИЕВ Гатаулла.**

***Тәхәллүсе:*** Миниев Гатаулла.

Туган вакыты, торган җире нәмәгълүм[2]. 1904 елда «Мәҗмәгыйльәмсал яки гүзәл мәкальләр» исемле китап бастыра. Китабына 2910 данә мәкаль кергән.

[1] Кабилиятен – сәләтлелеген.

[2] Нәмәгълүм – билгесез.

**561. МИНГАЗИЕВ Ибраһим Зариф улы** (1907–1970[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Ибраһим Гази, Гази Ибраһим, Зәлин, Ибрай Гази, Кәкәмәрун, Габделгаттарлар күршесе, Гази Край*, И. Гази*.

5 февральдә Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Карамалы авылында крестьян гаиләсендә туа. Балалар йортында тәрбияләнә. 1923 елда комсомолга керә. 1929–1931 елларда комсомол обкомында агитация бүлеге башлыгы була. Төрле редакцияләрдә эшли. Язучылар союзы рәисе була. Язган әсәрләре күп. Аларның шактые рус вә башка телләргә тәрҗемә ителә.

**562. МИРӘҮЛӘНБАЙ улы Габдулла (Габдулла Әүлани).** *Кара:* 1130.

***Тәхәллүсләре:*** Әүлани, А. Б., Араб нажат, Сүрәйә, Шөһрәт, Һиҗрәт, Әбелфәиз, Абил, Чигәбай, Чикәбай, Җал, Өндәмәс, Шапалак.

Үзбәк халкының танылган шагыйре. Ташкентлы. 1914 елда Ташкентта чыккан беренче үзбәкчә «Садаи Төркестан»ның редакторларыннан берсе.

**563. МИРВӘЛИЕВ Тимергали Мирвәли улы** (1864–1930).

***Тәхәллүсләре:*** Тимер калтай, Мирвәли калтай, М. Калтай, М.К. Калтай.

Уфа өязе Покровск районы Калтай авылында туа. «Ялт-Йолт», «Кармак», «Шура», журналларында шигырьләр, көлке мәкаләләр белән катнаша. Шагыйрь Шәехзадә Бабич аның турында:

> Мирзавәли Калтай ахун шалтай да балтай селкенә,
> Юкка мескен җилпенә, тырмашмый илнең күркенә.

**564. МИРЗАҺИДОВ Әсгать Мәсгуть улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Әсгат Мирзагитов, Ә. Мирзагитов.

1925 елның 13 октябрендә Башкортстанның Туймазы районы Бикмәт авылында крестьян гаиләсендә туа.

1945 елда башкорт театр мәктәбендә укып, артист була. 1958–1960 елларда Мәскәүдә Язучылар союзы хозурындагы югары әдәбият курсларын һәм Горький исемендәге институтның әдәбият бүлеген тәмамлый. 1953 елда партия сафына керә. Башкорт, рус телләрендә язган әсәрләре бар.

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1907–1971.

**565. МИРЗАНОВ Б.**

***Тәхәллүсе:*** Б. Мирзанов.

Революциягә кадәр чыккан вакытлы матбугатта, аннан соң да шигырьләр язып катнашкан шагыйрь.

**566. МИРМӨХСИН Ширмөхәммәтов.**

***Тәхәллүсләре:*** Мирмөхсин, Фитри[1].

Ташкентлык. 1913 елларда Уфада «Галия» мәдрәсәсендә белем алган үзбәк язучысы. 1914 елда Ташкентта чыккан «Садаи-Төркестан» исемле үзбәк газетасында языша. Хәмзә Хәкимзадә Ниязиның дусты.

**567. МИРҖӘЛИЛЕВ Мирхәмит.**

***Тәхәллүсе:*** Бүләк.

Үзбәк язучысы.

**568. МИФТАХОВ Вәдүд Кашшаф улы** (1915–1942).

***Тәхәллүсләре:*** Мифтах Вәдүд, М. Вәдүд, В. Мифтах.

20 ноябрьдә Татарстанның Сарман районы Яхшы Каран авылында туа. 1934 елда Вәдүд Лубьян каласында урманчылык техникумын тәмамлый. Аннан соң педагогия институтында укый. 1934 елда шигырьләр яза башлый. 1939 елда беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1942 елда Тула өлкәсе Арсен районы Рыдань авылында батырларча һәлак була. Аны шунда зур хөрмәт белән күмәләр.

**569. МИФТАХОВ Сәгыйть Мифтах улы** (1907–1942).

***Тәхәллүсләре:*** Сәгыйть Мифтахов, С. Мифтахов.

10 гыйнварда Башкортстанның Нуриман районы Кызылъяр авылында туа. 1919–1921 елларда Уфада педагогия курсларында укый.

1923 елда Мәскәүдә КУТВда укый. Уфада дәүләт театры директоры вазифасын башкара. Бөек Ватан сугышына үз ирege белән китә. 1942 елда батырларча һәлак була.

**570. МИФТАХЕТДИНОВ Сәрвәретдин.**

***Тәхәллүсләре:*** Сәрвәретдин Мифтахетдинов, С. Мифтахетдин.

---

[1] Фәйзи тәхәллүсе дә булырга мөмкин.

Мулла. Революциягә кадәр «Шура» журналында дин, ислам турында бик күп мәкаләләр яза. Ш. Бабич аны болай сурәтли:

Сәрвәретдин Мифтахетдин һәм мөдәррис, һәм имам,
Ул тугандук: «Ислам, ислам, ислам», – дип туган.

**571. ФӘХРЕТДИН БИНЕ МИФТАХЕТДИН** (1839–1913).

***Тәхәллүсе:*** Фәхретдин бине Мифтахетдин.

Татарстанда Лаеш өязе Елга авылында[1] крестьян гаиләсендә туа. 1861 елда Күкчәтауга барырга юлга чыгалар. Пермьдә акчалары беткәч, Себер тимерьюлында юл салыша. 6 ай дигәндә Кызылъяр (Петропавел) га җитә. Аннан Күкчәтауда тукталып, казакъ балаларын укыта башлый. Гаиләсен алып килә, 1866 елда аны солдатка алалар. 8 ел йөреп кайткач, тагын укыту һәм иҗат эшенә тотына. Язганнары: «Шаһмәрдан», «Сәитбаттал гази», «Хәятел-хәйванат», «Казан тарихы», «Дөнья тарихы» (гарәпчә), «Дөньядагы гыйбрәтләр һәм кызыклы вакыйгалар», «Җиһанша вә Шәмсебану», «Баштан кичкәннәрем». Болар барысы да кульязма.

**572. МОЗАФФАРОВ Габдерәүф Билал улы** (1889–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Г. М., Р. Мозаффаров, Г.Р. Мозаффаров.

1914 елда Ташкентта чыккан «Садаи-Төркестан» исемле үзбәкчә газетаның редакторы. Журналист, вакытлы матбугатта языша.

**573. МОЗАФФАРОВ Зариф.**

***Тәхәллүсе:*** Зариф Мозаффар.

Революциягә кадәр «Шура»да яза. 1919 елда Богырысланда «Кызыл маяк» газетасы чыгара.

**574. МОЗАФФАРОВ Мөхәммәдхәнәфи Мөхәммәтҗан улы.**

***Тәхәллүсе:*** Хәнәфи Мозаффар.

Татарстанның Кукмара районы Пычак авылы хәлфәсе. «Шура», «Вакыт»ларда языша.

**575. МОЗАФФАРИЯ Маһруй Габделвәли кызы** (1873–1945).

***Тәхәллүсе:*** Маһруй Мозаффария.

Тәтеш өязе Тормы авылында мулла гаиләсендә туа. 1891 елда Казандагы Хуҗахмәт муллага икенче хатынлыкка кияүгә бирәләр.

[1] Дөресе: Югары Елга авылы.

Хәдичә Әхмәрова ачкан мәктәптә татар теле укыта. 1901 елда «Нәсыйхәтнамә» исемле әсәрен бастыра. «Кызганыч Миңҗамал» вә башка шигырь вә хикәяләр яза. Казанда шәһәр Советына депутат була.

**576. МИҢНУЛЛИН Фәрваз.**

***Тәхәллүсе:*** Фәрваз Миңнуллин.

1934 елның 5 августында Татарстанның Арча районы Ишнарат авылында туа. 1946 [елда] авыл мәктәбен бетереп, Арча педагогия училищесын тәмамлый. 1954 елда университетның татар теле бүлегендә укый. Аннан соң «Казан утлары» журналында бүлек мөдире була.

**577. МОЗАФФАРИЯ Мәхмүдә Хөҗҗәтелислам кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** М. Мозаффария, Мәхмүдә Урманчиева, Урманчиева М.

1893 елда Казанда мулла гаиләсендә туа. 1907 елда «Әлислах»та шигырьләре басыла.

**578. МОЗАФФАРОВ Мансур Әхмәт улы (**1902–1966).

***Тәхәллүсе:*** Мансур Мозаффаров.

Казанда туа. 1919 елда Казанда техникумга керә. 1923 елда тәмамлап, Мәскәү консерваториясендә укый. Аны 1931 елда тәмамлый. Мәскәүдә башкорт студиясендә укыта. Җыр көйләре күп, талантлы композитор.

**579. МОЗАФФАРОВ Йосыф Хәсән улы** (1885–1939)[1].

***Тәхәллүсе:*** Йосыф Мозаффаров.

Сембер губернасы Иске Тимошкино авылында туа. Учительская школаны тәмамлый, укытучы була. 1909 елда Оренбургта «Яз» исемле көлке журналы чыгара. Язган нәрсәләре бар. Соңгы елларда Урта Азиядә яши.

**580. МОРАДЫЙ Ярулла**

***Тәхәллүсе:*** Ярулла Морадый.

Күптәнге язучы. 1913 елда «Тукай Уральскида» дигән әсәр иҗат итә. Вакытлы матбугатта язышa.

**581. МОРАТОВ Ибраһим.**

***Тәхәллүсләре:*** Ибраһим Моратов, Ванька, Зариф Садыйков.

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1887–1928 елдан соң.

1906 елда Казаннан Әстерханга килеп, социаль-демократлар оешмасы төзи. Аларның башлыгы Ибраһим Моратов була. Ул – Казанда Яңа Бистә егете. Бакуда эшли. Батыр җанлы, кыю йөрәкле революционер. Соңрак Кырымда 1907 елдан 1911 елга кадәр Симфереполь төрмәсендә утыра, аннан әллә ничә тапкыр кача. Туберкулез белән чирли. 1912 елда иреккә чыгып, Кырымда үлә. «Зариф Садыйков», «Ванька» псевдонимы белән йөри.

**582. МОРТАЗИН Вәлиулла.**

***Тәхәллүсе:*** Иманский.

Революциягә кадәр танылган артист.

**583. МОРТАЗИН Фатих.**

***Тәхәллүсләре:*** Фатих Мортазин, Ф. Мортазин, Икътисадчы*.

Самара (Куйбышев) шәһәре мулласы, революциягә кадәр вакытлы матбугатта языша. 1908 елда Самарада «Икътисад» исемле журнал чыгара. Чыгышы белән Буа районы Сөендекле авылыннан.

**584. МОСТАКАЙ Әхмәтҗан.**

«Түкә» имзасы белән яза.

**585. МӨХӘММӘД карый Болгари.**

***Тәхәллүсе:*** Мөхәммәт карый Болгари.

XVIII йөз урталарында «Гарәп-фарсы-татар сүзлеге» төзегән галим.

**586. МӨХӘММӘДҖАНОВ Бәдретдин Мөхәммәджан улы** (1909–1944).

***Тәхәллүсләре:*** Бәдрүш Мокамай, Б. Мокамай.

Башкортстанның Дүртөйле районы Каишево[1] авылында крестьян гаиләсендә туа. 1931 елда Уфада педагогия техникумын тәмамлый. Укытучы. Ватан сугышында батырларча һәлак була.

**587. МӨХТӘРОВ Хәсән Баһаветдин улы** (1901–1963).

***Тәхәллүсләре:*** Хәсән Мөхтәров, Х. Мөхтәр.

Башкортстанда Кушнаренко авылында кибетче гаиләсендә туа. 1916 елда тимерьюлда эшли. 1913 елда «Тормыш» газетасында наборщик. 1940 елда нәшрияттә баш редактор. Язган хикәя-повесть җыентыклары бар.

[1] Каишево – Каеш авылы.

**588. МОХТАРОВ Мөхәммәджан.**

***Тәхәллүсе:*** Васфи.

Үзбәк язучысы.

**589. МОХТАРИ Шакир.**

***Тәхәллүсе:*** Әскәри.

Үзбәк язучысы.

**590. МӨЭМИНОВ Рәфикъ.**

***Тәхәллүсләре:*** Дивана, Мәшрәб Фәрганәли.

Фирганәдән, үзбәк язучысы.

**591. МОХТАРОВ Мөҗаһит.**

***Тәхәллүсе:*** Амурский.

Татарстанда вакытлы матбугатта актив катнашкан комсомол работнигы. Журналист.

**592. МОХТАРОВ Әсгать.**

***Тәхәллүсе:*** Әсгать Мохтар.

1920 елда Фирганәдә туган. Чыгышы буенча татар. Үзбәкстанда яшәп, шунда гали белем алып, үзбәкнең зур шагыйре, танылган әдибе, драматургы булып китә. Хәзер Үзбәкстанның «Төркестан» исемле журналында редактор.

**593. МОСТАКАЕВ Габделкаюм Габдеррәхим улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Каюм Рәхим, К. Рәхим, Әхмәди, Гөлгазар, Ил мөхбире. Мөгаллим Гаян, К. Мостакай, К. Р., К. Әхмәт*, «К»*.

1885 [елның] 19 гыйнварында Ульяновск өлкәсендә Хвалынь (Кулаткы) районы Иске Зеленай авылында туа. Зимницы мәдрәсәсен бетергәч, Касыйм шәһәре (Ханкирмән) мәдрәсәсенең гали сыйныфын тәмамлый. 1906 елда Киевта 1911–1912 елларда учительская семинариядә диплом ала. 1903 елда «Шәркый рус» газетасында яза башлый. Каюм ага – тәҗрибәле педагог, көчле журналист. Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимовларның якын дусты. Хәзер пенсиядә. Казанда яши.

**594. МОСТАКАЕВ Габдулла Хәсән улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Биги, Габдулла Мостакай, Г. Биги*.

1890 елда Саратов губернасы Хвалынь өязе Татар Шәмалагы авылында крестьян гаиләсендә туа. «Буби», «Хөсәения»

мәдрәсәләрендә укый. Ташкент институты директоры. Заманының мәшһүр шагыйрьләреннән.

**595. МУСИН Гариф.**

***Тәхәллүсе:*** Гариф Мусин.

1917 елда Семипалат шәһәрендә «Халык сүзе» газетасы редакторы. Нашире – Фуат Айтикин.

**596. МУСИНСКИЙ – Рәхмәтулла Хәйрулла углы Исхаков** (1896–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Рәхмай Мусинский, Мусинский, Исхаков Рәхмәтулла.

Оренбург өлкәсендә Муса авылында туа. Вакытлы матбугатта язышкан журналист.

**597. МУСКИЕВ Әбрар Габдулла улы** (1894–1920).

***Тәхәллүсләре:*** Әбрар Мускиев, Әбмус.

Тәтеш өязе Кариле авылында туа. Казанда сәүдә мәктәбен тәмамлый, гидромеханика станциясендә эшли. 1919 елны аклар белән китеп, Кырымда үлеп кала.

**598. МОСТАЕВ Шакир.**

***Тәхәллүсләре:*** Касыймский, Качимский, Ш. Мостай, Нузад.

Касыйм татары. 1916 елда Петербургта «Сүз» туктап, «Ил» чыккач, редакторы. Вакытлы матбугатта языша, революциядән соңгы тәкъдире билгесез.

**599. МОСТАФИН Латыйф Әхмәтҗан хәлфә улы** (1890–1937).

***Тәхәллүсләре:*** «Ләм», Латыйф Мостафа, Л. Мостафа*.

Казанда укытучы гаиләсендә туа. Кушаматы – Мәңгелек студент, матбугатта язгалый.

**600. МОСТАФИН Нариман бине Сөләйман.**

***Тәхәллүсе:*** Нариман Мостафин.

Уфага якын Чуалкап (?) авылында имам була. 1807 елда төрмәдә утырганда язганнары бар. «Чәй эчү хакында» бәетен язган кеше.

**601. МУСИН Ногман Сөләйман улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Н. Мусин, Мусин Ногман.

1931 елда Башкортстанның Макаровск районы Колгына авылында туа. 1949 елда Эстәрлетамакта укытучы, 1951 елда гаскәри хезмәткә алына. 1953 елдан бирле Уфада төрле редакцияләрдә әдәби хезмәттә.

**602. МУТИН Мохтар Исхак улы** (1886–1938)[1].

***Тәхәллүсе:*** Мохтар Мутин.

Татарстанда Такталачык авылында туа. Оренбург, Уфа, Казан театрларында уйнап дан казана. 1926 елда «Татарстанның атказанган артисты» исеме ала. Талантлы, белемле, кыю артист.

Хәким Габдерәүф «Кармак» журналында аның турында болай ди:

Уйнады Рөстәм ролен артист каһарман ир – Мутин,
Ялтырап сәхнә эчендә шул кояшка булды тиң.

**603. МӘҮЛҮТОВ Хөсәен Баһаветдин улы.**

***Тәхәллүсе:*** Хөсәен Мәүлүтов.

1893 елда Чистайда туа. 1920 елларда Вятка (Киров) шәһәрендә чыккан «Коммунист», соңрак «Урак һәм Чүкеч» газеталарында язышкан хәрби комиссар. Партиядә җаваплы эшләр башкарган сәяси хезмәткәр.

**604. МӘГАЗИ Габдерәхим Габдулла улы.**

***Тәхәллүсе:*** Г. Мәгази.

Революциягә кадәр «Дин вә мәгыйшәт», дини журналларда язышa. «Мөәлләфат мөхәддисин кирам» әсәренең авторы.

**605. МӘЗИТОВ Зәит Мәзит улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Мәзитов Зәит, Зәит Мәзит.

1927 елның 25 августында Татарстанда Калинин районы Айман авылында туа. 1926 елда Казан университетының татар теле, әдәбияты бүлегенә керә. 1951 елда аспирантурада кала. Филология фәннәре кандидаты булырга диссертация яклый. 1956 елда партия сафына керә. 1940 елда шигырь җыентыклары басылып чыга. Хәзер университетта укыта.

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1886–1941.

**606. МӘККИ Морат Чистайлы.**

***Тәхәллүсләре:*** Морат Мәкки, М. Мәкки.

Чистай районында туа, революциягә кадәр булган матбугатта катнаша һәм «Тәлфикъ әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар [вә мүлүк әт-татар]» (гарәпчә-татарча) әсәренең авторы.

**607. МӘРҖАНИ Мәхмүт Галәветдин улы** (1886–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Мәхмүт Мәрҗани, М. Галәү, Мин, Әйтмим, Кармакбай, Каразадә, Мин сиңа әйтим, М. М., М. Мәрҗани*.

Татарстанның Арча районы Ташкичү авылында туа. «Буби» мәдрәсәсендә укый. Революциягә кадәр Оренбургта «Кармак» исемле көлке журналы чыгара. Көчле журналист, үткен каләмле юморист, сатирик. Аерым китап булып чыккан әсәрләре байтак, шагыйрь вә әдип.

**608. МӘРҖАНИ Шиһабетдин Баһаветдин улы** (1818–1889).

***Тәхәллүсе:*** Шиһаб Мәрҗани.

Казан арты Мәрҗән авылында[1] туган. Дини мәдрәсәләрдә белем алса да, фикер йөртергә, мөстәкыйль уйларга ярата. Казанда мулла һәм ахун булса да, дини хорафатларга каршы каты сугыш ача. Ике тапкыр урыныннан алалар, дәрес бирүне дә тыялар.

**609. МӘСГУДОВ Хәбибрахман ахун мулла Садыйк улы әл-Мәсгуди.**

***Тәхәллүсе:*** Хәбибрахман әл-Мәсгуди.

Татарстанда Алабуга өязе Морт авылында мулла. 1906 елларда Дәүләт думасында депутат. Язган нәрсәләре бар.

**610. МӘСГУТЬ ГАЙНУЛЛИН (**1907–1944).

***Тәхәллүсе:*** Г. Мәсгуд.

Уфа районы Нурлино[2] авылында туа. Башлангыч белемне үз авылында ала. Вакытлы матбугатта шигырьләр яза. Башкорт, татар телендә берничә әсәре бар.

**611. МӘҮЛА КОЛЫЙ.**

***Тәхәллүсе:*** Мәүла Колый.

---

[1] Дөресе: Казан өязе Ябынчы авылы.

[2] Нурлино – Нөрле авылы.

XVII йөзнең соңгы яртысында шигырьләр язган шагыйрь. Ул үзенең «газәл» һәм «хикмәтләрен» 1677 елда язганлыгын әйтә. Аның шигырьләре дини-мистик, суфилык идеологиясе белән сугарылган.

**612. МӘҮЛӘБИРДИЕВ Нәҗип Гасрый** (1887–1939)[1].

***Тәхәллүсләре:*** Нәҗип Гасрый, Н. Гасрый.

Әстерханда туа. Ул Казанда Мәрҗани мәдрәсәсендә укый, соңра Төркиягә китеп, дарелфөнүннең әдәбият бүлеген тәмамлый. Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. 1917 елда Әстерханда «Сарай» газетасының редакторы. Нашире – Фатих Шәммас. Соңра Мәскәүдә эшли. 1925 елда Әстерханга килә, аннан Ашхабадка китеп, укытучы була, дәреслекләр яза. Кулга алынмый. Ашхабадта тамак чахоткасыннан үлә. Тәҗрибәле журналист. «Хисаметдин менла» (тәнкыйди), «Мәзарстанда», «Гыйшкымның хәрабәләре» исемле әсәрләр авторы.

**613. МӘҮЛЕТЕВ Сәхаб Камал улы** (1907–1957).

***Тәхәллүсләре:*** Сәхаб Урайский, С. Урайский.

21 декабрьдә Ульяновск өлкәсендә Кече Кандал районы Татар Урайкино авылында туа, ятим кала. Самарада татар-башкорт педагогия техникумын тәмамлый. Казанга килеп, педагогия институтында укый. Ватан сугышында катнаша. 1941 елда партия сафына керә. Казанда нәшриятта редактор. «Көтүче кызы», «Давыллар аша», «Яшьлек тавышы», «Жигули буйларында», «Якты еллар», «Яз таңында», «Бәхетле балалар» исемле шигырь җыентыклары бар.

**614. МӘҖИДИ ГАБДЕЛХӘМИТ.**

***Тәхәллүсләре:*** Әбү Танбал, Чакмак.

Үзбәк язучысы.

**615. МӘҖИДИ МӘННАН.**

***Тәхәллүсе:*** Уйгур.

Үзбәк язучысы.

**616. МӘҖИТЕВ Шакир** (1907–1967).

***Тәхәллүсләре:*** Шакир Мәҗитов, Ш. Мәҗитов.

Казанда туа. 1927–1929 елларда Оренбургта, 1929–1939 елларда Әстерханда, 1939–1949 елларда Казанда татар театры артисты.

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1886–1937 еллар.

Сәхнә әсәрләре, бик күп җырлар язган композитор, драматург. Казанда үлә.

**617. МӘҖИТЕВ Әсгать.**

***Тәхәллүсе:*** Мәҗит Әсгать.

Сәнгать эшлеклесе, артист. Театр турында рецензияләр яза. «Гармун сөйләр» исемле әсәрнең авторы.

**618. МОНАСЫЙПОВ Габделгазиз** (1890–1922)[1].

***Тәхәллүсләре:*** Газиз Монасыйпов, Г. Монасыйпов, Таранчы.

Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Вакытлы матбугатта языша. Язган әсәрләре: «Өзелгән өмет», «Таранчы кызы», «Имчеләр корбаны». 1922 елда Ташкентта типографиядән бер машинка кәгазе алып чыкканда тотылып атыла.

**619. МӨДӘРРИСОВ Шәрәф Хасиятулла улы** (1919–1958)[2].

***Тәхәллүсләре:*** Шәрәф Мөдәррис, Ш. Мөдәррис, Ш. М.

Татарстанның Чүпрәле районы Түбән Каракитә авылында крестьян гаиләсендә туа. 1939–1941 елларда педагогия институтында укый. 1941 елда Бөек Ватан сугышына китә. Кайткач, «Совет әдәбияты», «Чаян» журналларында языша. 1937 елда «Үсү» исемле шигырь җыентыгы басыла. Аннан соң «Кыз вә кондыз», «Кечкенә эпизодлар», «Ант», «Минем хисләрем», «Әбдүш Ялаяпов», «Явыз йолдыз», «Бер төнне», «Онытылмас вакыйгалар», «Коммунист», «Рейхстаг стенасы», «Җиңүче бәхете», «Хамазан Гыйззәтуллин», «Снайпер Закир Гайфуллин», «Танкист Рөстәм», «Волга-Дон», «Луи-Арагон» вә башкалар авторы. Русчадан, чувашчадан тәрҗемәләре бар.

**620. МӨНИР ҺАДИ.**

***Тәхәллүсе:*** Мөнир Һади.

Чиләбе шәһәренең имамы. «Шура» журналында күп кенә тарихи мәкаләләр яза. «Башкорт тарихы» ның авторы. 1913 елда Чиләбедә үлә.

**621. МӨСЛИМОВ Хисаметдин бине Шиһабетдин.**

***Тәхәллүсе:*** Мөслими әл-Болгари.

«Тәварихе Болгария» китабының авторы.

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1888–1922.

[2] Татар энциклопедиясе: 1919–1963.

**622. МӨСЛИМЕВ Габделхәмит Гатаулла улы** (1889–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Габделхәмит Мөслими, Г. Мөслими.

Минзәлә өязе Мөслим авылында туа. Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Шундагы Кәрвансарай мәдрәсәсендә укыта. «Шура» журналында, «Вакыт» газетасында еш языша.

**623. МӨСЛИМОВ Миңнемулла Нәбиулла улы.**

***Тәхәллүсе:*** Мөслим Марат.

1909 [елның] 10 маенда Башкортстанда Бураев[1] авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1931 елда Уфа педагогия техникумын тәмамлый. Редакцияләрдә эшли. Язып бастырган шигырь-поэмалар җыентыклары бар.

**624. МӨСЛИМОВ Гыйсмәтулла.**

***Тәхәллүсе:*** Г. Мөслимов.

1917 елда Әстерханда «Азат ханым» журналы чыгара.

**625. МӨХЕТДИНОВА Әминә Фәсах кызы** (1893–1941)[2].

***Тәхәллүсләре:*** Әминә Мөхетдинова, Ә. Мөхетдиния.

Казанда туа. Яшьтән үк татар һәм рус әдәбияты белән таныш була. Гимназия бетергәч, Казан университетының юридик факультетында укый. Революциядән соң җәмәгать эшлеклесе булып китә. Татарстанда һәм Кырымда прокурор булып эшли. 1937 елда ире Госман Диваев белән кулга алыналар.

**626. МӨХӘММӘДЕВ Мәрдегаләм.**

***Тәхәллүсләре:*** Мәрдегаләм Мөхәммәдев, М. Мөхәммәдев.

Революциягә кадәр Троицк шәһәрендә Зәйнулла ишанның «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укый, аннан соң Казанда учительская школаны тәмамлый. Белемле педагог, тәҗрибәле журналист иде. Укыту-тәрбия турында мәкаләләр яза.

**627. МӨХӘММӘДДЕВ Шакир** (1865–1923).

***Тәхәллүсләре:*** Ш. Мөхәммәдев, Авыл кешесе, М. Ш., Бичура, Машаяк, Кайчылы, Карчыга.

Татарстанда Буа шәһәрендә туа. 1900 еллардан башлап язган әсәрләре: «Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр бай», «Яфрак асты, яхуд

[1] Бураев – Борай авылы.

[2] Татар энциклопедиясе: 1893–1944 еллар.

Мәкәрҗә ярминкәсе», «Япон сугышы, яки доброволец Батыргали», «Яңа Бәдәвам», «Хәсрәтле көннәр хикәясе», «Күз яшьләре», «Урал буе – татар туе», «Хан кызы», «Эшче халыкка», «Җуан корсакка ачык хат», «Безнең депутатлар», «Дума членнарына». «Тәҗрибәле карчыга» исемле көлке журналы чыгара.

**628. МӘХМҮТ ХАҖИ УЛЫ МӨХӘММӘДЬЯР.**

***Тәхәллүсе:*** М. Мөхәммәдьяр.

XVI йөзнең уртасында Болгар шәһәрендә яшәгән. «Төхфәимәрдан» («Егетләр бүләге), «Нуры содур» («Күңелләр нуры») исемле матур әсәрләр язган шагыйрь.

**629. МӨХӘММӘДӘЛИ УЛЫ МӨХӘММӘТЙОСЫФ.**

***Тәхәллүсләре:*** М. Алиев, М. Әли углы.

Үзбәк язучысы.

**630. МӨХӘММӘДЛАТЫЙФ УГЛЫ АТА МӘХЗҮМ.**

***Тәхәллүсе:*** Партави**.**

Үзбәк язучысы.

**631. МӨХӘММӘДҖАНОВ Мөэминҗан.**

***Тәхәллүсләре:*** Ташкын, Мохтарбад, Мик, Мим, Мулла Тиртыйк.

Үзбәк шагыйре һәм әдибе.

**632. МӨХӘММӘДЬЯРОВ Хәй Габдеррәфикъ улы** (1911–1942).

***Тәхәллүсләре:*** М. Хәй, Хәй Мөхәммәдьяров.

Чиләбе өлкәсе Сасна районы Кунакбай авылында туа. 1933–1937 елларда Уфа педагогия институтында укый. 1940–1942 елларда Бөек Ватан сугышы фронтында була. Шигырь-поэма җыентыклары бар.

**633. МӨХӘММӘДЬЯРОВ Фатих Гарифулла улы** (1883–1950).

***Тәхәллүсләре:*** Фатих Мөхәммәдьяров, Ф. Мөхәммәдьяров.

Казанда университетның медицина факультетын тәмамлап, профессор була. Татарстанда наркомздрав[1].

**634. МӨХӘММӘДЬЯРОВ Шакир Зариф улы** (1883–1967).

***Тәхәллүсләре:*** Шакир Мөхәммәдьяр, Ш. Мөхәммәдьяров, Ш. М-яров, Татар углы.

[1] Сәламәтлек саклау халык комиссары.

1910 елда Петербург университетын тәмамлап, юрист була. Революциягә чаклы «Таңчылар»дан берсе. Революциядән соң Кырымда милиционерлар өчен ачылган мәктәптә хокук фәненнән дәрес бирә. «Таң»да, «Мөхбир»дә, «Әхбар»да, «Йолдыз»да, «Вакыт» газеталарында күп яза. «Апама», «Сеңлем Латыйфага», «24 сәгать эчендә» исемле әсәрләре бар. «Шәркый Рус» газетасында «Татар углы» имзасы белән яза.

**635. МӨХӘРРӘМОВ Мидхәт.**

***Тәхәллүсе:*** Мөхәррәмов М.

1922 [елда] туа. Фәннәр академиясенең Казандагы Тел, әдәбият һәм тарих институтын[1] җитәкли.

**636. МӨШТӘРИЕВА Мәрьям Мозаффар кызы** (1894–1966).

***Тәхәллүсләре:*** Мәрьям Мөштәри, М. Мөштәри, Мәрьям Бөдәйли.

Казанда укытучы гаиләсендә туа, гимназия тәмамлый. Аннан соң Казан университетының медицина факультетын тәмамлап, врач була. Революциягә кадәр Казанда чыккан «Шәркый рус» журналында редакторлардан берсе. Революциядән соң Төркестанда «Кызыл Шәрык» исемле агитбюроның политотдел члены. Бохарада мәгариф нәзаратында коллегия члены. Балалар тәрбиясе турында язган берничә әсәре бар.

**637. МӨШТӘРИ Хәмит Мозаффар улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Хәмит Мөштәри, М. Мөштәри.

1900 елда Казанда укытучы гаиләсендә туа. Революциягә кадәр Казанда гимназиядә укый. Аны бетергәч, Мәскәүдә гали мәктәп тәмамлап, профессор була. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Физика-техника институтында җитәкче. Язган хезмәтләре бар. «Мәгариф» журналында секретарь була.

**638. МӨЭМИНОВА Энҗе Һилалетдин кызы.**

***Тәхәллүсе:*** Энҗе Мөэминова.

Казанда туган шагыйрә.

**639. НАДИЕВ Нургали Сибгатулла улы** (1883–1940).

***Тәхәллүсләре:*** Нургали Надиев, Н. Надиев, Лопатинский.

---

[1] Хәзер ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты.

Саратов өлкәсе Лопатинский районында Суляевка авылында[1] туа. Казанда Учительская школаны бетергәч, Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә, Октябрь революциядән соң Казанга күчеп килеп, университетта укыта. 1913 елда «Русия тарихы» язып бастырса да, патша хөкүмәте тарафыннан конфискацияләнә.

**640. НӘЗЕРКОЛОВ Түрәкол.**

***Тәхәллүсе:*** Зиһни.

Үзбәк язучысы.

**641. НАРИМАНОВ Нариман** (14.04.1870–1925).

***Тәхәллүсе:*** Н. Нариман, Нариманов Н.

Чыгышы ягыннан азәрбәйҗанлы. Революциягә кадәр Бакуда һәм Әстерханда социал-демократ большевиклар партиясе оештырып йөрүче. Октябрь социалистик революциясеннән соң Мәскәүдә Лениннар белән бергә Совет хөкүмәтенең зур җитәкчеләреннән берсе. «Нәдершаһ» пьесасының авторы.

**642. НАСЫЙБУЛЛИН Әхмәт Гариф улы** (1886–1962).

***Тәхәллүсе:*** Әхмәт Насыйбуллин.

Татарстанда Питрәч районы Шәле авылында туа. Вакытлы матбугатта языша.

**643. НАСЫЙБУЛЛИН Әһлиулла Фәтхулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Әһли, Ә. Насыйбуллин.

Әстерхан өязе Яңа Сәңар мулласы малае. Казанда Учительская [школа]да укый. 1907 елда эсерларга катнаша. 1910 елда Әстерханда донос буенча кулга алына. [...]

**644. НАСЫЙРИ Имаметдин Низаметдин улы** (1898–1942).

***Тәхәллүсләре:*** Насыйри Имай, Н. Насыйри.

Башкортстанның Стәрлетамак районы Түбән Усылы авылында туа. 1910–1917 елларда Стәрле мәдрәсәсендә укый. 1932–1934 елларда Мәскәүдә партия үзәк комитеты хозурындагы марксизм-ленинизм курсларында укый, журналист була. 1936 елда редактор. 1937 елда кулга алына. Башкортча-татарча-русча повесть, хикәя җыентыклары бар. Прозаик.

[1] Селәү авылы.

**645. НАСРЕТДИНОВ Гамир Гариф улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гамир Насыйри, Г. Насыйри, Н. Гамир.

1916 [елның] 3 гыйнварында Башкортстанда Кызыл Кама районы Иске Янегет авылында туа. 1934–1937 елларда Казан театр техникумында укый. 1937–1940 елларда Совет армиясендә хезмәттә була. 1941–1942 елларда радиокомитетта эшли. Язган китаплары күп.

**646. НАСЫЙРИ Зыятдин** (09.01.1886–1933).

***Тәхәллүсләре:*** Зыя Насыйри, З. Насыйри, Н. Зыя.

Төркиядә укып кайткач, чит илләрдә йөреп, «Шура» журналында һәм башка матбугатта мәкаләләр язып йөргән сәях журналист. [...] Төркиядән укып кайткач, укытучы була. Соңрак укытучылыкны ташлап, Уфада Шамгунов Сабирҗан дигән байлар фирмасына эшкә керә. Газета-журналларда соңрак үкенеч белдергәннәр иде, ул аңа җавап язып, акланып йөрде. Ш. Бабич аңа болай яза:

Йөрмәче, Зыя Насыйр, син төрлечә койрык булып,
Мәгънә чыкмас төрле байларга кереп, йөгереп йөреп.

Әсәрләре: «Поездда бер угрылык», «Кемнең баласы», «Бәбкәм ахун», «Китапча», «Көчләп кияүгә бирмиләр», «Ятимнәр», «Ахирәт йорты».

**647. НАСЫЙРОВ Зыя Шәйхи улы** (1890–1965)[1].

***Тәхәллүсләре:*** Зыя Ярмәки, З. Ярмәки, Насыйров Зыя.

Самара өлкәсе Камышлы районы Иске Ярмәк авылында туа. 1915–1916 елларда атасы урынына мулла була. 1918 елда муллалыкны ташлап, Богырысланда мөгаллимнәр курсында укый. 1919–1921 елларда укытучы була. 1931 елда Төркестанга китеп, совхозда эшли. Ташкентка килеп, район башкарма комитетына сайлана. Бүлек мөдире була. 1912 елдан башлап шигъри әсәрләр бастыра: «Яшьлек дәртләре», «Күрсәтәм», «Әдәбият гөлләре», «Тойгыларым», «Ак каен» исемле җыентыклар авторы.

**648. НАСЫЙРОВ Каюм** (Габделкаюм Габденнасыйр углы, 1825–1902).

***Тәхәллүсләре:*** Каюм Насыйри, К. Н., К. Насыйри.

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1887–1965 еллар.

Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында туа. Мәшһүр галим. Илледән артык әсәре бар.

**649. НАСЫЙРОВ Шакир Гыйниятулла улы** (1913–1968).

***Тәхәллүсләре:*** Шакир Насыйров, Ш. Насыйров.

Башкортстанда Гафури районы Ибраһим авылында крестьян гаиләсендә туа. 1929–1931елларда Уфада сәнәгать техникумын тәмамлый. 1946–1953 елларда Совет армиясе сафларында хезмәт итә. 1951 елда нәшрият редакторы. Хикәя, повесть, драма җыентыклары бар.

**650. НАУМОВ Хәнәф Нөсрәтулла улы (Нигъмәтуллин).**

***Тәхәллүсләре:*** Хәнәф Наумов, Х. Наумов, Х. Нигъмәти.

Сембер мишәре. Революциядән соң газета-журналларда еш язып. [...]

**651. НӘҮРУЗОВ Мөхәммәдвәгыйзь.**

***Тәхәллүсләре:*** Вәгыйзь Нәүрузов, Нәүрузов В.

1912 елда Томскида «Сибирия» газеты, 1914 елда Уфада «Тормыш» газетасы чыгара. [...]

**652. НӘҮРУЗОВА Фатыймаи-Фәридә ханым Мортаза кызы** (1889–1914).

***Тәхәллүсләре:*** Фәридә ханым, Ф. Нәүрузова.

Чистайда тора. Томск шәһәрендә «Сибирия» газетасы чыгарган Вәгыйзь хатыны. Вакытлы матбугатта язгалый. Белемле, мәгърифәтле ханым. «Сибирия» һәм «Тормыш» газеталарында «хатын-кыз дөньясы» бүлеген ача.

**653. НИЗАМОВ Рәис Гыйльметдин.**

***Тәхәллүсләре:*** Рәис Низамов, Р. Низамов.

1932 елда Башкортстанның Альшеевск[1] районы Ташлы авылында колхозчы гаиләсендә туа. 1949 елда Уфада елга техникумын тәмамлый. Шигырьләр яза башлый. 1950–1957 елларда Мәскәүдә Горький исемендәге Әдәбият институтында укый, шул елны партия сафына керә. 1966 елдан «Агыйдел» журналы редакторы урынбасары.

---

[1] Әлшәй районы.

**654. НИГЪМӘТУЛЛИН Гобәйдулла Мөхәммәтфәиз улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гобәйдулла Нигъмәти, Г. Нигъмәти.

Малмыж өязе Иж-Бубый авылында туа. 1899 елда «Кыйраәте-төрки» дигән әсәренең беренче кисәге басылып чыга.

**655. НИГЪМӘТУЛЛИН Галимҗан Әмирҗан улы** (25.07.1897–1941).

***Тәхәллүсләре:*** Галимҗан Нигъмәти, Г. Нигъмәти, Гайн-нун, Г. Н.

Башкортстанның Чишмә районы Үдрәкбаш авылында туа. Үз авылында башлангыч белем алгач, Уфага килеп, «Галия» мәдрәсәсен тәмамлый. Революциядән соң Казанга килеп, «Татарстан» газетасының редакторы була һәм педагогия институтында тел, әдәбият укыта. Эрудицияле журналист, көчле әдип, танылган профессор. Күп гыйльми әсәрләр авторы.

**656. НИГЪМӘТУЛЛИН Рәшит Нигъмәтулла улы** (1909–1959).

***Тәхәллүсләре:*** Рәшит Нигъмәти.

Самара өлкәсе Диңгезбай авылында крестьян гаиләсендә туа. 1931–1953 елларда Уфада рабфак бетергәч, төрле редакцияләрдә эшли. Башкорт, татар, рус телләрендә 30 дан артык шигырь, поэма, пьеса әсәрләре бар.

**657. НОГМАНОВ Камил.**

***Тәхәллүсләре:*** Алкыш, Яшен, Ногманов Камил.

Үзбәк язучысы.

**658. НОГМАНОВ Мостафа Ногман улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Мостафа Ногман, М. Ногман.

1912 елда Татарстанның Кызыл Юл районы Кызылъяр авылында сәүдәгәр гаиләсендә туа. Җидееллык мәктәпне бетергәч, Казан педагогика техникумын тәмамлый. 1933–1940 елларда Үзбәкстанда укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң Көнчыгыш телләре институтын тәмамлый. Казанда университетта фарсы телен укыта. Ватан сугышы елларында шигырь-поэмалар яза башлый. «Давыллы еллар лирикасы», «Апрель җилләре» басылып чыга.

**659. НОГМАНОВ Сәлим Сәләхетдин улы** (1889–1970).

***Тәхәллүсләре:*** Ногманов Сәлим, С. Ногманов.

Сембер өязе Кәшә авылында туа. Буада укый. Истанбулда гали мәктәп бетереп, Оренбургта «Хөсәения»дә физмат[1] укыта. 1930 еллардан Казанда рабфак, техникумнарда укыта. 1970 елның беренче апрелендә, мин барганда, Сәлим агай бик каты авырый иде.

– Мин озак яшәмәм, Мәхмүт, – диде. – Әйтеп калыйм: беренче, гомеремдә русларга каршы булган бер генә татарны да күрмәдем. Икенче, күкрәгем орден-медаль белән бизәкләнмәде, вөҗүдем пакь. Теге елларны дус-ишләремне, кардәшләремне чакмадым, – диде. Соңгы сүзе шул булды.

**660. НУГАЙБӘКОВ Гыймадетдин Шәрифҗан улы (**1881–1942)[2].

***Тәхәллүсләре:*** Гыймат Нугайбәк, Г. Н., Гн.

Ульяновск өлкәсе Николаев районы Олы Черкиле авылында туа. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый. «Йолдыз», «Кояш» газеталарының хәбәрчесе. Зур тел галиме. 1911 еллардан башлап дәреслекләр яза башлый.

**661. НУРГАЛИ Ахун ибне Хәсән әл-Болгари.**

***Тәхәллүсләре:*** Нургали әл-Хәсәни, Нургали әл-Болгари, Ибне Хәсәнел-Болгари*.

Буа шәһәренең ахуны, заманында зур мәдрәсә тоткан Мирзалар авылыныкы.

**662. НУРКИН Заһидулла Садретдин улы** (1889–1961)[3].

***Тәхәллүсләре:*** Заһид Нуркин, Дәрвиш, З. Н., Парчинский.

Мордва өлкәсендә Сыркыды авылында туа. «Кояш», «Йолдыз», «Таң»да еш язышa. Язган китаплары бар.

**663. НУРМАВИ Фәйзрахман.**

***Тәхәллүсе:*** Ф. Нурмави.

Троицк шәһәрендә Яушевларда приказчик булып эшли. Вакытлы матбугатка язышa. «Кемдә гаеп» пьесасының авторы.

**664. НУРУЛЛИН Ибраһим Зиннәтулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Ибраһим Зиннәтулла, И. Нуруллин.

1923 елның 18 гыйнварында Ульяновск өлкәсе Мәләкәс районы Боровка авылында туа. Авыл мәктәбен бетергәч, мехкомбинатка эшкә

[1] Физика һәм математика фәннәре.

[2] Татар энциклопедиясе: 1881–1943 еллар.

[3] Татар энциклопедиясе: 1888–1966 еллар.

керә. Ватан сугышына үз иреге белән китә. Аннан кайткач, 1945 елда Казан университетына кереп, аның тел, әдәбият бүлеген тәмамлый. Ул хәзер профессор, тел галиме, Тукайчы. Язганнары күп.

**665. НУРУЛЛИН Гата.**

***Тәхәллүсе:*** Гата Нуруллин.

1928 елда Казанда[1] туа. Театр мәктәбен тәмамлап, Республика күчмә театрында эшли. 1959 елда Әстерханга режиссер булып китә. Пьесалар яза. 1965 елда яңадан Казанга күчмә театрга кайта. 1972 елда «Татарстанның атказанган артисты» исеме ала.

**666. НУРУЛЛИН Вакыйф.**

***Тәхәллүсләре:*** Вакыйф Нуруллин, В. Нуруллин.

1935 елда Татарстанның Балык Бистәсе районы Югары Әшнәк авылында туа. Институт тәмамлагач, төрле редакцияләрдә эшли. Хәзер «Казан утлары» журналының секретаре.

**667. НУРЕТДИНОВ Зәки Шәрәфетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Н. Зәки, Зәки Нури, Н. Кизанов, З. Нури*.

1921 елның 24 декабрендә Татарстанның Чүпрәле районында Тат. Тюка[2] авылында туа. Авыл мәктәбен бетергәч, ул Лубян урман техникумында укый. Ватан сугышында чолганышта калып, партизаннарга кушыла. Аннан кайткач, төрле жанрдагы шигырьләр язуын дәвам иттерә, төрле редакцияләрдә эшли. Язучылар союзы җитәкчесе.

**668. НӘКЫЙ ШАҺБАЗ.**

***Тәхәллүсләре:*** Нәкый Шаһбаз, Н. Шаһбаз.

1918 елда Харьков шәһәрендә «Җәнүб тавышы» дигән газета чыгара.

**669. НӘҖИП мәхзүм Шәмсетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Нәҗип мәхзүм, Нәҗип Түнтәри, Н. Түнтәри*.

Түнтәр авылы имамы. Яңалыкны яклап, үз чорындагы матбугатка мәкаләләр яза.

**670. НӘҖМЕТДИНОВ Кави Һибәтулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Кави Нәҗми, Кан, Канәҗ, Кангазәл (Кави белән Закир Гали), Елга аръягы төпче.

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1923 елның 9 нчы маенда Лаеш районы Мишә Тамагы авылында туа.

[2] Татар Төкесе.

Горький өлкәсендә[1] Кызыл Атау авылында туа. 1918 елдан яза башлый. «Кызыл Армия» газетасының редакторы. Татарның танылган әдибе һәм шагыйре. «Язгы җилләр» исемле романы өчен Сталин премиясенә лаек була.

**671. НӘҖМЕТДИНОВ Назар Нәҗметдин улы.**

***Тәхәллүсе:*** Нажар Нәҗми.

1918 елның 5 февралендә Башкортстанның Дүртөйле районы Миңеште авылында туа. 1938 елда Уфа педагогия институтында укый. 1946 елда ИЯЛИны тәмамлый. 1955–1959 елларда «Сәнәк» журналы редакторы. 1962–1968 елларда Уфада Язучылар союзы җитәкчесе.

**672. ПОЗНЯКОВА Зәйнәп** (1890–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Зәйнәп Познякова, З. Познякова.

Үзбәкстанда Хоканд шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туа. Шигырьләр, хикәяләр яза, үзешчән яшьләр түгәрәгендә актив катнаша. «Иске тормыш исерткән» пьесасын яза.

**673. ПАЛЮТИН Хафиз** (1892–1937)[2].

***Тәхәллүсе:*** Хафиз Палютин.

1925 елларда Татарстанда юстиция (гаделия) халык комиссары була. Җаваплы эшче. Вакытлы матбугатта катнаша.

**674. ПОНОМОРЕВ Хәсән Мулләхмәт улы.**

***Тәхәллүсе:*** Пономорев Хәсән.

1911 елларда Томск шәһәрендә мулла. Вакытлы матбугатта язышса.

**675. ПАРСИН Мөхәммәд Зариф улы** (1897–1965)[3].

***Тәхәллүсләре:*** Мөхәммәд Парсин, М. Парсин, Агай баш, Юлазский.

Татарстанның Әтнә районы Олыяз авылында туа. 1922 елларда «Кызыл Шәрык яшьләре» журналында эшли. «Татарстан»[4] газетасының да редакторы була. «Ураза бәйрәмендә бал тәпәне» пьесасы авторы.

[1] Горький өлкәсе – Түбән Новгород өлкәсе.

[2] Татар энциклопедиясе: 1896–1937 еллар.

[3] Татар энциклопедиясе: 1899–1963 еллар.

[4] «Кызыл Татарстан» газетасы.

**676. ПАТИН Кашшаф.**

***Тәхәллүсләре:*** Кашшаф Патин, К. Патин.

Революциягә кадәр вакытлы матбугатта шигырьләр язып бастырган мулла. Ш. Бабич аны болай характерлый:

> Мулла кем. Кашшаф Патин бассаң да бик күптән тәпи,
> Чыкмады рәт. Бер карыш юл атлый алмадың тәки.

**677. ПОЗНЯКОВ.**

***Тәхәллүсе:*** Позняков.

Фамилиясе рус булса да, үзе татар һәм татарча шигырьләр, мәкаләләр яза.

**678. БУЛАТ Хәсән.**

***Тәхәллүсләре:*** Ягру, Хас.

Үзбәк язучысы.

**679. ПУТИЛЯКОВ Мөхәммәдгали Габделвахит улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гп, Гали Путиляков.

1906 елда Казанда «Таң йолдызы», «Таң мәҗмугасы» кебек газета-журналлар чыгара.

**680. РӘКЫЙПОВ Габдерәкыйп** (1887–1963).

***Тәхәллүсләре:*** Рәкыйп Рәкыйби, Р. Рәкыйби, Фбикар.

Казанда 1910 елларда «Бәянелхак» газетасының секретаре. Көчле журналист, тарихчы. «Шура», «Вакыт» идарәсендә эшли. Журналларга бик күп яза. Революциядән соң 1918 елда партия сафына керә. Марксизм-ленинизм классикларын татарчага тәрҗемә итә. Әсәрләре бар.

**681. РАМАЗАНОВ Гыйлемдар Җиһандар улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гыйлемдар Рамазанов, Г. Рамазанов, Р. Гыйлемдар.

1923 елның 16 июлендә Башкортстанның Чакмагыш районы Иске Балак авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1938–1941 елларда педагогия мәктәбендә укый. 1946 елда Башкортстанның Тел, әдәбият институтын тәмамлый. 1950–1953 елларда Мәскәү университетының аспиранты була һәм шунда кандидатлык диссертациясен яклый. Татар, башкорт, рус телләрендә 20 дән артык шигырь, поэма җыентыклары бар.

**682. РАМАЗАНОВ Каюм.**

***Тәхәллүсе:*** Торгынбай.

Үзбәк язучысы.

**683. РАМАЗАНОВ Шиһап Галим улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Ш. Рамазанов, Пәтәнә, Чулпан.

1887 елның 20 декабрендә Пенза өлкәсе Лопатин районы Иске Карлыгач[1] авылында туа. Укытучы һәм язучы. Тормышта рәһбәр[2] булырдай саф күңелле кеше. Саратовта «Ялкын» журналында «Пәтәнә» имзасы белән, «Йолдыз»да «Чулпан» имзасы белән яза.

**684. РАФЫЙКОВ Габдрахман Вәли улы** (1873–1954).

***Тәхәллүсләре:*** Габдрахман Рафыйков, Г. Рафыйков.

Казанда Учительская школаны тәмамлагач, гомер буе укытучы була. Иҗтимагый эшләргә актив катнаша. Вакытлы матбугатта тәгълим-тәрбия турында мәкаләләр яза.

**685. РАФЫЙКОВ Гали Лотфырахман улы** (1890–1944).

***Тәхәллүсләре:*** Гали Рафыйкый, Г. Рафыйкый.

Уфа өязе Җилдәр волосте Баязит авылында туа. Революциягә кадәр «Шура», «Ак юл» журналларында бик күп яза. Гомер буе укытучы була. 1926 елда партия сафына керә. Галим-журналист, белемле педагог. «Яшь йөрәкнең ашкынуы», «Ходай кушмый» әсәрләре һәм дәреслекләр авторы.

**686. РАФЫЙКОВ Сөббух Һади улы** (1913–1971).

***Тәхәллүсләре:*** Рафыйков Сөббух, Р. Сөббух, Р. С.

Татарстанда Ворошилов районы Олы Нөркәй авылында туа. Казанда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында гали[3] белем ала. Төрле редакцияләрдә эшли. Эшчән журналист. Язган әсәрләре бар.

**687. РАФЫЙКОВ Хуҗа** (1902–1964).

***Тәхәллүсләре:*** Хуҗа Рафыйков, Илгиз, Р. Хуҗа*.

1919 елда Мамадышта педагогия мәктәбен тәмамлый. Казанда педагогия институтында укый һәм завхоз булып эшли. Мөдир урынбасары була, соңрак хәрби мәктәпләрдә укый. Бөек Ватан сугышы

[1] Иске Карлыган авылы.
[2] Рәһбәр – юл күрсәтүче.
[3] Гали – югары.

вакытында дәүләт куркынычсызлыгын саклау органнарында эшли. Полковник дәрәҗәсенә ирешә. Вакытлы матбугатта языша.

**688. РӘХИМГУЛОВА Фәүзия Габдулла кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Фәүзия Рәхимгулова, Ф. Рәхимгулова.

1921 елның 15 декабрендә Башкортстанның Ишембай районы Янырыс авылында крестьян гаиләсендә туа. 1935–1938 елларда педагогия институтында укый. Укытучы була, шигырьләр яза. Башкорт, рус телләрендә унга якын шигырь җыентыклары бар. Балалар язучысы.

**689. РӘХИМОВ Габдерәүф улы.**

***Тәхәллүсе:*** Фитрәт.

Үзбәк язучысы.

**690. РӘХИМОВ Гафурҗан.**

***Тәхәллүсе:*** Гөлташ.

Үзбәк язучысы.

**691. РӘХИМОВА Мәхбүбә.**

***Тәхәллүсе:*** Иркен.

Үзбәк язучысы.

**692. РӘХИМОВ Насрулла.**

***Тәхәллүсе:*** Н. Рәхимов.

Үзбәк язучысы.

**693. РӘХИМОВ Мәхмүт.**

***Тәхәллүсе:*** Әҗам.

Үзбәк язучысы.

**694. РӘХИМОВА Сәгадәт.**

***Тәхәллүсе:*** Ялкын.

Үзбәк язучысы.

**695. РАХМАН Ильяс.**

***Тәхәллүсләре:*** Рахман Ильяс, И. Рахман.

Журналист. Язучы. Бөек Ватан сугышына үзе теләп китә. 1943 елда батырларча һәлак була. Ул «Горизонт» дигән әсәре белән танылa.

**696. РАХМАНКУЛОВ Габдрахман Мөхәммәтҗан улы.**

***Тәхәллүсе:*** Г. Рахманкулов.

Троицк шәһәрендә имам. 1912 елда Г. Тукай шуның дачасында кымыз эчеп ята. 1940 елларда Ташкентта үлә. Мәкаләләр язгалый.

**697. РАХМАНКУЛОВ Закир Хәсән улы.**

***Тәхәллүсе:*** Ильский.

1902 елда Оренбург өлкәсендә Буранлы авылында туа.

**698. РАХМАНКУЛОВ Марат Зариф улы.**

***Тәхәллүсе:*** Марат Рахманкулов.

Троицк шәһәрендә туа. Гали мәктәп тәмамлап, рәссам-сурәтче була.

**699. РАХМАНКУЛОВ Шәриф Зариф улы.**

***Тәхәллүсе:*** Шәриф Рахманкулов.

Троицк шәһәрендә туа. Театр мәктәбен бетереп, Казанда филармония башлыгы булып эшли.

**700. РАХМАНКУЛОВ Әхмәттаҗетдин Мөхәммәдҗан улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Әхмәттаҗетдин, Ә. Рахманкулов, Шәяхмәт.

Троицк шәһәрендә туа. Мәдрәсә бетергәч, Төркиягә китеп, гали белем ала. 1910 елда Истанбулда «Тәгърифел-мөслимин» исемле журнал чыгара.

Русиягә кайткач, төрле матбугатта языша. Революциядән соң 1917 елда Троицкида «Хөр милләт» газетасын чыгара. 1920 елда Казанга килеп, хикәя-роман, пьеса, сценарийлар яза, «Упкын», «Дулкын», «Боз астында», «Килмешәк», «Үлмәс ханым», «Тигәнәк», «Аферист», «Җиһан тетрәгәндә», «Сафура», «Петр Первый васыяте» исемле әсәрләр авторы.

**701. РАХМАНКУЛОВ Әхмәтсолтан Габделмәннан улы** (1888–1916).

***Тәхәллүсләре:*** Солтан Рахманколый, С. Рахманколый.

Мамадыш өязе Олы Шыңар авылында туа. 1908 елдан башлап яза башлый. «Тәрбия», «Аң» журналларында яза. «Русча-татарча лөгать» төзеп бастыра. «Мәликә куаклыгы», «Сугыш упкыннары», «Мишә буйлары», «Булган-беткән», «Илай», «Чын хикәя», «Төтен» исемле әсәрләр авторы.

**702. РАХМАНКУЛОВА Мәрьям Мәннан кызы.**

***Тәхәллүсе:*** Мәрьям Рахманкулова.

1901 [елда] Татарстанның Саба районы Олы Шыңар авылында туа. Казанда Фатыйма Аитова мәктәбен бетергәч, Мәскәүдә консерваториядә укый, опера артисткасы була.

**703. РӘХМӘТОВ Габдулла.**

***Тәхәллүсе:*** Ә. Рәхмәтзадә.

Үзбәк язучысы.

**704. РӘХМӘТУЛЛИН Габделбари Сибгатулла улы** (29.05.1897–1957).

***Тәхәллүсләре:*** Бари Рәхмәти, Б. Сибгат, Рәхмәтулла малае, Сибгат Бари.

Гурьев өлкәсендә Жилая Коса бистәсендә туа. Танылган балалар шагыйре. Язган әсәрләре бар.

**705. РӘХМӘТУЛЛИН Исхак Шиһабетдин улы** (1897–1943)[1].

***Тәхәллүсләре:*** Исхак Рәхмәтуллин, И. Рәхмәтуллин.

Татарстанда Зөя өязе Чукры авылында[2] туа. Мәдрәсә бетергәч, русча өйрәнә, 1919 елда партия сафына керә, Татарстанда мәгариф министры була.

**706. РӘХМӘТУЛЛИН Зариф Садыйк улы** (23.01.1873–1941)[3].

***Тәхәллүсе:*** Зариф Рәхмәтуллин.

Воткинск заводта[4] туа. Талантлы педагог, Чистайда һәм Казанда укыта.

**707. РӘХМӘТУЛЛИН Шиһабетдин Габделгазиз улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Шиһаб Рәхмәтуллин, Ш. Рәхмәтуллин.

Татарстанда Зөя өязе Чокырлы Ялан[5] авылында туа. 1893 елда «Яңа әлифбаи-төрки», «Гыйлем хисап рисаләсе», «Календарь», «Мәхлукатта зур һәм куркыныч хикмәтләрнең заһир булу вакыйгалары», «Чын әкият» исемле әсәрләр авторы.

**708. РИЗВАНОВ Гаяз.**

***Тәхәллүсе:*** Г. Ризванов.

Журналист. Татар язучысы.

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1897–1937 еллар.

[2] Чукры Алан авылы.

[3] Татар энциклопедиясе: 1872–1943 еллар.

[4] Воткинск заводы поселогы.

[5] Дөресе: Ындырчы авылы.

**709. РИЗВАНОВ Хәсән Гыйниятулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Хәсән Ризванов, Х. Ризван.

1893 елда Мордовия өлкәсе Ләмберә Алтары[1] авылында туа. 1917 елда партия сафына керә. Пенза шәһәрендә «Сабанчы», Бакуда «Баку эшчесе» газеталарын чыгарыша.

**710. РУЗИЕВ Мөхәммәтҗан.**

***Тәхәллүсе:*** Тулкын.

Үзбәк язучысы.

**711. РУЗИБАЯНОВ Әсхәт.**

***Тәхәллүсе:*** Җәяү сәях.

Үзбәк язучысы.

**712. РӘИМИ Сафа** (1895–1938).

***Тәхәллүсе:*** Срәи.

Татарстанда комсомол эшчесе. Вакытлы матбугатта катнаша. 1927–1928 елларда Мәскәүдә студент булып укып йөри. 1929 елда кулга алына. Аннан Соловки утравына җибәрелә.

**713. РӘМИЕВ Исмәгыйль Габдулла улы** (1893–1969)[2].

***Тәхәллүсләре:*** Исмәгыйль Рәми, И. Рәми, Ганкәбут, Чүпләүче.

Стәрледә туа. Уфада «Галия»дә укый. Казанда приказчик була. Төрле редакцияләрдә эшли. Язган әсәрләре: «Милләт мәҗлесе», «Вакытлы татар матбугаты», «Татар матбугатлары».

**714. РӘМИЕВ Мөхәммәдзакир Садыйк улы** (1859–1921).

***Тәхәллүсләре:*** З. Рәмиев, Дәрдемәнд.

Эстәрле өязе Җиргән авылында туа. 1880 елда Төркиягә китә. Хосусый рәвештә шәрык телләрен өйрәнә. Аннан кайткач, шигырьләр яза башлый. «Шура», «Вакыт»ларның нашире була. Танылган шагыйрь. 1921 елда Орск шәһәрендә 62 яшендә тифтан үлә.

**715. РӘМЗИ Шакир Махиян улы** (1898–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Шакир Рәмзи, Ш. Рәмзи, Ш. Р.

Минзәлә өязе Аеш авылында мулла гаиләсендә туа. 1915 елда Уфада «Галия» мәдрәсәсен тәмамлый. 1919 елны 5 нче армиянең Петроград полкында агитатор була. Екатеринбург (Свердловск)

[1] Алтар авылы.

[2] Татар энциклопедиясе: 1895–1969 еллар.

мәктәбендә укыта. Үзе теләп армиягә языла. «Кызыл Шәрык» газетасын чыгарыша. 1922–1925 елларда Мәскәүдә дәүләт журналистлары институтында укый. 1928 елда Казанга кайтып, редакцияләрдә эшли.

**716. РӘМИЕВ Сәгыйть Лотфулла улы** (1880–1926).

***Тәхәллүсләре:*** Сәгыйть Рәмиев, С. Рәми, Г. М.

Оренбург өязе Акман (Ибрай) авылында мулла гаиләсендә туа. Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. 1910 елларда Әстерханда «Идел» газетасы редакциясендә эшли. Күбрәк Уфада яши. Революциядән соң 1923 елда Уфада «Яңа тормыш» газетасын чыгарыша.

**717. РӘСҮЛЕВ Атилла Кадыйр улы.**

***Тәхәллүсләре:*** А. Расих, Атилла Рәсүлев, Атилла Расих.

1916 елның 16 октябрендә Троицк шәһәрендә укытучы гаиләсендә туа. 1934 елда Казанда ветеринария институтына керә. 1950 елда аспирантураны бетереп, кандидатлык диссертациясен яклый. 1939 елда яза башлый. Хәзер танылган әдип, зур язучы.

**718. РӘСҮЛЕВ Зәйнулла Хәбибулла углы** (1830–1917)[1].

***Тәхәллүсе:*** Зәйнулла ишан.

Златоуст өязе Шәриф авылында туа. Троицк шәһәрендәге мәшһүр ишан. Мәдрәсә тота. «Әлифба хакында» исемле әсәре бар.

**719. РӘСҮЛЕВ Габдрахман Зәйнулла улы.**

***Тәхәллүсе:*** Габдрахман Рәсүлев.

Троицк шәһәрендә мулла. Соңыннан мөфти була. Габдрахман Төркиядә укый.

**720. РӘХИМ Кәрим.**

***Тәхәллүсе:*** Рәхим Кәрим.

1921 елда «Бүз егет» исемле 9 пәрдәлек пьеса яза.

**721. РӘХМӘТИ Сәхи.**

***Тәхәллүсләре:*** Сәхи Рәхмәти, С. Рәхмәти, Рәхмәти С., Сәхи Р., С. Р.

Сәхиулла Зәкәрия улы Рәхмәтуллин. 1894 елның 28 февралендә Башкортстанда Эстәрлетамак өязе Балыклы авылында туа. Оренбургта «Заһидия» мәдрәсәсендә, аннан соң «Хөсәения»дә укый. 1911 елда Таҗикстан җирендә Канибәдам шәһәрендә канторщик

[1] Татар энциклопедиясе: 1833–1917 еллар.

булып эшли. 1915 елда гаскәри хезмәткә алына. 1919 елда Бозаулык шәһәрендә армиянең политбүлегендә эшли. 1921 елда Үзбәкстанга килеп, төрле җаваплы эшләрдә эшли. 1948–1952 елларда Үзбәк Фәннәр академиясендә тел, әдәбият өлкәсендә гыйльми хезмәткәр булып эшли.

**722. РӘҖӘПОВ Шәһит Гауни.**

***Тәхәллүсе:*** Шәһит Гауни.

Саратов губернасы Кузнецк өязе Колчура авылында туа. Вакытлы матбугатта языша, календарьлар чыгара.

**723. РӘКЫЙПОВ Шамил Җиһанша улы.**

***Тәхәллүсе:*** Шамил Рәкыйпов.

1929 елда Татарстан илендә туган язучы.

**724. САБИРОВ Габдулла.**

***Тәхәллүсе:*** Җәнҗалов.

1891 елда туа. 1916 елда Оренбургта чыккан «Кармак» журналында «Җәнҗалов» имзасы белән мәкаләләр язган журналист.

**725. САБИРОВ Рәүф Әхмәдулла улы** (22.09.1894–1937).

***Тәхәллүсе:*** Рәүф Сабиров.

Татарстанда Лаеш өязе[1] Айдар авылында туа. Сатыш мәдрәсәсендә укый. Русча хосусый рәвештә өйрәнә. Революциядән соң 1918 елда партия сафына керә. Мамадышта мәгариф бүлеге мөдире була. 1922 елда Татарстан үзәк башкарма комитеты рәисе. Обком әгъзасы. 1922 елда «Безнең юл» журналының редакторы. 1937 елда шәхес культы корбаны.

**725а. САДРЕЛҖИҺАНОВ Җәлал Гаяз улы.**

***Тәхәллүсе:*** Садрелҗиһанов Җәлал.

1910 [елда] Урал буенда баракта туа. Анасы ачтан, атасы янып үлә. Җәлал «беспризор» була. ГПУ[2] табып алып укыта. Зур дирижер булып танылды.

**726. САБИРОВА Мәнзүрә.**

***Тәхәллүсләре:*** Сабир кызы, Айдын.

Үзбәк язучысы.

---

[1] Дөресе: Мамадыш өязе.

[2] Государственное политическое управление – Дәүләт сәяси идарәсе.

**727. САБИРОВ Сафа Сабир улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Сабиров Сафа, С. Сабиров.

1915 елның 21 августында Татарстанның Питрәч районы Иске Йорт авылында крестьян гаиләсендә туа. Елга мәктәбен бетереп, пароход капитаны була. Партия сафына керә. Прозаик язучы. Хикәя җыентыклары бар. Нәшриятта редактор.

**728. САБИТОВ Габделхәй.**

***Тәхәллүсе:*** Сибай.

«Ялкын» журналына языша.

**729. САБИТОВ Хәлим.**

***Тәхәллүсе:*** Хәлим Сабит.

Самара губернасы Мәләкәс янындагы бер авылда туа. Самарада беркадәр белем алгач, Төркиягә китеп, Истанбулда университет тәмамлый. Бик талантлы галим-философ. «Шура, «Таң» журналларында языша.

**730. СӘГЫЙТЬ Ташбулат.**

***Тәхәллүсләре:*** Т. Сәгъди, Гаураш, Сандугач*.

Үзбәк язучысы.

**731. СӘГЫЙДУЛЛИН Миннегәрәй** (1898–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Әюп Гәрәй, Г. Сәгыйдуллин.

Минзәлә өязеннән. Мәктәпне бетергәч, Мәскәүдә гали белем ала. Сәләтле журналист. Талантлы язучы. 1937 елда кулга алына. Шәхес культы корбаны.

**732. СӘГЫЕВ Садыйк Мөхәммәдрәхим улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Садыйк Сәгыев, С. Сәгыев.

1883 елның 28 декабрендә Казанда туа. 13 яшендә Бишбалтада русча-татарча мәктәптә укый. 14 яшендә Алафузов заводына эшкә керә. 1905 елда большевиклар партиясе сафына керә. Төрмәдә дә утыра. Бик җаваплы урыннарда сәяси-иҗтимагый эшләр башкара.

**733. САДРЕТДИНОВ Габделхаликъ Гариф улы** (04.08.1890–1955).

***Тәхәллүсләре:*** Халикъ Садри, Садри малае, Садри Самарлы, Ирдас.

Куйбышев өлкәсендә[1] Камышлы районы Иске Ярмәк авылында туа. 1912 елда яза башлый. 1917 елда Куйбышев тәкъдиме белән партия сафына керә. 1918 елда Самарада «Киңәш» исемле газета чыгара. 1919 елда Мәскәүдә җыелган Икенче шәрык халыклары коммунистларының съездында делегат. 1925–1928 елларда Коммунистлар университетын тәмамлый. Гражданнар сугышы чорында партизаннар отряды оештыра. Ватан сугышында батальон комиссары була. «Тегермәндә», «Безнең таң», «Ватан геройлары», «Тимерче малае», «Зыятдин малайлары», «Сөргендә» пьесасы һәм башка әсәрләр авторы.

**734. САДРЕТДИНОВ Зәкәрия.**

***Тәхәллүсе:*** Зәкәрия Садри.

Казанда бай Кәримовлар кияве. «Кояш» газетасының нашире. Төркиядә гали белем алып, 1908–1909 елларда «Галия» мәдрәсәсендә укыткан кеше.

**735. САДРЕТДИНОВ Мөхәммәт Хәбибулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Мөхәммәд Садри, М. Садри.

1913 елның 20 маенда эшче гаиләсендә туа. Яшьтән ятим кала. Крестовников (хәзер Вахитов) сабын заводының ФЗӨ мәктәбендә укый. 1932–1937 елларда театр институтының драма факультетында укый, Совет армиясендә хезмәт итә. 1941–1946 елларда Бөек Ватан сугышы сафында була. Аннан кайткач, Язучылар союзы секретаре. Хәзер ул – татар халкының танылган шагыйре.

**736. САДЫЙКОВА Сара.**

***Тәхәллүсләре:*** Сара Садыйкова, С. Садыйкова.

1907 елда[2] Казанда туа. 1921 елда педагогия техникумында хор бүлегендә укый. Аннан соң Псковта консерватория тәмамлый. Танылган композитор.

**737. САИНОВ Мирзагали.**

***Тәхәллүсе:*** Мирзагали Саинов.

1908 елда Казанда «Тәрбия» журналы чыгара.

**738. СӘИТ Зыя.**

***Тәхәллүсләре:*** Тургай, Кашшафчы, Мулла шалган.

Үзбәк язучысы.

---

[1] Самара өлкәсендә.

[2] Татар энциклопедиясе: 1903 елда.

**739. СӘИТМОРАДОВ Садретдин.**

***Тәхәллүсләре:*** Әзгыч, Мохтаҗи, Рузадар, Ялганчы, Әбни, Бер кечәлек футурист, Бер мосафир, Бохарадан бер кеше, Аен.

Бохарада танылган әдип.

**740. САКАЕВ Нури Нәбиулла улы** (1885–1927).

***Тәхәллүсләре:*** Нури Сакаев, Сакай Н.

Уфа губернасы Бәләбәй өязе Богдан волосте Шланлыкүл авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Тимерьюлда эшли. «Сәйяр» труппасында танылган артист.

**741. САКАЕВ Хәмзә.**

***Тәхәллүсе:*** Сакай бабай.

Татар шагыйре.

**742. САЛАВАТОВ Шәфикъ.**

***Тәхәллүсе:*** Сал-Шәф.

Вакытлы матбугатта шигырьләр яза.

**743. СӘЛИЕВ Булат.**

***Тәхәллүсләре:*** Булат Сәли, Б. Сәлиев, Булат С.

Укытучы-тарихчы. Тарих фәннәре докторы. Үзбәкстанның ике томлык тарихын язып бастыра. 1914 елны Фирганәдә «Яңа Шәрык» газетасын чыгара. 1937 елда шәхес культы корбаны була.

**744. САЛИХОВА-ТАҺИРОВА Зөһрә Шакирҗан кызы.**

***Тәхәллүсе:*** Зөһрә Салихова.

1889 елда Казанда туа. Татар укытучылар мәктәбе хозурында хосусый имтихан тотып, рус теле укытучысы була. Казанда дүртенче кызлар гимназиясендә 1907–1912 елларда татар теле укыта. Балалар өчен язган әсәрләре дә бар.

**745. СӘЛАХОВ Ибраһим Низам улы.**

***Тәхәллүсләре:*** И. Сәлахов, Ибраһим Сәлахов.

1911 елда Казакъстанда Күкчәтау шәһәрендә туа. 1927 елда Казанга килеп, педагогия мәктәбенә керә. Аны бетергәч, газета-журнал редакцияләрендә эшли. 1933–1935 елларда армия сафында була. Аннан кайткач, педагогия институтында укый. 1936 елда «Ярату» пьесасы[1],

[1] Повесте.

«Постта»[1] шигырьләр җыентыгы, 1937 елда «Дуэль»[2] повесте басыла.

**746. САЛИХОВ Һибәтулла Сәитбаттал улы** (1794–1867).

*Тәхәллүсе:* Һиббәтулла.

Оренбург янында Чебенле авылында мулла гаиләсендә туа. Сәгыйть Каргалысында мулла була. 1856 елда «Мәҗмәгыль-әдәп» әсәрен яза.

**747. САЛИХОВ Әхмәтбик.**

*Тәхәллүсләре:* Әхмәтбик Салихов, А. Цаликов*, Ахметбек*.

Революциягә кадәр Петербургта «Ил», «Сүз» газеталарын чыгарышып йөри. Февраль революциясеннән соң 1917 елда Петербургта рус телендә «Мөселман бюросы хәбәрләре» чыгара. Аклар белән китеп, эмигрант була. 1926 елда чит илдә торып, Гаязны[3] милләтчелектә гаепләп, мәкалә яза.

**748. СӘЛИМ улы Гобәйдулла.**

*Тәхәллүсе:* Зәүкый.

Үзбәк язучысы.

**749. СӘЛИМОВ Касыйм.**

*Тәхәллүсе:* Зыя Сәит.

Үзбәк язучысы.

**750. СӘЛИМОВ Мирсәит.**

*Тәхәллүсе:* Чыгай.

Үзбәк язучысы.

**751. Сәлимҗан ГАББАСОВ.**

*Тәхәллүсе:* Гарәпша.

«Гарәпша» имзасы белән шигырьләр язган кеше.

**752. САТИЕВ Фәйзи Габдулла улы.**

*Тәхәллүсе:* Сатиев Г.

Укытучы. Язган әсәре бар.

**753. САТТАРОВ Рәкыйп Саттар улы.**

*Тәхәллүсләре:* Саттаров Рәкыйп, С. Рәкыйп.

---

[1] Пьесасы.

[2] Шигырьләр җыентыгы.

[3] Гаяз Исхакый.

1911 елда Кукмара районы Мәмәшир авылында крестьян гаиләсендә туа. 1927 елда Феодосиягә барып, индустриаль техникумда укый. Аннан соң Казанга кайтып, мастер-технолог, баш механик һәм инженер булып эшли. Яшьләрне тәрбияләүгә карата язган әсәрләре бар.

**754. САТТАРОВ Каюм** (1894–1937).

***Тәхәллүсе:*** Каюм Саттаров.

1917 елда партия сафына кереп, Мулланур Вахитов белән бергә комиссариат төзи. Төрле җаваплы эшләр башкара. Вакытлы матбугатта язышa.

**755. САТТАРОВ Садыйк.**

***Тәхәллүсе:*** Садыйк Саттаров.

Уфада укытучы була. 1916 елда Уфада укытучылар курсы ача. Вакытлы матбугатта язышa.

**756. САТТАРОВ Шәриф** (1887–1971).

***Тәхәллүсләре:*** Шәриф Саттаров, Ш. Саттаров.

Оренбург өлкәсе Сәгыйть бистәсендә туа. 1909 елда Казанда Учительская школаны тәмамлый. Бубида русча укыта. 1911 елда кулга алына. 1913 елга кадәр полиция надзоры астында була. 1919 елда Әстерханда «Халык мәгарифе» дигән журнал чыгара. Язган әсәрләре: «Зөһрә йолдызы», «Татар тәгассеб вә җәһаләт корбаны», «Татар милләтен тәрәккый иттерүчеләр», «Бәхетсез татар кызы», «Бетсә-бетсен», «Татар халкы», «Азат халык корбаннары», «Фабрикант кызы», « Стенька Разин», «Мирзалар һәм чуарлар».

**757. САФИН Закир** (26.02.1905–1945)[1].

***Тәхәллүсе:*** Закир Сафин.

Татарстанның Әлмәт шәһәрендә[2] туа. 1926 елда Казанда театр техникумын тәмамлый. 1926–1934 елларда Мәскәү һәм Әстерхан труппаларында уйный. 1938 елда Мәскәү консерваториясе хозурындагы татар студиясен тәмамлый. Аннан соң Татар дәүләт опера һәм балет театрында, академия театрларында артист, режиссер булып эшли. «Атказанган сәнгать эшлеклесе» исемен ала.

[1] Татар энциклопедиясе: 1905–1965 еллар.

[2] Чистай өязе Яңа Әлмәт авылында туа.

**758. САФИН Мирсәит.**

***Тәхәллүсе:*** Мирсәит Сафин.

1920 елда Эстәрледә «Мәгариф эшләре» журналын чыгара.

**759. САФИН Рафаэль Әхмәтсафа улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Р. Сафин, Сафин Рафаэль.

1932 елның 16 февралендә Башкортстанның Кигинск районы[1] Еланлы авылында колхозчы гаиләсендә туа. 1947 елда Уфада музыка мәктәбендә укый. Аны бетергәч, Мәскәүдә Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый. Аннан соң төрле редакцияләрдә эшли. Шигырь, поэма җыентыклары бар.

**760. САФИН Шамил Сабир улы.**

***Тәхәллүсе:*** Шамил Сафин.

1917 елда Әлмәт районы Мәмәт авылында туа. Укытучы, тарихчы, язучы.

**761. САФИУЛЛИНА Соня.**

***Тәхәллүсе:*** Сафиуллина Соня.

1894 елда Әстерханда туа. Кызлар мәктәбендә укый. 1911 елда сәхнәдә уйный башлый. 1919 ел урталарына кадәр Әстерханда эшли. Аннан соң фронт труппалары белән китә.

**762. СӘФӘРГАЛИЕВ Зариф.**

***Тәхәллүсләре:*** Зариф Сәфәргалиев, З. Сәфәргали.

Элекке Алафузов заводы эшчесе, соңгы вакытта большевиклар партиясе члены булып йөри. 1894 елда эшчеләр хәрәкәтенә катнаша. [...]

**763. СВЕРИГИН Рифат.**

***Тәхәллүсе:*** Сверигин Р.

1933 елда[2] туа. Фәннәр академиясе Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли.

**764. СЕМЕНОВ Тимофей.**

***Тәхәллүсләре:*** Т. Р., Т. С.

Чуваш шагыйре.

---

[1] Кыйгы районы.

[2] Дөресе: 1932 елда.

**765. СИТДИКОВ Басит.**
***Тәхәллүсләре:*** Сәнҗар, Бер кеше.
Үзбәк язучысы.

**766. СИТДИКОВ Сәитәхмәт.**
***Тәхәллүсләре:*** Мөтәллид, Алмас, Назчы, Майна.
Үзбәк язучысы.

**767. СИМАЕВ Әхмәт Садретдин улы** (1915–1944).
***Тәхәллүсе:*** А. Влиндор.
Пенза өлкәсендә (хәзер Мордва республикасы) Усть-Рахманов авылында туа. Журналист. Германиядә фашистлар төрмәсендә Муса Җәлил шигырьләрен русчага тәрҗемә иткән кеше. Әнисе Шәрифә Старькованы, хатыны Валентина Листопадны, кызы Людмиланы фашистлар җәзалап үтерәләр.

**768. СИРАҖЕТДИНОВ Гали.**
***Тәхәллүсе:*** Г. Сирай.
Язгалаган кеше.

**769. СИРИН Хәниф улы Батыршин** (1896–1969).
***Тәхәллүсләре:*** Б. Сирин, Б. С., С. Батыршин.
Баулы районы Кәрәкәшле авылында туа. Бәйрәкәдә, Бөгелмә шәһәрендә укый. 1931–1932 елларда Казан педагогия институтында укый. Шигырь җыентыклары бар. Шагыйрь. 1937 елда кулга алына.

**770. СОЛОВЬЕВ Тимерша Салават улы** (1882–1947).
***Тәхәллүсләре:*** Т. Соловьев, «Чүкеч», Тимерша С.
Оренбугта революциягә кадәр «Чүкеч» исемле көлке журналы чыгарган буржуаз язучы.

**771. СОЛТАНГАЛИЕВ Мирсәит Хәйдәргали улы.**
***Тәхәллүсләре:*** Солтангалиев Мирсәит, Көлке баш, «Мөселманин».
Учительская школаны бетереп, укытучы һәм язучы булган кеше. Революциядән соң Коммунистлар партиясенә кереп, җаваплы эшләр башкара. [...]

**772. СОЛТАНОВ Вәсим.**
***Тәхәллүсләре:*** Вәсим Солтанов, В. Солтанов.

Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укый. Тозсызрак булса да, шигырьләр язгалый. «Канау буе», «Ләззәт яки тәм», «Акча тик ятмый» кебек әсәрләре бар.

**773. СОЛТАНОВ Зәйни – Зәйнелгабидин Гобәйдулла хаҗи улы Сөләйманов** (1892–1952).

***Тәхәллүсләре:*** Зәйни Солтан, З. Солтан.

Әстерханда хаҗи гаиләсендә туа. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. 1907 елда театрга катнаша башлый һәм бөтен гомерен театр сәнгатенә багышлый. Күренекле актер, режиссер, педагог, тәнкыйтьче һәм тәрҗемәче булып китә. 1919 елда Әстерханда, 1920 елда Самарада беренче татар театр студиясе, 1923 елда Казанда Театр техникумын ачу аның исеме белән баглы.

1924 елда – «Хезмәт батыры», 1926 елда – атказанган, 1939 елны «Халык артисты», 1946 елда «РСФСРның атказанган артисты» исемнәрен ала. 1952 елның 2 маенда Казанда үлә.

**774. СОЛТАНБЕКОВ Фәйзрахман Фәйзелхак улы** (1892–1940).

***Тәхәллүсләре:*** Фәйзрахман Солтанбик, Ф. Солтанбик, С. Фәйзи, Ф. С.

Татарстанның Минзәлә өязе Бигеш авылында мулла гаиләсендә туа. Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. 1910 елларда кузгалган шәкертләр хәрәкәтенә кушылып, «Хөсәения»не ташлап чыгып китә. Троицкига килеп русча укый. Аннан соң Бакуга китеп, Бибихәят мәхәлләсендә мөгаллим була. Революциядән соң Башкорт республикасын төзүдә катнаша.

1918 елда партия сафына керә. Революциягә кадәр «Йолдыз» газетасында, «Сөембикә» журналында язышкан булса, революциядән соң 1919 елда «Мамадыш тавышы» газетасында да, башка газеталарда да язышa. Мамадыш мәгариф бүлегендә инструктор булып эшли. 1919 елда Мәскәүдә җыелган бөтен шәрык халкы коммунистларының 2 нче съездында[1] делегат була. Соңгы елларда Казанда зур җаваплы вазифалар башкара.

[1] Көнчыгыш мөселман халыклары коммунистик оешмаларының II Бөтенроссия съезды.

**775. СӨБХАНКУЛОВ Әхмәт Сәитгәрәй улы** (1899–1927).

***Тәхәллүсләре:*** Әхмәт Сөбханкул, Ә. Сөбханкулов.

Оренбург Каргалысында хезмәткәр гаиләсендә туа. 1918 елны партия сафына керә. 1920 елларда Бохара, Хива җирләрендә революция җитәкчеләренең берсе. Вакытлы матбугатта языша.

**776. СӨБХАНКУЛОВ Габдулла.**

***Тәхәллүсе:*** Габдулла Сөбханкул.

1894 елны Троицк шәһәрендә аксак ишан гаиләсендә туа. Төркиягә китеп, гали белем алып кайта. 1919 елларда Уфада «Ватан» газетасы чыгара. Партиягә кергәнен хәтерләмим. Партиядән куылганын да хәтерләмим.

**777. СОРОКИН Касыйм.**

***Тәхәллүсләре:*** Сорокин Касыйм, К. С.

1919 елда Фирганә шәһәрендә «Яңа Шәрык» газетасының редакторы.

**778. СӘГЫЙТОВ Кәрим Мөхәммәдша улы** (1888–1939).

***Тәхәллүсләре:*** Кәрим Сәгыйть, К. Сәгыйть, «Шималь» корреспонденты», К. С., Габделкәрим С.

Тәтеш өязе Килдураз волосте Таугилде[1] авылында туа. Укытучы һәм журналист. 1906–1907 елларда Дәүләт думасыннан «Кояш» газетасының махсус хәбәрчесе булып яза. Революциядән соң укытучылар съездын җыю эшләрендә актив катнаша. 1918 елда Петербургта «Шимал ягы» газетасының редакторы да, нашире дә була. Язган дәреслекләре һәм хикәя җыентыклары бар.

**779. СӘГЪДЕТДИНОВ Габдрахман Гайнан улы** (1889–1956).

***Тәхәллүсләре:*** Габдрахман Сәгъди, Г. Сәгъди, А. Сәгъди, Г. С., Зәүкый, Рухи, Фикри.

Уфа губернасы Златоуст өязе Таимов[2] авылында мулла гаиләсендә туа. Троицкида «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укый. Аннан соң Төркиядә гали белем алып кайта. 1906 елда укыту эшенә керешә. 1908 елда яза башлый, гомер буе укытучы һәм язучы була. 1956 елның 6 июнендә Сәмәрканд шәһәрендә күренекле татар галиме, пе-

[1] Төйгелде авылы.

[2] Дөресе – Таими авылы.

дагог, филология фәннәре докторы, профессор Сәгъди вафат була. Калдырган әдәби, фәнни мирасы зур.

**780. СӘГЪДИ Һади Гайнан улы** (1891–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Һади Сәгъди, Һ. Сәгъди.

Г. Сәгъдинең туганы, дәреслекләр язган укытучы.

**781. СӘГЫЙТОВ Әбрар Закир улы** (1895–1939).

***Тәхәллүсләре:*** Әбрар Сәгыйди, Ә. Сәгыйть, Хәмит, Путиляк, Әбү тигәнәк, Әбү Сәгыйть, Шәрык баласы, Ә.С. Хәмит.

Татарстанның Кайбыч районы Килдураз авылында[1] туа. Шул заман мәдрәсәсен бетергәч, Кошман авылында укытучы була. 1917 елда «Ирек азаны» исемле әсәрен бастырып, иҗат эшенә тотына. Вакытлы матбугатта шигырьләр язып, актив катнаша. 1921–1924 елларда Килдуразда мулла булып тора. Соңыннан муллалыгын ташлап, мәгариф эшенә бирелә.

Сандугачлар сайрый сахраларда,
«Бристоль»дә Кәрим Әмири.
Гошер, фитыр, садака җыеп ята
Килдуразда Әбрар Сәгыйди, –

дип җырлый торган идек ул чакта.

**782. СӘГЪДИЕВ Роальд Зиннур улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Р.З. Сәгъдиев.

Татар академигы.

**783. СӘЕТГАЛИЕВ Сәхипгәрәй** (1892–1937)[2].

***Тәхәллүсе:*** Сәхипгәрәй Сәетгалиев.

Октябрь революциясенә чаклы Екатеринбургта циркта уйнаучы артист. 1917 елда партия сафына кереп, иҗтимагый-сәяси юнәлештә зур җаваплы эшләр башкара. Татарстан һәм Кырым республикаларында министрлар советы рәисе була.

**784. СӘГЫЙТОВА Энҗе Мөхәммәдкәрим кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Энҗе Сәгыйтова, Э. Сәгыйтова.

---

[1] Дөресе – Кече Кошман авылы.

[2] Дөресе: 1894–1939 еллар.

Анасы – Халисә Шәрәф. Ленинградта Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәнең шәрык бүлеге мөдире. Филология фәннәре доценты[1]. Пенсиядә.

**785. СӘЙДӘШЕВ Салих** (1900–1954).

***Тәхәллүсе:*** Салих Сәйдәш.

Татар халкының яраткан данлыклы композиторы.

**786. СУБАЕВ Мәхмүт** (1898–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Казалы казасы, Сәмруг, Әбү Варәҗә, Рәмул, Субай.

Казалы шәһәрендә туа. «Вакыт» газетасының хәбәрчесе була. Журналист.

**787. СӘЙДӘШЕВ Шакир.**

***Тәхәллүсе:*** Һәшрәб.

Үзбәк язучысы.

**788. СӘЛИМИ Фатих.**

***Тәхәллүсе:*** Сәлими Ф.

«Дин вә мәгыйшәт» журналында язучылардан.

**789. СӘЛИМОВ Ләбиб.**

***Тәхәллүсе:*** С. Ләбиб.

Уфада «Галия» шәкерте. Вакытлы матбугатка язып тора. Төркиягә китеп врач була һәм шунда кала.

**790. СӘЙФУЛЛИНА Абруй-Сәйфи** (1890–1960).

***Тәхәллүсләре:*** Нәкыя, Абруй, Миләүшә, А. Гыйльманова, Абруй Сәйфи.

Татарстанның Чистай районы Күлбай-Мораса авылында туа. 1915–1916 елларда әстерханлы Мортаза Гыйльмановка кияүгә чыгып, Әстерханда укытучы була. Бу елларны Абруй «Аң» журналында язышa, соңрак Гыйльмановтан аерылып, Фатих Сәйфи-Казанлыга кияүгә чыга. Казанда сәхнәгә җыр белән чыккалый. Соңрак елларда адвокат була. 1937 елны кулга алынып, 10 ел лагерьда йөреп кайта. Әсәрләре бар.

**791. СӘЙФУЛЛИН Габбас Шиһабетдин улы** (1887–1951).

***Тәхәллүсләре:*** Габбас Сәйфи, Г. Сәйфи, Сәйфуллин Габбас.

[1] Кандидаты.

Зур педагог. Белемле журналист һәм язучы. Лөгатьче. «Русча-татарча-гарәпчә сүзлек» язышкан кеше. Язган дәреслекләре бар.

**792. СӘЙФИ Хафиз.**

***Тәхәллүсе:*** Хафиз Сәйфи.

Гаскәри хезмәттәге кеше. Белемле журналист, политработник. Казанда «Коммунистлар клубы» дип аталган офицерлар йортының башлыгы булып тора.

**793. СӘЙФИ-КАЗАНЛЫ – Фатих Камалетдин улы Сәйфуллин** (1888–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Фатих Сәйфи-Казанлы, Ф. С-Казанлы, Исәнбай, Гарби, Бакыр күз, Батыр күз, Ф. Камалов, Чәпи Камали малае, Казанлы.

Татарстанның Әлки районы Карамалы авылында туа. Укытучы һәм журналист, язучы, әдип. Ул күп эшли, күп яза. Педагог буларак та күп кадрлар әзерли. Галимҗан Ибраһимов, Шәһит Әхмәдиевләрнең якын дусларыннан. Бик күп газеталарга редактор була. Язган әсәрләре: «Безнең заман», «Талак», «Ямьсез тормыш», «Дошманнар», «Зәкуан мулла шәҗәрәсе», «Зөбәрҗәт», «Өч нарат», «Җәмәгать хадиме» вә башкалар.

**794. СӘЙФЕТДИНОВ Галимҗан Җамалетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Галимҗан Сәйфетдинов, Баязитов, Баязит, Гыйсъян, Г.Җ. Сәйфуллин, Ибнеямин.

1882 елның 29 гыйнварында Оренбург губернасы Троицк шәһәрендә туа. Әнисе Хәбибҗамал. 1895 елда русча укый башлый. 1901 елда Казанга килеп, Учительская школада укый. Ямашев, Коләхметовлар белән таныша. Татар яшьләре арасында демократик хәрәкәт формалаша башлаган чорда бик актив эшли. 1904 елда кулга алына.

Чыгышы белән Биектау районы Дөбьяз авылыннан.

**795. СӘИТБАТТАЛОВ Сөләйман Фәхретдин улы.**

***Тәхәллүсе:*** Сөләйман С.

Уфада сәяси-иҗтимагый җаваплы эшләрдә эшли. Башкорт министрлар советы рәисе урынбасары була. Кәлимулла Хәсәнов турында китап яза.

**796. СӘЙФЕЛМӨЛЕК.**

***Тәхәллүсе:*** Сәйфелмөлек.

«Табылдык» дигән әсәр язып, шундый имза куйган теш врачы.

**797. СӘЙФЕТДИНОВ Фатих-Уфалы** (1889–1923).

***Тәхәллүсләре:*** Фатих Сәйфетдинов, Ф. Сәйфи, Ф. С., Фатих Сәйфи учитель*, Ф. Сәйфи Уфалы.

Тәҗрибәле педагог, тәгълим-тәрбия турында матбугатта бик күп язган язучы. Язып бастырган дәреслекләре бар. Танылган әдип.

**798. СӘЛИМОВ Хәйдәр.**

***Тәхәллүсләре:*** Хәйдәр Сәлимов, Үзе, Х. Сәлимов.

1884 елда Куйбышев өлкәсе Мәләкәс районы Мукшы Күле авылында крестьян гаиләсендә туа. 1918 елда Самарада «Яңа көч» газетасында, 1919 елда Самарада «Кызыл Идел» газетасында редактор була. Сатирик шигырьләр яза.

**799. СӘЛИМГӘРӘЕВ Габдрахман.**

***Тәхәллүсе:*** Г. Сәлимгәрәев.

Омскида 1919 елда «Наша газета. Хакыйкать»[1] чыгара. Шул ук кеше «Алла полкы» (Божий полк) төзеп йөри.

**800. СӘМИТОВА Газизә Баһаветдин кызы** (1862–1929).

***Тәхәллүсләре:*** Сәмитова Газизә, Баһаветдин кызы*.

Әстерхан өлкәсендә Ташлыяр авылында сәүдәгәр гаиләсендә туа. Сайланма шигырьләре 1965 елда басылып чыга. 1929 елда Ташлыярда үлә. Кабере шунда.

**801. СӘҮБАНИ Г.**

***Тәхәллүсе:*** Сәүбани Г.

1919 елда Стәрлетамакта «Кызыл Ашказар» исемле газета чыгара.

**802. СҮНЧӘЛӘЙ Сәгыйть Хәмидулла улы** (1889–1941).

***Тәхәллүсләре:*** Сәгыйть Сүнчәләй, С. Сүнчәләй, Сәгыйть Әбелфәрид, Әбелваккас, Сәгыйть Ваккас, С. С.

Хвалынь өязе Мәстәк[2] авылында туа. Казанда Учительская школаны бетереп, укытучы була. Вакытлы матбугатта бик еш ши-

[1] «Хакыйкать. Безнең газета» – «Правда. Наша газета».

[2] Иске Мәстәк авылы.

гырьләр яза. Тукайның дусты, хатлар язышa. 1929 елда донос буенча кулга алына. Соловки утравына озатыла. 1913 елда Генрих Гейненың «Әл-Мансур»ын тәрҗемә итә, «Рахилә» пьесасын яза. Баби мәзһәбе тарихын язган «Баб» атлы әдәби китаптан көчле поэма язып калдыра.

**803. СҮНЧӘЛӘЙ Ваккас.**

***Тәхәллүсләре:*** Эшче, Ваккас С*.

Ташкентлы. Үзбәк язучысы.

**804. СҮНЧӘЛӘЙ ШӘРИФ** (1885–1959).

***Тәхәллүсләре:*** Ш. Сүнчәләй, Шәриф Сүнчәләй.

Чистай өязе Иске Әлмәт авылында туа[1]. Укытучы һәм журналист. Революциядән соң Уфада 1922 елда «Мәгариф фронты» журналын чыгарыша.

**805. СӨЛӘЙМАНИЯ Фәхрелбәнат Сибгатулла кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Фәхрелбәнат Сөләймания, Ф. Сөләймания.

1852 елда «ОПУ»лар авылында туа[2], ире Хәлил – Горький шәһәрендә[3] ахун, улы Габдулла Сөләймани Уфада казый була. 1905 елда «Казан мөхбире» газетасында шигырьләре басыла. 1910 елда «Микъраз әт-тәгассеб», «Гаилә дәресләре» исемле китаплары Казанда басылып чыга. Хатын-кызлар мәсьәләсендә иске шәригать карашындагы кеше.

**806. СӨЛӘЙМАНИ Габделхәмит Юнусов.**

***Тәхәллүсләре:*** Чулпан, Хәмит Сөләймани, Календарь, Әндиҗанлы.

Әндиҗанлы үзбәк язучысы. 1914 елда «Шура» журналында, Ташкентта чыккан үзбәкчә «Садаи Төркестан» газетасында яза.

**807. СӨЛӘЙМАНОВ Габдулла Хәлиулла ахун улы** (1886–1920)[4].

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Сөләймани, Г. Сөләймани.

Горький шәһәрендә, Мәскәүдә мулла була. Аннан соң Уфада Диния нәзарәтендә казый була. Бәйрутта Америка көллиятен тәмамлый,

[1] Дөресе: Хвалынь өязе Иске Мәстәк авылы.

[2] Казан губернасы Чар өязе Түбән Оры авылында туа.

[3] Горький шәһәре – Нижний Новгород шәһәре.

[4] Дөресе: 1886–1937 еллар.

гарәпчә, русча, французча, инглизчә яхшы белә. Хөтбәләрен татарча укып, Коръәнне дә татарчалаштыру мәсьәләсен күтәрә.

**808. СӨЛӘЙМАН ФӘТХЕЛКАДЫЙР (Габделкадыйр).**

***Тәхәллүсләре:*** Җалкынбай, Тимербай курайчы, Ф. Сөләймани, Инан.

1888 елда Башкортстанда туа. «Шура», «Ак юл» журналларында языша, «Салават» пьесасын яза, «Үләт», «Батыр» пьесаларын яза. Төркиягә китеп, анда профессор була, «Мәкаләләр һәм тикшерүләр» исемле төрекчә китап яза. Төркиядәге имзасы – «Инан».

**809. СӨЛӘЙМАНОВ Мөдәррис хаҗи Вәли улы** (1908–1943).

***Тәхәллүсләре:*** Мөдәррис Сөләйманов, М. Сөләйманов.

Башкортстанның Благовар районы Шәмәй авылында туа. 1924 елда комсомолга керә. 1929 елда партия сафына кабул ителә. 1936 елда гали авыл хуҗалыгы мәктәбен бетереп, төрле редакцияләрдә эшли, Бөек Ватан сугышы вакытында үз ирегe белән фронтка китә. Политработник, 1943 елда барган каты сугышларда батырларча һәлак була.

**810. СӨЛӘЙМАНИ ШАКИР.**

***Тәхәллүсләре:*** Сер, Хокандлы.

Үзбәк язучысы, хокандлы.

**811. СӨНГАТУЛЛИН Габдрахман** (1893–1917)[1].

***Тәхәллүсләре:*** Г. Сөнгати, Г. Сөнгать, Г. С.

Татарстанда Тәтеш өязе Балчыклы авылында мулла гаиләсендә туа. Казанда «Халидия» мәдрәсәсендә укый, «Ак юл», «Сөембикә», «Аң» журналларында шигырьләр-поэмалар яза. 1915 елны солдатка алына. Шуннан кайтмый. «Хозыр», «Су анасы» балладаларының авторы.

**812. САТТАРОВ Маннур.**

***Тәхәллүсе:*** Маннур Саттаров.

Казанда укытучы һәм юморист шагыйрь. «Чаян»да да эшли. Язган әсәрләре бар.

**813. ТАИПОВ Фазыл Абдулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Фазыл Таипов, Ф. Таипов.

[1] 1894–1917 елдан соң.

1896 елда туа, кайда тууын белмәдек. 1918 елда партия сафына керә. 1919 елда Икенче армия тарафыннан чыгарылган «Кызыл көрәшче» газетасының редакторы була. Сарапул шәһәрендә газетаның 10 саны чыга.

**814. ТАКТАШЕВ Һади Хәйрулла улы** (1901–1931).

***Тәхәллүсләре:*** Һади Такташ, Аллан, Мокамай, Мокамайның якын кардәше, Шагыйрь № 1, Камай, Ата шагыйрь, Чабата, Һәдия Такташева, Һәдия Хәйрулла кызы, Хәйрулла малае, Һ. Таш, Точка, Атакай, Абдул, Һ. Т., Т.Һ. Таш*.

Тамбов өлкәсе Сыркыды авылында крестьян гаиләсендә туа. 13 яшендә ул Төркестанга барып чыга. Атасы шунда күчеп китә. 1918 елда авылына кайтып укытучы була. Оренбург шәһәренә килеп, «Юксыллар»[1] газетасында секретарь. 1921 елда Ташкентка килеп, «Белем йорты» журналында эшли. 1922 елда Казанга килә һәм ахыр гомеренә кадәр шунда кала. Анда төрле редакцияләрдә эшли. «Төркестан сахраларында», «Җир уллары». «Гасырлар һәм минутлар», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Киләчәккә хатлар» «Күмелгән кораллар» һ.б. әсәрләрен шунда яза.

**815. ТАНАЛИН Һиббәтулла Әдиятулла улы.**

***Тәхәллүсе:*** Таналин Һ.

Оренбург өлкәсендә Саракташ районы Никитин авылында туа. Ченәкәй турында язган нәрсәсе әһәмияткә ия.

**816. ТАНАЧЕВ Вәлитхан** (1882–1970).

***Тәхәллүсләре:*** Вәлитхан Таначев, В. Таначев.

Әстерхан ягыннан. Казан адвокаты. 1910 елларда Әстерханда «Идел» газетасында языша. Университетны бетергәч, Миролюбов дигән атаклы адвокатта ярдәмче булып эшли. Хәдичә Ямашевага өйләнеп, Казанда яши. 1939 елда икесе дә кулга алына. Хәдичә апа шунда үлеп кала, Вәлитхан ага срогын тутырып кайта. 1970 елда Казанда үлә.

**817. ТАРПИЩЕВ Хөсәен Гани улы** (1894–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Тарпищев Х, Хөсәен Тарпищев.

Пенза өлкәсе Енә авылында туа. 1918 елда партия сафына керә. 1919 елда гаскәрдә. Шәрык коммунистларының 2 нче съездында

[1] «Юксыллар сүзе».

катнаша. 1920 елда Самарада «Кызыл дөнья» газетасы чыгара. Анда Мәхмүт Тимербаев, З. Малик, Сирин, Мирза Давыдов. Г. Хәлим, Кәрим Тинчуриннар языша. 1925 елларда Казанга килеп, наркомфин булды.

**818. ТАШМӨХӘММӘТ мулла Кушак.**

***Тәхәллүсе:*** Мискин.

Үзбәк шагыйре.

**819. ТАШМӨХӘММӘДОВ Муса.**

***Тәхәллүсе:*** Айбик.

Үзбәк әдибе. Танылган кеше, язган романнары бар.

**820. ТАХТАМЫШЕВ Нәҗип Сибгатулла улы** (1883–1933).

***Тәхәллүсләре:*** Н. Думави, Нәҗип Думави, Өй анасы, Әбелфаикъ, Чистайлы, Дамавай.

Татарстанның Аксубай районы Яңа Дума авылында туа. Үз чорында еш кына вакытлы матбугатка шигырьләр, хикәяләр язып тора, шагыйрь. «Әрәмтамаклар», «Уйгану», «Хәсрәт чаткылары», «Иблис», «Күке һәм тәкәллефсез кунак», «Черки һәм кигәвен», «Энә карагы», «Чәнечкеле корт», «Тасма суалчан», «Куыклы корт», «Әйләнчек» вә башка шигырь һәм хикәяләр авторы.

**821. ТАҢГАТАРОВ Әхнәф.**

***Тәхәллүсләре:*** Әхнәф Таңгатаров, Ә. Таңгатаров.

Язучы. 1914 елда «Шура» журналында «Тел ярышы» игълан иткәч, шул ярышта Мәҗит Гафури белән Таңгатаров җиңүче булып чыгалар. Белемле язучы. Саф татар телендә яза.

**822. ТАҺИРОВ Афзал** (1890–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Афзал Таһиров, Таһиров Афзал, А. Таһиров*, Бичура*.

Татарстанның Әлмәт районы Габдрахман авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый, 1911 елда солдат хезмәтенә китә. 1913 елда большевиклар партиясе сафына керә, Гражданнар сугышында катнаша. 1922 елда Урта Азиядә басмачлар белән көрәшә. 1925–27 елларда Партия Үзәк комитеты хозурындагы курсларда укый. 1931 елда Башкортстан Башкарма комитеты рәисе. 1932 елда Бөтенрусия Башкарма комитеты әгъзасы. Башкорт, татар, рус телләрендә 30 га якын җыентыклары бар.

**823. ТАҺИРОВ Гай.**

***Тәхәллүсләре:*** Гай.

Татарстанның атказанган артисты. Бию остасы һәм остазы.

**824. ТАҺИРОВ Мөхәммәт Хәмзә улы** (1897–1929).

***Тәхәллүсләре:*** Таһиров Мөхәммәт, М. Таһиров.

Татарстанда сәяси-иҗтимагый җаваплы эшләрдә. Татарстан мәгариф министры була, 1929 елда үлә.

**825. ТАҺИРОВ Индус Ризак улы.**

***Тәхәллүсе:*** Таһиров Индус.

Гали мәктәп тәмамлап, университетта укытучы галим.

**826. ТАҺИРОВ Ибраһим.**

***Тәхәллүсе:*** Ибраһим Таһири.

1914 елларда Ташкентта «Чаян» исемле көлке журналы чыгара башлый, ләкин тиз туктаталар. Себер татары. Курган шәһәрендә укытучы.

**827. ТАҺИРОВ Солтан.**

***Тәхәллүсләре:*** Фәрихат, Исбах Таһиров, Т. С.

Әстерханда яшь журналист.

**828. ТАҺИРОВ Һади.**

***Тәхәллүсләре:*** Һ. Таһиров, Һ. Таһири*.

«Янгура» әсәрен язган кеше[1]. Екатеринбург шәһәреннән «Шура», «Аң» журналларына язып торган шагыйрь һәм журналист, укытучы.

**829. ТАҖИ Карый Мөхәммәдрәхим.**

***Тәхәллүсе:*** Тикән.

Үзбәк язучысы.

**830. ТАҖЕТДИНОВ Басыйр Габдулла улы** (1894–1935).

***Тәхәллүсләре:*** Таҗетдинов Басыйр, Б. Таҗи*.

Татарстанда Мамадыш өязе Качимир авылында мулла гаиләсендә туа. Укытучы, 1918 елда партия сафына керә. Сәяси-иҗтимагый җаваплы эшләрдә катнаша.

**831. ТАҖЕТДИНОВ Мөхетдин Базар улы.**

***Тәхәллүсе:*** М. Таҗи.

[1] Дөресе: «Янгура» әсәренең авторы – Афзал Таһиров.

1906 елның 16 мартында Башкортстанның Белорецкий районы Карталы[1] авылында урман эшчесе гаиләсендә туа. 1925–1929 елларда Уфа педагогия техникумын, 1934 1936 елларда педагогия институтын тәмамлый. Танылган язучы. Башкорт, рус телләрендә 10 нан артык шигырь, пьеса җыентыклары бар.

**832. ТАҖЕТДИНОВ Сәгыйть.**

***Тәхәллүсе:*** Сәгыйть Таҗетдин, С. Таҗи.

Оренбург өлкәсе Саракташ районы Карагуҗа авылында туа. Журналист, язучы. Хәйретдин Мөҗәй белән бергә фашистларның Дахау лагеренда җәзалап үтерелә.

**833. ТОЛЫМБАЙСКИЙ Гомәр** (Габделхак Шаһиәхмәтов (1900–1938)).

***Тәхәллүсләре:*** Гомәр Толымбайский, Г. Толымбай, Түки, Г. Т., Шәяхмәт.

Татарстанның Буа районы Толымбай авылында туа. Педагогия институтында белем алгач, төрле редакцияләрдә эшли. Язучы-прозаик, тәнкыйтьче. «Толымбайский хикәяләре», «Чуан тишелде», «Соңгы хат», «Бал корты», «Тәти кунаклар», «Язгы ташкыннар», «Кызыл Армиядән кайткач», «Баҗайлар» исемле хикәя җыентыкларының авторы.

**834. ТЕРЕГУЛОВ Гомәр Хәбибрахман улы** (1886–1942)[2].

***Тәхәллүсләре:*** Гомәр Терегулов, Г. Терегулов.

Уфа мирзаларыннан. Казанда Учительская школаны бетергәч, 1904–1905 елларда Швейцариядә укый. Кайткач, 1913 елда Мәскәүдә юридик факультет бетереп юрист [була]. Эсер-таңчы буларак, Вяткага сөргенгә сөрелә. 1919–1920 елларда чит илләргә китә. 1920 елда Харбинда газета чыгарыша. Ак эмигрант. «Шәкерт һәм яшьләр», «Нигә болай» әсәрләре авторы.

**835. ТЕРЕГУЛОВ Ибраһим Вәлиулла улы** (1852–1922).

***Тәхәллүсе:*** Ибраһим Терегулов.

1874 елда Казан гимназиясен бетергәч, ветеринария институтына керә һәм мәктәпләрдә русча укыта. 1878 елда Учительская шко-

[1] Кәртәле.

[2] Татар энциклопедиясе: 1883–1938 еллар.

лада укыта. Күренекле педагог һәм язучы. Төрле фәннән тәрҗемә иткән һәм хайваннар турында үзе язган әсәрләре бар.

**836. ТЕРЕГУЛОВ Әбүбәкер Гәрәй улы** (1884–1966).

***Тәхәллүсләре:*** Әбүбәкер Терегулов, Ә. Терегулов.

Уфада туа. Медицина факультетын тәмамлап, эчке авырулар профессоры була. Медицина журналы чыгара. 70 тән артык фәнни әсәрләре бар.

**837. ТЕЛЛӘХАНОВА Хасият.**

***Тәхәллүсе:*** Х. Телләхан кызы.

Үзбәк язучысы.

**838. ТИМЕРОВ Сөнгат.**

***Тәхәллүсе:*** Тимери.

«Тимери» имзасы белән язган китаплары бар.

**839. ТИНЧУРИН Кәрим Мөхәммәдгали улы** (1887–1947)[1].

***Тәхәллүсләре:*** Кәрим Тинчурин, К. Тинчурин, К. Үзбәк, Тараканлы*.

Пенза губернасы Бедный Демьян районы Таракан авылында туа. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлагач, сәхнә эшчесе булып китә. Күренекле актер, тәҗрибәле педагог, белемле драматург һәм режиссер. «Биктимер бабай», «Ак өрәкләр», «Юбилей», «Манзара», «Нәни абый», «Беренче чәчәкләр», «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе», «Ил», «Өч гыйшык», «Хан кызы», «Кандыр буе», «Зәңки баласы», «Җилкуарлар», «Җилкәнсезләр», «Назлы кияү», «Шомлы адәм», «Мәрҗәннәр», «Алар өчәү иде», «Дача мөбарәк булсын», «Американ», «Сүнгән йолдызлар», «Сакла, шартламасын», «Йосыф – Зөләйха», «Хәләл кәсеп», «Соңгы сәлам» исемле әсәрләрнең авторы.

**840. ТУЙБАХТИН Касыйм Шаһиҗиһан улы, (Шиһабетдинов)** (1888–1918).

***Тәхәллүсләре:*** Касыйм Туйбахтин, Челтәрле, Әрсез, Милләтче, Касыйм.

Татарстанда Спас өязе Ромаданский волосте Каргалы авылында туа. Казанда «Мөхәммәдия»дә укый. Революциягә кадәр булган газеталарда актив языша. Революциядән соң партия сафына кереп,

[1] Татар энциклопедиясе: 1887–1938 еллар.

сәяси-иҗтимагый эшләргә чума. Әстерханда «Тартыш», «Солдат ялкыны» газеталары чыгарыша. Җаваплы эшләрдә җитәкчелек итә, 1918 елда Әстерханда аклар кыйнап, таптап үтерәләр.

**841. ТУИШЕВ Фәйзулла** (1884–1958).

***Тәхәллүсе:*** Фәйзулла Туишев.

Танылган музыкант-гармунчы.

**842. ТУЙКИН Фазыл** (1887–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Фазыл Туйкин, Туки, Ф. Туйкин.

Шагыйрь һәм прозаик. «Шура» һәм «Аң» журналларында шигырьләр һәм хикәяләр яза. «Салих бабай», «Ватан каһарманнары», «Тормыш корбаннары», «Җырлар әхтәрисе», «Нардуган» (шигырьләр җыентыгы) әсәрләренең авторы.

**843. ТУКАЕВ Габдулла Мөхәммәдгариф улы** (1886–1913).

***Тәхәллүсләре:*** Г. Тукай, Шүрәле, Тиктормас, Һөд-һөд, Бичура, Феакут, Имам хатыйп, Имзасыз да Яраретдинов, Тәнкыйть сөюче, Бик усал, Т. Г. Т, Мин язмадым, Гөмберт, Кыйссасел-әнбия Рабгузи, Кырмыска, Милләтче, Сөемсез, Мәҗнүн, Ишан мөнкире, Хәятел-хәйванаттан күчерүче, Догачы Шүрәле, Сәгыйть, Аннук Самакай малае, «Г.».

Татарстанның Кушлавыч авылында туа. Татар халкының бөтен дөньяга танылган халык шагыйре. Биографиясе һәркемгә мәгълүм.

**844. ТУКТАРОВ Идрис Ильяс улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Булышлы, Идрис Туктар, И. Туктар, Җамакай, Кучкар елы, Мөртәт, Әлиф, «Туктар».

1896 елның 3 октябрендә Башкортстанның Сәфәр районы Булышлы авылында туа. Мәдрәсә тәмамлагач, укытучы була, журналист, язучы.

«Партизаннар», «Гыйльметдин солдат вакыйгасы», «Хәсән солдатның үлеме», «Бала туды», «Үлем эшелоны», «8 нче штольня»[1], «Ике егет», «Фәнни хикәяләр», «Җир җиләге», «Кечкенә хикәяләр», «Тамчылар», «Батырлыкта матурлык», «Авыраяк» әсәрләренең авторы.

[1] Сиксән беренче штольня.

**845. ТУКТАРОВ Мәхмүт Фуат улы** (1882–1934)[1].

***Тәхәллүсләре:*** Мәхмүт Фуат, М. Ф. Туктаров, Усал.

Татарстанда Чистай өязе Мораса авылында туа. Казанда университетның юридик факультетын тәмамлап, юрист була. Журналист, «Сүз», «Ил» газеталарында актив языша. 1917 елда «Корылтай» исемле газета редакторларыннан берсе. Г. Гыйсмәти белән бергәләп «Татар теле» исемле әсәр яза. Дәүләт думасында мөселман фракциясенең әгъзаларын тәнкыйтьләп, «Усал» имзасы белән зур гына әсәр бастыра. Революциядән соң чит илләргә китеп, ак эмигрант була.

**846. ТУЛБИН Зиннәт Шәймулла улы.**

***Тәхәллүсе:*** З. Тулбин.

«Сөембикә» журналында шигырьләр язган шагыйрь.

**847. ТУЛПАНОВА.**

***Тәхәллүсләре:*** Сандугач.

Казакъ артисткасы.

**848. ТҮНТӘРИ Нәҗип Шәмсетдин улы.**

***Тәхәллүсе:*** Нәҗип Түнтәри.

Түнтәр авылында мулла. Революциягә кадәр булган дини журналларда һәм вакытлы матбугатта языша.

**849. ТУПЧЕБАШЕВ Галимәрдан.**

***Тәхәллүсе:*** Галимәрдан Тупчебашев.

Азәрбайҗанлы юрист. Дәүләт думасында әгъза. Дума хозурындагы мөселман фракциясенең башлыгы. Революциядән соң югала.

**850. ТУРАГИРОВ Солтанмәхмүт** (1893–1920).

***Тәхәллүсе:*** М. Турагиров.

Павлов өлкәсе Баянаулда ярлы казакъ гаиләсендә туа. 1912 елда Троицк мәдрәсәсендә укып, укытучы була һәм «Айкап» исемле казакъча журналда шигырьләр язган шагыйрь.

**851. ТОРСУНОВ Миртимер.**

***Тәхәллүсләре:*** Миртимер, Лачын.

Үзбәк язучысы.

---

[1] Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда. 2 т. / төз.: Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. Б. 452: 1880–1938 еллар.

**852. ТҮРӘКУЛОВ Нәзир.**

***Тәхәллүсләре:*** Нәзир Түрәкулов Ю, Н. Түрәкулов, Дәрвиш, Абнамак, Намакаб.

Фирганә өлкәсендә Хоканд шәһәрендә туган казакъ. Шәрык телләре буенча гали белем алган язучы. Революциядән соң 1917 елда партия сафына кереп, Урта Азиядә сәяси җитәкче була. 1920 елда Төркестан партия үзәк комитеты секретаре. 1924 елларда Мәскәүдә фәнни, әдәби журнал чыгара. 1937 елда шәхес культы корбаны була.

**853. ТУФАН – Фәхретдинов Хәсән Фәхри улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Х. Туфан, Хәсән Туфан.

1900 елның 9 декабрендә Татарстанның Аксубай районы Кармәт[1] авылында крестьян гаиләсендә 8 нче бала булып дөньяга килә. 1913 елда Тобол губернасында шахтер булып эшли торган туганнары янына китә. 1914 елда Уфага килеп, «Галия» мәдрәсәсендә укый. 1916–1917 елларда Пермь өлкәсе Лысьва шәһәрендә токарь. 1918–1929 елларда укытучы булып эшли. «Галия»дә укыганда, Галимҗан Ибраһимов һәм Шәехзадә Бабичлар тәэсирендә әдәбият белән кызыксынып, шигырьләр яза башлый. Казанга килгәч, 1924 елда әдәбият мәйданына чыга. Такташ, Нәҗми, Кутуйлар белән аралашып, шигърият дөньясына чума. 1940 елда кулга алына һәм 17 ел буена мәхрүмияттә[2] йөреп, 1956 еллар тирәсендә генә Казанга кайта. Тукай премиясе алган, танылган, мәшһүр шагыйрь.

**854. ТӨХФӘТУЛЛИН Рафаэль Газиз улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Рафаэль Төхфәтуллин, Р. Төхфәтуллин.

1924 елның 1 гыйнварында Татарстанның Тукай районы[3] Яңа Иябаш авылында укытучы гаиләсендә туа. 1941 елда 9 классны тәмамлагач, Горловкага китә. Анда ФЗӨ мәктәбендә укый. 1942 елда фронтка китә. Кайткач, 1945 елда Мәскәүдә Максим Горький исемендәге Әдәбият институтының югары курсларында укый. 1954 елдан «Таныш гөрелдәү», «Безнең районда», «Көймә күләгәсе», «Нишләргә», «Таныш көй», «Татар хикәяләре» исемле әсәрләр авторы.

[1] Дөресе: Иске Кармәт.

[2] Мәхрүмияттә – хаксызлыкта, биредә: тоткынлыкта.

[3] Хәзер Татарстан Республикасы Арча районы.

**855. ТӨХТӘМИТЕВ Төхтәмит Гафур улы.**

***Тәхәллүсе:*** Гафур Төхтәмит.

Үзбәк язучысы.

**856. ТӘРҖЕМАНОВ Кәшшаф Кыяметдин улы** (1877–1940)[1].

***Тәхәллүсе:*** Кәшшаф Тәрҗемани.

Татарстанда Спас өязе Әнҗерә авылында туа. Борһан Мәрҗани мәдрәсәсендә укый һәм шунда хәлфәлек итә. Казанда 11 нче мәхәлләдә имам була. Укыта, революциядән соң дини идарәдә казый. Уфага күчә.

**857. ТӘРҖЕМАНОВ Җәвад Әфтах улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Тәрҗеманов Җәвад, Җ. Тәрҗемани.

1920 елның 8 августында Казанда мулла гаиләсендә туа. 1938 елдан балалар өчен шигырьләр яза башлый. Ул химия-технология институтын тәмамлап, техник фәннәр кандидаты исемен яулый. Балалар өчен фәнни-популяр әсәрләр яза.

**858. ТӘФКИЛЕВ Габделгазиз.**

***Тәхәллүсе:*** Габделгазиз Тәфкилев.

Петербургта яшәгән генерал. XIX гасыр ахырларында үзбәк, казакъ халыклары рус патшасыннан ризасызлык белдереп, ихтиляль[2] күтәргәч, шуларны бастырырга хөкүмәт Тәфкилевне җибәрде. Шунда Тәфкилев «егетлекләр» күрсәтә. Шәехзадә Бабич шул турыда болай яза:

> Син түрә Габделгазиз, бар ихтиляльләрне бетереп!
> Торма һич вөҗдан-иман дип бар мөселманны үтереп.
> Тәфкилев – безнең тарихта чирканыч-мәлгунь нәсәп.
> Шул тарихтан, әйтегез, кемнәр булыр мәмнүн вә шат?...

**859. ТӘФКИЛЕВ Котлугмөхәммәт.**

***Тәхәллүсе:*** Тәфкилев Котлугмөхәммәт.

Уфа мирзасы. Дәүләт думасында әгъза. Думада әллә ни эш күрсәтә алмый. Ш. Бабич болай тасвирлый:

> Кортлыкайлар-котлыкайлар, тик йөриләр кортланып,
> Безгә бер әйбер бирмәйләр «дума»дан үткәреп.

[1] Татар энциклопедиясе: 1877–1943 еллар.

[2] Ихтиляль – фетнә.

**860. ТӨХФӘТУЛЛИН Камил Мотыйгулла улы** (1884–1940)[1].

***Тәхәллүсләре:*** Камил Мотыйги, К. Мотыйгуллин, Мөфәссир.

Уральск шәһәрендә мулла гаиләсендә туа. Казанда, соңра Каһирәдә укып кайтып, 1906 елда Уральск шәһәрендә «Әлгасрелҗәдид» һәм «Уклар» исемле журналлар, «Фикер» исемле һәм русча «Уралец» газетасын чыгара башлый. Вакытлы матбугатта катнаша. Ул дини белем алып, муллалыкка әзерләнсә дә, мулла булмады, киресенчә, артист булып китә. Яхшы тавышы бар. Җырчы булып, бөтен Русия шәһәрләрендә концерт биреп йөри. Татарның җыр музыкасын «мунча»лардан, өйләрдән чыгарып, Яурупа сәхнәсенә күтәреп чыгучыларның берсе була.

**861. ТӨХФӘТУЛЛИН Хәмит Камил улы.**

***Тәхәллүсе:*** Төхфәтуллин Хәмит.

1902 елда Уральскида туа. Мәскәүдә консерватория бетереп, опера җырчысы була. 1937 елда кулга алынып, күп еллар тоткынлыкта яши. Хәзер пенсиядә.

**862. ТҮРӘЕВ Әбүзәр Зариф улы** (1906–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Әбүзәр Түрәй, Ә. Түрәй, Корчагин, Т. Әбүзәр.

Горький өлкәсе[2] Кызыл Октябрь районы Татар Семчукие авылында туа. Ленинградта балалар йортында үсә. 1925 [елда] Казанга килеп укый. «Кызылармеец» газетасында, «Атака» журналында секретарь булып эшли. 1932–1937 елларда Әлмәт, Баулы районнарында урта мәктәптә укыта. «Сыйныфташ», «Бишне дүрттә», «Барыр юллар», «Комбат Сафин» поэмасының авторы.

**863. УРАЛЬСКИЙ Габдулла** (1903–1942).

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Уральский, Г. Уральский, әл-Бари.

«Бал-кваслы туй», «Малик ширкәт», «Камчылы ишан», «Туктамыш хан», «Балыкчы кыз» исемле әсәрләр язган язучы.

Габдулла Насыйбуллин-Уральский Әстерханда эшче гаиләсендә туа. 1918 елда профессиональ театрга алына. Шуннан башлап Әстерхан, Казан театрларында артист, режиссер һәм драматург булып китә. «Тәңре ярлыкаса», «Соңгы күләгә» пьесалары бар.

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1883–1941.

[2] Горький өлкәсе – Нижний Новгород өлкәсе.

**864. УРАЗАЕВ Габдулла.**

***Тәхәллүсе:*** Уразаев Габдулла.

Казанда рабфак бетергәч, төрле редакцияләрдә эшли. «Серле шалаш» пьесасын яза. Ташкентка китеп, анда редактор була. Соңгы еллары Ташкентта Әхмәт Фәйзинең «Тукай» исемле әсәрен үзбәкчәгә тәрҗемә итү белән мәшгуль.

**865. УРМАНОВ Салихҗан.**

***Тәхәллүсләре:*** Салихҗан Урманов, С. Урманов.

Революциягә кадәр Сибириядән мәхкәмәи-шәргыягә казый булып килә. 1937 елда кулга алына. Котылгач, Ташкентка китеп, шунда үлә.

**866. УРМАНОВА Хәнифә** (1886–1925).

***Тәхәллүсе:*** Урманова Хәнифә.

Себердә Благовещенскта хезмәткәр гаиләсендә туа. 1906 елда Уфада кызлар гимназиясен тәмамлый. Шул елны чыга башлаган «Фикер», «Казан мөхбире», «Вакыт» газеталарында мәкаләләр язып, хатын-кызларны ireккә өнди.

**867. УРМАНОВ Хәсән Гыйззәтулла улы.**

***Тәхәллүсе:*** Хәсән Урманов.

1895 елның 21 июлендә Рязань өлкәсе Ермишинск районы Азеево[1] авылында туа. Укытучы була. Революциядән соң 1917 елда партия сафына кереп, җаваплы эшләрдә җитәкче. Туганнары: Нәфисә, Фатиха, Мәстүрә, Мәрьям, Әхмәтҗан.

**868. УРМАНОВА Рауза** (1906–1970).

***Тәхәллүсе:*** Урманова Рауза.

Уфада беренче ачык спектакльдә катнаша. Шуннан соң Уфа, Казан, Оренбург, Ташкент труппаларында уйный. 1929–1939 елларда Әстерхан театрында эшли. Аннан Ташкентка китеп, 1970 елда шунда үлә.

**869. УРМАНЧИЕВ Әхмәт Шәрәфетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Әхмәт Урманче, Ә. Урманчиев, Аучы*.

Касыймлы. Пешләк авылында туа. 1910 елларда Казанда «Ялт-Йолт» журналы чыгара. 1922 елны үлә.

[1] Әҗе авылы.

**870. УРМАНЧЕ Габделбакый Идрис улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Бакый Урманче, Бакый Урманче, Габделбакый сурәтче.

Урманче Габделбакый Идрис улы 1897 елда Буа районы Күл Черкене авылында укытучы гаиләсендә туа. Казанга килеп, 10 яшендә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. 1924 елда аннан китеп, завод-фабрикаларда эшли. Шушы рәвештә русча укытучылыкка әзерләнә. 1916 елда солдатка алына. Революцияне Хоканд шәһәрендә каршы ала. 1917 елда Казанга кайта. Казанда художниклар мәктәбенә керә, редакцияләрдә эшли, укытучы була. 1920 елда Мәскәүгә барып, гали художниклар институтында укый. 1926 [елда] аны бетереп, Казанга кайта. Художниклар техникумында укыту бүлеге башлыгы. 1929 елдан 1933 елга кадәр шәхес культы фәлякәтенә[1] очрый. 1934 елда янә Мәскәүдә иҗат эше башлый. 1963 елда пенсиягә чыга. Хәзергә кадәр иҗат эше белән шөгыльләнә. Тукай премиясен ала.

**871. УРМАНЧИЕВА – Мәхмүдә Хөҗҗәтелислам кызы Мозаффарова.**

***Тәхәллүсләре:*** Мәхмүдә Мозаффария, М. Урманчиева.

1893 елда Казанда туа. Казанда кызлар мәктәбендә укый. 1907 елда «Әлислах»та шигырьләре басыла башлый. Революциядән соң төрле мәгариф учреждениеләрендә хезмәт итә.

**872. УСАЕВ Габдулла** (1910–1943).

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Усаев. Усай.

1910 елда Әстерханда туа. Әстерхан, Оренбург, Мәскәү театрларында эшли. Әстерхан театрында эшләгәндә сугышка алына һәм шунда үлә.

**873. УСМАНОВ Әбүбәкер Нурҗан улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Ә. Усманов, Әбүбәкер Усманов, Бәкер Усман.

1910 елның 24 апрелендә Башкортстанның Балтач районы Имән авылында крестьян гаиләсендә туа. 1930–1933 елларда Башкортстан педагогия институтында укый. 1935–1937 елларда Мәскәүдә тарих буенча аспирантураны тәмамлый. Аннан соң төрле фәнни-иҗтимагый учреждениеләрдә җитәкче булып эшли. 1938 елдан партия сафында. Тарих фәннәре кандидаты.

[1] Фәлякәтенә – афәтенә.

**874. УСМАНОВ Мәҗид.**

***Тәхәллүсе:*** Усманов.

Үзбәк язучысы.

**875. УСМАНХУҖАЕВ Сәйид Алихуҗа.**

***Тәхәллүсе:*** Сәйид Али.

Үзбәк язучысы.

**876. УТЫЗ ИМӘНИ Габдерәхим Госман улы** (1754–1834).

***Тәхәллүсләре:*** Габдерәхим Болгари, Г. Утыз Имәни.

Татарстанда Чистай өязе Яңа Кади авылында туа. 1805 елда «Мөһиммәтез-заман» китабын яза. Ул Оренбург Каргаласында, Бохарада вә башка шәһәрләрдә белем ала. Әфган, Харәзем якларында сәяхәт кыла. Кайтып, төрле авылларда имам була. Гарәп, фарсы телләрен яхшы белә. 50 дән артык әсәр яза. Тимәш авылында үлә.

**877. ФӘЙЗИ Мирза Габдулла Сәмәрканди.**

***Тәхәллүсе:*** М. Фәйзи.

Үзбәк халык җырчысы.

**878. ФАЗЛУЛЛИН Мөхәмәтхан Шәрифҗан[1] улы** (1883–1964).

***Тәхәллүсләре:*** Мөхәммәтхан Фазлуллин, М. Фазлуллин, М. Ф.

Татарстанның Балык Бистәсе [районы] Ширдан[2] авылында туа. Революциягә кадәр Казан мәдрәсәләрендә укып, Учительская школаны тәмамлый. Мамадыш шәһәрендә укытучы була. Революциядән соң Казанга килеп, педагогия институтында укыта, тел, әдәбият факультетының җитәкчесе, профессор була.

**879. ФӘЙЗУЛЛИН Бари** (1887–1927)[3].

***Тәхәллүсе:*** Ф. Болгарский.

Казанда итек тегүче гаиләсендә туа. Мәдрәсә тәмамлагач, «Сәйяр»гә кушылып, артист булып китә.

**880. ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахман улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Равил Фәйзуллин. Р. Фәйзуллин.

1943 елда Балык Бистәсе районы Балтач (Юлсубино) авылында туа. Тиз арада үзен талантлы шагыйрь итеп таныта. Әлмәттә Язучылар союзы секретаре.

---

[1] Дөресе: Әшрәфҗан.

[2] Дөресе: Яшел Үзән районы Тугай авылы.

[3] Дөресе: 1884–1927 еллар.

**881. ФӘЙЗУЛЛИН Мирхәйдәр Мостафа улы** (1891–1928).

***Тәхәллүсләре:*** Мирхәйдәр Фәйзи, М. Фәйзи, Мәзлум.

Орск өязе[1] Күкшел авылында туа. Мәдрәсә бетергәч, революциягә кадәр, чыккан газета-журналларда шигырьләр, көлке нәрсәләр яза. «Хәсәения»не бетергәч, укытучы була. Танылган драматург булып дан тота.

«Галиябану», «Асылъяр», «Урал суы буенда», «Ак калфак», «Кызыл йолдыз», «Яшьләр алдатмыйлар», «Кызганыч», «Авыл бәйрәме», «Яшь күңел», «Кара падиша», «Адашкан күңел», «Минем шигырьләрем» кебек җыентыкларның авторы.

**882. ФӘЙЗУЛЛИН Мөдәррис.**

***Тәхәллүсләре:*** Фәйзи Зайсанлы, Мөдәррис Фәйзи.

1911 елларда «Шура» журналында шигырьләр язган укытучы, шагыйрь.

**883. ФӘЙЗУЛЛИН Сәгыйть Сәетгәрәй улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Фәйзуллин Сәгыйть, Сәгыйть Ф, Җүнәй Ф.

1899 елда Орск өязе Күкшел утарында туа[2]. Малмыж шәһәрендә гимназиядә укый. Революциядән соң партия сафына кереп, 1919–1920 елларда Малмыжда «Ярлылар тавышы» газетасы, 1926–1927 елларда Казанда «Крестьян» газетасы редакторы, 1924–1931 елларда Татарстан радиокомитеты рәисе, 1931–1962 елларда Татарстан нәшрияты хозурында марксизм-ленинизм әсәрләрен тәрҗемә итү секциясенең башлыгы.

**884. ФӘЙЗИ – ФӘЙЗУЛЛИН Харис Зариф улы** (1870–1933).

***Тәхәллүсләре:*** Харис Фәйзи, Х. Фәйзи, Хыф.

Чистай өязе Шыкмай авылында сәүдәгәр гаиләсендә туа. Чистай мәктәбендә белем алгач, солдаттан качып, Истанбулга китеп, лицей-гимназиясендә укыган. Аңа агасы Шакирҗан ярдәм итә. Төркиядән кайткач, Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. Җәдит мәктәпләре өчен дәреслекләр яза. 1907 елда Казанда «Әхбар» газетасында редактор була. Революциядән соң Казанда нәшриятта эшли.

---

[1] Орск өязе Оренбург губернасына кергән.

[2] Орск өязе Күкшел авылында әтисе Фәйзуллин Сәетгәрәй Мостафа улы (Мирхәйдәр Фәйзинең абыйсы) туган, Фәйзуллин Сәгыйть Сәетгәрәй улы үзе Түнтәр авылында туган.

**885. ФӘЙЗУЛЛИН Әхмәт Әхмәтсафа улы** (1903–1958).

***Тәхәллүсләре:*** Фәйзуллин Әхмәт, Әхмәт Фәез Идел, Фәез Идел, Кызыл җырчы, Зәңгәр Әхмәт, Ә. Фәез.

Уфа шәһәрендә туа. Авылда җәдит мәктәбен бетергәч, 1921 елда Оренбургта Шәрык институтында[1] укый. 1922 – 1924 елларда Төрекмәнстанда укытучы була. 1924 – 1927 елларда Донбасста рабочийлар арасында сәяси, мәгариф эшләрен алып бара. 1928 елда Казанга килә. Арчада беркадәр эшләп, Мәскәүгә китә. Бөек Ватан сугышы фронтында була. Татар халкының танылган шагыйре, әдибе һәм драматургы. Тукай премиясе лауреаты.

**886. ФӘЙЗУЛЛИН Җәүдәт Харис улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Җәүдәт Фәйзи, Җ. Фәйзи.

1910 елның 4 гыйнварында Оренбургта туа. Мәдрәсәдә белем алганнан соң, Мәскәүдә композиторлар гали мәктәбен тәмамлап, композитор була. Казанга 1926 елны килә. Тәҗрибәле педагог буларак, күп кадрлар әзерли. Атаклы композитор-педагог.

**887. ФӘЙЗИ Һади** (1897–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Һади Фәйзи, Һ. Фәйзи, Шәрык баласы.

Ташкентта туа. 1919 елда партия сафына керә. Сәяси-иҗтимагый җаваплы эшләр башкара. 1919 елда Фирганәдә «Янги шәрык» газетасының редакторы була. Бохарада революция ясау эшендә катнаша.

**888. ФИРАКЫЙ.**

***Тәхәллүсләре:*** Фиракый.

Фиракый 1911 елда «Шура» журналының 14 нче санында «Фиракый кем?» дип сорауга җавап итеп болай ди: «Ошбу мөхтәрәм зат тарафыннан язылмыш бер мәктүптә русча адрес соңында:

Җибәрдем Сезгә бераз хезмәтемде,
Искә алып, батып җаткан милләтемде.
Эчендә җарайтогын[2] сүзе булса
Тастамаңыз энтепатсыз бу катымды[3] –

шигыре генә бар дип яз».

---

[1] Шәрык педагогия институты.

[2] Җарайтогын – ярый торган.

[3] Тастамаңыз энтепатсыз бу катымды – ташламагыз илтифатсыз бу хатымны.

Фиракый казакъ булса кирәк. Аның Әхмәт исемле малае үлгәч, тәгъзия[1] хатлары да казакъчарак барылганын күрдем.

**889. ФӘЕЗХАНОВ Хөсәен** (1821[2]–1866).

***Тәхәллүсе:*** Хөсәен Фәезханов.

Сембер губернасы Сабачай авылында мулла гаиләсендә туа. Казанда Шиһаб Мәрҗанидән дәрес ала. 1853 елда Казан университетында, 1856 елда Петербург университетында татар-гарәп, төрек телләре укыта. 1862 елда «Краткая грамматика татарского языка» исемле дәреслек бастыра. В.В. Вельяминов-Зернов[3], К.К. Стасов, Чокан Вәлиханов белән дус булган.

**890. ФӘЕЗХАН улы Габделгалләм.**

***Тәхәллүсе:*** Габделгалләм Фәезхан[4].

Фәезхан улы Габделгалләм Уфада яши. 1887 елда «Тутыйнамә»не тәрҗемә итә. «Мөхәррикел-әфкяр»[5] һәм 1890 елда «Хикәят вә мәкаләт»[6] исемле әсәрләрен бастыра. 1910 елда үлә.

**891. ФАСИЕВ Камил.**

***Тәхәллүсе:*** Камил Фасиев.

Зур галим, күренекле сәяси-иҗтимагый эшләрдә җитәкче – райкомда секретарь.

**892. ФӘСХЕТДИНОВ Гыйлаҗ** (1905–1937).

***Тәхәллүсе:*** Гыйлаҗ Фәсхи.

Бондюг заводында эшче гаиләсендә туа. Журналист, Татарстанда Наркомтруд.

**893. ФӘТТАХОВ Нурихан Садри улы.**

***Тәхәллүсе:*** Нурихан Фәттах.

1928 елның 25 октябрендә Башкортстанның Яңавыл районы Күчтавыл авылында туа. 1946 елда Казан университетының татар теле, әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1951 елны тәмамлап, нәшри-

---

[1] Тәгъзия – үлгән кешенең якыннарын юату.

[2] Татар энциклопедиясе: 1828 елда туган.

[3] В.В. Вельяминов-Зернов – танылган шәркыятьче (востоковед).

[4] Габделгалләм Фәезханов (1850–1910) – Хөсәен Фәезхановның бертуган энесе.

[5] «Мөхәррикел-әфкяр» («Фикерләр уяткыч» әсәре).

[6] «Хикәят вә мәкаләт» («Халык әкиятләре һәм мәкальләре»).

ятта балалар әдәбияты секторы редакторы була. «Сезнеңчә ничек?» һәм «Итил акар кидәр»[1] романын яза. Оста тәрҗемәче.

**894. ФӘТХИ Альберт.**

***Тәхәллүсе:*** Фәтхи Альберт.

Татарстанда Такталачык[2] авылында туа. Казан университеты хозурындагы Лобачевский исемендәге фәнни көтебханәнең кулъязмалар бүлеге мөдире.

**895. ФӘТХЕТДИНОВ Касыйм** (1906–1943).

***Тәхәллүсләре:*** Касыйм Фәтхетдинов, Демьян[3] Фәтхи, Колмаери.

Ульяновск өлкәсе Чардаклы районы Колмаер[4] авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Татарстанның танылган шагыйре. Шигырь-поэма җыентыклары бар. 1929 елда «Тальян», «Металл тавышлары», «Бураннар», «Бояр урманында» исемле әсәрләре һәм тәрҗемәләре бар.

**896. ФӘТХУЛЛИН Г.**

***Тәхәллүсе:*** Сирин.

«Сирин» имзасы белән шигырьләр яза. Кайда, кайчан үлүе мәгълүм түгел.

**897. ФӘТХУЛЛИН Хәлилрахман Габдерәшид улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Фәтхуллин Хәлил, Балыкчы.

1901 елда Тәтеш районы Сөендек авылында туа. Казанда партия мәктәбен бетергәч, дәүләт журналистлар институтында укый. 1930 елда «Татарстан» газетасы идарәсендә эшли. Бөек Ватан сугышында 4 ел була.

**898. ФӘТХУЛЛИН Фәтхулла Зәйнулла улы.**

***Тәхәллүсе:*** Фәтхул.

[...].

**899. ФӘХРЕТДИНЕВ Әсгад Йосыф улы** (1901–1926).

***Тәхәллүсләре:*** Ф. Әсгад, Әсгад Фәхри, «Ф Ә-д».

---

[1] «Ител суы ака торур» исемле романы.

[2] Актаныш районында урнашкан авыл.

[3] Шагыйрь Демьян Бедный (Ефим Алексеевич Придворов) иҗаты белән кызыксынганга, ул исемне тәхәллүс итеп алган.

[4] Татар энциклопедиясе: Татар Колмаеры авылында туган.

1901 елда Татарстанның Әлки районы Алпар[1] авылында туа. 1913 елда Казанга килеп, Котдус абыйсында тора. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Соңрак Чистайда педагогия техникумында, 1921 елда авыл хуҗалыгы институтында укый. «Тормыш кочагында», «Сүзләрдән чәчәкләр» исемле әсәрләрнең[2] авторы. 1926 елда туберкулездан үлә.

**900. ФӘХРЕТДИНОВ Габдрахман Ризаэтдин улы[3].**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Фәхретдин, Җәләэтдин улы, Габдрахман Фәхри.

Бөгелмә өязе Илбәк[4] авылында мулла гаиләсендә туа. «Шура», «Вакыт» идарәсендә эшли. Тәҗрибәле журналист. 1918 елда «Уфа хәбәрләре», «Башкортлар», «Вестник правительства Башкирии»[5] чыгара.

**901. ФӘХРЕТДИНОВ Ризаэтдин бине Фәхретдин** (1858–1935).

***Тәхәллүсләре:*** Ризаэтдин бине Фәхретдин, Гафил бине Габдулла, Морад.

Самара губернасы Кичүчат авылында туа. Мәдрәсә тәмамлагач, Бөгелмә өязе Илбәк авылында мулла, аннан соң Диния нәзарәтендә казый була. Аннан соң Оренбургка килеп, 1908 елда «Шура» журналы чыгара башлый. Бик күп гыйльми вә әдәби әсәрләр яза. Танылган галим, философ. «Мәшһүр ирләр», «Мәшһүр хатыннар», «Асар» (16 кисәк), «Имам Газали», «Ибн Тәймия», «Ибн Гарәби», «Ибн Баттута», «Әхмәт бай», «Сәлимә»[6], «Әсма»[7] вә башка әсәрләр авторы. Революциядән соң Уфада Диния нәзарәтендә мөфти була.

**902. ФӘХРЕТДИНОВ Габдерәшид Ризаэтдин улы[8].**

***Тәхәллүсләре:*** Рәшид Фәхри, Наразый.

Бөгелмә өязе Илбәк авылында мулла гаиләсендә туа. Татарча-русча укып, укытучы, журналист була.

---

[1] Татар энциклопедиясе: Иске Алпар авылы.

[2] Җыентыклар исеме.

[3] Ризаэтдин Фәхретдиновның өлкән улы.

[4] Татар энциклопедиясе: туган авылы Түбән Чыршылы.

[5] «Вестник Башкирского Правительства» газетасы «Башкорт тавышы» һәм «Башкорт» газеталары берләшүеннән барлыкка килгән.

[6] «Сәлимә, яки Гыйффәт» әсәре.

[7] «Әсма, яки Гамәл вә җәза» әсәре.

[8] Ризаэтдин Фәхретдиновның өченче баласы.

**903. ФӘХРИ Габдулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Фәхри, Г. Фәхри.

Касыймлы, Әхмәт Урманченың туганы, 1908–1909 елларда «Шура», «Вакыт»та язышты. Төркиягә китеп Истанбулда гимназия тәмамлагач, медицина факультетының 4 нче курсын бетерә. Оренбургка кайтып, «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. Бунтарьлыгы өчен аннан куылгач, «Буби» мәдрәсәсенә китә. Буби вакыйгасыннан соң төрмәдән чыгып, Төмән шәһәренә китә. Анда укытып, 1923 елда Казанга тәгълим-тәрбия техникумында укытучы булып чакырыла. Шул елны Казанда туберкулездан үлә. Дәреслек китаплары бар.

**904. ФӘХРИ Сарим.**

***Тәхәллүсләре:*** Сарим Фәхри, Япанчы, Җомагол.

Революция башында Уралда Свердловта эшли. Соңра Казанга килеп, вакытлы матбугатта актив язышкан журналист.

**905. ХӘЙДАРИ Баһрам.**

***Тәхәллүсе:*** Б. Хәйдари.

Үзбәк язучысы.

**906. ХӘЙДАРИ Назрулла.**

***Тәхәллүсе:*** Биктас.

Үзбәк шагыйре.

**907. ХӘЙДӘРОВ Мөхәммәд Хәйдәр улы.**

***Тәхәллүсе:*** М. Хәйдәров.

1915 елның 7 мартында Башкортстанның Учалы районы Өрген авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1930–1933 елларда Белорецкий металл техникумында укый. 1941–1945 елларда Башкортстан педагогия институтын тәмамлый. Прозаик, хикәяләр җыентыгы бар.

**908. ХӘЙРЕТДИНОВ Гайнан Бәдретдин улы** (1903–1938).

***Тәхәллүсе:*** Гайнан Хәйри.

15 июньдә Башкортстанның Нуриман районы Иске Күл авылында крестьян гаиләсендә туа. 1926 елда Оренбург педагогия техникумында укый. 1928–1933 елларда редакцияләрдә эшли. Башкортстан педагогия институтында укый. Шигырь, поэма, повесть, хикәя, очерк, җыентыклары бар.

**909. ХӘЙРУЛЛИН Исмәгыйль.**

***Тәхәллүсе:*** Хәйруллин Исмәгыйль.

1903 елның 30 мартында Әстерханда туа. Самара студиясендә укый, Әстерханда укытучылар курсында белем ала. 1934–1936 елларда Баку татар театрында эшли. 1941 елга кадәр Әстерхан театрында артист була. Ватан сугышында катнаша. 1945–1951 елларда Филармониядә эшли. Хәзер пенсиядә.

**910. ХӘКИМОВ Рамил Гараф улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Рамил Хәкимов, Р. Хәкимов.

1932 елның 13 июнендә Уфада туа. 1954 елда партия сафына керә һәм редакциядә[1] эшли. Киноуен, сценарий яза. Шигырь, поэма җыентыклары бар. Русчадан, грузинчадан тәрҗемәләре бар.

**911. ХАКОВ Вахит Хөҗҗәт улы.**

***Тәхәллүсе:*** Хаков Вахит.

1926 елда туа. Казан университетының тел, әдәбият факультеты доценты.

**912. ХАЛИДОВ Габделкасыйм Мөхәммәдгали улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Касыйм Халид, К. Халиди.

1893 елда Татарстанның Кама тамагы районы Олы Карамалы авылында мулла гаиләсендә туа. Казанда «Халидия» мәдрәсәсен[2] тәмамлагач, һөнәр мәктәбендә белем ала. 1921 елда Наркомзем хозурындагы «Игенче» журналының редакторы була. Шәхес культы шаукымы кагыла. 25 ел бирәләр, 3 елдан котыла.

**913. ХАЛИДИ Фатих Хаммат улы** (1850–1923).

***Тәхәллүсләре:*** Халиди Фатих, Ф. Халиди, Ф. Х.

Татарстанның Тәтеш өязе Яңа Сала авылында мулла гаиләсендә туа. Атасы Казанга килеп, Зәңгәр мәчеткә мулла була. Казанда укыта. 73 яшендә вафат булып, мираска күп әсәрләр калдырган галим. 1888 елда «Рәдде бичара кыз», 1896 елда «Җиһан абад патшаның угланларының кайгысы», 1897 елда «Болгарның Солтангадел Туктамыш хан кызының бәхәсе», 1899 елда «Мәшһүр гашыйк-мәгъшук Ләйлә илә Мәҗнүн хикәясе», «Өстәл календаре», 1900 елда «1901, 1902, 1903, 1904, 1905, 1906, 1907 еллар өчен календарь», 1904 елда

---

[1] «Советская Башкирия» газетасында.

[2] Зәңгәр мәчет каршында ачылган борынгы мәдрәсә.

«Кемгә тиеш», 1906 елда «Залим ачлык, яхуд Испанияле Сәет Яхъя бәянында», «Саран, надан Теллә бай», «Мәхрүсә ханым» вә башка пьеса вә повестьлар яза. «Мең дә бер кичә»не, «Ләйлә вә Мәҗнүн»-не ул тәрҗемә итә.

**914. ХАЛИТОВ Гали Мөхәммәтгали улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гали Халид, Г. Халид.

1915 елның 26 июнендә Татарстанның Олы Тархан районы[1] Үтәмеш авылында туа. 1930 елда Казан педагогия техникумын тәмамлап, 1932 елда педагогия институтында укый. 1936–1942 елларда Арча педагогия техникумында укыта. 1943 елдан бирле Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында олы гыйльми хезмәткәр. Фәннәр докторы, тукайчы, тәнкыйтьче, яшь кадрлар җитештерүче, бөтен көчен сарыф иткән гадел, сәяси, иҗтимагый эшләрдә партияле эшче.

**915. ХАЛИТОВ Яхъя Мөхәммәтгали улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Яхъя Халитов, Я. Халитов.

1929 елда Татарстанның Тархан районы[2] Үтәмеш авылында туа. Югары уку йортларында гали белем алгач, җиң сызганып, әдәбият, тәнкыйть эшенә керешкән язучы. «Казан утлары» журналының җаваплы хезмәткәре.

**916. ХАЛИКОВ Муллаҗан** (1894–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Муллаҗан Халиков, М. Халиков.

Троицкида «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Аннан соң хосусый рәвештә русча өйрәнә. Революциягә кадәр вакытлы матбугатта языша. Революциядән соң 1919 елда партия сафына керә. 1925 елларда Башкортстанның министрлар киңәше рәисе. 1937 елны шәхес культы корбаны була.

**917. ХӘМЗИН Касыйм Зыятдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Касыйм Хәмзин, К. Хәмзин.

Хәмзин Касыйм Зыятдин улы 1894 елда туа. Казанда гали белем алып, педагог, язучы һәм дәреслекләр язган галим. «Гарәпчә, фарсыча, русча, татарча лөгать» язучыларның берсе.

---

[1] Олы Тархан волосте – хәзерге Тәтеш районы.

[2] Хәзерге Тәтеш районы.

**918. ХАММАТОВ Кәшфи.**

***Тәхәллүсе:*** К. Х. Ф.

«Яшьлек ядкәре» исемле шигырьләр җыентыгы авторы.

**919. ХАММАТОВ Янибай Хаммат улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Х. Янибай, Давытгәрәй.

1925 елның 19 гыйнварында[1] Башкортстанның Белорецк районы Исмакаев авылында туа. 1940–1942 елларда әртил (артель) бригадиры. 1942–1946 елларда Совет армиясе сафында. Кайткач район комсомол секретаре. 1949 елда партия сафына керә. 1954 елда Башкортстан педагогия институтын тәмамлап, партия обкомында инструктор була язган. Әсәрләре бар.

**920. ХАМРАЛИЕВ Аскарали.**

***Тәхәллүсе:*** Чархи.

Үзбәк язучысы.

**921. ХАМРАТОВ Мөхәммәткол.**

***Тәхәллүсе:*** Полкан.

Үзбәк язучысы.

**922. ХАНГИЛДИН Вәли Нигъмәтулла улы** (1890–1972)[2].

***Тәхәллүсләре:*** Вәли Хангилдин, В.Н. Хангилдин.

Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтының элекке өлкән фәнни хезмәткәре. Филология фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. 1934 елны Казан педагогия институтының аспирантурасын тәмамлый. Шунда ук 20 ел буена татар теле курслары алып бара. 1944 елдан Тел, тарих һәм әдәбият секторы мөдире булып эшли. 1954 елда «Татар теле морфологиясе», 1959 елда «Татар теле грамматикасы» (ике томда) әсәрләрен бастыра. 1962 елда «Татарстанның атказанган эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

**923. ХАНЗАФАРОВ.**

***Тәхәллүсе:*** Ханзафаров.

Уфа шәһәрендә «Мәгълүмате җәдидә» журналының редакторы. Бервакыт Ф. Сәйфи секретаре.

---

[1] Татар эниклопедиясе: 16 гыйнвар.

[2] Татар энциклопедиясе: 1891–1971 еллар.

**924. ХАНИКОВ Кәрим** (1897–1930).

*Тәхәллүсе:* Хаников Кәрим.

Әстерханда туа. 1918 елдан башлап театрда эшли. Ахыр гомеренә кадәр артист була.

**925. ХАНИФ – Чыңгыз Һадиев** (1915–1941).

*Тәхәллүсләре:* Ч. Ханиф, Ханиф Чыңгыз.

1915 елда Башкортстанның Салават районы Аркаул авылында туа. 1936 елда Башкорт педагогия институтын тәмамлагач, марксизм-ленинизм классикларын тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. 1940 елда солдатка алына һәм Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак була.

**926. ХАНСКАЯ – Хәдичә (Таһирова).**

*Тәхәллүсе:* Ханская Хәдичә.

1899 елда Әстерханда туа. 1915 елда сәхнәгә чыга. 1922 елга кадәр шунда эшли, Оренбургка китә. 1925 елларда Казанда уйный, хәзер Оренбургта яши.

**927. ХАНТИМЕРОВ Исмәгыйль Ситдыйк улы.**

*Тәхәллүсләре:* Исмәгыйль Хантимеров, Хантимеров Н.

1898 елда Саратов өлкәсе Новоузенский районы Сафаровка авылында туа. Авылда мәктәп бетергәч, Әстерханда урта белем ала. Соңрак Мәскәүдә Тимирязев институтында агрономия факультетын тәмамлый. 1926 елда Казанга килә. Анда 2 нче авыл хуҗалыгы фирмасында укытучы була. 1929 елда провокаторлар доносы буенча кулга алына. Соловки лагеренда була. Коми республикасына сөргенгә җибәрелә, соңыннан аклана. Фәннәр докторы, профессор. Тоткында – Соловки утравында чакта да Савватиевода тоткыннарны укыта.

**928. ХАРИСОВ Габдулла Харис улы** (1893–1931).

*Тәхәллүсләре:* Г. Харис, Шәүкәт, Апуш, Җылтыр күз, Тәлгать, Азат.

Тәтеш өязе Ябалаклы авылында мулла гаиләсендә туа. 1910–1911 елларда яза башлый. «Йолдыз» газетасында, «Аң», «Ак юл», «Сөембикә» журналларында шигырьләр яза. Укытучы була. Беренче Герман сугышында катнаша. «Яшьлек поэмасы», «Күңел көзгесе» исемле шигырь, поэма җыентыклары бар. «Өрәк» поэмасы авторы.

**929. ХАРИСОВ Әхнәф Ибраһим улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Әхнәф Харисов, Али Ашказаров.

1914 елда Башкортстанның Балтач районы Имән авылында крестьян гаиләсендә туа. 1935 елда Башкортстанның педагогия институты Тел, әдәбият, тарих факультетын тәмамлый. 1941 елда аспирантура бетерә. Кандидатлык диссертациясе яклый. 1944 елдан партия сафына керә. Фәннәр академиясенең Тарих, тел, әдәбият институтында җитәкче, профессор. Кадрлар җитештерүгә барлык көчен вә игътибарын сарыф итә.

**930. ХАРИСОВ Мәлих Харис улы** (1915–1944).

***Тәхәллүсе:*** Мәлих Харис.

Башкортстанның Чакмагыш районы Яңакүл[1] авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1941 елда Башкорт педагогия институтының тел, әдәбият факультетын тәмамлый. Совет армиясенә алынып, 1944 елда батырларча һәлак була.

**931. ХАРИСОВ Ренат.**

***Тәхәллүсе:*** Ренат Харисов.

1941 елда Ульяновск өлкәсендә Цильнинский (Чынлы) районы Кәшә авылында туа. Казан педагогия институтын тәмамлый. Төрле матбугатта шигырьләр белән чыгыш ясап, тиз арада үзен талантлы шагыйрь итеп таныта. Хәзер Язучылар союзының җаваплы секретаре булып эшли. Казанда яши.

**932. ХӘСӘНОВ Бәшәр Хәсән улы** (1910–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Бәшәр Хәсән, Б. Хәсән.

Самара өлкәсендә Черниговка районы Бөрҗән авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Гражданнар сугышында Чапаев армиясендә була. 1928 елда Уфага килеп, нәшриятта тәрҗемәче. 1938 елда шәхес культы корбаны була.

**933. ХАФИЗОВ Нәҗибәк Шаһикамал улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Хафизов Нәҗибәк, Х. Нәҗибәк.

1921 елның 17 декабрендә Башкортстанның Учалинский районы[2] Уразаев авылында крестьян гаиләсендә туа. 1937–1941 еллар-

[1] Татар энциклопедиясе: Яңа Коты авылы.

[2] Учалы районы.

да башкорт театр техникумында укый, 1942–1947 елларда японнарга каршы сугышта катнаша. 1950–1953 елларда сәнгать эшчеләре союзы обкомында рәис була. 1950 елда партия сафына керә. Язган берничә пьесасы бар.

**934. ХАФИЗОВ Сафа** (1893–1940).

***Тәхәллүсе:*** Хафизов Сафа, Сафа Хафиз.

Революциягә кадәр вакытлы матбугатта язгалый. Революциядән соң үзен анархист дип йөргән җиңел табигатьле кеше. Язган нәрсәләре дә бар.

**935. ХАҖИТАБИБ улы Мөхәммәдхәсән.**

***Тәхәллүсләре:*** Мөшриб.

Үзбәк шагыйре.

**936. ХИСАМЕТДИНОВ Гомәр Мөхетдин улы.**

***Тәхәллүсе:*** Гомәр Хисаметдинов.

Хисаметдинов Гомәр Мөхетдин улы 1907 елда туа. Язучы.

**937. ХӨСӘЕНОВ Гайсә Батыргәрәй улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гайсә Хөсәенов, Г. Хөсәенов.

1923 елның 10 апрелендә Башкортстанның Кырмыскалы районы Үтәгән авылында крестьян гаиләсендә туа. Авылда мәктәп тәмам иткәч, 1947–1951 елларда Башкортстан педагогия институты студенты, 1954 елда Мәскәүдә Максим Горький исемендәге Әдәбият институтында гыйльми хезмәткәр, башкорт әдәбият тарихын өйрәнүче галим. Ул уку программаларын төзү, дәреслекләр язу эшендә актив эшли. Язган гыйльми китаплары бар.

**938. ХИСМӘТУЛЛИН Габделхәй Хисмәтулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Хәй Хисмәтуллин, Укытучы, Учитель.

1895 елның 8 ноябрендә Татарстанның Тукай районы Кысна авылында мулла гаиләсендә туа. 1916 елларда ул мәдрәсә, мәктәпләрдә укыта. Мәгариф органнарында эшли. 1929–1938 елларда Казан педагогия институты хозурындагы рабфакта укыта. Үзе дә шул ук институт хозурындагы ике еллык камилләштерү курсларында укый. 1938–1941 елларда Укытучыларны камилләштерү институтында гыйльми хезмәткәр булып эшли. Язган хезмәтләре бар. Фатих Әмирхан, Шиһап Мәрҗани, Фатих Кәримиләр турында язган әсәрләре мәгълүм.

**939. ХИСМӘТУЛЛИН Зөлфәр Фазлетдин улы.**

***Тәхәллүсе:*** З. Хисмәтуллин.

1923 елның 11 июлендә Башкортстанның Белорецк районы Югары Сәрмән авылында крестьян гаиләсендә туа. Мәктәп бетергәч, Белорецк металлургия техникумында укый. 1941 елда гаскәри хезмәткә алына. 1946 елда төрле редакцияләрдә эшли. Журналист була. 1956 елда «Сәнәк» журналында баш редактор. 1943 елда партия сафына керә. Берничә хикәяләр җыентыгы авторы.

**940. ХИСМӘТУЛЛИН Рахмай.**

***Тәхәллүсе:*** Фаяз Дунай.

«Фаяз Дунай» имзасы белән хикәя язган язучы.

**941. ХАҖИЕВ Кадир (Хаджаев).**

***Тәхәллүсләре:*** Кадир Хадҗаев, К. Хаджаев.

1897 елда Әстерханда туа. Урта белем алгач, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, гыйльми агроном була. 1930 елда «Чаяновлар эше» дип аталган компаниядә кулга алына. 1933 елда Караганда лагерында хаксызлыкка протест йөзеннән асылынып үлә.

**942. ХӘЯЛИН Сәгыйть.**

***Тәхәллүсе:*** Сәгыйть Хәялин.

Старшина. Петр Первый аңар указ биреп, Урта Азиягә китә торган кәрван юлы өстендә сәүдә пункты оештырырга куша.

**943. ХОДАЙБИРДИН Шәһид.**

***Тәхәллүсләре:*** Шәһид Ходайбирдин, Ходайбирдин Ш.

Башкортстанның күренекле сәяси эшчеләреннән. 1919 елда Уфада Мәхмүт Тимербаев белән «25 нче дивизия сәяси бүлеге хәбәрләре» газетасы[1] чыгара. Аны Фурманов мактап чыга.

**944. ХАДЖАЕВ Гобәйдулла Әсәдулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гобәйдулла Хаджаев, Гобәйдулла Әсәдулла.

1914 елда Ташкент шәһәрендә чыккан беренче үзбәк газетасы «Садаи Төркестан»ның нашире һәм редакторы. Үзбәк адвокаты.

**945. ХОДАЯРОВ Галәэтдин Гайнетдин улы** (1891–1966).

***Тәхәллүсләре:*** Галә Ходаяр, Г. Дим, Мәктәпче.

[1] «25 нче дивизиянең сәяси шөгъбәсе хәбәрләре» газетасы.

Башкортстанның Бәләбәй өязе Иске Калмаш волосте Аблай авылында[1] туа. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укый. Хосусый рәвештә русча укытучылыкка әзерләнә. Революциягә кадәр «Шура» журналында шигырьләр яза. Революциядән соң 1919 елда партиягә кереп, 1920 елда ул Уфа губернасының партия обкомы әгъзасы була. «Шәрык ярлылары» исемле газета чыгара. Казанга килеп, җаваплы эшләрдә катнаша.

**946. ХОДАЙБӘХИТОВ Анкобай.**
*Тәхәллүсе:* Анкобай.
Үзбәк язучысы.

**947. ХАКАНДИ Хәйрулла.**
*Тәхәллүсе:* Мирза.
Үзбәк язучысы.

**948. ХУРАМШИН Җамалетдин.**
*Тәхәллүсе:* Хурамшин Җамалетдин.

1906 елларда Бәләбәй шәһәрендә мулла һәм Дәүләт думасында әгъза. 1913 елда Николай Романовларның өч йөз еллык юбилеенда Хурамшин Коръән укып тәбрикләгән иде. Бабич шуңа ишарә итә:

Син, Җамалетдин, җамал таптың Бәләбәйдә дә син,
Шөһрәт алдың сыздырып Коръән юбилейларда да син.

**949. ХӨСӘЕН Сатти.**
*Тәхәллүсе:* Хөсәен Сахин.
Үзбәк язучысы.

**950. ХУҖАМИЯРОВ Түләгән.**
*Тәхәллүсләре:* Тәвәллә, Мәгъзави.
Үзбәк язучысы.

**951. ХУҖАЕВ Нәбихан.**
*Тәхәллүсе:* Чүмәти.
Үзбәк язучысы.

**952. ХАДЖАЕВ Низаметдин Исаметдин улы** (1885–1942).
*Тәхәллүсе:* Хаджаев Низам.

[1] Хәзерге Чакмагыш районы.

Ташкентлы, 1918 елдан Коммунистлар партиясе әгъзасы. Искешәһәр партия оешмасының җитәкчесе.

**953. ХУҖИН Мәгъсүм Хәмит улы.**

***Тәхәллүсләре:*** М. Хуҗин, М. Хәмәдиев, М. Хәррасов.

1930 елның 15 маенда Татарстанның Саба районы Тенеки авылында туа. 1954 елда Казан дәүләт университетының татар бүлеген тәмамлый, хәзер «Чаян» журналының җаваплы секретаре[1].

**954. ХУҖИЕВ Гали Хаҗи улы[2]** (1912–1966).

***Тәхәллүсләре:*** Гали Хуҗи, Г. Хуҗи, Хуҗиев Г.

Татарстанның Кайбыч районы Карамасар авылында тимерче гаиләсендә туа. Партия әгъзасы. Танылган шагыйрь. 1941 елда Казанда педагогия институтын тәмамлый. 1936 елдан 1956 елга кадәр 13 җыентыгы чыга.

**955. ХӘБИБ Габделхәй Хәбибулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Хәбиб, Хисам Тыңламыш, Чутайлы, Чаянчы, Г. Хисам.

1903 елда Татарстанның Балтач районы Чутай авылында туа. Мәдрәсә бетергәч, русча укып, төрле редакцияләрдә эшли, «Чаян»-да секретарь була.

**956. ХӘБИБ Габдулла** (1894–1941).

***Тәхәллүсләре:*** Х. Габдулла, Аблай.

Татарстанның Тәтеш районы Каратай авылында туа. 1923 елларда Казанда чыккан «Игенче» журналының җаваплы секретаре.

**957. ХӘБИБИ Әхмәтсолтан.**

***Тәхәллүсләре:*** Хәбиби Солтан, Х. Әхмәтсолтан.

1917 елда Уфа шәһәрендә «Алга» газетасы чыгара. Кәшфеләсрар Кәбиров белән языша.

**958. ХӘБИБРАХМАНОВ – Гали Хәбибрахман улы Баязитов** (1888–1954).

***Тәхәллүсләре:*** Гали Хәбиб, Г. Хәбиб, «Берәү».

---

[1] 1969 елдан алып 1990 елга кадәр «Чаян» журналының җаваплы сәркатибе.

[2] Татар энциклопедиясе: Хуҗи улы.

Татарстанның Мамадыш районы Ташлы Елга авылында туа. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый, соңрак Төркиягә китеп, Истанбулда укып, укытучы була.

**959. ХӘБИРОВ Гомдәтелислам.**

***Тәхәллүсләре:*** Гомдә Хәбиров, Хәбиров Гомдә.

Революциягә кадәр вакытлы матбугатта языша, Уфада чыккан «Тормыш» газетасының секретаре була. Революциядән соң да язгалый.

Ш. Бабич аны болай тасвирлый:

Гомдә инсафлы шәкерт. «Тормыш»та эшләй сәркатип,
Каш төзим дип күз чыгарып, барча эшне таркатып.

**960. ХӘБИБУЛЛИН Габдрахман.**

***Тәхәллүсе:*** Шәрә.

Габдрахман Сәгъдинең каенесе. «Ялт-Йолт»та язгалый.

**961. ХӘЗРӘТОВ Гыйзбулла.**

***Тәхәллүсе:*** Кусинов.

**962. ХӘЙДӘРОВА Ләлә Габдуллаҗан кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Сабирова Ләлә. Хәйдәрова Л.

1928 елда Татарстанның Дөбьяз районы Әлдермеш авылында туа. Филолог, университет хозурындагы фәнни көтепханәдә гыйльми хезмәткәр.

**963. ХӘЙРИЕВ Гайнан Бәдретдин улы** (1903–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Гайнан Хәйри, Г. Хәйри.

Башкортстанның Нуриман районы Иске Күл авылында туа. Башкорт язучысы. 1921 елда Оренбургта педагогия техникумында укый. 1924 елда Уфага килә, 1926 елда «Башкортстан яшьләре»нең баш редакторы. 1928–1933 елларда «Сәнәк» һәм «Трактор» журналларында секретарь була. 1938 елда туберкулездан үлә. 7 данә шигырь, хикәя җыентыклары бар.

**964. ХӘЙРУЛЛИН Фәрит** (1893–1961).

***Тәхәллүсләре:*** Фәрит Хәйруллин, Ф. Хәйруллин.

1918 елдан партия әгъзасы. Татарстанда баш судта рәис була. 1937 елда кулга алына. Лагерьда суык тидереп, аякларын кисәләр.

**965. ХӘЙРУЛЛИН Салават** (1894–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Салават Хәйруллин, С. Камский, Салават Камский.

Пермь өлкәсеннән. «Коммунист», «Урак һәм чүкеч» газеталарында шигырьләр яза. Казанга килгәч тә, «Чәй идарәсе»нең[1] башлыгы була, вакытлы матбугатка шигырьләр язып тора.

**966. ХӘЙРУЛЛИН Хәсән Фәхретдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Хәсән Хәйри, Х. Хәйри.

1910 елның 5 февралендә Көнбатыш Казакъстан өлкәсе Чапаев районы Чапай поселогында туа. 1920–1926 елларда Уральскида балалар йортында тәрбияләнә. 1924 елда комсомолга керә. 1927–1930 елларда Казанда рабфакта укый. 1930–1932 елларда Себердә «Азат Себер» газетасында эшли. 1934–1942 елларда Казанда «Совет мәктәбе» журналында җаваплы секретарь. 1947 елда партия обкомы бүлегендә эшли. «Совет мәктәбе» редакторы була. 1950– 1953 елларда Фәннәр академиясендә[2] эшли, кандидатлык диссертациясен яклый. Тел, әдәбият, тарих институтында җитәкче була. Гыйльми, әдәби әсәрләр язу өстенә күп классикларны тәрҗемә итә.

**967. ХӘКИМОВ Сибгать Таҗи улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Сибгат Хәким, С. Хәким.

1911 елның 24 декабрендә Татарстанның Күлле-Киме авылында (Әтнә районы) туа. 1933 елда беренче шигырь җыентыгы чыга. «Пар ат», «Шагыйрьнең балачагы» поэмаларын бастыра. Ватан сугышында командир була. Сугыштан соң «Дала җыры», «Бакчачылар» поэмалары, алардан башка бик күп шигырь җыентыклары басылып чыга, күп телләргә тәрҗемә ителә. Казанда педагогия институтын тәмамлый. Нәшриятта, «Совет әдәбияты»нда редактор. Язучылар союзында җитәкче була. Берничә лауреатлык яулый.

---

[1] «Чай управления».

[2] Мәскәүдә Иҗтимагый фәннәр академиясе аспирантурасында укып, «Сугыштан соңгы татар әдәбиятында социалистик реализмны үстерү өчен көрәш» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклагач, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтына директор итеп билгеләнә.

**968. ХӘКИМЗАДӘ Хәмзә Ниязи.**

***Тәхәллүсләре:*** Хәмзә Хәкимзадә, Х. Ниязи, Таван Тистәр, Нихан.

1914 елда Ташкентта үзбәкнең беренче газетасы «Садаи Төркестан»да язышкан мәшһүр шагыйре, әдибе, драматургы. Музыкант, иң зур талантлы җәмәгать эшлеклесе.

**969. ХӘКИМОВ Нигъмәт** (1898–1937).

***Тәхәллүсе:*** Нигъмәт Хәким.

Ташкентта мәгариф институтында (1921–1922 елларда) укытучы. Казанга килгәч, язучы, укытучы, тәнкыйтьче була.

**970. ХӘКИМОВ Һидаят.**

***Тәхәллүсе:*** Һидаят Хәкимов.

1907 елда Әстерханда туа. 1924–1932 елларда Әстерханда артист була. Аннан соң Бакуда театр техникумында укый. 1936 елдан башлап, Баку филармониясендә иллюзионист-фокусник булып эшли.

**971. ХӘЛИМОВ Айдар.**

***Тәхәллүсләре:*** А. Хәлим, Хәлимов Борис, Хәлимов Айдар.

Вакытлы матбугатта А. Хәлим имзасы белән бик күп шигырьләр язган шагыйрь һәм язучы. «Йөрәгем ялкыннары», «Кызыл гөлләр», «Җәһәннәм кисәве» исемле әсәрләр авторы.

**972. ХӘЛИМОВ Ибраһим.**

***Тәхәллүсләре:*** И. Хәлим, Ибраһим Хәлим, Чүкәй.

Лаеш өязендәге бер авылдан язучы, укытучы һәм шагыйрь.

**973. ХӘЛИЛИ Якуб Ибраһим улы** (1877–1945).

***Тәхәллүсләре:*** Якуб Хәлили, Я. Хәлили.

Татарстанда Иж-Бубый авылында[1] туа. Шунда укый һәм укыта. 1912 елгы Бубилар вакыйгасыннан соң[2] Казанга килеп, «Сөембикә» журналы чыгара. 1917 елдан соң «Балалар дөньясы» [журналы] һәм «Мөгамәлят» китабын бастыра. Тукай болай дип көлә: «Һәяте дөнья әкаллүн мин калили; Сыра эчеп утыра Якуб Хәлили», – дип, аның зәвыксызлыгын фаш итә. Ул үзен бик тә зәвыклы күрсәтергә тырышкан булган һәм Тукай аны күреп калган.

[1] Әгерже районына керә.

[2] «Буби» мәдрәсәсе эше патша хөкүмәте тарафыннан туктатылган була.

**974. ХӘЛФИН Ибраһим Исхак улы** (1773–1828)[1].

***Тәхәллүсе:*** Хәлфин Ибраһим.

Казанда туа. XIX йөзнең беренче яртысында фәнни әсәрләр язып, мәгърифәтчелеккә ярдәм иткән зыялыларның берсе. 1800 елда атасы Исхак вафат булгач, Казан гимназиясендә татар теле укыта башлый. 1812 елда Казан университетында шәрык телләре кафедрасына күчерелә. Анда, беренче буларак, 1823 елда адъюнкт (профессор ярдәмчесе) дигән гыйльми дәрәҗә ала. Ул рус, татар телләреннән башка гарәп, фарсы, госманлы төрек телләрен яхшы белә. 1818 елда «Казан губернасының кыскача географиясе»[2] исемле әсәрен бастыра. «Дастаны Чыңгызхан вә Аксак Тимер»[3] дигән (1630–1660 елларда язылган) кулъязманы эшкәртеп, 1819 елда Казан университетының типографиясендә бастыра. «Шәҗәрәи төрки»не эшкәртеп бастыра. «Азбука и этимология татарского языка»[4] әсәрен 1804 елда 1200 данә чыгара, 150 сум бүләк ала.

**975. –**

**976. ХӘЛФИН Исхак Сәгыйть улы.**

***Тәхәллүсе:*** Хәлфин Исхак.

1785 елда атасы Сәгыйть пенсиягә чыккач, Казан гимназиясендә татар теле укыта башлый.

**977. ХӘЛФИН Исмәш Сәгыйть улы.**

***Тәхәллүсе:*** Хәлфин Исмәш.

Хәлфин Исмәш Сәгыйть улы Казан гимназиясендә татар теле укыта.

**978. ХӘЛФИН Мөхәммәдрәхим Хәсән улы.**

***Тәхәллүсе:*** Хәлфин Мөхәммәдрәхим.

1757 елда Пруссия сугышында рус армиясе белән катнаша. 1782–1785 елларда Казанда Иске Татар бистәсе башлыгы булып тора. Гадел, туры сүзле, халык яклы кеше.

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1778–1829 еллар.

[2] И. Хәлфинның студент П. Юнаков белән зерләгән «Кыскача Русия тарихы һәм географиясе» хезмәте күз алдында тотыла булса кирәк.

[3] «Әхвале Чыңгызхан вә Аксак Тимер».

[4] «Татар теленең әлифбасы һәм этимологиясе» хезмәте.

**979. ХӘЛФИН Нәҗип.**

***Тәхәллүсләре:*** Нәҗип Хәлфин, Н. Хәлфин.

Татарстанның Сарман районы Теләнче-Тамак авылындагы зур байлар саналган Хәлфиннарның ярлы туганы. Яшьтән ятим кала. Казанда татарча һәм русча укып университет тәмамлый, юрист була. Бакуда укыта. 1937 елны кулга алына.

**980. ХӘЛФИН Сәгыйть Хәсән улы** (1732–1785).

***Тәхәллүсе:*** Хәлфин Сәгыйть.

Иске Татар бистәсендә туа. Ул татар һәм рус телләрен белү өстенә гарәп, фарсы телләрен дә яхшы үзләштерә. Казанда Адмиралтик верфь (Бишбалта) конторында тәрҗемәче булып эшли. Екатерина II боерыгы белән 1767 елда Казанда гимназия ачылып, анда татар теле укытучысы итеп Сәгыйть Хәлфин билгеләнә. 1785 елгача укыткач, пенсиягә чыгып, үз урынына улы Исхак Хәлфинне укытучы итеп калдыра. 1774 елда «Татар теле әлифбасы» басылып чыга. 1778 елда «Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов»ны яза.

**981. ХӘСӘН Айтуган улы Хәлфин** (1700–1759).

***Тәхәллүсе:*** Хәлфин Хәсән.

Казанда Иске Татар бистәсендә туа. Аның уллары: Сәгыйть, Мөхәммәдрәхим, Ягафар, Саләт. 1769 елда Исхак, Исмәгыйль исемле уллары белән «подушный оклад»тан чыгарылалар.

**982. ХӘЛФИН Шаһингәрәй Ибраһим улы.**

***Тәхәллүсе:*** Хәлфин Шаһингәрәй.

Хәлфин Шаһингәрәй Ибраһим улы 1807 елда Ибраһимның өченче баласы булып дөньяга килә. Гимназиядә, аннан соң университетта укый. Университетта татар теле укыта. Тәрҗемәче була. Аны Уфа губернасындагы гаскәри хезмәткә җибәрәләр.

**983. ХӘМИДИ Латыйф Габделхәй улы.**

***Тәхәллүсе:*** Латыйф Хәмиди.

1906 елда Казан губернасы Зөя өязе Кошман волосте[1] Бүәле авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Кәттәкурган шәһәрендә Заһидә Бурнашевада укый. 1920 елда Ташкентка килә. 1926 елда

---

[1] Хәзерге Кайбыч районына керә.

мәгариф институтын тәмамлый. Казанга килгәч, Муса Җәлил белән дуслаша. 1927 елда Мәскәүдә музыка техникумында укый. 1933 елда чакыру буенча Алма-Атага килә. Шул көннән бирле ул казакъ композиторы булып исәпләнә. Бүләкләр, бөек исемнәр ала.

**984. ХӘМИДИ Идрис.**

***Тәхәллүсе:*** Хәмиди Идрис.

Укытучы, «Шура», «Вакыт» һәм башка газеталарда языша. «Рәсемле гыйльме хәйванат» дәреслеге яза.

**985. ХӘМИДУЛЛИН Фазылҗан Хәмидулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Фазылҗан Хәмидулла, Ф. Хәмидулла.

1891 елда Сембер губернасы Сабачай авылында туа. Гомер буе укытучы һәм журналист.

**986. ХӘМИДИ Шакирҗан Әсәдулла улы** (1884–1929).

***Тәхәллүсләре:*** Шакирҗан Хәмиди, Ш. Хәмиди.

Татарстанның Минзәлә өязе Карамалы волосте Яхшыкаран авылында[1] туа. Партия әгъзасы. 1914 елларда Верхотурье[2] төрмәсендә утыра. «Динсез Морат Сәйфигә хөкем», «Мостафа муллага сәяси хөкем» пьесалары, «Җәннәт әһле кемнәр?»нең авторы. 1917 елда Минзәләдә «Минзәлә иле» газетасы чыгара.

**987. ХӘМИТОВ Габделмалик Хәмидулла улы[3].**

***Тәхәллүсләре:*** Хәмитов Малик, М. Хәмитов.

1930 елның 2[2] августында Норлат районы Күҗәй авылында[4] туа. 1948–1953 елларда Казан университетында укый, 1952 елдан «Совет әдәбияты» (хәзер «Казан утлары») журналында бүлек мөдире.

**988. ХӘМИТ М.**

***Тәхәллүсе:*** Хәмит М.

«Чалгы чыңнары»н язгандагы имзасы шундый.

---

[1] Татар энциклопедиясе: 1880 елда Сембер губернасы Буа өязе (хәзерге Чүпрәле районы) Татар Төкесе авылында туа, 1932 елда Казанда вафат. 1910, 1914–1917 елларда Уфа губернасы Минзәлә өязе (хәзерге Сарман районы) Яхшыбай авылында мулла һәм мөгаллим булган.

[2] Свердловск өлкәсендә.

[3] Татар энциклопедиясе: Әхмәдулла улы.

[4] Дөресе: Хәзерге Яшел Үзән районы Күгәй авылында.

**989. ХӘНӘФИ Мөбарәкша.**

***Тәхәллүсе:*** Хәнәфи Мөбарәкша.

Стәрлетамак шәһәренең имам һәм мөдәррисе. Революциягә кадәр мәдрәсә тотып укыта, журналларга язгалый. Революциядән соң 1917 елда Уфада «Дини мохтарият» журналында секретарь, 1918 елда «Уфа хәбәрләре» исемле [...] газетада языша. Спекулянт булып йөреп, Колчак белән китә. «Габбасның кызганыч картиналары», «Аракы исерткеч вә аның зарары» [әсәрләренең] авторы.

**990. ХӘСӘНОВ Кәлимулла Гомәр улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Кәлимулла Хәсәнов, К. Хәсәнов, К. Депутат.

Казан арты Теләче волосте[1] Чулпыч авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Атасы Казандагы Учительская школада дворник була. Кәлимулланы шунда укыта. Кәлимулла учительская семинарияне бетергәч, «рус-башкорт» земствосы училищесына укытучы итеп билгеләнә. Бу училище Уфа губернасы Борай авылында[2] була. Башкортлар Хәсәновны бик яраталар, 1906 елда Дәүләт думасына депутат итеп сайлыйлар. 1907 елда Петербургта «Дума» газетасының редакторы. Шул Думада шактый җитди чыгышлар ясый. Аның Думадагы речьләре белән В.И. Ленин бик кызыксына. Ул болай ди: «Башкортлар исеменнән депутат Хәсәнов (Уфа губернасы) ике миллион дисәтинә җирнең хөкүмәт тарафыннан талап алынуын искә төшерә һәм бу җирләрне кире кайтарып алуны таләп итә», – ди. (Тулы әсәр. 16 нчы том, 390 нчы бит.)

**991. ХӘЙРЕТДИНОВ Мөҗаһит Хәйретдин улы** (1901–1944).

***Тәхәллүсләре:*** Х. Мөҗәй, Хәйретдинов М.

Башкортстанның Туймазы районы Төрекман авылында туа. Хәрби мәктәп бетерә, подполковник дәрәҗәсенә ирешкән кадровый командир, бүлек командиры була. 1938 елда Хасан күлендә японнарга каршы сугыша. Бөек Ватан сугышында әсир булып, Германиядә Дахау лагеренда фашистлар тарафыннан ерткычларча җәзаланып үтерелә һәм яндырыла. Шигъри әсәрләре бар.

**992. ХӘСӘНОВ Нургали ахун.**

***Тәхәллүсе:*** Хәсәнов Нургали.

---

[1] Казан губернасы Мамадыш өязе (хәзерге Саба районы) Чулпыч авылында туа.

[2] Уфа губернасы Бөре өязе Борай авылында.

Татарстанның Буа районында Мирзалар авылында туа. Буада мәдрәсә үтеп, язгалаган кеше.

> Нургали Ахун – утыз ел хәлфәлек иткән кеше,
> Бер-ике әйбер язып һәм борчагын сипкән кеше, –

ди Бабич.

**993. ХӘСӘНОВ Мөхәммәтсабир мулла.**

***Тәхәллүсләре:*** Сабир әл-Хәсәни, С. Хәсәни.

Уфа шәһәрендә мулла. Дәүләт думасында депутат. 1916 елларда «Әл-галәм әл-ислами» журналында вә башка дини журналларда яңалыкка каршы фикерләр яза. Тукай вакытында аны нык тәнкыйтьли. Бабич та, аңар карап:

> «Әлхәсән мулла Сабир булды тәгассыб[1] үрнәге,
> Арканлы кискә[2] тыгып, ул эчне байтак тырнады», –

дип яза.

**994. ХӘСӘНИ Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы** (1883–1933[3]).

***Тәхәллүсләре:*** Әхмәтгәрәй Хәсәни, Г. Хәсәни, Г. Ильяс.

Татарстанның Әтнә районы Кенәр Ашыт авылында[4] туа. Революциягә кадәр Казанда «Аң» исемле популяр журнал чыгара. Казанда «Мөхәммәдия»дә укый, революциядән соң редакцияләрдә эшли. Хатыны Зәйнәп ханым Хәсәния зыялы кеше була. Шәехзадә Бабич аның турында да әйтми калмый:

> Башкаларга нисбәтән азрак талай «Аң»чы Гәрәй,
> Бер мәрәйгә тәгәрәй дә тәгәрәй ... анысы ярай.

**995. ХӨСНИ Зәйнәп Шәйхетдин кызы Мифтахетдинова.**

***Тәхәллүсе:*** Зәйнәп Хөсни.

Уфада туа, укытучы Хөсни Кәримовның хатыны. Вакытлы матбугатта язгалый.

**996. ХӨСӘЕНОВ Шәриф Нургали улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Шәриф Хөсәен, Ш. Хөсәенов.

---

[1] Тәгассыб – фанатизм.

[2] Кискә – кисеп аударылган озын һәм юан агач кәүсәсе.

[3] Татар энциклопедиясе: 1934 елда вафат булган.

[4] Татар энциклопедиясе: Иске Ашыт авылы.

1929 елның 26 ноябрендә Татарстанның Буа районы Черки-Ишмяков авылында[1] туа. 1944–1947 елларда Буада урта мәктәп бетергәч, дәүләт медицина институтының дәвалау-профилактика факультетында укый. 1953 елда врач-терапевт була. 1952 елда «Профессор кияве» дигән комедия, 1954–1956 елларда «Күңелле сәхнә», «Чулпан» пьесаларын яза.

**997. ХӨСӘЕНОВ Мәхмүт Хафиз улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Мәхмүт Хөсәен, М. Хөсәен, М. Х.

1923 елның 15 апрелендә Көнбатыш Казакъстан [өлкәсе] Җаңакала районы Урда авылында туа. 1941 елда Петропавел шәһәрендә урта мәктәп бетерә. Казанга килеп, университет тәмамлый, Бөек Ватан сугышында була. 1945 елда «Туган ил өчен» исемле беренче шигырь җыентыгы чыга. «Сүнмәс яшьлек», «Ак күгәрчен», «Идел таңнары», «Кореяга хатлар», «Базар һәм казлар», «Нәни дусларыма», «Чебиләр», «Дания белән Сания», «Урал баласы» исемле шигырь һәм башка поэма җыентыклары басылып чыга.

**998. ХӨСӘЕНОВ Мөхәммәтвәли** (1871–1933).

***Тәхәллүсе:*** Хөсәенов Вәли.

Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсе мөдире һәм «Дин вә мәгыйшәт» журналының нашире.

**999. ХӨСНЕТДИНОВ Вәлиулла** (1880–1922).

***Тәхәллүсе:*** Хөснетдинов Вәли.

Татарстанның Тәтеш өязе Олы Кариле волосте Атабай авылында туа. 12 яшендә Алафузов заводында эшли. 1902 елда РСДРП әгъзасы була. 1907 елда төрмәгә эләгә. Билалов Әһлиулла белән бергә банк баскан дип уйлыйлар. Билалов атыла, Вәлиулланы кыйныйлар. 1922 елда туберкулездан үлә.

**1000. ХӨСНЕТДИНОВ Фатих Хөснетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Фатих Хөсни, Ф. Хөсни, Гафи, Кәли.

1908 елның 13 февралендә Теләче районы Олы Мәтәскә авылында[2] туа. 1933 елда финанс-экономия институтын тәмамлый. 1933–

[1] Черки-Ишмяков авылы татарча Өчмунча дип йөртелә.

[2] Казан губернасы Лаеш өязе (хәзерге Саба районы) Олы Мәтәскә авылы.

1935 елларда Кызыл армия сафына алына. Аннан кайткач, төрле редакцияләрдә эшли. Язучылар союзында секретарь була. Фатих Хөсни – танылган әдип, зур юморист, шагыйрь, тәнкыйтьче һәм прозаик.

**1001. ЧАНЫШЕВ Хафиз.**

***Тәхәллүсе:*** Чанышев Хафиз.

1917 елдан Коммунистлар партиясе әгъзасы. 1918 елларда Мәскәүдә эчке эшләр министрлыгының коллегия әгъзасы, 1919–1922 елларда «Кызыл шәрык» исемле «Агитпоезд»ның политотдел әгъзасы, 1924 елда Татарстанда Эчке эшләр комиссары була.

**1002. Чанышев Якуб Җиһангир улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Чанышев Якуб, Я. Чанышев.

1892 елда Башкортстанда туа, 1917 елдан партия әгъзасы. Октябрь революциясен оештыручылардан. Беренче Герман сугышында һәм Гражданнар сугышында катнаша, Бөек Ватан сугышында генерал-лейтенант дәрәҗәсенә ирешә.

**1003. ЧЕНӘКӘЙ – Төхфәтулла Гыйззәтуллин** (1893–1959).

***Тәхәллүсләре:*** Төхфәт Ченәкәй, Ченәкәй, Сәмави, Кечкенәкәй, Бәләкәй, Бүкәнче.

Кайда туганын белмәдем[1]. Кайда торганын белү тагын да кыенрак. Төхфәтнең кайбер язганнары: «Кан тулкыннары», «Өмид очкыннары», «Җырлар юргасы», «Җыр капчыгы» вә башкалар. Вакытында танылган шагыйрь.

**1004. ЧИРКӘСОВ Солтан.**

***Тәхәллүсе:*** Чиркәсов Солтан.

Революциягә кадәр 1910 елларда Троицк шәһәрендә укытучы һәм «Йолдыз» газетасының хәбәрчесе.

**1005. ЧИРКӘСОВ Фәйзрахман.**

***Тәхәллүсләре:*** Фәйзрахман Чиркәсов, Ф. Чиркәсов.

Троицк шәһәрендә яшәп, вакытлы матбугатка язышкан кеше. «Әхмәрулла» журналының редакторы, «Хезмәт» исемле китап кибете тотып, китаплар нәшер иткән җәмәгать эшлеклесе.

---

[1] Татар энциклопедиясе: Оренбург губернасы Рәдүт авылы.

**1006. ЧОКАЛЫЙ – Гариф Гайнуллин.**

***Тәхәллүсләре:*** Чокалый Гариф, Г. Чокалый.

Татарстанның Буа өязе Иске Чокалы авылында туа. Революциягә кадәр вакытлы матбугатта язышкан кеше, «Кызыклы шигырьләр» исемле шигырь җыентыклары бар.

**1007. ЧАПУРИНСКИЙ – Әхмәт Мәүләкәев.**

***Тәхәллүсе:*** Чапуринский.

Чапуринский Әхмәт Мәүләкәев Әстерханда укытучы вә Волгоград өлкәсе Чапурин авылында туа. Театр турында мәкаләләр яза.

**1008. ШАДИ Голям.**

***Тәхәллүсләре:*** Дилбәр, Мискин.

Үзбәк язучысы.

**1009. ШӘЙХЕТДИНОВ Рәкыйб Кирам улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Рәкыйп Шәйхетдинов, Р. Шәйхетдинов.

1924 елның 13 июнендә Татарстанның Минзәлә районы Подгорный Байлар авылында туа. Ул Минзәлә педагогия мәктәбендә укый, 1943–1948 елларда Совет армиясе сафында була. Кайткач, Алабуга педагогия институтын, соңрак Максим Горький исемендәге Тел, әдәбият институтын тәмамлый. 1955 елда партия сафына керә. «Ыкның матур ярлары», «Яз башы», «Беренче адым» әсәрләрен яза.

**1010. ШӘЕХЗАДӘ Мәкъсуд.**

***Тәхәллүсе:*** Иртугрул.

Үзбәк язучысы.

**1011. ШАКИРОВ Самат Фәтхерахман улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Самат Шакир, С. Шакир.

1924 елның 15 апрелендә Татарстанның Әтнә районы Күәм авылында туа. Җидееллык мәктәпне бетергәч, Арчада педагогия мәктәбендә укый. Укытучы. 1943–1945 елларда Совет армиясендә була. Сугыштан соң 1951 елда «Очрашу» исемле шигырьләр җыентыгы басылып чыга. «Бәхетле көн» һәм «Иң кадерлесе» китапларын яза. Казанда университетның журналистлык бүлеген тәмамлаган журналист.

**1012. ШАКИРҖАНОВ Касыйм Мөхәммәтҗан улы**[1] (1903–1920).

***Тәхәллүсләре:*** Касыйм Шакирҗан, Шамун Фидаи.

Оренбургта икмәк пешерүче гаиләсендә туа. 1916 елда иске карашлы аталарын ташлап, Уфага килә һәм «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә. 1917 елда Уфа большевиклары белән аралашып, халык арасында аңлату-өндәү эшләре алып бара. Уфада чыга торган «Алга» исемле большевиклар газетасында вакытлы хөкүмәткә каршы берничә шигырен бастыра. Бөек Октябрь революциясеннән соң Уфа комсомол җитәкчеләреннән берсе була. «Яшь көч», «Яшь коммунист» газеталарының редакторы, 1919 елда Колчак һөҗүме вакытында Оренбургта «Кызыл яу» газетасында эшли. Колчакка каршы сугышта катнаша, күпсанлы шигырьләр һәм мәкаләләр бастыра. Колчакны җиңгәннән соң, яңадан Уфага кайтып, губерна комсомол комитетында җаваплы эшләр алып бара. 1920 елда кулаклар тарафыннан ерткычларча үтерелә.

**1013. ШӘКҮРОВ Сәед.**

***Тәхәллүсе:*** Сәед Шәкүров.

Казанда гали белем алгач, татар театрының артисты һәм драматургы була.

**1014. ШӘМИГУЛОВ Гали.**

***Тәхәллүсе:*** Шәмигулов Гали.

1917 елдан большевиклар партиясе әгъзасы. Революция башында Мәскәүдә, Уфада вә башка шәһәрләрдә партия һәм советны ныгыту юлында актив эшләгән коммунистларның берсе. Милли мәсьәләдә Бухарин карашындарак кеше.

**1015. ШАМИЛ Заһит.**

***Тәхәллүсе:*** Заһид Шамил.

Мәшһүр кавказлы Шамилнең оныгы. Петербургта цензор була. 1900 еллардан соң Казанда басылачак шәрык китаплары Петербургка Заһит Шамил карамагына җибәрелә башлый. 1907 елда Мәскәүдә балалар өчен «Тәрбиятел-әтфаль» журналы чыгара. Секретаре Фатих Әмирхан була.

---

[1] Татар энциклопедиясе: Хәсән улы.

**1016. ШАМИЛ Касыйм.**

***Тәхәллүсләре:*** Касыйм Шамил, К. Шамил.

1892 елның 30 августында Татарстанда Әлмәт авылында туа. Казанда «Мәрҗани» мәдрәсәсендә укый. 1909 елда «Сәйяр» труппасына суфлер булып керә һәм аның артисты булып китә. Бик күп җирләрдә татар театр труппалары оештыра. Татар кадрлары әзерли. 1929–1934 елларда Әстерхан театрында художество җитәкчесе. Артист һәм педагог буларак, ул татар театры һәм кадрлары үсешенә күп ярдәм итә. Тарихи материаллар күп туплый.

**1017. ШАММАСИ Имаметдин.**

***Тәхәллүсе:*** И. Шаммаси.

Революциягә кадәр чыккан газета-журналларда, бигрәк тә «Аң» журналында шигырь, поэмалар язган шагыйрь.

**1018. ШАММАСОВА Хәдичә Сөнгатьзадә**[1] (1875–1939[2]).

***Тәхәллүсе:*** Шаммаси Хәдичә.

Ульяновск өлкәсе Колмаер авылында мулла гаиләсендә туа. Атасында укый. Соңра мөстәкыйль рәвештә укып белем ала. 1913–1915 елларда «Кызлар бакчасы»[3], «Таң җиле» шигырь җыентыклары белән әдәбиятка килә. Хатын-кыз иреге өчен актив көрәшче.

**1019. ШАҺИМОРАТОВ Зәйни Әхмәт улы.**

***Тәхәллүсе:*** Ш. Зәйни.

1913 елның 7 мартында Троицк районы Кондыз-Тамак авылында[4] туа. Ташкентта Шәрык педагогия институтын, Казанда театр техникумын бетерә. 1941 елда фронтка китеп, 1946 елда гына кайта. 15 ләп драма әсәрләре яза.

**1020. ШАМОВ Афзал Шиһабетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Афзал Шамов, А. Шамов, А. Тәүгилде, Кызыл йөрәк, Әлфишин.

---

[1] Хәдичә Сөнгатьзадә буларак билгеле.

[2] Татар энциклопедиясе: үлгән елы 1949 ел дип күрсәтелгән.

[3] Җыентыкның тулы исеме: «Кызлар бакчасы, яки һәмширәләремә тәзкирәм».

[4] Татар энциклопедиясе: Оренбург өлкәсенең Тук районы Кондызлытамак авылында туган.

1901 елның 4 мартында Татарстанның Норлат районы Татар Танае авылында мулла гаиләсендә[1] туа. Урта мәктәп бетергәч, 1926–1930 елларда Мәскәүдә университетның әдәбият, сәнгать бүлегендә укый. Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышында үз ирке белән фронтка китә. Партиягә керә. Нәшриятта редактор булып эшли. Күренекле әдип. Басылып чыккан хикәя җыентыклары бар. Оста каләм иясе, прозаик. Яшьләрне коммунизм рухында тәрбияли торган әсәрләр язучы рәссам.

**1021. ШӘМСЕТДИН СУФИ ЗӘКИ** (Шәмсетдин Ярәхмәт улы Гобәйдуллин; 1825–1865).

***Тәхәллүсе:*** Шәмсетдин Суфи Зәки.

Оренбург өязе Зәк суы буендагы Ишмәт авылында туа. Ул суга нисбәтән «Шәмсетдин Суфи Зәки» дип йөртелгән. Яшьтән Суфи бик зиһенле була. 1865 (1282) елда кырык яшендә хаҗга барышлый Таганрог шәһәрендә вафат. Сукыр көе мәдрәсә тотып, мөдәррис була. Күп галимнәр әзерли, күп китаплар яздыра. Мәрҗани аны мактап яза.

**1022. ШАМУКОВ Габдулла Рухулла улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Шамуков, Г. Шамук.

1909 елның 11декабрендә Ульяновск өлкәсе Иске Майна районы Әсән авылында туа. 1929–1931 елларда Башкортстанның сәнгать техникумында укый. 1946–1948 елларда марксизм-ленинизм кичке университетының студенты. 1948–1952 елларда Казан педагогия институтында укый. 1930–1946 елларда Башкортстан дәүләт академия театрында эшли. Тукай һәм Ленин образларын биргән талантлы актер. Шагыйрь, әдип, юморист, журналист, мәсәлче.

**1023. ШӘМСИ Хөсәен.**

***Тәхәллүсе:*** Кәүкәб.

Үзбәк язучысы.

**1024. ШӘРИФБИКОВ Кәримбик.**

***Тәхәллүсе:*** Кемий.

Үзбәк язучысы.

[1] Татар энциклопедиясе: хәлле крестьян гаиләсендә туган.

**1025. ШӘРӘФЕТДИНОВ Галим.**

***Тәхәллүсе:*** Аин.

Үзбәк язучысы.

**1026. ШӘРӘФЕТДИНОВ Шәмсетдин.**

***Тәхәллүсе:*** Хөршид.

Үзбәк язучысы.

**1027. Ш. Н. Т.**

***Тәхәллүсе:*** Ш. Н. Т.

1908 елда «Кечкенә Мөхәммәдия» [әсәрен] язып, Казанда Харитонов матбагасында бастыра.

**1028. ШИРМӨХӘММӘТОВ Мирмулла.**

***Тәхәллүсе:*** Мулла.

Үзбәк язучысы.

**1029. ШӨКРУЛЛАЕВ Хаҗимогыйн.**

***Тәхәллүсләре:*** Әгърафи, Батырбик, Мәшрәб, Маһри, Хатыйб Пәрвәз.

Үзбәк язучысы. Сәмәркандлы. Хоканд шагыйре.

**1030. ШӘРӘФ Мөдәррис Хасиятулла**[1] (1919–1966[2]).

***Тәхәллүсләре:*** Хасиятулла малае, Ш. Хасиятуллин.

Мәшһүр шагыйрь. Ләбибә Ихсанованың тормыш иптәше.

**1031. ШӘЙМӘРДӘНОВ Шәңгәрәй** (1889–1937).

***Тәхәллүсе:*** Шәймәрдәнов Шәңгәрәй[3].

Татарстанда Минзәлә өязе Иске Байлар авылында[4] туа. 1918 елдан партия әгъзасы. Татарстанда Үзәк башкарма комитеты рәисе.

**1032. ШӘРКЫЙ ЙОСЫФ – Заһит Гайфулла улы Димикәев** (1901–1961).

***Тәхәллүсләре:*** Йосыф Шәркый, Й. Шәркый, Фидаи, Заһит Шәркый, Заһит Йосфи, З. Юсупов.

1901 елда Оренбургта эшче гаиләсендә туа. «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый.1912 елда аннан куыла. 13 яшендә наборщик була.

---

[1] Шәрәф Хасиятулла улы Мөдәррисов.

[2] Татар энциклопедиясе: үлгән елы 1963.

[3] Шәймәрдәнов Шәйгардан Шәймәрдән улы.

[4] Иске Байсар авылында туа.

1918 елда партия сафына керә. 1918 елда «Оренбур мөхбире», «Очкын» газеталарының редакторы. Аннан Себергә китеп, Томск шәһәрендә татар педагогия техникумында директор. 1924–1925 елларда «Каләм», «Сәлим бабай» пьесаларын яза. 1960 елларда филология фәннәре докторы.

**1033. ШӘРӘФЕТДИНОВ Самат** (1886–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Самат Шәрәфетдинов, Моңсыз, С. Д.

1912 елда Уфада «Тормыш» газетасында секретарь. 1917 елда «Уфа кооператорлары»н тәрҗемә итә. 1918 елда Уфада чыккан «Көрәш», «Кызыл яу» газеталарында язышa.

**1034. ШӘРӘФ Борһан Шәрәфетдин улы** (1883–1942).

***Тәхәллүсләре:*** Борһан Шәрәф, Б. Ш.

Татарстанның Буа районы Аксу авылында крестьян гаиләсендә туа. 1913–1914 елларда Оренбургта «Вакыт» идарәсендә эшли. Журналист. Язучы. 1909 елда «Иран тарихы», «Төркестанга сәяхәт», «Вамбери тәрҗемәсе», «Гани бай», «Тиредән күн эшләү» исемле әсәрләр авторы.

**1035. ШӘРӘФ Закирә Гыйльман кызы Кәримия.**

***Тәхәллүсләре:*** Закирә Шәрәф, З. Гыйльман, Закирә Кәримия.

1888 елда Оренбургта мулла гаиләсендә туа. Агасы Фатих Кәримидән укып, татар, төрек әдәбияты белән таныша. 1909–1916 елларда «Мәхәббәт җәфасы», «Онытылмаслык дуслык», «Хәкимә әбиемнең үткән яшьлеге» исемле хикәяләр авторы.

**1036. ШӘРӘФ Галимҗан Шәрәфетдин улы** (1896–1950).

***Тәхәллүсләре:*** Галимҗан Шәрәф, Г. Шәрәф, Җан Шәрәф.

Буа районы Аксу авылында туа. Укытучы, журналист, язучы, профессор. 1917 елда «Кояш» газетасында Радлов турында зур мәкалә яза.

**1037. ШӘРӘФ Гыйльметдин Шәрәфетдин улы** (1885–1943[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Гыйльми Шәрәф, Г. Шәрәф.

Татарстанның Буа районы Аксу авылында крестьян гаиләсендә туа. Китаплар нәшер итә. 1915 елда «Сугыш» исемле әсәр яза.

---

[1] Татар эниклопедиясе: үлгән елы 1942 елның 5 гыйнвары.

**1038. ШӘРӘФ Шәфика Гыйльметдин кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Шәфика Шәрәф, Ш. Ш.

Казанда туа. Урта мәктәп бетергәч, Ленинград университетының физика-математика факультетын тәмамлый. Фәнни хезмәтләре бар. Физика-математика фәннәре докторы.

**1039. ШӘРӘФ Шәрәфетдин Хөснетдин улы.**

Тәтеш өязе (Буа районы) Аксу авылында 1852 елда туа. Хатыны – Гайнелнәвал Нигъмәтулла кызы (Шәрәфләрнең ата-аналары).

**1040. ШӘРӘФ Шәһәр Шәрәфетдин улы.**

***Тәхәллүсе:*** Шәһәр Шәрәф.

1903 елда Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыта, 1881–1938 елларда мулла була. «Гасыр сәгадәт», «Әсхабе Кирам» вә башка дини-тарихи әсәрләр авторы. 1924–1926 елларда дүрт туган Шәрәфләр турында болай шаярта торганнар иде: «Шәһәр Шәрәф, Борһан Шәрәф, Гыйльми, Галимҗан Шәрәф; берсе мулла, берсе шәкерт, икесе "ниҗан"». Шәрәф 1933 елда төрмә полициясендә параличтан соң үлә.

**1041. ШӘРИФИ Мөхәммәтгариф (Чистай).**

***Тәхәллүсе:*** Гариф Шәрифи Чистай.

1910–1912 елларда «Йолдыз» газетасында, «Ялт-Йолт» журналында языша. «Күңел зары», «Идеал яки күз яше», «Сафсызлар», «Хур-хур», «Бүз егет» әсәрләрен яза.

**1042. ШӘФИЕВ Исмәгыйль** (1913–1943).

***Тәхәллүсләре:*** Исмәгыйль Шәфиев, И. Шәфиев.

Башкортстанның Кыйгы районы Югары Кыйгы авылында ярлы крестьян [гаиләсендә туа]. 1933 елда Уфада педагогия рабфагын бетерә, 1935–1937 елларда армиядә хезмәт итә. Кайткач, Казанда педагогия институтын тәмамлый, Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак була.

**1043. ШӘФИГУЛЛИН Вәли Сәлим улы** (1894–1939).

***Тәхәллүсләре:*** Вәли Шәфигуллин, Әүлия, Шәфигуллин В.

Революциягә кадәр 1913–1914 елларда Ташкент шәһәрендә приказчик. 1917 елда партия сафына кереп, Мәскәүдә Мулланур Вахитов белән берлектә Мөселман социалистлар комитеты төзи.

Октябрьдә Казанда революцион вакыйгаларга актив катнаша. Мәскәүдә партия үзәк комитеты хозурындагы шәрык халыклары коммунистларының бюросында әгъза. Журналист, 1918–1919 елларда Казанда «Эш», Мәскәүдә «Эшче» газеталарының редакторы.

**1044. ШӘҺИДИ Габдерәүф.**

***Тәхәллүсе:*** Шәһиди Рәүф.

Шәһиди Габдерәүф – 1917 елда «Начар гадәт сәясендә исәпсез үлемнәр» исемле 4 пәрдәлек пьесаның авторы.

**1045. ШӘҢГӘРӘЕВ Гайнелислам.**

***Тәхәллүсе:*** Шәңгәрәев Гайнелислам.

Уфа губернасы Чишмә стансасында мулла. [...] «Дин вә мәгыйшәт» язышучысы.

**1046. ШӘҺИДУЛЛИН Шәрәфетдин.**

***Тәхәллүсе:*** Шәһидуллин Шәрәфетдин.

Революциягә кадәр бик күп еллар татар календарьлары чыгарып килгән кеше. 1914 елда Казанда «Русия сәүдәсе» журналын чыгара. Секретаре Шәриф Байчура була. 1919 елда русча-татарча «Игъланәт» газетасын чыгара.

**1047. ШӘҺӘРЕТДИНОВ Шиһабетдин Шәһәретдин улы** (1904–1941).

***Тәхәллүсе:*** Ш. Шәһәр.

Татарстанның Тәтеш өязе Чирмешән авылында туа. 1923 елда Шәрык халыклары университетына керә. 20 нче елларның азагында Уфага күчә. Анда төрле редакцияләрдә эшли. Журналист. Тәнкыйди мәкаләләр яза. 1967 елда «Серле сукмак» исемле хикәя-очерк җыентыгы басылып чыга.

**1048. ЮЗИЕВ Ибраһим Ибнеямин улы** (1869–1912).

***Тәхәллүсе:*** Юзиев Ибраһим.

Татарстанда Тәтеш өязе Зур Бакырчы авылында крестьян гаиләсендә туа. Хәреф кисү һөнәрчесе. Оста, атаклы гравюр.

**1049. ЮЗЕЕВ Илдар Гафур улы.**

***Тәхәллүсе:*** Юзеев Илдар.

1933 елның 3 гыйнварында Башкортстанның Яңавыл районы Ямады авылында туа. 1954 елда Казанда педагогия институтын

тәмамлап, шигырьләр яза башлый. Ул – танылган шагыйрь. Язган әсәрләре күп.

**1050. ЮЛДАШЕВ Кыяметдин Исхак улы** (1890–1955).

***Тәхәллүсләре:*** Кыям Юлдаш, Юлчы, Шад.

Татарстанда Чистай өязе Әлмәт волосте Кульбаево-Мораса[1] авылында туа. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Касыйм хәзрәттән дә дәрес ала. Революциягә кадәр чыккан газета-журналларда шигырьләр язып бастыра. Революциядән соң партия сафына кереп, җаваплы эшләр башкара. 1937 елны утырып чыга. Котылгач, Казанда татар китап сәүдәсендә эшли. «Моңлы тавышлар», «Зилзилә хикәясе» вә башка әсәрләре бар.

**1051. Юлтый Дауд Исхак улы** (1893–1942).

***Тәхәллүсләре:*** Дауд Юлтый, Д. Юлтый, Сөендек, «Ди».

Куйбышев өлкәсе[2] Бозаулык (Бузулукский) өязе Юлтый авылында крестьян гаиләсендә туа. Беренче Герман сугышында катнаша. 1919 елда партия сафына керә. 1921 елда «Башкортстан»да редактор. «Октябрь» журналында редактор. 1925–1926 елларда Мәскәүдә «Красный профессура»да[3] укый, татар, башкорт, рус телләрендә 20 дән артык әсәре бар.

**1052. ЮМАЕВ Җамалетдин** (1892–1933).

***Тәхәллүсләре:*** Җамалетдин Юмаев, Җ. Юмай, Шаян, Җ. И, «Җәй».

Чиләбе өязе Искен (Ичкинская) волосте Әлмән (Альменево) авылында туа. Рәшит казый Ибраһимов – аның ерак агасы. Ул яшьтән ятим кала. Карт атасы карамагында үсә. 1910–1914 елларда Троицк шәһәрендә Яушевлар мәдрәсәсендә, аннан соң русча-татарча мәктәптә укый. Революциядән соң Уфага китеп, «Тормыш» газетасының корректоры була. Мәҗит Гафурилар белән дуслаша. Басылып чыккан ике шигырьләр җыентыгы бар.

**1053. ЮНАЙ Габделхәй Габдрахман улы.**

***Тәхәллүсе:*** Юнай Г.

---

[1] Күлбай-Мораса авылы.

[2] Хәзерге Самара өлкәсе.

[3] Институт красной профессуры.

Революциягә кадәр вакытлы матбугатта язышкалый. 1918 елда Томск шәһәрендә «Кандала» исемле көлке журнал чыгара.

**1054. ЮНУСОВ Мирсәед** (учитель).

***Тәхәллүсләре:*** Юнусов Мирсәед, «Бирски».

Уфа губернасы Бирск[1] өязендә рус теле укытучысы. [...] Кайда, кайчан үлүе мәгълүм түгел.

**1055. ЮНУСОВ Гази.**

***Тәхәллүсләре:*** Эшче, Мәлгунь, Мәрдкяр, Акпадар, Сумалак әүлия.

Ташкентлы. Үзбәк язучысы.

**1056. ЮНУСОВ Мәшрикъ.**

***Тәхәллүсләре:*** Өмәрбик, Әлбик.

Үзбәк язучысы.

**1057. ЮНУСОВ Әхмәт Юныс улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Әхмәт Юныс, Ә. Юныс.

1916 елда Татарстанның Кукмара районы Әсән Елга авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1931–1935 елларда укытучы. 1937[2] елда «Гүзәл яшьлек» әсәрен яза. 1945–1950 елларда «Тантана», «Әсән Елга», «Яз килә», «Без кайтырбыз», «Кырларга сәяхәт» исемле шигырь җыентыклары бастыра.

**1058. ЮСУПОВ Габдулла** (1899–27.IX.1969).

***Тәхәллүсе:*** Юсупов Габдулла.

Уральск шәһәре тирәсендәге Бөреле авылында туа. Уральск гимназиясендә укый. Гражданнар сугышына катнаша. Казанда татар театр техникумын тәмамлый. 1929–1932 елларда Мәскәүдә театр режиссеры була. 1939 елда Михайлов, Камышлы, Мамадыш татар театрларында җитәкче. Бөек Ватан сугышына алына, аннан кайткач, Әлмәт республика академия театрында эшли. «Татарстанның атказанган эшлеклесе» исеме ала. 1969 елда Казанда үлә.

**1059. ЮСУПОВ Гайсә Галиәкбәр улы** (1905–1941).

***Тәхәллүсе:*** Гайсә Юсупов.

---

[1] Бөре.

[2] Татар энциклопедиясе: 1936 ел.

Башкортстанның Мәләвез районы Дәүләткол авылында крестьян гаиләсендә туа. 1930 елда Уфада рабфак бетерә. 1930–1934 елларда Ленинградта хәрби медицина академиясендә укый, хәрби врач була. 1941елда үлә.

**1060. ЮСУПОВ Муса** (1896–1945).

***Тәхәллүсләре:*** Муса Юсупов, «Якуб улы».

Вакытлы матбугатта языша. Революциягә кадәр дә язгалый. 1917 елда «Безнең юл»да мәкаләләре чыга. 1919 елда Омск шәһәрендә «Азат Себер» газетасы, 1924 елда Уфада «Яңа авыл» газетасы чыгара. «Башкортстан хәбәрләре», «Яшь юксыллар» газеталарында актив языша.

**1061. ЮСУПОВ Юныс.**

***Тәхәллүсе:*** Әйями.

Үзбәк язучысы.

**1062. ЯФУЕВ Ибраһим.**

***Тәхәллүсе:*** Әйвар.

Үзбәк язучысы.

**1063. ЯКУПОВА Зәйнәп (Бакирова).**

***Тәхәллүсләре:*** Зәйнәп Якупова, З. Сәгыйдә, З. Якупова, С. Зәйнәп.

Оренбург губернасы Каргалы бистәсендә 1897 елда мулла гаиләсендә туа. Иске тормыштан туеп, өеннән качып, Оренбургтагы абыйсы Габдулла Якупов янына барып укый. 1914 елдан башлап, Аллабирде авылында, соңрак «Багбостан мәктәбе»ндә укыта. Мөстәкыйль [рәвештә] русча өйрәнә. Шул ук вакытта яза да башлый. Пугачев турында «Җүләр егет», «Каргалы легендалары» исемле әсәрләрен бастыра.

**1064. ЯКУПОВ Нургали Гали улы** (1896–1964).

***Тәхәллүсе:*** Якупов Нургали.

Оренбургта туа. Урта белем алгач, татар театрында артист була.

**1065. ЯКУПОВ Мортаза** (1900–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Мортый Якуб, Мортый Я., М. Я., Й. М.

Башкортстанда туа. Казанда төрле редакцияләрдә эшли. Журналист. Язган нәрсәләре бар.

**1066. ЯКУПОВ Әхмәт Гаяз улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Якупов Әхмәт, Фаикъ.

1909 елда туа. Урта белем алгач, хәрби белем алып, полковник дәрәҗәсенә ирешкән журналист.

**1067. ЯМАНГУЛОВА Мәдинә.**

***Тәхәллүсе:*** Мәдинә Ямангулова.

1906 елда Татарстанда туа. Казанда театр техникумын тәмамлый. 1928 елда Әстерханга китә. 1945 елга кадәр эшләп, Әлмәт театрына күчә, шунда пенсиягә чыга.

**1068. ЯМАШЕВ Хөсәен Минһаҗетдин улы** (1882–1912) .

***Тәхәллүсләре:*** Х. Ямашев, Али, Гали, Сул, Кызыл.

1882 елның 6 гыйнварында Чистайда туа. 1897 елда[1] Казанда Учительская школаны тәмамлый. 1903 елда большевиклар партиясе сафына керә. Татар хезмәт ияләренең беренче җитәкчесе, беренче большевик, «Урал» газетасы чыгарган мәшһүр революционер.

**1069. ЯММӘТ Каршин.**

***Тәхәллүсе:*** Вәлидов.

**1070. ЯНБУЛАТОВ Муса.**

***Тәхәллүсләре:*** Янбулат Муса, Евгений, Николай, Борис Разин.

Ул Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсен бетереп чыга. Аннан соң Уфага килеп, институт тәмамлый. 1905 елларда революция хәрәкәтенә катнашып, «С. Р.» партиясенә[2] керә. Төрмәләргә эләгә. Ниһаять, жандармнар тозагына эләгеп чукына да, «Борис Разин» була. [...]

**1071. ЯЛЧЫГОЛ Таҗетдин.**

***Тәхәллүсе:*** Ялчыгол Т.

Ялчыгол Таҗетдин – 1801 елда «Тәварихе татар»[3] әсәрен язган кеше.

**1072. ЯНӘБИ – Төхфәтулла Кәлимулла улы Кәлимуллин** (1894–1939).

***Тәхәллүсе:*** Төхфәт Янәби.

---

[1] Татар эниклопедиясе: 1902 елда диелгән.

[2] Социал-революционерлар партиясе.

[3] «Тәварихе Болгария» әсәре күз алдында тотыла.

Башкортстанның Кыргыз Миякә районы Янәби авылында крестьян гаиләсендә туа. 1913 елда Оренбургка «Хөсәения»гә килә. Аны кабул итмиләр. 1919 елда Кызыл армиягә үзе языла. 1919 елда партия сафына керә. Мәскәүдә Свердлов исемендәге университетта укый. 1921 елда профсоюз эшендә була. 1924 елда «Башкортстан»да редактор. 1931–1932 елларда Партия Үзәк комитеты хозурындагы марксизм-ленинизм курсларында укый. Уфада Язучылар союзында секретарь. Башкорт, татар, рус телләрендә 20 дән артык җыентыклары бар.

**1073. ЯНГАЛЫЧЕВ Зыя.**

***Тәхәллүсе:*** Зыя Янгалычев.

«Шура» журналында актив язышкан журналист. Укытучы. Укытучылыкны ташлап, Саратовта мулла була.

**1074. ЯНГАЛЫЧЕВ Сәгыйть.**

***Тәхәллүсе:*** Сәгыйть Янгалычев.

Янгалычев Сәгыйть революциягә кадәр вакытлы матбугатта язгалый. 1917 елда Саратовта «Мохтарият» исемле газета чыгара.

**1075. ЯПАНЧИЕВ Әхмәт.**

***Тәхәллүсе:*** Япанчы.

Япанчиев Әхмәт язганнарына «Япанчы» имзасы куя.

**1076. ЯРМӨХӘММӘТОВ Хәмит Хөснетдин улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Хәмит Ярми. Х. Ярми.

1904 елның 5 маенда Төмән өлкәсендә Яңа йорт авыл советы Казарово авылында[1] туа. Казанда гали белем алгач, 1939 елда Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият, тарих институтында өлкән гыйльми хезмәткәр булып эшли. 1948 елда кандидатлыкны яклый. Татар фольклорыннан күп кенә әсәрләре бар. Партия әгъзасы.

**1077. ЯХИН Альберт Гатаулла улы[2].**

***Тәхәллүсләре:*** Гатаулла, Хәйриев, Фәхриев, А. Яхин.

1931 елда Арчада туа. Казан университетының тел, әдәбият, тарих факультетын тәмамлагач, «Чаян» журналына редактор итеп билгеләнә.

---

[1] тат. Кырынкүл авылы.

[2] Татар энциклопедиясе: Гатуф улы.

**1078. ТАИП Яхин.**

***Тәхәллүсе:*** Яхин Таип.

Учительская школада укытучы. «Сабый балалар өчен мәргуб[1] булган хикәяләр» (1894), «Балалардан ялкаулыкны җибәрә торган хикәяләр» (1900), «Бәйрәмнәр мәгълүмате һәм яшь балаларга нәсыйхәт»[2] (1897) исемле әсәрләр язган укытучы.

**1079. ЯУШЕВ Нәүширван Шарияздан улы** (1890–1917).

***Тәхәллүсләре:*** Нәүширван Яушев, Яушев Н., Нәүширван Я.

Бәләбәй өязе Кечкенә мең тал[3] авылында [туа], чабаталы дворяннардан. Мәдрәсә бетергәч, сәяхәтче журналист була. Урта Азиядә йөреп, вакытлы матбугатта шактый мәгълүматлар биреп йөри. 1917 елда Ташкентта авырып үлә.

**1080. ЯҺҮДИН Ильяс Бикмөхәммәт улы** (1889–1937).

***Тәхәллүсләре:*** Яһүдин Ильяс, И. Яһүдин**.**

Революциягә кадәр сул с[оциал]-р[еволюционер]. 1917 елдан Коммунистлар партиясе сафына керә. 1918–1919 елларда Мамадышта собес[4] комиссары, соңрак Казанда горкомсобес була. Вакытлы матбугатка язгалый.

**1081. ЯҺҮДИН Әзәл.**

***Тәхәллүсе:*** Яһүдин Әзәл.

1908 елда туа. 1930–1933 елларда Әстерханда, аннан соң Казанга килеп, Академия театрында һәм дәүләт филармониясендә эшли. Аеруча нәфис сүз остасы буларак танылa. Татарстанның атказанган артисты.

**1082. ҺАДИЕВ Мәхмүд.**

***Тәхәллүсләре:*** Бату, Эзче.

Ташкентлы. Үзбәк язучысы.

**1083. ҺАДИЕВ Мөнир.**

***Тәхәллүсе:*** Мөнир Һади.

Чиләбе мулласы. «Башкорт тарихы»н яза. 1913 елда вафат.

[1] Мәргуб – сыйфатлы.

[2] «Бәйрәмнәр мәгълүматы һәм яшь талибәләргә нәсыйхәт».

[3] Арслан авылы.

[4] Собес – социальное обеспечение.

**1084. ҺАДИЕВ Закир** (1863–1933).

*Тәхәллүсе:* Закир Һади.

Бәләбәй өязе Ярәмкә авылында туа. 1904 елда «Бәхетле кыз», 1908 елда «Җиһанша хәзрәт», «Мәгъсүм» әсәрләрен язган автор.

**1085. ҺИДИЯТУЛЛИН Рамазан.**

*Тәхәллүсе:* Һидиятуллин Рамазан.

Язгалаган кеше. Гаскәри. Ветеран.

**1086. ҺИДИЯТУЛЛИН Шәүкәт Гали улы.**

*Тәхәллүсләре:* Шәүкәт Гали, Котбетдин.

1928 елда Татарстанның Кайбыч районы Бакырчы авылында туа. Гали белем алгач, шигырьләр яза башлый. «Чаян»да эшли. Тукай премиясен алган атаклы шагыйрь була. Хәзер нәшриятта редактор.

**1087. ӘБЛӘМИНОВ Ибраһим.**

*Тәхәллүсе:* Әбләминов И.

1913 елның 3 апрелендә Әстерханда туа. 1932–1941 һәм 1946–1957 елларда Әстерханда эшли. Ватан сугышында катнаша. 1957 елдан Әлмәт театрында эшли.

**1088. ӘБҮБАКИРОВ Гали.**

*Тәхәллүсе:* Уральский.

Әбүбакиров Гали 1917 елда Уральскийда «Хәбәрләр» газетасы чыгара.

**1089. ӘБҮБАКИРОВ Хөсәен.**

*Тәхәллүсе:* Әбүбакиров Хөсәен.

Мулла. [...]

**1090. ӘБҮЗӘРОВ Хөсәен Габдрахман улы.**

*Тәхәллүсе:* Әбүзәров Х.

Саратов губернасы Хвалынь өязе Адоевщинск волосте Зимницы авылында туа. Казанда 1917–1918 елларда «Тавыш» газетасы чыгара.

**1091. ӘБЕЛМӘНИХ Әбелфәиз улы,** аның атасы Габдессәлам бине Урай (1200–1240 һиҗри елларда), 40 яшендә үлә.

*Кара:* 453.

**1092. ӘЛМӨХӘММӘТОВ Гомәр Камал улы** (1895–1941).

***Тәхәллүсләре:*** Әлми Гомәр, Әлми, Г. Әлми, Гы. Ә.

Башкортстанда Мәләвез авылында туа. Мәдрәсә бетергәч, укытучы булып эшли. Революциядән соң 1919 елда партия сафына кереп, сәяси хезмәткәр, журналист була.

**1093. ӘГЪЛӘМОВ Габдулла.**

***Тәхәллүсе:*** Темучин.

Үзбәк язучысы.

**1094. ӘГЪЛӘМОВ Тухтаморад.**

***Тәхәллүсе:*** Торгын.

Үзбәк язучысы.

**1095. ӘПСӘЛӘМОВ Габдрахман Сафа улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Әпсәләмов, Г. Камилов.

1911 елның 28 декабрендә Мордва республикасы Рыбкин районы Аллагол авылында туа. Башлангыч белем алгач, заводта слесарь булып эшли. Соңрак Мәскәүдә Максим Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый. Төрле редакцияләрдә эшли. Ул яшьтән үк нәфис әдәбият белән кызыксына һәм, ниһаять, үзе дә яза башлап, татар әдәбият дөньясының танылган мәшһүр әдибе булып китә.

**1096. ӘМИРИ – Гайнан Гыймадетдин улы Әмиров.**

***Тәхәллүсләре:*** Гайнан Әмири, Г. Әмири.

1911 елның 25 августында Башкортстанның Яңавыл районы Уртавыл авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Башкорт халкының танылган шагыйре һәм әдибе. Татар, башкорт, рус телләрендә 25 тән артык әсәре бар.

**1097. ӘХМӘТШИН Миңлегәрәй.**

***Тәхәллүсләре:*** Әхмәтшин Гәрәй, М.Г. Әхмәтшин.

Әхмәтшин Миңлегәрәй Татарстанның Чаллы районы[1] Биклән авылында туа. Революциядән соң партия сафына кереп, җәмәгать эшләрендә җитәкче була. 1924 елларда Чаллыда кантон башкарма комитетында рәис була. Соңрак Казанга күчеп, Татарстан Республикасы Башкарма комитеты рәисе була.

---

[1] Татарстан Республикасы Тукай районы.

**1098. ӘБҮГАЛИСИНА.**

***Тәхәллүсе:*** Әбүгалисина.

Шәрыкта Ибн Сина, Яурупада Авиценна исеме белән йөртелгән кешенең чын исеме Хөсәен Әбүгали (Галинең атасы дигән мәгънәдә). Атасының исеме Габдулла, бабасы Сина атлы. Ул 980 елда Бохара якынында Әфшана авылында таҗик гаиләсендә туа.

**1099. ӘДҺӘМОВА Сәрвәр Сабирҗан кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Сәрвәр Әдһәмова, С. Әдһәмова, Көлемсәр.

1901 елда Троицк шәһәрендә туа. Гимназиядә укый. 1923 елларда Казанга килеп, юридик курслар тәмамлый. Совет хокукы һәм төзелеш институтын бетерә. Юрист була һәм балалар өчен шигырьләр, хикәяләр яза. Мәшһүр Кави Нәҗминең тормыш иптәше була. Язган хикәяләре бар. 1937 елны шәхес культы җиле кагылып, 10 ел тоткынлыкта була. Хәзер пенсиядә.

**1100. ӘДҺӘМОВ Закир Фәйзрахман улы.**

***Тәхәллүсе:*** Әдһәмов Закир.

1928 елда Башкортстанның Күгәрчен районы Нукай авылында туа. Башкорт галиме. Уфада университетта укыта.

**1101. ӘЛМӘШЕВ.**

***Тәхәллүсе:*** Әлмәшев[1] .

1924 елларда Татарстанның танылган артисты була.

**1101а. ӘБСӘЛӘМОВ.**

***Тәхәллүсе:*** Әбсәләмов.

1924 елларда Казанда татар театрында режиссер була, талантлы артист.

**1102. АГАМБИРДЕ Суфи улы Мөхәммәтшәриф.**

***Тәхәллүсләре:*** Биквадә, Суфизадә, Вахиш, Задә, Мәйле.

Нәманганлы[2]. Үзбәк шагыйре һәм әдибе.

**1103. ӘМИНЕВ Бәдретдин.**

***Тәхәллүсе:*** Әмин.

[1] Әлмәшев Исхак Мөхәммәтҗан улы (1892–1937).

[2] Үзбәкстандагы Нәманган шәһәре.

Бәләбәй өязе Чукады волосте[1] Балтай авылында туа. 1920 елда кулаклар үтерә. Язгалый иде.

**1104. БАРИ Әминев.**

***Тәхәллүсе:*** Әминев Бари.

1924 елларда Казанда театрда уйный һәм газета-журналларда язышa.

**1105. ӘМИРОВ Мирсаяф Мәсәлим улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Мирсәй Әмир, Җиргән, Чаянист, Мир, Ә. Мирсәй, М. Ә., Күзле ут, Җидегән.

1907 елның 6 гыйнварында Башкортстанның Мәләвез районы Җиргән авылында крестьян гаиләсендә туа. Атказанган сәнгать эшлеклесе. Күренекле прозаик. Драматург. Танылган әдип. Язган әсәрләре күп.

**1106. ӘМИРОВ Кәрим Хөсәен улы** (1893[2]–1962).

***Тәхәллүсләре:*** Кәрим Әмири, К. Әмири, Карт Чаян, Черки, Бөрчә, Кәләй, Әрем, Хәбәрче трест.

Башкортстанның Тәтешле районы Бүл-Кайпан авылында мулла гаиләсендә туа. Мәдрәсә тәмамлагач, укытучы була. 1913 елда «Шура» журналында беренче шигырьләре басыла. Шуннан башлап, ул шигырь яза башлый. 1925–1927 елларны яшьләр, аңар төбәп, болай җырлыйлар: «Тәрәз төбем туңган, Кәрим Әмири кунган, Ярымай санап җырлый иде, «Сулф» булган, чукынган». Язган әсәрләре: «Пайтәхет җәлладлары», «Казан кызы», «Печән базары», «Тимер ага», «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Йосыф-Зөләйха», «Габдрахман мулла», «Уңган кыз» вә башкалар.

**1107. ӘМИРХАНОВ Зариф Хөсәен улы.**

***Тәхәллүсе:*** Зариф Әмирханов.

Казанда Яңа Бистәдә имам. Мәшһүр әдип Фатих Әмирханның атасы. 1921 елда үлә.

**1108. ӘМИРХАНОВ Фатих Зариф улы** (1886–1926).

***Тәхәллүсләре:*** Ф. Ә., Даменла, Зәмзәметдинов, Имгәк, Марксист, «Т-д», Фатих Әмирхан, Ташмөхәммәт*.

[1] Чокадытамак волосте.

[2] Татар энциклопедиясе: туган елы 1896 ел.

Казанда мулла гаиләсендә туа. 1905 елда Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый. Шул еллардагы шәкертләр хәрәкәтенә актив катнаша. 1907–1908 елларда «Әлислах» газетасының редакторы. 1910 елда «Ялт-Йолт» журналын чыгарыша. 1912–1918 елларда «Кояш» газетасының мөхәррире. Совет матбугат һәм мәгариф органнарында эшли. Татар әдәбият классигы.

**1109. ӘМИРХАН улы Рәхмәтулла** (1807–1874).

*Тәхәллүсе:* Рәхмәтулла Әмирхани.

Казан арты Яңа Кишет авылында туа. Озак еллар Казан Ратушасында тылмач булып эшли. Ш. Мәрҗани аны телләр белүе өчен мактый. Казан байларыннан һәм муллаларыннан ачы көлә торган була.

**1110. ӘНӘС Кари** (1920[1]–1954).

*Тәхәллүсе:* Әнәс Кари.

Татарстанның Азнакай районы Уразай авылында туа. 1939 елда педагогия институтын тәмамлый. Укытучы була. 1935 елдан башлап, «Балаларга бүләк», «Гөлчәчкә»[2], «Күңелле»[3], «Дуслык», «Беренче адымнар», «Сыналган мәхәббәт» исемле әсәрләр яза.

**1111. ӘХМӘДУЛЛИННАР: Габделвәли, Мөхәммәтгали.**

*Тәхәллүсләре:* Әхмәдуллиннар.

Парлап түбәндәге китапларны язалар: 1900 елны «Госман батыр һәм аның башыннан үткән гаҗәеп вакыйгалар», 1900 елда «Хикәяти Тимерша», 1901 елда «Шәһре Болгарның беренче кадими гыймарәтләре[4]», 1904 елда «Көтебханәи ибтидаийә[5]».

**1112. ӘХМӘДУЛЛИН Фәтхи.**

*Тәхәллүсе:* Әхмәдуллин Фәтхи.

1917 елда Уфада «Солдат теләге»[6] газетасы чыгара.

---

[1] Татар энциклопедиясе: туган елы 1925 ел дип күрсәтелгән.

[2] «Гөлбакча» исемле булса кирәк.

[3] «Күңелле ял» исемле булса кирәк.

[4] Гыймарәтләре – корылмалары.

[5] Ибтидаи – башлангыч.

[6] « Солдат теләге һәм Уфа мөселман гаскәри шурасының хәбәрләре» – атналык газета, 1917 елның 15 июненнән 14 сентябренә кадәр нәшер ителә, мөхәррире – Фәтхи Әхмәдуллин.

**1113. ӘХМӘДУЛЛИН Ярулла.**

***Тәхәллүсе:*** «Ярул».

Вакытлы матбугатта язышa.

**1114. ӘХМӘРОВА САРА.**

***Тәхәллүсе:*** Әхмәрова Сара.

Казанда гимназиядә укып, социал-демократ була. Соңыннан Букешпан исемле еврейга кияүгә чыгып чукына һәм бик ихласлы лютеран була.

**1115. ӘХМӘРОВА Хәдичә.**

***Тәхәллүсе:*** Хәдичә Әхмәрова.

Татарлар өчен ачылган Учительская школа инспекторы, Шаһбазгәрәй Әхмәровның тормыш иптәше. Шуның ярдәмендә рус, татар әдәбияты белән танышып, 1901 елда Толстойның кайбер хикәяләрен татарчага тәрҗемә итеп бастыра. Шул елларны Казанда кызлар өчен русча-татарча мәктәп ачарга рөхсәт ала. Анда татарча укытыр өчен Маһруй ханым Мозаффарияне чакыра. Хәдичә ханым хатын-кызлар хокукы өчен актив көрәш алып бара.

**1116. ӘХМӘРОВ Мөхәммәтҗан хафиз.**

***Тәхәллүсе:*** Мөхәммәтҗан хафиз.

Бу кеше Казанның Печән базары мәчете астында кибет тотып, үткән-барган яшьләрдән кычкырып көлеп, төрле хурлау сүзләре әйтеп кала торган кадимче була. Җәдитчеләргә каршы шигырь-бәет китаплары бастырып чыгара. Тукайның «Көфер почмагы» дип атаган җир – шул почмак. [...]

**1117. ӘХМӘРОВ Шаһбазгәрәй.**

***Тәхәллүсе:*** Шаһбазгәрәй Әхмәров.

1887 елда[1] Казанда Учительская школаның инспекторы. Шәрык телләрендә чыга торган әсәрләрне тикшерүче цензор.

Казанда Г. Ильяс дигән кеше газета чыгарырга йөри һәм Әхмәров «Казан» газетасының редакторы булырга ризалык бирә. Ләкин газета чыкмый кала.

[1] Татар энциклопедиясе: 1881 елдан.

**1118. ӘХМӘРОВ Шиһабетдин Шәрәфетдин улы** (1882–1966).

***Тәхәллүсе:*** Шиһаб Әхмәров.

Татарстанның Чүпрәле районы Яңа Задур авылында туа. Революциягә кадәр Казанда (1913 елда) «Мәктәп» исемле журнал чыгарган сәүдәгәр. Композитор Салих Сәйдәшевны тәрбияләгән җизнәсе. Нашир дә була. «Мөнтәхәб[1] әлифба» (I–II кисәк) авторы.

**1119. ӘХМӘТОВ Фәрхи Шәйхи улы** (1890–1938).

***Тәхәллүсләре:*** Фәрхи Әхмәт, Сәлим.

Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укыта. Укытучы. 1913 елларда Хәлим Искәндәров белән бергә татарча «Хрестоматия» чыгара. Казанда 1924 елларда нәшрият редакторы була. 1918 елда Бөгелмәдә һәм Уфада хәрби «Кызыл яу» газетасы чыгара. Шәхес культы корбаны.

**1120. ӘХМӘДИЕВ Вафа Исхак улы.**

1937 елда Башкортстанда Ишембай районы Гомәр авылында туа. Урта мәктәп бетергәч, армиягә китә. 1961–1966 елларда Башкорт дәүләт университетын тәмамлый. 1968 елда «Талпыну» дигән шигырь җыентыгы чыга.

**1121. ӘХМӘДИ Гыйнаятулла Әхмәтов.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Әхмәди, Гыйнаятулла Әхмәди.

Харбин шәһәре мулласы, 1920 елда Харбинда «Ерак шәрык» журналы чыгара һәм бер көнлек «Мең ел» исемле (ислам кабул итү бәйрәменә багышлап) газета чыгарыша.

**1122. ӘХМӘДИЕВ Шәһит Гыймадетдин улы** (1888–1930).

***Тәхәллүсләре:*** Шәһит Әхмәдиев, Ш. Әхмәди, Ә. Шәһид, Хәмзә.

Татарстанда Чистай өязе Татар Ялтаны авылында туа. Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укый. Галимҗан Ибраһимовның якын дусты. 1919 елны партия сафына керә. 1917 елда Казанда «Аваз» исемле газета чыгара. Революциядән соң 1920 елда «Кызыл шәрык» исемле агитпоезд белән Төркестанга җибәрелә. Анда Ташкентта Төркестан халык мәгарифе комиссары була.

---

[1] Мөнтәхәб – сайланма, сайлап җыелган.

**1123. ӘХМӘТОВ Габдулла Сафа улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Әхмәт, А. Әхмәт.

1905 елның 25 мартында Курган өлкәсендә Звериноголовск авылында туа. Урта белем алгач, Казанда педагогия институтын тәмамлый. 1935–1941 елларда технология техникумында һәм музыка мәктәбендә укыта. 1941 елда Бөек Ватан сугышына китә. Партия сафына керә. Балалар өчен хикәя, шигырьләр яза. «Солдат балалары», «Солдат хикәяләре», «Кара алтын», «Тормыш көче», «Сер», «Гөлчәчәк», «Үги кыз», «Йолдыз», «Күршеләр», Хуҗа Насретдин хикәяләре» исемле әсәрләр яза.

**1124. ӘХМӘДУЛЛИН Азат.**

***Тәхәллүсе:*** Әхмәдуллин Азат.

Филология фәннәре кандидаты. Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтының гыйльми секретаре. Татар драматургиясе буенча эшли.

**1125. ӘХМӘТГАЛИЕВ Мөхәммәт** (1920–1943).

***Тәхәллүсләре:*** Мөхәммәт Әхмәтгалиев, Мөхәммәт Галиев.

1937 елда Казанда педагогия институтында укый, 1935 елдан башлап, газета-журнал битләрендә күренә башлый. 1943 елны комсомолга алына һәм шул елны батырларча һәлак була.

**1126. ӘХТӘМОВ Биньямин Габдесогуд улы[1].**

***Тәхәллүсе:*** Әхтәмов Биньямин.

Уфа мирзаларыннан. 1906 елларда Дәүләт думасына депутат итеп сайлана. Университетның юридик факультетын тәмамлый. Мөселман фракциясенең эшлекле әгъзаларыннан.

**1127. ӘХТӘМОВ Ибраһим Габдесогуд улы[2].**

***Тәхәллүсе:*** Әхтәмов Ибраһим.

Казан университетында Ленин белән бер чорда укый. Юридик факультетны тәмамлап, юрист була. Уфага кайтып, социал-демократларның Уфадагы җитәкчеләреннән. Цюрупа белән бергә эшли. Революциядән соң төшеп кала. Мәскәүдә юрист булып эшли. 1937 елларда юкка чыга.

---

[1] Исемен Ибнеямин дип йөрткәннәр, атасының исеме – Әбүсогуд.

[2] Атасының исеме Әбүсогуд.

**1128. ӘХТӘМОВ Садыйк Мөхәммәтҗан улы** (1877–1926).

***Тәхәллүсләре:*** Әхтәм карт, Садыйк абзый.

Татарстан җирендә, Апас районы Тутай авылында туа. 1917 елда большевиклар партиясе сафына керә. «Болак арты республикасы»н туздыруда катнаша. 1918 елда Казанда мөселман комиссары. 1919 елда Крупская белән «Кызыл йолдыз» агитпароходында агитатор була. Чехлар вакытында Идел күперен саклый. Казанда аның исеменә урам бар.

**1129. ӘҖИМОВ Мортаза.**

***Тәхәллүсе:*** Мортаза Әҗимов.

Әҗем мәчетен салдыра, Казан байларыннан берәү.

**1130. ӘҮЛАНИ Габдулла Мирәүланбай улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Әүлани, Әбелфәиз, Әүлани, Шөһрәт, Һиҗрәт, Аб, Абил, Өндәмәс, Чигәбай, Чал, Шапалак, Сүрәйә.

Ташкентлы. Үзбәк халкының танылган шагыйре. 1914 елларда Ташкентта үзбәк телендә чыккан «Садаи Төркестан» газетасының редакторларыннан. Үзбәкстан әдип-классигы.

**1131. ӘРИФХУҖА улы Сайһибәтулла хуҗа.**

***Тәхәллүсе:*** Хисләт.

Үзбәк шагыйре.

**1132. ӘМИНОВ Юныс Шәрип улы.**

***Тәхәллүсе:*** Юныс Әминов.

1921 елның 1 декабрендә Татарстанның Әгерже районы Ярза[1] авылында туа. Редакциядә эшли.

**1133. ӘХМӘТОВ Корбангали** (1896–1968).

***Тәхәллүсе:*** Корбангали Әхмәтов.

Әстерханда туа һәм шунда артист була.

**1134. ӘХМӘТҖАНОВ Ким Әбүзәр улы.**

***Тәхәллүсе:*** Ким Әхмәтҗанов.

1932 елның 5 февралендә Башкортстанның Әбҗәлил районы Әлмөхәммәт авылында туа. Уфада Фәннәр академиясенең Тарих, тел, әдәбият институтында гыйльми хезмәткәр.

---

[1] Салагыш авылында.

**1135. Әхмәтҗанов Журабай.**

***Тәхәллүсе:*** Фалончи.

Үзбәк язучысы.

**1136. ӘХМӘТШИН Габдулла Габдрахман улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Габдулла Әхмәтшин, Г. Әхмәтшин.

1921 елның 14 октябрендә Башкортстанда Бишбүләк районы Яңа Биктәш авылында крестьян гаиләсендә туа. 1941 елда партия сафына керә. Башкорт язучысы һәм тәрҗемәче. 10 лап язган әсәрләре бар.

**1137. ҮТӘЙ Җ.**

***Тәхәллүсе:*** Үтәй Җ.

«Яңа тормыш юлында» пьесасын язган да, «Үтәй» дип кул куйган.

**1138. ҖӘМИЛОВ Хан Баттал улы.**

***Тәхәллүсе:*** Хан Җәмил.

1902 елның 5 апрелендә Татарстанда Норлат районы Танай авылында крестьян гаиләсендә туа. 1919 елдан комсомол. 1922–1936 елларда Казанда театр техникумын тәмамлый. 1939–1941 елларда радио комитетында эшли. Партия сафына керә. «Көрәк», «Сөрем», «Гөлсем», «Сабан туе», «Әбкәй», «Яшьтәшләр», «Ташкичү» пьесаларын яза.

**1139. ҖАНТУРИН Сәлимгәрәй.**

Уфада алпавыт. 1906 елларда Дәүләт думасында депутат. Уфада «Галия» мәдрәсәсенә 30 мең сум иганә иткән бай. 1914 елда Петербургта «Милләт» исемле газетаның нашире. Редакторы Исмәгыйль Леманский[1] була.

**1140. ҖӘЛӘЛОВ Вакыйф.**

***Тәхәллүсе:*** Вакыйф Җәлял.

Җәләлов Вакыйф вакытлы матбугатта шигырьләр язып йөргән назыйм[2]. «Сәгадәт моңнары», «Күңел чәчәкләре», «Күз нурларым», «Вакыйф Җәлал шигырьләре» дигән әсәрләре бар. [...]

[1] Исмәгыйль Леманов.

[2] Назыйм – шагыйрь.

**1141. ҖӘЛИЛОВ Муса Мостафа улы (1906–1944).**

***Тәхәллүсләре:*** Муса Җәлил, М. Мостафа малае, М. Җ., М. Җәлил, Шахмай.

Оренбург өлкәсе Мостафа авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1924 елда партия сафына керә. Муса Җәлил – Советлар Союзы герое, үзен генә түгел, бөтен татар халкын дөньяга таныткан мәшһүр шагыйрь. Сугышта әсир төшеп, Берлинда тоткыннар арасында яшерен оешма төзи. 1944 елда фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелә.

**1142. ҖӘЛӘЛЕТДИНОВ Латыйф Җәләлетдин улы** (1894–1964[1]).

***Тәхәллүсләре:*** Латыйф Җәләй, Л. Җәләй.

Ульяновск өлкәсендә Кече Кандал районы Иске Кызылсу авылында туа. Филология фәннәре докторы. Татар теле профессоры. Күп яшьләрне тәрбияләп, яхшы кадрлар әзерли.

**1143. ӨММӘТИ Зыя.**

***Тәхәллүсе:*** Зыя Өммәти.

Өммәти Зыя – Уфада укытучы. «Галия»дә укыта. Татар-башкорт җырларын җыючы фольклорчы.

**1144. МУСИН Флүн Мөслах улы.**

***Тәхәллүсе:*** Мусин Флүн.

Татарстанның Мөслим районы Иске Карамалы авылында туа. Мәскәү университетының[2] филология факультетын 1962 елда тәмамлый.

**1145. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН Нур Габделхәй улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Г. Нур, Н. Гыйззәтуллин, Нур Гыйззәтуллин.

1928 елның 12 июнендә Татарстанның Актаныш районы Яңа Байсар авылында туа. 1949 елда Казан педагогия институтын, 1952 елда Фәннәр академиясе ИЯЛИда[3] аспирантура тәмамлый. 1953 елдан филология фәннәре кандидаты. 1957 елда Язучылар союзы члены.

---

[1] Татар энциклопедиясе: үлгән елы 1966 ел.

[2] М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университеты.

[3] Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты.

**1146. ХИСАМОВ Нурмөхәммәт Шаһиәхмәт[1] улы.**

***Тәхәллүсе:*** Хисамов.

Хисамов Нурмөхәммәт 1935[2] елда Чүпрәле районында крестьян гаиләсендә туа. ИЯЛИда гыйльми хезмәткәр.

**1147. ИБРАҺИМОВ Нәгыйм Фәйзи улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Ибраһимов Нәгыйм, Н. Ибраһим.

1935 елда Татарстанда Дөбьяз районы Суыксу авылында крестьян гаиләсендә туа. Урта мәктәп бетергәч, укытучы була. Казан университетының тел, әдәбият, тарих факультетын тәмамлый. Фәннәр академиясе ИЯЛИда гыйльми хезмәткәр булып эшли.

**1148. ЯРКИМБАЕВА Флюра Фәтхи кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Яркимбаева Флюра, Ф. Яркимбаева.

Яркимбаева Флюра 1937 елда Иске Ютазы авылында (Баулы районы) [туа]. 1959 елда Казан педагогия институтын тәмамлый.

**1149. ГАТИНА Хәмидә Хәнәфи кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Гатина Хәмидә[3], Х. Гатина.

1919 елда Татарстанда Куйбышев районы Көек авылында туа. Казан университетының филология факультетын тәмамлый. Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында гыйльми хезмәткәр булып эшли.

**1150. ӘХМӘТОВА Флора Ваһһап кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Флора Әхмәтова, Фольклорчы Флора, Ваһһап кызы.

Әхмәтова Флора 1935 елда Төмән өлкәсе Тубыл районы Күкрәнде авылында укытучы гаиләсендә туа. Төмән педагогия институтын һәм Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантура тәмамлый.

**1151. НАДИРОВ Илбарис Нурислам улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Надиров Илбарис, Н. Илбарис, И. Надиров.

1925 елда Татарстанның Әлмәт районы Нәдер авылында туа. Филология фәннәре кандидаты. Татар халкы иҗаты өлкәсендә җырлар буенча эш алып баручы.

---

[1] Дөресе: Шаһвәли улы.

[2] Татар энциклопедиясе: 1937 елда туган.

[3] Дөресе: Халидә, сүз Хәмит Ярминең хәләл җефете хакында.

**1152. ГӘРӘЙ Рәхим.**

***Тәхәллүсләре:*** Гәрәй Рәхим, Г. Рәхим, Г. Р.

Гәрәй Рәхим 1941 елда Татарстанның Лениногорск районы Федотовка исемле керәшен-татар авылында колхозчы семьясында туа. 1959 елда 10 еллык мәктәпне тәмамлап, 1962 елга кадәр колхозчы булып эшли. 1962–1967 елларда Казан дәүләт университетының тел, әдәбият, тарих факультетын тәмамлап, шигырьләр яза. Хәзер танылган шагыйрь исәпләнә.

**1153. МИРВӘЛИЕВА Маһирә Тимергали кызы.**

***Тәхәллүсе:*** М. Мирвәлиева.

1896 елда Уфа губернасы Покровский районы Калтай авылында туа. Урта мәктәп бетергәч артистка, Октябрь революциясеннән соң медфак бетереп, врач була. Ватан сугышында хәрби врач. Хәзер Уфада пенсиядә.

**1154. ГАРИФЬЯНОВ Нургаяз Салихҗан улы** (1920–1970).

***Тәхәллүсләре:*** Гарифьянов Н., Нургаяз Гарифьянов.

Киров өлкәсе Малмыж районында[1] крестьян гаиләсендә туа. Малмыжда урта мәктәп бетергәч, 1939 елда университетка керә, ләкин сугыш укуны бүлә. Сугыштан 1949 елда кайткач, Гарифьянов университетның физика-математика факультетын яхшыга тәмамлый һәм шунда аспирантурада кала. 1966 елда докторлык диссертациясен яклап, профессор була. Аның бу хезмәте электрон-парамагнитик тирбәлешләргә багышланган. Хәзер безнең илдә генә түгел, дөньяның күп почмакларында бу теманы профессор Гарифьянов исеме белән бәйләп йөртәләр. Казанда аның исеменә урам бар.

**1155. НАСЫЙРИЯ Хәбирә Габделкави кызы.**

***Тәхәллүсе:*** Хәбирә Насыйрия.

Аның «Татар әдәби телендә кулланыла торган гарәп, фарсы, төрки сүзләр сүзлеге»[2] әсәре 1902 елда басылып чыга. Икенче китабы саф татарча язылган, хикәя-новеллалардан торган җыентыгы 1904 елда басылып чыга. (Каюм Насыйриның туганы – Кави кызы Насыйрия.)

---

[1] Хәзерге Балтач районы Чутай авылында туа.

[2] «Фарси, гарәби һәм төрки лөгате» хезмәте.

**1156. ТЕРЕГУЛОВА Әминә Ибраһим кызы.**

***Тәхәллүсләре:*** Әминә Терегулова, Рабига Габитова.

Терегулова Әминә Ибраһим кызы Казанда туа. 1905 елларда татар большевикларының татарча прокламацияләрен гектографта басып күбәйтүчеләр Рабига Габитова белән Әминә булалар.

**1157. ГЫЙСМӘТУЛЛИНА Хәнифә.**

***Тәхәллүсе:*** Хәнифә Гыйсмәтуллина.

Гыйсмәтуллина Хәнифә Томск шәһәрендә мөдәррис гаиләсендә туа. Атасыннан укып урта белем алгач, Сембер губернасы Акчуриннар фабрикалары янында кызлар мәктәбе ачып, кызларны яңача укыта башлый. Шуның белән ул шигырьләр язу белән дә шөгыльләнә, аның «Тәгъзыя» исемле лирик шигырьләр җыелмасы 1897 елда басыла. «Тәргыйб» – 1898 елда; «Гакыйдәтел әһле хак» – 1895 елда; «Мәгъдәнел мәсаил» 1900 елда басылып чыга.

**1158. РӘХМӘТУЛЛИНА Галимә.**

***Тәхәллүсе:*** Галимә Рәхмәтуллина.

Рәхмәтуллина Галимә ханымның «Аналарга яднамә» исемле әсәре 1903 елда, «Иҗмагъ ишеге» 1906 елда басылып чыга.

**1159. ВӘЛИТОВА Мәфтуха** (1894–1925).

***Тәхәллүсе:*** Мәфтуха Вәлитова.

1915 елда Казанда «Күңел җимешләрем» дигән әсәре басыла.

**1160. САТТАРОВ Гомәр Фәиз улы[1].**

***Тәхәллүсләре:*** Саттаров Гомәр, Гомәр Мулла Илле.

1932 елның 2 июлендә Зеленодольск районы Мулла Иле авылында туа. Хәзер университетта доцент. Авыл, кеше исемнәре турында гыйльми әсәр бастыра.

**1161. МӨХӘММӘДЬЯРОВ Әхмәтҗан Латыйф улы.**

***Тәхәллүсләре:*** Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров, Панфиловчы.

1904 елда Казакъстанның Тимер шәһәрендә туа. Үзе теләп Кызыл армиягә язылып, Гражданнар сугышында катнаша. Ватан сугышында үлемсез генерал Панфилов дивизиясенең полк комиссары була. Хәзер Чиләбедә яши.

---

[1] Татар энциклопедиясе: Фәйзрахман улы.

# АЧЫЛМАГАН ПСЕВДОНИМНАР[1]

## I. «Ялт-Йолт» журналында.

1. Ләкләк.
2. Фәлән.
3. Имгәк.
4. Тутый.
5. Соңгы.
6. Очкын.
7. Күрдем.
8. Гифрит.
9. Телсез телеграф.
10. Келтрифап.
11. Пәри.
12. Лачин.
13. Буранбак («Кармак»та да).
14. Тимерләң.

## II. «Кояш» газетасында.

1. Аксакал.
2. Е.С. Кизләви.
3. Телмач.?
4. Яңгырчы.
5. Сирин.
6. Мөэмин.
7. Пешмәгән.
8. Рафаил.
9. (гарәп хәрефләре белән) әлиф, сад, хи.
10. Кикиморк.
11. Адәм улы.

## III. «Кармак»та.

1. Арслан.
2. Булат.
3. Балыкчы.

[1] Текстның бу өлеше КФУ китапханәсенең Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә саклanучы кулъязмадан алынды.

4. Күгәрчен.
5. Чәүкә.
6. Догаи Сәйфи.
7. Күзәтүче.
8. Ал-бир.
9. Мырр.
10. Шомбай.
11. Җиз тырнак.
12. Баскет.
13. Тимербай.
14. Җиһангир.

**IV. «Акмулла»да.**

1. Без тырнак.
2. Җылтыр күз.
3. Шаянбай.
4. Кызыл пәри.
5. Җиргән.
6. Бәкре мохит.

**V. «Кызыл Армия» газетасында.**

1. Нузад.
2. Габделбари.
3. Канбәр.
4. Гаден(л).
5. Тради.

# II бөлек

# ПСЕВДОНИМНАР ТУРЫНДА

**М. Бурнашева**

# ПСЕВДОНИМНАР ТУРЫНДА

Псевдоним – грек сүзе, грекча «ялган исем» дигән сүз, татарча «яшерен имза», яисә «кушамат» мәгънәсендә. Псевдонимнан язучылар, политик эшчеләр, артистлар, художниклар һәм сирәк кенә фән эшчеләре – галимнәр файдаланалар.

Культура тарихында бик борынгы заманнарда ук псевдоним кулланган шагыйрьләр, художниклар һәм галимнәр билгеле. Мәсәлән, Данте, Вольтер, Мольер, Микеланджело, Рафаэль һ. б. Болар – барысы да псевдонимнар. Аларның чын исемнәре: Алигьери, Франсуа Мари Аруэ, Жан Батист Поклен, Буанаротти, Санти һ.б.

Рус әдәбиятында псевдонимнар язма дини китаплардан башланып китә һәм XVIII йөз рус вакытлы матбугатында бик күп очрый. Революцион көрәш елларында псевдоним белән язылган мәкаләләрнең саны 75–80% ка җитә. Мисал өчен, революциягә кадәр чыккан большевистик «Искра» газетасын күрсәтергә мөмкин. Бу елларда төрле газета-журналларда К. Тулин, Вл. Ильин, В. Н. Ульянов һәм Н. Ленин имзалары белән ялкынлы мәкаләләр басылган – алар барысы да бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ульянов хезмәтләре, аларның псевдонимнары аныкы. Революциядән соң бу псевдонимнардан берсе – «Ленин» псевдонимы – Коммунистлар партиясенә һәм Советлар дәүләтенә нигез салучы бөек юлбашчының төп фамилиясенә әйләнә. Рус совет әдәбиятының атаклы язучысы Алексей Максимович Пешковның әдәби псевдонимы – Максим Горький – шулай ук язучының төп исеме булып китә.

Әдәбият һәм сәнгатьнең кайсы гына тармагын өйрәнергә, тикшерергә тотынсаң да, псевдонимнар белән очрашасың. Мәсәлән, бер язучының барлык әдәби мирасын, аның язган әсәрләрен туплау өчен, иң башта аның нинди псевдоним белән язганын һәм кайсы газета-журналларда язышканын ачыкларга тиеш буласың. Революцион көрәш тарихын өйрәнәсеңме, әдәбият һәм сәнгать тарихын тикшерәсеңме, аерым дәвердәге матбугатка күзәтү ясыйсыңмы – һәрберсендә псевдонимнар очратасың. Эшең дөрес барсын, фактик

материалың, текстларың анык булсын өчен, син шул псевдонимнарны ачарга тиеш буласың. Шулай итеп, әдәбиятчы, тарихчы, тәнкыйтьче, укучы алдына яшерен имзаларны ачу проблемасы бөтен киңлеге һәм кыенлыгы белән килеп баса.

Безнең әдәбиятта псевдонимнар куллану татар телендә вакытлы матбугат чыгару оешкач – 1905 елдан башлана дияргә була. Ә менә шул псевдонимнарны өйрәнү бездә бөтенләй кузгатылмаган хәлдә тора. Татар әдәбиятындагы псевдонимнар укучылар өчен «табышмак» булып торалар әле. Уральск шәһәрендә чыккан «Әлгасрелҗәдид», «Уклар» журналында, «Фикер» газетасында; Казанда чыккан «Әлислах» газетасында, «Яшен», «Ялт-Йолт» журналларында; Оренбургта чыккан «Урал», «Вакыт» газеталарында, «Карчыга», «Шура» журналларында; Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң чыккан «Кызыл Байрак», «Кызыл Армия», «Эш», «Эшче», «Таң», «Татарстан хәбәрләре» газеталары һәм башка бик күп татар вакытлы матбугаты битләрендә басылган меңләгән псевдонимнарны ачуга әле кул да тимәгән дисәк ялгыш булмас.

Революциягә кадәр патша охранкасының эзәрлекләвеннән, цензура күзәтүеннән, фанатик дин башлыкларыннан яшерenү өчен, әдипләр, революцион эш алып баручы политик эшлеклеләр, галимнәр, художниклар үзләренә төрле яшерен имза алырга – псевдоним кулланырга мәҗбүр булганнар. Билгеле, псевдоним куллануның моңардан башка сәбәпләре дә күп, әлбәттә. Мәсәлән, башлап язучылар, беренче әсәрләрен бастырганда, әдәбият мәйданында көч сынап караганда, чын фамилияләрен куярга кыюлыклары җитми, уңайсызланалар һәм псевдоним кулланалар. Мәсәлән, Галиәсгар Камал беренче пьесаларыннан «Бәхетсез егет» һәм «Өч бәдбәхет»не «Г. Казаный» псевдонимы белән чыгарган. Заһидә Бурнашева беренче шигырьләрен «Гыйффәт туташ» псевдонимы белән бастырган. Галимҗан Ибраһимов «Гыйрфанзадә» псевдонимы белән язган һ.б.

Сатирик журналларда көлке шигырьләр, чәнечкеле сүзләр, дусларча шаярулар, пародияләр бастырганда яисә язучы, тәнкыйтьче һәм артистның чын фамилиясе яңгырамый торган, төссез булганда һ. б. очракларда чын фамилияләрне псевдоним белән алмаштыру кулланыла.

Псевдонимнарны ачу – бик җаваплы эш. Ул күп эзләнүләр һәм тикшеренүләр белән бәйләнгән. Псевдонимнарны ачуның күптөрле юллары бар. Шулардан, нигездә, түбәндәгеләрне күрсәтергә була:

1. Автор төрле урыннарда псевдоним белән басылган әсәрләрен бергә туплап чыгара һәм шул җыентыгына язган сүз башында псевдонимын үзе ача. Мәсәлән, Габдулла Тукай, «Яшен» журналында псевдоним белән бастырган әсәрләрен җыеп, «Яшен ташлары» исемендә бер җыентык чыгарган. Фәтхи Бурнаш, газета-журналларда төрле псевдоним белән бастырган әсәрләрен бергә җыеп, «Шаян кыллар» исемле җыентык төзегән һәм шул китабына язган кереш сүзендә кайбер псевдонимнарын санап киткән.

2. Язучы турындагы төрле мәгълүматларны өйрәнү нәтиҗәсендә псевдонимнарны ачарга мөмкин. Бу мәгълүматлар, гадәттә, бик таркау булалар. Төрле архив материалларын, истәлекләр, хатларны, көндәлекләрне, отчетларны, гонорар ведомостьларын һ.б.ны җентекләп өйрәнергә кирәк була. Мәсәлән, 1960 елда Нәкый Исәнбәтнең тормыш һәм иҗат юлы турында Г. Шамуков монографик хезмәт чыгарды. Аңарда Исәнбәт әсәрләренең библиографиясе бирелгән һәм Н. Исәнбәтнең нинди псевдонимнар белән кайсы газета һәм журналда катнашуы әйтелгән. Бу мәгълүматлар аның псевдонимнарын ачуга нигезле дәлил булып торалар.

3. Авторның барлык әдәби мирасын өйрәнеп, текстларына әдәби-стилистик анализ ясау һәм алынган темаларның бердәмлеген, якынлыгын тикшерү нәтиҗәсендә, псевдонимнарны ачыкларга мөмкин. (Бу – әдәбият белгечләренең, тарихчыларның, өлкән библиографларның бергә коллектив хезмәтләре нәтиҗәсендә эшләнә торган эш.)

Псевдонимнар сайлау һәм куллануның күптөрле очракларын күрсәтергә мөмкин. Язучы, публицист яки журналист тарафыннан сайланып алынган псевдоним кайвакытта билгеле һәм төгәл бер мәгънәне белдерә (мәсәлән, Дәрдемәнд, Фидаи, Гыйффәт, Дәрвиш, Гафил бине Габдулла, Сәмави, Мокамай. Русларда М. Горький, Д. Бедный, М. Голодный һ.б.).

Кайберәүләр, үзләренең исем һәм фамилияләренең баш хәрефләрен кыскартып, псевдоним ясыйлар. Мәсәлән:

Гак – Гадел Кутуй,

Шк – Шәриф Камал,

Мм. – Мәхмүт Мәрҗани (М. Галәү),

Сабур – Сафа Борһан,

Буф – Бурнаш Фәтхи һ. б.

Язучы исем-фамилиясенең актыккы иҗеген кирегә таба үзгәртеп уку буенча эшләнгән псевдонимнар да очрый.

Феакут – Тукаев,

Сәләй – Сәлах Атнагулов,

Рим – Фатих Кәрим.

Авторның милләтен, туган һәм торган җирен, яисә берәр әсәренә бәйләнешен күрсәткән псевдонимнар була. Мәсәлән:

Татар хатыны – Заһирә Байчурина,

Г. Казаный – Г. Камал.

Күп вакыт юмор-көлке журналларында көлке псевдонимнар кулланыла. Мәсәлән: Шүрәле, Гомберрт, Бичура, Мин язмадым, Имзасыз да яраретдинов, Дөбернуш – Г. Тукай псевдонимнары. Ф. Әмирханныкы – Төшмөхәммәт, Дамелла һ. б. Нәкый Исәнбәтнең псевдонимнары – Мәлгунь, Күкташ, Каплан, Башы бозык, Дамелла Талпан һ. б. Ф. Бурнаш псевдонимнары – Физалба, Кәбәй, Иген игүче, Номерсыз урындык һ. б.

Шуның белән бергә, коллектив псевдонимнар да яши. Татар әдәбиятында андый псевдонимнардан: Әүлия һәм компаниясе – Галиәсгар Камал һәм Вәли Шәфигуллин, Шагыйрь-трест – Кави Нәҗми һәм Һади Такташ, Канәзагел – Кави Нәҗми һәм Закир Гали псевдонимнарын алырга мөмкин. Болар ике яки берничә авторның бергәләп язган әсәрләрендә кулланыла.

Бер үк чорда бер псевдоним белән ике яки берничә кеше файдаланырга да мөмкин. Мәсәлән, «Дәрвиш» псевдонимын алыйк. Бу псевдоним белән Нәкый Исәнбәт һәм Заһит Нуркин язганнар. Андый псевдонимнарны аеру өчен, башта авторларның кайсы җирдә яшәгән һәм нинди газета яки журналда язышкан икәнен ачыкларга кирәк. З. Нуркин «Кояш» газетасында эшләгән, бу псевдоним белән шунда басылган һәм кайбер мәкаләләрнең астына «Дәрвиш Парчинский» диеп тә җибәргән – димәк, Парча елгасы буеннан дигән сүз була, шуның белән аның кайсы «Дәрвиш» икәнлеге ачыклана. Н. Исәнбәт кайбер әсәрләрен шушы ук псевдоним белән бастырган.

«Cружди» псевдонимы белән дә шундый ук хәл. Революциягә кадәр әлеге псевдоним белән «Ялт-Йолт» журналында Зариф Бәшири, революциядән соң Закир Гали язган. Билгеле булганча, күп кенә кешеләр берничә псевдоним кулланганнар. Кайсы әсәрдә нинди псевдоним файдалануның үзенә күрә бер тәртибе дә була. Мәсәлән, Галимҗан Ибраһимов «Габди» псевдонимы белән әдәби бәхәс, тәнкыйть-библиография мәкаләләрен генә язган, аның бер хикәясе дә, бер романы да бу псевдоним белән чыкмаган.

Фатих Әмирханның «Ташмөхәммәт» псевдонимы белән сатирик әсәрләре, «Дамелла» имзасы белән әдәби-критик мәкаләләре, рецензияләре чыга, «Марксист», «М-т» имзасы белән политик мәсьәләләргә бәйләнешле мәкаләләре басыла. Габдулла Тукай иң яраткан «Шүрәле» имзасы белән әдәби эшләнеше һәм эчтәлеге ягыннан җитлеккән, яхшы дип уйлаган шигырь һәм мәкаләләрен генә чыгара. Бу турыда аның «Ялт-Йолт» редакторы Әхмәт Урманчиевка язган хаты бик характерлы факт булып тора: «...Мәкаләләр шәп чыкмадылар, моны «Шүрәле» имзаи шәрифе куймавыннан да аңларга мөмкин...», – ди ул.

Псевдонимнар ачу, аларны тикшерү – гаять җитди, авыр эш. Ул тикшеренүчеләрдән зур түземлелек, күп көч сорый. Фәлән кеше фәлән псевдонимнар кулланган дип санап чыгу белән генә котылып булмый монда. Чөнки бу юл белән бик зур буталчыклар, аңлашылмаучылыклар туарга мөмкин.

Нәтиҗәдә шуны әйтергә кирәк: бездә, революциягә кадәр һәм аннан соңгы чордагы татар әдәбияты, аның үсүе һәм формалашуы турында күп һәм күләмле хезмәтләр чыгуга карамастан, псевдоним һәм анонимнарны ачуга тиешенчә әһәмият бирелгәне юк. Шуңа күрә күп кенә газета-журналларның тарихы, аларның килеп чыгуы, эше, кадрлары һәм алар турында бик күп башка мәгълүматлар хәзерге көндә дә әле табышмак булып кала. Бу өлкәдә чынлап эшли башларга бик вакыт.

*«Казан утлары». 1960. № 8. Б. 151–153*

**Мөхәммәт Мәһдиев**

# XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ПСЕВДОНИМНАР

XX йөз башы татар әдәбиятында моңарчы махсус өйрәнелмәгән өлкәләрнең берсе – псевдонимнар мәсьәләсе. Мәгълүм булганча, Бишенче ел революциясе тәэсирендә төрле төбәкләрдә бик күп санда газета-журналлар ачылган. Берьюлы күпләп дөньяга килгән матбугат органнарына татар укымышлыларының, бигрәк тә мәдрәсә хәлфәләренең, шәкертләренең меңләгән армиясеннән әдәби әсәрләр яуган. Әдәбият теориясенең эшләнмәгән, журналистикада мәгълүм бер кануннарның урнашмаган булуы аркасында, әдәбият-матбугат битләрендә бүгенге көндә ачыклавы читен булган кайбер мәсьәләләр калган. Арадан берсе – газета-журналларда зур-зур гына әдәби тәнкыйть мәкаләләренең еш кына имзасыз басылган булуы. Кайбер матбугат органнарында еллар буе инициалдан (бер-ике хәрефтән) торган псевдоним белән мәкаләләр бастырып килгән авторлар бар. Казан, Оренбург нәшриятларында бу чорда авторлары күрсәтелмәгән әллә никадәр әдәби әсәрләр аерым китап булып чыккан. Кыскасы, аерым әсәрләрнең авторларын табу, күп кенә псевдонимнарны ачу, ә кайбер «ачылган» псевдонимнарга төзәтмәләр кертү әдәбият галимнәренең алдагы бурычы булып кала.

Псевдономастика – татар филологиясендә әлегә тиешенчә өйрәнелмәгән фән. Шулай да, алтмышынчы еллардан башлап, псевдонимнарны өйрәнү өлкәсендә бераз җанлану сизелә башлады. Мәсәлән, Ш. Абилов әдәбият тарихында моңарчы Мәүла Колый исеме белән йөргән шагыйрьнең исеме Меллагол булу ихтималын күрсәтте[1]. Г. Саттаров исә, шагыйрьнең исеме Мәүла, «Колый» туган җиренә бәйләнешле исем дигән фикер әйтеп, Ш. Абилов белән бәхәскә керде[2].

М. Бурнашева татар әдәбиятында псевдономастика мәсьәләләрен гыйльми нигезгә куеп өйрәнергә кирәклеген әйтүче кешеләрнең

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 1958. № 1.

[2] «Казан утлары» журналы. 1966. № 1.

беренчесе булды. «Совет әдәбияты» журналының 1960 елгы 8 нче санында басылган мәкаләсендә ул, аерым язучыларның иҗатын өйрәнгәндә, псевдонимнарны ачыклауның әһәмиятенә, псевдонимнарны ачуның кайбер ысулларына туктала. «Псевдонимнарны ачу, – ди автор, – тикшеренүчедән зур түземлелек, күп көч сорый. Фәлән кеше фәлән псевдонимнар кулланган дип санап чыгу белән генә котылып булмый монда. Чөнки бу юл белән бик зур буталчыклар, аңлашылмаучылыклар туарга мөмкин». М. Бурнашева шул ук вакытта язучыларның үзләренә псевдоним алу тәртибендәге бер әһәмиятле закончалыкны ача. Язучылар, ди ул, псевдонимнарны язган әсәрләренең характерына карата кулланалар. Мәсәлән, Г. Ибраһимов бервакытта да хикәяләренә «Габди» дип имза куймаган. Ф. Әмирхан исә сатирик әсәрләренә «Ташмөхәммәд», «Т-д», әдәби-әнкыйди мәкаләләренә «Дамелля», Октябрь революциясеннән соң язган политик мәкаләләренә «Марксист» дип имза куйган. Әлбәттә, мәкаләдә әле бәхәсләшерлек урыннар да бар. Автор, мәсәлән, безнең әдәбиятта псевдонимнар куллану 1905 елдан соң башланды, дигән фикер уздыра. Хәлбуки XVIII–XIX йөз әдипләрен һәм галимнәрен алып карасак, барысының да диярлек псевдонимнан файдаланганын күрербез: Утыз Имәни, Курсави, Кандалый, Мәрҗани, Шәмсетдин Зәки, Акмулла, Гафил бине Габдулла... Г. Камал да гасыр башында ук инде псевдоним кулланган: аның беренче пьесалары «Г. Казаный» псевдонимы белән дөньяга чыкканнар.

Псевдонимнарны ачуның әдәбият һәм иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүдә никадәр әһәмиятле урын алып торганлыгын профессор Р. Нәфыйгов та әйтә. «Тукайның, – ди ул, – ...шушы көнгә кадәр кайбер псевдонимнары бөтенләй ачыкланмаган, ачыкланганнарының да кайберләре бәхәсле»[1]. Чыннан да, Г. Тукайның дүрт томлы басмасына кертелгән берничә фельетон һәм мәкалә бернинди дәлилсез рәвештә шагыйрь тарафыннан язылган итеп күрсәтелә.

Тарих фәннәре докторы М. Мөхәррәмов һәм филология фәннәре кандидаты А. Әхмәдуллин, «Эш» газетасы битләрендә басылган әдәбият-сәнгать мәсьәләләрен тикшереп, шулай ук татар әдәбия-

[1] «Казан утлары» журналы. 1966. № 8.

ты публицистикасын өйрәнүдә псевдономастиканың әһәмиятле урын алып торганын әйтәләр. Галимнәр бу газета битләрендә очраган күп кенә псевдонимнарның авторларын ачалар һәм авторлары мәгълүм булмаган псевдонимнарның исемлеген бирәләр[1]. М. Һади «Псевдонимнар хакында берничә сүз» исемле мәкаләсендә XX йөз башы һәм Совет чоры татар әдәбиятына кагылышлы кайбер әдәби исемнәрне ачып бирә. Татар әдәбиятындагы псевдонимнарны ачу методикасына карата ул бик әһәмиятле бер фикер әйтә. «Псевдонимнарны ачканда, – ди ул, – кайсы язучының нинди стильдә язуын, уйлау һәм җөмлә төзү алымнарын үзенең чыгышы ягыннан кайсы төбәкнеке икәнлеген, ул җирлектә нинди сүз-тәгъбирләр кулланылуын һәм башка бик күп моментларны» искә алырга кирәк. Аның язуынча, псевдономастикага Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Ш. Камал зур әһәмият биргәннәр[2].

Татар әдәбиятында псевдонимнарны ачуның никадәр әһәмиятле икәнлеген исбатлау өчен мисаллар күп: әдәби-политик-фәлсәфи журнал булган «Шура»да әлегә ачылмаган сиксәнгә якын псевдоним бар. Болар аерым сүзләрдән (Гарип, Гасаби, Татар, Тугъры һ.б.), инициаллардан (Г. М.; М. М. һ.б.), аерым хәрефләрдән (Б. Н. Ә.), аерым атау җөмләләрдән («Дөньяга килүе өчен мәхзүн бер адәм») һ.б. бик күптөрле шартлы исемнәрдән гыйбарәт. Мондый имзалар белән басылган әсәрләр арасында, әлбәттә, әдәбият тарихы өчен әһәмиятле булмаган чүп-чарлар да, реакцион эчтәлеклеләре дә бар. Әмма гаҗәп матур лирик хикәя, нәсер, үткен телле прогрессив мәкалә авторлары да, кызганычка каршы, ниндидер сәбәпләр аркасында тыйнаклык күрсәткәннәр.

Соңгы елларда псевдонимнар өйрәнүне гыйльми нигезгә салу буенча кайбер конкрет эшләр эшләнде. Казан дәүләт университетында профессор Х. Госман җитәкчелегендәге гыйльми лаборатория псевдонимнарның алфавитлы каталогын булдыруда беренче адымын ясады. Университет китапханәсенең кульязмалар бүлегенә дә татар язучыларының пседонимнарын ачкан кульязмалар килеп керде. Ләкин болар әле беренче адымнар гына. Шуның өстенә бу

[1] «Казан утлары» журналы. 1967. № 5.
[2] «Казан утлары» журналы. 1969. № 1.

мәгълүматлар билгеле бер гыйльми нигезгә салынмаганнар. Кайбер псевдонимнар өлкән әдип-журналистларның хәтерләве буенча гына ачылып, фәнни әйләнешкә кереп китәләр. Тукайның Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатларын «Сәгыйть» дигән сүзеннән чыгып кына Сәгыйть Рәмиевкә язылган дип аңлату әдәбият тарихында никадәр буталчыклык керткәне моңа мисал.

Мәгълүм булганча, гарәптән кереп татарларда кулланыш тапкан кеше исемнәре сан ягыннан әллә ни күбәя алмаган. Нәтиҗәдә бер үк исемнәр күп кабатланган. XX йөз башы татар әдәбиятында һәм матбугатында әнә шуңа күрә ун-унбиш исем астында бик күп язучы-журналист язган (Гафил бине Габдулла, Габдулла Тукай, Габдулла Харис, Габдулла Кариев; Ш. Камал, Г. Камал; Галимҗан Ибраһимов, Фәрит Ибраһимов; Харис Фәйзи, Мирхәйдәр Фәйзи, Фәйзи Вәлиев; Сәгыйть Сүнчәләй, Сәгыйть Рәмиев һ.б.) Хәтта исем-фамилияләре белән туры килгән әдипләр, журналистлар бар: Фатих Әмирхан беренче һәм икенче; Фатих Сәйфи-Казанлы һәм Фатих Сәйфи-учитель һ.б.

Нәкъ шундый кабатлаулар псевдонимнар арасында да еш очрый. Моны «Габди» дигән псевдоним мисалында тикшереп карыйк. Габди – Галимҗан Ибраһимовның псевдонимы дигән караш фәндә ныклы урын алган. Ләкин «Габди» имзасы Г. Ибраһимов темасына, стиленә бөтенләй туры килми торган вак, әһәмиятсез мәкаләләр астында да очрый. Татар дөньясын тутырган Габдулла, Габдрахманнарның берсе үзенең мәкаләсенә шулай имза куя икән, бу бер дә гаҗәпләнерлек эш түгел. Шуңа күрә псевдонимнарның чын ияләрен ачканда, зур саклык таләп ителә. Мәсәлән, «Вакыт» газетасында «Габди» псевдонимы белән берничә мәкалә басылган. Болар Г. Ибраһимовныкымы? Башка кешенекеме? Шул мәкаләләрнең берсендә Габдинең Ишми ишан доносы буенча төрмәгә эләккән кешеләрдән интервью алганлыгы әйтелә[1]. Г. Ибраһимов биографиясендә бу хәл булганмы, чагылыш тапканмы? Әгәр бу кеше Г. Ибраһимов түгел икән, «Габди» псевдонимы белән тагын кемнәр язган?

[1] «Вакыт» газетасы. 1911. № 872.

Күрәсең, псевдонимнарны ачканда, хәтергә таянып кына эш итеп булмый. Аларны ачу – иҗади эш. Һәм, әлбәттә, һәрбер псевдонимны ачу тарихи фактларга нигезләнгән булырга тиеш. Бу мәкаләдә XX йөз башы татар әдәбиятында һәм публицистикасында очраган кайбер псевдонимнарны ачу ысуллары турында сүз барачак. Псевдонимнарны ачканда, еш кына гарәп алфавитындагы хәреф исемнәре белән очрашырга туры килә. Мәсәлән, бер әдәбиятчы үзенең мәкаләләренең ахырына «Гайннун» дип имза куя. Нәрсә дигән сүз бу? «Гайнуллинмы?» Алфавитны хәтерлик: «Гайн» гарәп алфавитында («гади» дигәндәге) «г» хәрефенең «нун» исә «н» хәрефенең әйтелеше. Димәк, автор бу очракта үзенең инициалларын гына куйган: «Г. Н.» Ә «Г. Н.» үзе кем? Бу кадәресен ачу инде икенче мәсьәлә. «Җим Әлиф» дигән псевдоним белән дә шул ук хәл. Моның нигезендә «Җ. А.» дигән инициал алынган. Димәк, болар икеләтә авырлаштырып яшеренгән фамилияләр булалар.

Ләкин псевдонимнарның бик нык катлауландырганнары очрый. «Йолдыз» газетасында, мәсәлән, «Йыгъбд» яки «Ягъбд» дигән псевдоним еш күренә. Моны ничек укырга? Ихтимал, монда инде кабул ителгән, укучылар массасы өчен ачылган псевдонимны тагы да ныграк яшергәннәрдер? «Габди»нең бер варианты түгелме бу? Әллә «Гыйбди»нең катлаулы бер формасымы? Гарәп шрифты белән язганда, «Габди, Гыйбди» сүзләрендә бер үк тартыклар кулланыла.

Псевдоним шулай шиккә калдырган очракларда стиль һәм тема ягыннан ачу мөмкинлеге кала. Мәсәлән, мәктәп-мәдрәсә темасына язган кайбер мәкаләләрнең яки бик гади информациянең астына «Габди» дип имза куелган. Сорау туа: Г. Ибраһимов мәктәп-мәдрәсә мәсьәләләрен күтәргәнме? Күтәргән. Бу органда Г. Ибраһимов мәкаләләр бастырганмы? Бастырган. Димәк, тема, псевдоним, файдаланган матбугат органы барысы да Г. Ибраһимовка туры киләләр. Ләкин тикшеренүче филолог шикләнә. Чөнки тема бер булса да, мәкаләнең стиле шикләндерә. Филолог өчен мәгълүм: Г. Ибраһимовның тыныч кан белән, салмак стильдә язган мәкаләсен очратуы кыен. Публицистикасында һәм тәнкыйть мәкаләләрендә ул гаҗәп югары, чакыручан, һөҗүмчән стильдә яза, үзе дөреслегенә инанган

фикерне ул логика көче белән, куәтле сүзләр белән укучыга җиткерә, «Һәр милләтнең һәр эше – мөхәррире, шагыйре, мөдәррисе, мәдрәсәсе, мәктәбе – бары да әхваль мәдәнияте илә мөтәнасиб була. Без башка һәрнәрсәне инкяр итә алырбыз, “Хөсәения”гә башка булган һәрбер мәдрәсәнең берничә фидаи затларның тырышлыгы белән генә барганлыгын инкяр итү сукырлык булыр.

Кайда дәүләтебез? Кайда хәзинәбез? Кайда вәкыфларымыз? Кайда мәдрәсәләрнең матди ягын тәэмин итә торган җәмгыятемез?»[1]. Менә бу – Г. Ибраһимов стиле һәм мәкаләнең ахырына таба эчтәлекнең эмоциональ куәте арта бару – Г. Ибраһимов мәкаләләрендәге төп сыйфат. Псевдонимнарны ачканда, мондый үзенчәлек белән исәпләшү, әлбәттә, ярдәм итә. Кайбер очракларда аерым мәкаләләрдә кулланылган лексик фонд та авторның кемлегенә ишарә ясый. «Хәзер шундый заман килде ки, дөньядагы бөтен милләтләр, хәтта бер-берсенә дошман булган кавемнәр, бәйле бер-берсен танырга, бер-берсенә дуслашырга тырышалар. Мисал: немецлар илә инглизләр һәр ел берничәшәр балаларын алмаштырып торалар (укыталар. – *М. М.*)»[2] Бу – Ф. Кәрими мәкаләсе, салмак, үгет-нәсыйхәтле, вәгазьле тон. Хәзер шул ук елларда язылган башка мәкаләләрне алып карыйк: «Европаның мәдәният кадиме мәркәзе булган Юнанда һәм Румда...» Яки: «Ләкин дөньяда иң аз дәвам иткән нәрсә сәгадәт диләр. Шагыйрь алдында ачылган шул киң, якты күкне карап туя да алмады – анда куе кара болыт чыгып, күк күкрәде, яшен яшьнәде, күз ачып йомганчы, шагыйрь үзен арестант киемендә Петербург юлында күрде». Менә болар – образлы, тирән мәгънәле, көчле эмоцияле куәтле сүзләр – шулай ук Г. Ибраһимовныкы.

Аерым бер газета яки журналдагы кайбер псевдонимнарны башка чыганаклардан эзләп ачарга мөмкин. Мәсәлән, «Йолдыз»да «Хәерби» псевдонимы белән басылган мәкаләләр, фельетоннар бик күп. «Йолдыз» моны үзе ачмый. Бәлки, «Хәерби»не башка газеталар телгә аладыр? «Кояшны» актарабыз. «Йолдыз» мөхәррире Хәерби әфәндене кем генә белми торгандыр инде»[3], – дип яза Ф. Әмирхан

[1] «Йолдыз» газетасы. 1913. № 967.
[2] «Вакыт» газетасы. 1913. № 1230.
[3] «Кояш» газетасы. 1914. № 380.

үзенең бер фельетонында. «Йолдыз»ның мөхәррире Һади Максуди икәнлеге ул чордагы газета укучыларга мәгълүм. Псевдоним, димәк, бу юлы башка матбугат органы аркылы, башка чыганактан алынды.

Псевдонимнарны башка чыганаклар буенча тикшереп карау кайвакытта бөтенләй көтелмәгән нәтиҗәләр бирә. «Сәгъды Ваккас» С. Сүнчәләй псевдонимы дигәнгә без инде ияләнеп беткәнбез. Моңа шикләнерлек урын да юк кебек. 1919 елда шагыйрьнең бер җыентыгы Ваккас Сүнчәләй исеме белән чыга. Аннан соң С. Сүнчәләйнең Пермь губернасы, Уса өязендә укытучы булып эшләгәнлеге мәгълүм. «Йолдыз»ның бер санында «Пермь губернасында инородецлар» дигән мәкалә бар[1]. Имзасы – Сәгъды Ваккас. Шулай итеп, бу псевдоним С. Сүнчәләйнеке булган дип уйларга тулы нигезебез бар. Ләкин «Мусульманская газета»да татар әдәбиятына багышланган бер мәкаләгә күз салыйк. Авторы – Ваккас. Анда татар әдәбиятының шул чорына күзәтү ясала. Автор Тукайдан соң күренекле шагыйрьләр калмавына ачынып яза. Бу кадәресен әле С. Сүнчәләй дә язарга мөмкин. Ләкин алга таба автор (С. Сүнчәләй иҗатына туктала һәм, шагыйрь буларак аның турында әлегә фикер әйтергә иртә, дигән нәтиҗә чыгара[2]. Үз шәхесең турында чит исем астында язу әдәбият дөньясы өчен сәеррәк хәл бит. Димәк, «Ваккас» – башка кешенең псевдонимы. Менә тагын бер мисал. «Йолдыз»ның 1911 елгы бер санында мондый белдерү укыйбыз: «Ошбуның 4 нче рамазан шәрифтә, 15 августта әткәмез... дарелфәнадан дарелбәкага рихләт әйләде». Имзасы – Сәгъды Ваккас Әүхәди угылы. Чар өязе, Яңа Шашы авылыннан.

Хәлбуки С. Сүнчәләйнең Чар өязе, Яңа Шашы авылына бернинди мөнәсәбәте юк. Ул анда тумаган, анда яшәмәгән. Тукайның «Сәгъды Ваккас әфәндегә» исемле мәкаләсе С. Сүнчәләйгә адресланган дигән фикер дә шикле. Мәгълүм булганча, Г. Тукай белән С. Сүнчәләй арасындагы дуслык 1911 елның көзендә башлана. Бу турыда С. Сүнчәләй үзе әйтә[3]. Тукай аңа уникеләп хат җибәргән. Арадан берсендә Тукай аңа болай дип яза: «Сине мин һәр тугърыда

[1] «Йолдыз» газетасы. 1911. № 742.
[2] «Мусульманская газета». 1914. № 89.
[3] Тукай турында замандашлары. Казан, 1960. Б. 128.

садәдил кеше таптым»[1] (1911 ел, 15 ноябрь). С. Сүнчәләйнең истәлекләренә кайтыйк: «Ул көзне мин (1911 елның көзе. – *М. М.*) Казанда күп тора алмадым. Әмма Тукайның фәкыйрь генә, күңелле генә бүлмәсендә үткәргән күңелле, рәхәт, сабыр сәгатьләрне, кичләрне, төннәрне гомеремә онытмам. Чөнки Тукай белән без әллә ничек килешә идек. Күп кеше белән таныша алмаган Тукай белән без иптәш идек. Күп вакытларны икәү генә үткәрә идек»[2]. «Сәгъды Ваккас әфәндегә» исемле фельетонында, мәгълүм булганча, Тукай әлеге авторны шактый кыен хәлгә куя, аның «такылдамак белән мәүзүн сүз сөйләмәк»не аера алмавыннан көлә. «Сәгъды Ваккас әфәндегә» исемле фельетонга исә 1911 ел, 18 ноябрь датасы куелган. Ягъни ике шагыйрь арасындагы дуслыкның – эч сереңне чишеп сөйләшүләр, самими-җылы хат язышулар, төннәр буе утырып сөйләшүләр белән бер вакытта бу.

Шулай итеп, «Сәгъды Ваккас»ның С. Сүнчәләй генә икәнлегенә шик туа. Бу псевдоним белән XX йөз башы татар матбугатында берничә кеше язган булырга тиеш.

Архив материаллары нигезендә дә псевдонимнарны ачарга мөмкин. Яшерен күзәтү астында булган язучыларның псевдонимнары, мәсәлән, жандармерия документларында чагылыш тапкан. Кайбер язучыларның шәхси архивларында сакланган кульязмалар да (псевдоним белән басылган әсәрнең төп нөсхәсе) псевдоним ачарга ярдәм итәләр. Мәсәлән, унынчы елларда «Вакыт»та, «Шура»да күп кенә әдәби парчалар, шигырьләр «Рухи» псевдонимы белән басылганнар. Кем ул «Рухи»? Безгә Ленинградтагы М.Е. Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәдә Г. Сәгъдинең тюрколог А.Н. Самойловичка җибәргән бер кульязмасы очрады. Г. Сәгъди анда үзенең «Вакыт» һәм «Шура»дагы лирик әсәрләрен «Рухи» псевдонимы белән бастырганын күрсәтә.

Кайбер очракларда газета-журнал битләрендәге бәхәс, полемика аркылы да псевдонимнар ачыла. Мәсәлән, псевдоним белән басылган бер әсәр турында матбугатта тискәре бәя яки фельетон күренә. Автор исә моңа җавап бирергә мәҗбүр була. Җавабында инде ул

---

[1] *Тукай Г.* Сайланма әсәрләр. 4 т. Б. 217.
[2] Тукай турында замандашлары. Б. 129.

псевдоним түгел, ә чын исем-фамилиясен куя. Чөнки автор, үзенең абруен сакларга кирәк булганда инде, оппонентына чын исем-фамилиясен куеп җавап бирүне отышлы саный.

Ләкин газета-журналлар үз авторларының псевдонимнарын бик сирәк ачкан. Баштарак кайбер «саксызлыклар» очраса да (мәсәлән, «Йолдыз» газетасы, 1906 елгы 70 нче санында бер авторны ача, газетаның язышучыларын «Җим-нун»ның Җарулла Насиб икәнлеген әйтә), ахырга таба авторларын сак астына ала. «Йолдыз» үзенең меңенче санын бәйрәм иткәндә әсәрләре, мәкаләләре, хатлары басылган авторларның исемлеген бирә. Ләкин исемлектә Г. Ибраһимов аерым, Габди аерым, Һ. Максуди белән Хәерби дә аерым биреләләр... Бу – авторларның хокукын саклауга бер мисал. «Йолдыз»ның 1911 ел, 706 нчы санында М. Укмасыйның «Интикад» исемле мәкаләсе басылган. Анда болай диелгән: «...татар дөньясында тәнкыйтьчеләремез сирәк-мирәк кенә ялтырый башладылар... «Имгәк» имзалы Галиәсгар Камал җәнаплары...». Редакция исә мәкаләнең ахырына болай дип өсти: «Имгәк» Г. Камал имзасы түгел». Ләкин псевдонимның кемнеке булуын ачмый.

«Йолдыз»да «Тимербай» псевдонимы белән «Сәйранга чыгу» исемендә бер фельетон басылган. Анда «Фәтхулла хәзрәт» повесте тәнкыйть ителә һәм Ташмөхәммәтнең «Яңа бистәдә, Малый Симбирский урамда яшәүче автор икәнлеге әйтелә[1], Ташмөхәммәт исә, «Йолдыз» идарәсенә хат язып, псевдонимга расшифровка ясауга протест белдерә: «Псевдонимнарга ияләрен танытырлык тәгърифләр гыйлавә итү матбугат әдәбеннән хариҗ; Тимербай әфәнде булса, Ташмөхәммәтнең адресын да укучыларга гарыз итә»[2].

Псевдонимнарны ачуда мемуар әдәбиятыннан файдалы мәгълүмат алып була. М. Гали үзенең бер истәлегендә татар әдәбиятына кагылышлы ике псевдонимны ача. Редакциягә килеп кергәч, аны Г. Камал болай дип каршы алган:

---

[1] «Йолдыз» газетасы. 1910. № 516.

[2] «Йолдыз» газетасы. 1910. № 518. Сүзлек: тәгъриф – белдерү; гыйлавә – өстәмә; хариҗ – тыш, тышкы; гарыз итү – алга китереп кую.

«– Мәшһүр Әүхәди шушымыни инде ул? Кил, алай булса, танышыйк үзең белән, мин үзем дә мәшһүр «Ишан Гали» булам, – дип көлеп, кулын бирде...»[1].

Язучының псевдоним алуы нәрсәгә нигезләнгән? Моның татар әдәбияты һәм публицистикасы өчен характерлы үзенчәлекләре бармы? Хәзер шул сорауга җавап биреп карыйк.

Җитди матбугат органнарында баштарак псевдоним сирәк күренә. Кем нәрсә язса, үз исемен куеп бастыра. Ләкин тора-бара матбугат органнары авторларга карата талымчанлык күрсәтә башлыйлар. Газета-журналларның соңгы полосаларында җаваплар бүлеге ачыла. Анда «язган нәрсәгез басылырлык түгел», яки «шигырь язуыгызны ташлагыз» дип тә җавап урнаштыралар. Редакцияләр белән корреспондентлар арасында полемика башлана. Язучы-хәбәрчеләр челтәре киңәйгән саен, редакциягә яраксыз материал да күбрәк килә. Конкурентлар арасында югалып калмас өчен стабильләшкән газета-журналлар үз тирәләренә әдипләрне тартырга тырышалар. Шулай итеп, һәр газета-журнал тирәсендә ныклап эшли, көндәлек-айлык санны әзерләп бара торган 7–8 язучы туплана. «Вакыт»та – Ш. Камал, Б. Шәрәф, Җ. Вәлиди, Ф. Кәрими; «Йолдыз»да – Г. Камал, К. Бәкер, Г. Ибраһимов, Г. Тукай, Ф. С.-Казанлы, С. Рахманколый, Г. Кәрәм; «Идел»дә – С. Рәмиев, С. Сүнчәләй; «Шура»да – Р. Фәхретдинов, Ф. Кәрими, Г. Ибраһимов, З. Бәшири; «Кояш»та – Ф. Әмирхан... Болар бик күп һәм бик еш язалар. Кайвакытта атналар буена төрле темага һәр көн саен мәкалә биреп баралар. Бер үк исем белән укучыларны ялыктырмас өчен, бу сәләтле журналистлар һәм язучылар үзләренең әсәрләренә псевдонимнар тагалар. Ләкин кайвакытта көн саен бер мәкалә биреп бару гына да редакцияне кытлыктан коткара алмый. Язучы-журналист газета-журналның бер үк санында икешәр мәкалә бастыра башлый. Нәтиҗәдә автор үзенә берничә псевдоним алырга мәҗбүр була. Кыска гына әдиплек һәм журналистлык гомерендә гаҗәп күп шигырь, мәкалә, фельетон язган Тукайда псевдонимнар күп булуның сәбәбе әнә шул; Октябрь революциясеннән соң «Татарстан хәбәрләре» һәм башка матбугат органнарында көненә икешәр-өчәр мәкалә бастыр-

[1] *Гали М.* Сайланма әсәрләр. Казан, 1964. Б. 314.

ган язучы-журналист Ф. Бурнашта псевдонимнар күп булуның сәбәбе шуның белән аңлатыла. Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ф. Кәрими һ.б. бик күп әдипләрнең берничә псевдоним кулланулары – күп язу, матбугатта көн саен диярлек катнашып баруларыннан туган хәл.

Псевдонимнарның зур күпчелеге юмористик-сатирик әдәбиятка хас. Г. Тукайның җитди әсәрләренә, нигездә, имза ачык куелган. Бу хәл инде жанр үзенчәлегеннән килеп чыга. Ни өчен халыкны Шүрәле булып кытыкламаска, ни өчен берәр кадимчегә «Гөмберт» итеп китереп сукмаска?

Әдәбият дөньясында язылмаган бер закон, ниндидер бер сәер күренеш бар: язучы, тәнкыйтьче, драматургларның күп өлеше башта әдәбиятта шигырь белән күренәләр. Ш. Камал, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди шигырь язганнар. Озак та үтми, болар үзләренең төп юлларын табалар һәм шигырь язудан баш тарталар. Ләкин барысы да түгел. Мәсәлән, Г. Сәгъди әдәбият теориясе буенча гыйльми хезмәтләр яза. Бер яктан, ул башка шагыйрьләрнең әсәрләренә анализ ясаган, тәнкыйтьләгән, икенче яктан, «Шура»да үзе бик еш кына уртакул шигырьләр бастырган. Әдәбият теориясе белән шөгыльләнгән (димәк, башкаларны өйрәткән) галим үзенең уртакул шигырьләренә «Г. Сәгъди» дип имза куярга җөрьәт итмәгән һәм «Рухи», «Зәүкый», «Фикри» кебек псевдонимнар алып, галим Габдрахман Сәгъдинең абруен саклаган.

Патша хөкүмәтен тәнкыйть иткән, ачыктан-ачык социаль мәсьәләләр күтәргән әсәрләрне реакция һәм яңа революцион күтәрелеш елларында либераль матбугатта псевдоним белән бастырганнар. Бу хәл цензураның, администрациянең эзәрлекләвеннән качарга омтылу белән аңлатыла. XX йөз башы татар әдипләреннән яңа революцион күтәрелеш елларында Г. Ибраһимов, М. Гафури, Г. Коләхмәтов, Г. Камал, Г. Газиз, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, С. Сүнчәләй, Ф. Кәрими һ.б. жандармерия күзәтүе астында булганнар. Псевдонимнарны актив кулланучылар да шулар. Псевдоним куллану газета-журнал полосасын цензор укыганда цензорны әсәртмәс өчен кирәк булган. Чөнки цензура эчтәлеккә караганчы башта авторның шәхесенә игътибар иткән. Ышанычсызлар исемлегендә түгелме? Ә патша чиновниклары өчен һәр язучының, журналистның матбугат битләрендә күтәрә торган тематикасы якынча мәгълүм.

Шуңа күрә авторына карап, цензураның игътибар дәрәҗәсе дә төрлечә булган.

Цензурадан узарга тырышу, аның игътибарын автордан читкә юнәлдерергә омтылуның рус публицистикасында бай тарихы бар. Рус телендә чыккан «Современник», «Отечественные записки», «Дело» журналлары һәм Герценның «Колокол»ы псевдонимны матбугатның әһәмиятле элементына әвереллдерәләр[1]. Маркс, Энгельс, Ленинның псевдонимнардан киң файдалануы революцияләр тарихына барып тоташа. В. И. Ленинның йөздән артык псевдонимы булган. Бары тик Октябрь революциясеннән соң гына ул үзенең чын фамилиясен куя башлаган, ләкин җәяләр эчендә төп псевдонимын саклаган: В.И. Ульянов (Ленин)[2].

Псевдонимнар алуның татар әдәбиятында үзенчәлеге дә бар. Мондый үзенчәлек бигрәк тә мөлкәтле катлаудан чыккан авторларда күзгә ташлана. Аларның мохите өчен язучылык эше дәрәҗәле эш түгел. Г. Камалның этисе, мәсәлән, улының язучы булып китүенә риза булмаган. Ф. Әмирхан болай дип искә ала: «Фәтхулла хәзрәтнең үлгәч терелүе» дигән кыйсса яза башладым. Әти, Йосыф хәзрәтне тәхкыйрь итәсең дип, башыма кыяматләр кубара»[3]. Г. Газизнең атасы – Казанның атаклы купецы Салих Гобәйдуллин. Аның белән шәһәр управасы да, губернатор да исәпләшә. Халык арасында да исеме зур. Ләкин аның улы, башка бай балалары кебек, кибет, контора, банк эше белән түгел, бәлки дәрәҗәсез булган «язу-сызу» эше белән шөгыльләнә. Казанның зур сәүдәгәре Мөхәммәтшакир Габдрәхимовның улы да, әтисе теләгенә каршы килеп, кибет-сәүдә эшенә кул селти һәм язучылык эшенә керешә. Әнә шулай итеп, мөлкәтле катлаудан чыккан каләм әһелләре псевдоним куллануга барганнар.

Татар демократ язучылары, журналистлары арасында дин хезмәтчеләре семьясыннан чыгып ислам динен, шәригатьне тәнкыйть итә башлаучылар бар. Ата-анасын рәнҗетмәү, туган-тумача арасында аларны кыен хәлгә калдырмау максаты белән алар, үз исемнәрен

[1] *Масанов Н.Ф.* Словарь псевдонимов русских писателей, ученых и общественных деятелей; в 4 т. Т. I. М.: Изд-во Всесоюз. кн. палаты, 1956. С. 6.

[2] *Дмитриев В.Г.* Скрывшие свое имя. М.: Наука, 1970. С. 45.

[3] *Әмирхан Ф.* Сайланма әсәрләр. I т. Казан, 1957. Б. 11.

яшереп, кадими мәдрәсәләрдән, корсак колы булган муллалардан, халык җилкәсендәге ишаннардан, дини журналлардан ачы рәвештә көлгәннәр. Ф. Әмирханның «Дин вә мәгыйшәтчеләр», ишмиләрдән көлеп язган фельетоннары «Ташмөхәммәт», «Зәмзәметдинов» псевдонимы белән басылганнар. Ләкин шул ук чорда педагогика, әдәбият мәсьәләләренә багышлап язган мәкаләләренә ул «Ф. Әмирхан» дип имза куеп барган. Моның да традициясе әдәбиятта бик тирәннән: католикларны фаш иткән памфлетларын Д. Дефо, Вольтер һ. б. аноним рәвештә бастырып килгәннәр. Шуннан Г. Газиз, Г. Сәлман (Газиз Гобәйдуллин), Ташмөхәммәт, Зәмзәметдинов, Дамелла (Фатих Әмирхан), Бикчәнтәй угылы (Гали Рәхим) кебек псевдонимнар туган...

Язучы яки публицистның күтәргән темасы белән аның социаль хәле арасында аерма зур булганда да, псевдоним кулланыла. Моның мисалы – Дәрдемәнд. Бу исем шагыйрь характерының төп сыйфатын күрсәтә, фарсыча «кайгылы, бичара, гаҗиз» дигән сүз. Псевдономастикада мондый исемне френоним дип атыйлар (русларда Горький, Скорбный һ. б.).

Ни өчен әдәбиятта Закир Рәмиев исеме түгел, ә Дәрдемәнд исеме йөри? «Дәрдемәнд» сүзе бит фактта шагыйрьнең үз фамилиясен бөтенләйгә кысрыклаган һәм әдәби фамилиягә әйләнгән. Моңа җавапны шагыйрьнең социаль хәленнән чыгып эзләргә кирәк. З. Рәмиев – татарлар арасында танылган бай. Хәзер шушы байның татар матбугатында чыккан беренче шигыренә игътибар итик:

Кара туфрак тулы мазлум нидасы.
Алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы?..[1]

Ягъни үзенең файтоннары, конторалары, миллионнары булган бай җир йөзен болай күрә: анда җәберләнгән, кыерсытылганнарның күз яше, җәберләүчеләрнең корбаннары... Бу шигырьгә ничек инде Закир Рәмиев дип кул куясың? Шагыйрь монда хәтта Дәрдемәнд дип тә түгел, ә «Д» хәрефе белән генә имза куйган. Ләкин «Вакыт»та басылган аз сандагы рәсми мәкаләләренә ул «З. Рәмиев» дип кул куйган. (Мәсәлән, 1906, № 24; 1917, № 2286.)

[1] «Казан мөхбире». 1906. № 33. Сүзлек: нида – тавыш; фида – корбан.

Әдәбиятка аяк баскан, сәнгать дөньясына зур дәрт белән омтылган яшь язучыны, шагыйрьне үзенең иң гади исем-фамилиясе канәгатьләндерми башлый. Нииндидер күркәм, кешедә булмаган, поэтик яңгырашлы исем аласы килә. Мәсәлән, Тукай «Габдулла Мөхәммәтгариф улы» яки, һичьюгында, «Габдулла Гарипов» булырга тиеш иде. Ләкин ул үзенең иң беренче публикациясенә үк «Габдулла Тукаев» дип имза куя. Тукайның нәсел-нәсәбеннән дә, замандашларыннан да бу псевдонимның каян килгәнен әйтеп калдыручы булмаган. Тукайның ерак нәселендә дә андый кешенең барлыгы искә алынмый. Каян килгән бу? Габдулла Гарипов аны очраклы рәвештә алмагандыр бит? «Тукай» сүзенең мәгънәсен, бәлки, гарәп-фарсы сүзләреннән чыгып эзләргә кирәктер? Гарәп-фарсы телләренең белгечләре моны ачыкларга, бәлки, ярдәм итәрләр?

Кыскасы, көнкүрештә ияләнелгән, таушалган фамилиядән качарга тырышу псевдонимнар туугa шулай ук бер сәбәп булган.

Псевдонимнар алуда берәр закончалык бармы, аларның эчтәлеге язучының шәхесенә мөнәсәбәтлеме? Безнең уебызча, бу принципиаль мәсьәлә түгел. Чөнки язучының иҗат манерасы, шәхесенә бернинди мөнәсәбәттә булмаган псевдонимнар шактый гына. Әйтик, тәнкыйтьче Г. Кәрәм кайвакытта «Әкмәли» дип кул куйгалаган икән, авторның иҗат юнәлешенә моның бернинди бәйләнеше юк. Ләкин инде Тукай үзенең сатирик әсәрләренә «Шүрәле», «Бичура» дип кул куйган икән, моның, әлбәттә, эчке мәгънәсе бар. Ул – шагыйрьне әдәбиятка алып килгән инешләрнең башлангычына ишарә. Ягъни ул халыкча көлә, халыкча чеметә, автор – халыктан. Г. Сәгъди дә «Зәүкый», «Фикри», «Рухи» кебек исемнәр белән үзенең эчке дөньясын, әдәбиятка мөнәсәбәтен белдерергә омтылган. С. Рәмиев үзенә «Себектәгин» псевдонимын алган икән, бу да очраклы булмаса кирәк. Себектәгин – төрки ханнарының берсе, Һиндстанда, Әфганстанда яу башлыгы булып дөнья шаулаткан кеше. Татарның тыныч вәзенле, салмак эчтәлекле поэзиясенә шаулап җил-давыл булып килеп кергән С. Рәмиев бәлки, әдәбиятта үзен яу башлыгыдай хис иткәндер? Ф. Кәрими дә гомере буе «Вакыт»ка баш мәкаләләр яза-яза талгач, «Карт эшче» яки «Каләм» дигән псевдоним алырга үзен хаклы санагандыр?

Кыскасы, псевдонимнарның мәгънәсе, принципиаль әһәмияткә ия булмаса да, кайбер язучының шәхесен, әдәбиятка мөнәсәбәтен азмы-күпме билгели ала.

Югарыда күренгәнчә, псевдонимнар татар әдәбиятында шактый зур кулланыш тапканнар. Октябрь революциясеннән соң псевдоним куллануның практик хаҗәте калмаса да, татар әдипләре арасында псевдоним сәхнәдән төшмәгән. Шуңа күрә псевдонимнарны махсус өйрәнү һәм алар буенча бер белешмәлек төзү киләчәкнең бурычы булып кала. Татар әдәбиятында гына түгел, рус газеталарында татар әдәбияты турында язып чыккан авторларның да (мәсәлән, «Камско-Волжская речь»тә «Мусульманка», «День» газетасында Тукай турында «Татарский Пушкин» дигән мәкалә урнаштырган Н. Поволжанин һ. б.) псевдонимнарын ачарга кирәк. Ә моның өчен укырга, шул чорның газета-журналларын өйрәнергә, бик күп белешмәләрне актарырга кирәк.

Псевдонимнарны гыйльми дәрәҗәгә куеп өйрәнмәү, әдәби мирасны бастырып чыгарганда, адашуларга юл куя. Язучыга чама белән псевдонимябыштыру, имзасыз әсәрне фәлән-фәлән язучыга дәлилсез генә тагып кую әдәбият тарихын бутый. Әйтик, Тукай «Ялт-Йолт»та эшләгән икән, бу әле журналдагы барлык имзасыз әсәрләрне Тукай язган дип уйларга хокук бирми. Әдәби мирасны дөньяга чыгаручылар исә күренекле язучылар, журналистлар эшләгән матбугат органнарындагы имзасыз әсәрләрне бернинди дәлилсез бу язучыларның әсәрләре дип укучыга тәкъдим иткәлиләр.

Марксизм-ленинизм классикларын бастырып чыгарганда, мәсәлән, алай итмиләр. КПСС ҮК каршындагы марксизм-ленинизм институты, В. И. Ленин әсәрләрен чыгарганда, киләчәк эзләнүләр һәм тикшеренүләр өчен юл калдырып, Ленин тарафыннан язылу ихтималы булган әсәрләрне аерым күрсәтеп бирә. Шунда ук редакцияләвендә Ленин катнашкан әсәрләрнең исемлеге бирелә. Бу ысулны әдәбият тарихында да куллану файдалы булыр иде. Проф. Х. Госман, мәсәлән, Г. Кандалый җыентыгын нәкъ әнә шул принциптан чыгып төзегән иде. Кандалый шигырьләренең бик нык халыклашкан һәм шагыйрьнең үзенең дә халыктан бик күп алганлыгын истә тотып, Х. Госман бу китапта үзе авторын аныклый алмаган шигырьләрне «Г. Кандалыйныкы булуы ихтимал әсәрләр» дигән бүлеккә туплап

бирде[1]. Моны, бәлки, Тукайга, Ф, Әмирханга, Ш. Мөхәммәдевка һ. б. әдипләрнең мирасына карата да куллану кирәк булыр?

Әдәбият тарихын тикшергәндә, безгә рус совет галимнәреннән өйрәнү житеп бетми кебек. Алар әле дә булса Пушкин, Лермонтовларның әсәрләренә, биографияләренә кагылышлы документлар табалар, аларны өйрәнәләр, бәхәсләшәләр. Аерым әдипләрнең мирасын бастырганда җибәрелгән бер хәреф хатасын төзәтү мәсьәләсенә зур гына галимнәрнең катнашып полемика алып барган очраклары бар. С. Есенинның бер поэмасында нибары бер хәрефне ялгыштыру да полемикага сәбәп булды һәм Есенин текстының дөрес укылуына ирешелде[2]. Безнең әдәби мирасыбызны өйрәнгәндә дә, шундый таләпләр куелса әйбәт булыр иде. Чөнки XX йөз башы татар әдәбияты – безнең әдәбият тарихыбызның иң катлаулы чоры. Бу чорның демократ карашлы язучылары күп төрле матбугат органнарында авыр шартларда, бер яктан, самодержавиегә, икенче яктан, татар милләтчеләренә, татар буржуаларына каршы көрәш алып барганнар.

Псевдономастиканы әдәбият тарихын өйрәнүнең әһәмиятле тармагы итеп танырга вакыт җитте.

XX йөз башы татар демократик язучыларының барлык әсәрләренә тулы библиография, шул чор әдәбияты һәм публицистикасында очраган барлык псевдонимнарның сүзлеген төзү әдәбият тарихын теоретик яктан өйрәнүнең материаль базасын тәшкил итәр иде.

*«Казан утлары». 1973. № 12. Б. 173–182.*

[1] *Кандалый Г.* Шигырьләр / төзүчеләре: Хатип Госман һәм Җәвад Алмаз; редакторы А. Гомәров. [Казан]: Татар. кит. нәшр., 1960. Б. 171–180.

[2] «Литературная Россия» газетасы. 1971. № 2.

**Мөнир Абдуллин**

# ПСЕВДОНИМ КУШАМАТ ТҮГЕЛ

Псевдоним – грек сүзе. Сүзлекләрдә аның уйлап чыгарылган исем, фамилия булуы, чын исем, фамилияне яшерү өчен, сәясәтчеләр, язучылар, артистлар тарафыннан кулланылуы әйтелә. В. Дмитриевның 1970 елда Мәскәүдә чыккан «Скрывшие свое имя» дигән китабында аңа мондый билгеләмә бирелгән: псевдоним – уйлап чыгарылган яки үзгәртелгән исем һәм фамилияләрне алыштырган имзаларның гомуми аталышы.

Псевдоним күптән, әле китап бастыру уйлап чыгарылганчы ук барлыкка килгән. Кешеләр цензура эзәрлекләвеннән куркып, яисә яшерен исем белән үзләренең әсәрләрен бастырырга омтылып, йә уңышсызлыкка очрармын да гаеп ташларлар, дип уйлап һәм башка сәбәпләр белән псевдоним алганнар. Ә менә теге яки бу язучы, артист, галим, сәясәтче ни өчен нәкъ менә шундый псевдоним алган, башкасын түгел? Бу сорауга һәрвакытта да дөрес җавап табу кыен. Чөнки ул кешенең характеры, туган ягы, яшәгән урыны, нәселнәсәбе белән бәйле булырга мөмкин.

Псевдонимнар куллану XVII гасырда аеруча киң тарала. Яңарыш дәверендә фән һәм мәдәният өлкәсендә халыкара тел булып латин теле санала. Шуңа күрә псевдонимнар турында беренче сүзлекләр дә латин телендә язучы авторларга багышлана. Шундый беренче сүзлек 1652 елда нәшер ителә. Аның авторы – И. Суарес. Китап «О подписях и знаках, под коими скрыты истинные имена» дип атала. 1669 елда Лейпцигта немец телендә Ф. Гейслерның «Үзгәртелгән исемнәр һәм аноним язучылар турында» дигән хезмәте дөнья күрә. 1806–1809 елларда француз телендә Наполеон Беренченең китапханәчесе Антуан Барбье үзенең исемен яшергән авторларның әсәрләреннән дүрт томлык сүзлек бастырып чыгара. Кеннидиның инглиз телендә нәшер ителгән 7 томлык сүзлегендә 60 меңгә якын псевдоним тупланган.

Мондый сүзлекләр һәр илдә диярлек бар. Хәтта кечкенә генә Даниядә дә псевдонимнар турында сүзлек төзеп чыгарганнар.

Рус телендә исә шундый хезмәт 1874 елда басылып чыга. Ул «Рус телендә чыккан аноним китаплар, аларның авторлары исемнәре һәм тәрҗемәчеләре исемлеге» дип атала. 1865–1889 елларда псевдоним белән чыккан әсәрләрнең авторлары турында Н. Голицинның библиографик сүзлеге нәшер ителә. 1891 елда «Рус язучылары псевдонимнары сүзлеге тәҗрибәсе» дөнья күрә. Шуннан соңгы чорда танылган библиограф И. Масанов аеруча актив эшли. Ул 80 меңнән артык псевдоним җыя. Әмма революциягә кадәр аны китап итеп чыгарырга рөхсәт бирмиләр. Ләкин аңа карап И. Масанов эшен туктатмый. Күп еллардан соң ул теләгенә ирешә. 1936 елда китабының беренче томы чыга. Вафатыннан соң аның эшен улы Ю. Масанов дәвам иттерә.

Татар телендә псевдонимнар турында аерым бер китап булып чыккан хезмәтләр юк. Ләкин безнең татар язучылары, артистлары арасында исем, фамилияләрен яшереп, яисә үзгәртеп үзенең әсәрләрен бастырган һәм бастыручы әдипләребез, олы сәхнәләрдә уйнаган, җырлаган һәм җырлаучы артистларыбыз аз түгел. Әмма псевдонимнар белән кызыксынучылар булган. Мәсәлән, язучы һәм журналист Мәхмүт Бөдәйли, аларны җыеп, сүзлек төзегән. Бу хакта «Казан утлары» журналының 1969 ел, 1 нче санында хәбәр ителә. М. Бөдәйли җыйган псевдонимнарның бер өлеше кереш сүз белән бирелгән.

1956 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә болай диелә: «Псевдоним – кайбер язучыларның үз әсәрләрен матбугатта чыгарганда куйган кушаматлары». Моңа ачыклык кертү кирәктер. Беренчедән, псевдоним алу язучыларга гына хас нәрсә түгел, аннан артистлар да, сәясәтчеләр, галимнәр дә, рәссамнар да файдалана. Икенчедән, псевдоним кушамат түгел. Кушаматның үз мәгънәсе, үз урыны бар. Аның кайберләре кешенең килеш-килбәтенә, холык-фигыленә, тышкы кыяфәтенә карап бирелә. Мәсәлән, борынгы Рим шагыйре Клавдийны Сукыр Клавдий дип йөрткәннәр. Римның атаклы ораторы Марк (бүтән исеме Туллий) битендәге сөяле өчен «Цицерон» кушаматы алган. Цицерон «цицеро» дигән сүздән ясалган. Ул борчак бөртеген аңлата, күрәсең, Маркның сөяле шуңа охшап торган булса кирәк. Шулай да псевдонимнарның килеп чыгу тарихы,

кемнең ничек башка исем, фамилия артына яшеренү очраклары шактый кызыклы.

Кемнәр генә заманында нинди генә псевдонимнар алмаган?! Марк Твен, Мольер, Вольтер, Стендаль, Анатоль Франс бу псевдонимнарны үзләре уйлап тапканнар. Язучылык эшенә керешкәнче, аларның чын исем, фамилияләре бөтенләй башка булган. Горький, Серафимович, Д. Бедный, Багрицкий, Гайдар, Светлов та әти-әниләре биргән фамилияләреннән ваз кичкәннәр.

И. Масанов үзенең сүзлегендә Владимир Ульяновның 99 псевдонимын китерә. Ләкин ул тарихка Ленин булып кереп калган. Бу псевдоним беренче тапкыр 1901 елда «Заря» газетасында күренә. Аның ничек килеп чыгуы төгәл генә билгеле түгел. Бериш тарихчылар, В. Ульянов унтугызынчы гасырның сиксәненче елларында Ярославль губернасында яшәгән Николай Егорович Ленин фамилиясен алган, диләр. Николай Егоровичның вафатыннан соң аның паспортын туганнары В. Ульяновка биргәннәр. Рәсми документларда «Ленин» сүзенең Лена елгасыннан алынуы фаразлана. Ул елларда Джугашвили – Сталин, Бронштейн – Троцкий, Розенфельд – Каменев, Родомышельский Зиновьев фамилиясен ала. Сергей Костриков Кировка әйләнгән. Ул, «Терек» газетасында эшләгәндә, мәкаләләрен «Миронов» псевдонимы белән бастыра. Бу аның үзенә бик ошап бетми. Редакция коллективы белән бергәләп аңа башка псевдоним эзлиләр һәм «Кир»га тукталалар. Кир Персия патшасы, полководец исеме булган. Шуннан соң Костриков Киров булып киткән.

Мәгълүм бер чорда әдәбият, сәнгать, гомумән, мәдәният, фән хезмәткәрләренең псевдоним алулары модага кереп китә. Атаклы артист Качаловның чын фамилиясе Шверубович, эстрада жырчысы Леонид Утесовныкы – Лейзер-Вайсбейн, язучы һәм журналист Михаил Кольцовның – Фридлянд, тюрколог, академик Василий Радловның – Фридрих Вильгельм, режиссер һәм артист Станиславскийның Алексеев икәнлеген күпләр белмидер дә әле.

Яки менә атаклы артистыбыз Габдулла Кариев кем ул? Бу – Чистай өязенең Күлбай Мораса авылында туып үскән Миңлебай Хәйруллинның сәхнә псевдонимы. «Габдулла Кариев турында истәлекләр»дә Миңлебайның Такталы авылы мәдрәсәсендә укыган

чагында бик зирәк малай булуы хакында әйтелә. Ул унике яшендә Коръәнне яттан белгән, димәк, карый булган (карый дип Коръәнне яттан белүче, аны кычкырып укучы кешегә әйтәләр). Мондый зирәк баланың Миңлебай дип аталуы мәдрәсә мөдәррисе Зариф муллага ошамый. Ул аңа Габдулла исемен куша. Моны белеп алган авылдашлары Миңлебайны Габдулла карый дип йөртә башлый. Габдулла Уральск шәһәренә укырга китә. Аннан ул, бу шәһәрдә чуалышлар башлангач, качып кайта һәм полиция эзәрлекләвеннән куркып, Хәйруллин фамилиясен Кариевка алыштыра. Шулай итеп, авылның ярлы крестьян Хәйрулла малае Габдулла Кариев булып, сәхнә йолдызына әйләнә. Замандашлары һәм аны белгән, күргән кешеләрнең истәлекләреннән күренгәнчә, ул үзенә шундый псевдоним алуына һич тә үкенмәгән.

Гомумән, заманында күп кенә артистлар псевдоним алырга яратканнар. Гөлсем Болгарская (Өммегөлсем Мостафина), Гөлсем Камская (Гөлсем Ильясова), Бари Тарханов (Бари Гафаров), Газиз Айдарский (Газиз Вәлитов) һәм башка кайбер артистларны моңа мисал итеп китерер идем.

Күп кенә михнәтләр күргән, ГУЛАГ зинданнарында да рухы сынмаган аксакал әдибебез Хәсән Туфан да чын фамилиясен псевдонимга алыштырган. Ул вафатына кадәр шуңа тугры кала. Туфан мәдрәсәдә укыган елларында Хизбулла Хәзрәтев була. Аннары Хәсән Кусинов булып киткән. Бабасын Туфан дип йөрткәннәр. Күрәсең, бу аның холык-фигыле, табигате белән бәйле булгандыр. Хәсән Кусинов бабасының кушаматын үзенә псевдоним итеп алган.

Элек әдәбиятта псевдонимнар сер итеп сакланган. Хәтта шул тирәдә кайнаган кешеләр дә озак вакыт аның кем икәнлеген белә алмыйлар. Күренекле галим Мөхәммәт Гайнуллин «Татар әдипләре» дигән китабында Закир Мөхәммәтсадыйк Рәмиев турында болай дип яза: «...Киң күпчелек, хәтта әдәбият дөньясына якын торучылар да «Дәрдмәнд» (Дәрдемәнд) псевдонимы астына яшеренгән шагыйрьнең кем булуын берничә ел буена белә алмый киләләр». Мәҗит Гафури да башта «Дәрдмәнд» имзасы белән басылган шигырьләрнең авторы кем икәнлеген озак вакыт белми. Ул шул хакта «Шагыйрьнең алтын приискасында» исемле повестенда да искә ала: «Еллар үткәннән соң гына, «Дәрдмәнд» имзасы белән язылган

шигырьләрнең иясе Закир әфәнде Рәмиев булып, аның шул ук приска хуҗасы икәнен белдем». Профессор Габдрахман Сәгъдинең 1911 елда «Шура» журналының 23 нче санында чыккан мәкаләсендә мондый юллар бар: «Дәрдмәнднең кем идеке безгә мәгълүм түгел, бәлки идарәгә мәгълүм булса кирәк».

Ни өчен Закир Рәмиев «Дәрдмәнд» псевдонимын алган? «Дәрдмәнд» сүзе үзе кайгылы кеше мәгънәсен аңлата. Бу, бәлки, чыннан да, Закир Рәмиевнең холык-фигыленә туры килгәндер, ул үз ихтыяры белән шушы псевдонимны алган бит. Ә, бәлки, алтын приискасы тоткан кешенең шигырь язуын, шагыйрь йөрәкле кеше икәнлеген өнәп бетермәүчеләр дә булыр дип уйлагандыр.

«Ә Габдулла Тукайның псевдонимы булганмы?» дигән сорауга Галимҗан Нигъмәти сүзләре белән җавап бирәм: «Тукайның ятып кулланылган псевдонимы да татар фольклорының усал, кытыклап үтерә ала торган, рәхимсез, капризлы, мифологик Шүрәледән гыйбарәт».

Фатих Әмирхан үзенең әсәрләрен «Ташмөхәммәт» псевдонимы белән бастырган. М. Бөдәйлинең язуына караганда, Ф. Әмирханның «Имгәк», «Марксист» псевдонимнары да булган.

1914–1915 елларда вакытлы матбугатта «Гыйффәт туташ» имзасы белән шигырьләр күренә башлый. «Гыйффәт туташ шигырьләре» исемле җыентык та басылып чыга. Шушы псевдоним белән шигырьләре басылып чыккан кешенең Заһидә Бурнашева икәнлеге беленгәч, әти-әнисе аны бик нык рәнҗетә. Китаплары яндырыла. Ахыр чиктә Заһидә йортын ташлап китәргә мәҗбүр була. Әмма ул әдәбият тарихына «Гыйффәт туташ» псевдонимы белән кереп кала.

1927 елның 20 апрель санында «Кызыл Татарстан» газетасы «Ишетүче» псевдонимы белән «Казан храмы күренешләреннән» дигән шигырь бастырып чыгара. Аның Һади Такташ икәнлеге ачыклана. Такташның псевдонимнары күп була. Нигездә, ул икесе белән – «Аллан» һәм «Мокамай» псевдонимнары белән басыла.

Кайбер әдипләр, артистлар үзләре яшәгән төбәк-район, шәһәр, авыл исемнәре белән бәйле псевдонимнар ала. Мәсәлән, 1906–1917 елларда «Йолдыз», «Аң», «Ялт-Йолт», «Мәктәп», «Ак юл» газета-журналларында заманның иҗтимагый-сәяси тормышын яктырткан үткен публицистик мәкаләләр басылып чыга. Аларга

«Сәйфи-Казанлы» имзасы куела. Бу язучы Мөхәммәтфатих Камалетдин улы Сәйфуллин була. Аның башка псевдонимнары да бар: Ф. Камалов, Исәнбай, Бакыр күз, Батыр күз, Чәпи Камали малае...

Күп кенә әдипләр чын фамилияләрен псевдонимнарга алыштыралар һәм без аларның кайчандыр бүтән фамилия йөрткәнлекләрен күз алдына да китермибез. Ә бит иҗат эшен башлаганчы Гомәр Толымбай – Габделхак Шаһиәхмәтов, Миргазиз Укмаси – Миргазиз Зәбиров, Мәхмүт Галәү – Мәхмүт Мәрҗани, Газиз Иделле – Габделгазиз Усманов, Нәкый Исәнбәт – Нәкый Закиров, Нәҗип Думави Нәҗип Тахтамышев булган.

Мәшһүр артисткабыз Фатыйма Ильскаяның да сәхнә псевдонимы алуы кызыклы. Ул Оренбургтан Казанга килә. Аның кыз чагындагы фамилиясе Хуҗасәетова була!

Фатыйма Хуҗасәетованы театрга кабул иткәндә, кайбер артистларга аның фамилиясе ошап бетми. Габдулла Кариев, Кәрим Тинчурин, профессор Фатих Бәкер өчәүләп утырып киңәшәләр. Шул вакытта Г. Кариев тәкъдиме белән Ил кызы дип йөртергә карар кылалар. Шулай итеп, Оренбург кызы Хуҗасәетова Фатыйма Ильская булып китә. Бу псевдоним аның үзенә дә ошый һәм тамашачы күңелендә дә ул Фатыйма Ильская булып калды.

Татар милләтендәге әдипләрнең, русча яңгырашлы исем, фамилия алып, аны үз фамилиясе итү очраклары да бар. Мәсәлән, танылган язучы Роман Солнцевның Ренат Суфиев икәнлеген беләбез. Ул Минзәлә районының Күзкәй авылында туган. 1992 елда «Юность» журналында аның беренче әсәре «Роман Солнцев» имзасы белән басыла. Константин Симонов Ренат Суфиевка, китабына кереш сүз язам, әмма моның өчен сиңа Роман Солнцев булырга туры килер, ди. Бу вакытларда инде ул Красноярск шәһәренә күчеп киткән була һәм шул псевдоним белән басыла башлый. Үзен рус шагыйре дип йөрткән Михаил Львов та бит – татар егете Рифкать Дәүләтша улы Габитов. Ул татар авылында туган. Фронт газеталарында шигырьләре Михаил Львов исем-фамилиясе белән басыла. Журналист һәм галим Мәхмүт Әхмәтҗанов Рифкать Габитовның «Михаил Львов» псевдонимы алуының мондый сәбәбе бар дип фаразлый. Читтә яшәп, яһүд гаиләсендә тәрбияләнеп, аларга рәхмәт йөзеннән Львов фамилиясен алмады микән?

Кайбер кешеләр үзләренең иң якын туганнарының исем-фамилиясен псевдоним итеп ала. Шагыйрә Анна Горенко әнисенең кыз чагындагы фамилиясенә – Ахматова фамилиясенә күчә. Авар халык шагыйре Гамзат Цадасаның улы Рәсүл Цадаса Рәсүл Гамзатов буларак танылa. Серафимович атасының исемен псевдоним итеп алган, Шәриф Байгильдеев та, атасының исемен алып, Шәриф Камал булып йөри. Псевдонимнарның нәселдән-нәселгә күчкәннәре дә бар. Мәсәлән, язучы Аркадий Голиковның ике псевдонимы була: Гайдар һәм Райдар. Ул беренчесен фамилия итеп ала һәм аның улы Тимур да, оныгы Егор да Гайдар фамилиясен йөртә.

Бериш әдипләргә псевдонимнар шулкадәр ошап китә, алар аннан аерылырга да теләмиләр, чын фамилияләреннән дә ваз кичмиләр. Шул сәбәпле псевдоним чын фамилиясенә кушыла: Салтыков-Щедрин, Новиков-Прибой, Мамин-Сибиряк, Сергеев-Ценский («Ценский» псевдонимы авторның туган шәһәре Тамбовның Цен елгасы буенда утыруы белән бәйле), мәшһүр артистка Гыйззәтуллина-Волжская.

Язучылар, рәссамнар арасында күмәк псевдоним алучылар да бар. Мәсәлән, Козьма Прутков – рус язучылары Александр, Алексей, Владимир Жемчужниковлар һәм граф Алексей Толстойның уртак псевдонимы. Рәссам Кукрыникслар Куприянов, Крылов һәм Соколов фамилияләреннән барлыкка килгән. Остап Бендер турындагы китап авторлары Ильф һәм Петров – Илья Файнзильберг белән Евгений Катаев псевдонимнары.

Ләкин кайбер псевдонимнар тиз онытыла. Әйтик, Гоголь кайчандыр Алов, Константин Федин Нидсфак фамилияләрен йөрткән. Гомәр Бәширов үткән гасырның утызынчы еллары башында «Г. Разин» псевдонимы белән яза. Аның «Сиваш» повесте башта «Г. Разин» псевдонимы белән басыла. Аннары инде ул Г. Бәширов фамилиясенә күчә һәм шуның белән таныла.

Язучылар арасында фамилияләрен кыскарту юлы белән яки шуңа бер-ике хәреф өстәп, псевдоним алу гадәте дә бар. Рус теленә чыккан сүзлекләргә карап фикер йөртсәк, аларны да псевдоним дип әйтергә мөмкин. Мәсәлән, «Псевдонимнар энциклопедиясе»ндә, Әхмәт Фәйзуллин – «Әхмәт Фәйзи», Мирхәйдәр Фәйзуллин «Мирхәйдәр Фәйзи» псевдонимын алганнар, диелә. Шул ук хезмәттә

Муса Җәлиловның псевдонимы «ҖәлилХ булуы әйтелә (М. Җәлилнең «Шахмай» псевдонимы да булган). В. Дмитриевның «Скрывшие свое имя» дигән китабында Мусаның псевдонимы «Җәлил» дип турыдан-туры әйтелмәсә дә, ул псевдонимның бер төренә – проксонимга кертелгән. В. Дмитриев фикеренчә, проксоним – автор исеменнән яки фамилиясеннән кыскартып ясалган сүз. Димәк, безнең күпчелек татар язучылары һәм шагыйрьләре дә әсәрләрен псевдоним белән бастырганнар һәм бастыралар. Әйтик, Габдулла Тукай, Фәтхи Бурнаш, Шәехзадә Бабич, Галиәсгар Камал, Абдулла Алиш, Мирсәй Әмир, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни, Гариф Гобәй, Таҗи Гыйззәт, Ибраһим Гази, Гадел Кутуй, Салих Баттал, Хәй Вахит, Шәрәф Мөдәррис, Кави Латыйп, Гамил Афзал, Әхсән Баян, Рәшит Гәрәй, Ренат Харис, Айдар Хәлим, Рәфикъ Юныс һәм башкалар.

Мәхмүт Бөдәйли, моннан тыш, Шәехзадә Бабичның – «Шөпшә», «Чытырман», «Башкорт», Фәтхи Бурнашның – «Мишәр», «Кәбәй», Гадел Кутуйның – «Казбек», «Руслан», Галиәсгар Камалның «Ишан», «Әүлия» псевдонимнары булуын искә ала.

Боларга тагын бер-ике хәреф өстәп ясалганнарын да псевдоним дип санасак, татар әдәбияты псевдонимнарга бик бай икән: Садри Максуди, Һади Атласи, Жамал Вәлиди, Каюм Насыйри, Мәҗит Гафури, Гаяз Исхакый, Кави Нәҗми, Гамир Насрый, Нәби Дәүли, Мөхәммәт Садри...

Әдәбиятта псевдонимнарның башка төрлеләре дә кулланыла. Мәсәлән, кайберәүләр үзен бер исем белән генә атап йөртүне хуп күрә. Шагыйрьләр Сирин (Сирин Батыршин), Зөлфәт (Дөлфәт Маликов), драматург Аманулла (Әмир Камалиев), җырчы Витас (Виталий Грачев) һ.б.

Кайвакытта бер үк исем, фамилия белән аталып йөргән әдәбият яки сәнгать эшлеклеләре, укучы яисә тамашачы бутамасын өчен, псевдоним алырга мәҗбүр булалар. Мәсәлән, Илсур Сафиннар күбәеп киткәч, аларның берсе эстрада җырчысы Илсафка әйләнде. Халык та моңа тиз күнегеп китте. Халык Илсаф концертына аның кем икәнлеген белеп бара. Яки менә танылган композитор Азат Хөсәенов белән җырчы Азат Хөсәенов. Җырчы кешегә сәхнәдә композиторга караганда ешрак күренергә туры килә. Хәзер аны тамашачы Азат Тимершәех дип белә.

Безнең байтак кына урта буын язучылар һәм шагыйрьләр дә әсәрләрен псевдонимнар белән бастыралар. Бу – табигый күренеш. Моңа мисал итеп Рабит Батулланы (Роберт Батуллин), Мөхәммәт Мирза (Илфак Ибраһимов), Гәрәй Рәхим (Григорий Родионов), Рәдиф Гаташ (Рәдиф Гатауллин), Зиннур Хөснияр (Зиннур Хөснетдинов), Әхмәт Гадел (Әхмәт Гаязов), Рашат Низами (Рашат Низамиев), Госман Садә (Госман Зәйнетдинов), Ләбиб Лерон (Лемон Леронов), Мансур Вәли-Барҗылыны (Мансур Вәлиев) һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин.

Мин, псевдонимнар турында сөйләп, кемнедер шаккатырырга җыенмыйм. Псевдонимнар – кеше биографиясендәге гади генә бер исем түгел, ул аның визит карточкасы да, аның девизы да. Кайвакытта псевдоним, автор ихтыярына буйсынып, аның чын йөзен яшерә, аны көтелмәгән күңелсез хәлләрдән саклап кала. Бу, әлбәттә, һәр язучы һәм журналист, псевдоним куеп язсын, яисә һәр артист һәм галим, сәясәтче үзенә псевдоним уйлап тапсын, дигән сүз түгел. Татар әдәбиятында, сәнгатендә һәм фәндә булганнары да бик җитәрлек. Аларҗентекләп өйрәнүгә генә мохтаҗ. Бәлки, псевдонимнарны җыйган, татар мәдәниятендә аларның барлыкка килү тарихы, урыны һәм роле белән кызыксынган кешеләр бардыр. Без дә башка халыклар үрнәгендә саллы гына бер сүзлек яки энциклопедия төзеп чыгара алсак, бик игелекле эш эшләр идек. Без башкалардан киммени?!

*«Казан утлары». 2009. № 8. Б. 181–183.*

**З. Рәмиев**

## ДАМЕЛЛА, МАРКСИСТ, ТАШМӨХӘММӘД

Әдәби мирасны җыйнап, китап рәвешенә китереп бастырып чыгару, беренче карашка, әллә ни кыен эш түгел. Язучылары исәнимин заманнарда нәшер ителгән китап-җыентыклардан, газета һәм журналлардан, я булмаса кульязмаларыннан (әгәр сакланган булса) иҗат җимешләрен күчереп аласың да нәшрияткa илтеп тапшырасың. Мондый эш белән гомерендә дә таныш булмаган кеше фикеренчә, әйе, җиңел. Гамәлдә исә бик күп четерекле мәсьәләләрне хәл итәргә туры килә. Арада иң җаваплысы, – минемчә, авторлыкны билгеләү. Безне кызыксындырган әсәрне кем язган? Иҗатчысы без уйлаган, без фараз иткән кешеме? Әллә инде башка берәү тудырганмы бу әсәрне? Нинди дә булса бер катгый фикер әйткәнче, әдәбиятчы-текстолог моның ише сорауларга җавапларны әзерләгән булырга тиеш.

Татар әдәбияты классигы Фатих Әмирхан мирасын барлаганда да, авторлык мәсьәләсе һаман саен туып тора. Егерме еллык иҗат дәверендә, сүз сәнгатенең төрле-төрле жанрларына мөрәҗәгать итеп, ул үзенең әсәрләрен – роман, повесть, хикәя, драма, мәкалә, фельетон һәм рецензияләрен дистәдән артык имза белән бастырган, бер ишеләре исә имзасыз да (аноним рәвештә) нәшер ителгән.

Хәер, махсус тикшерелмәсә дә, Ф. Әмирхан имзалары беркадәр ачыкланган инде. Болай дигәндә, мин М. Һади (М. Бөдәйли) төзегән «Псевдонимнар сүзлеге»ндәге мәгълүматларны, Ф. Әмирханның дүрт томлы «Әсәрләр»енә Ф. Ибраһимова, Н. Садыйкова, З. Рәмиев, М. Әхмәтҗановлар язган аңлатма һәм искәрмәләрне күз алдында тотам.

Мөхәммәтфатих Мөхәммәтзариф улы Әмирханның ачык һәм яшерен имзаларыннан иң еш кулланылганы – «Фатих Әмирхан» («Ф. Әмирхан»). Хәер, беренче мәртәбә татар матбугатында күренгәндә, ул «Фатих әл-Әмирхани» рәвешендә була әле. Яшь әдипнең «71 нче ел коммунасы» дигән мәкалә-очеркы (урысчадан тәрҗемәсе) «Әлгасрелҗәдид» журналының 6 нчы һәм 8 нче

(1906 ел, 10 июнь һәм 10 август) саннарында шулай имзаланган. Ә «Фикер» газетасының шул ук елгы 6 август санында Габдулла Тукай аңа «Фатих әл-Әмирхан» дип мөрәҗәгать иткән.

Шунысы да мәгълүм: «Фатих Әмирхан» имзасын унсигез ел дәвамында кулланганның соңында, әдипкә аңардан баш тартырга туры килә.

Егерменче еллар башында татар көндәлек матбугатында журналист, тәрҗемәче Солтанфатих Насретдин улы Әмирханов та мәкаләләре белән чыга башлый. Фатих Әмирхан апасы Сәгадәтнең ире, Казанның Бишбалта бистәсе имамы Габдулла Әмирхановка эне тиешле бу кеше дә, аны-моны уйламыйча, исемен һәм фамилиясен кыскартып, «Фатих Әмирхан» имзасын ала. Нәтиҗәдә саташтырулар, буташтырулар килеп чыга. Әдип, үзен шулардан саклар өчен, «Татарстан» газетасы редакциясенә мәктүпләр белән мөрәҗәгать итсә дә, җаваплы мөхәррир Фәтхи Бурнаш, ни сәбәпледер, аларны урнаштырмый. «Минем өчен бер дә матлуб булмаган бу буташтырылудан котылыр өчен, миңа бердәнбер юл – унсигез еллык имзамны үзгәртеп, әсәрләремне үзгәртелгән имза белән нәшер итү... юлы гына калды», – дип яза Фатих Әмирхан бер язмасында (М. Әхмәтҗанов билгеләвенчә, 1924 елда) һәм киләчәктә әсәрләрен «Фатих Зариф улы Әмирхан (Фатих Әмирхан)» рәвешендәге имза белән нәшер итәргә ниятләвен белдерә. Соңрак әлеге журналист язганнары астына «Фатих Әмирхан II» (Икенче) дип куя башлый.

Фатих Әмирханның яшерен имзаларыннан шактый еш кулланылышта йөргәннәре икәү: «Дамелла» һәм «Ташмөхәммәд». 1907–1909 елларда, «Әлислах» газетасында эшләү чорында ук, аларга мөрәҗәгать итә әдип. Хәер, болар арасында үзенә бертөрле «хезмәт бүленеше» дә булган шикелле.

Ул елларда «дамелла» сүзенең «мәдрәсә тотып, дәрес бирүче мулла, гыйлем иясе, укымышлы кеше» мәгънәсендә йөргәнлеге билгеле. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган заманнарда (ул анда берара укыткан да әле) Фатих Әмирхан «Дамелла» кушаматы алган була. Шуны искә төшерепмедер, яшь әдип 1907 елның 25 октябрендә чыккан «Әлислах» газетасында беренче мәртәбә «Дамелла» имзасын куллана. Басылган нәрсә – әдипнең беренче әдәби әсәре – «Гарәфә көн төшемдә» хикәясе (китап булып басылгандагы

исеме – «Гарәфә кич төшемдә»). «Дамелла» имзасын Ф. Әмирхан җитди хикәяләрен, татар әдәбияты һәм сәнгате тормышына караган мәкаләләрен, рецензияләрен нәшер иткәндә куя. Ә «Ташмөхәммәд» исә, билгеле ки, әдипнең сатирик һәм көлке әсәрләре, фельетоннары ахырында күренә. Мәсәлән, атаклы «Фәтхулла хәзрәт» повестенең ике басмасы да (1909–1910 һәм 1911–1912 еллар) әлеге имза белән дөньяга чыга. Шунысы да мәгълүм: бу имза кинәттән генә ачылып куя. Бервакыт «Тимербай» имзалы берәү (З. Бәшири) «Фәтхулла хәзрәт»кә пародия – «кечкенә фельетон» язып, анда «Ташмөхәммәд»нең торган урынын – Яңа Бистәнең Малый Симбирский исемле урамындагы йортны телгә ала. Ә Фатих Әмирханның чыннан да шушы адрес белән яшәве газета укучыларга билгеле, һәм әдип, әдәби этиканы бу рәвешле бозуга борчылып, «Йолдыз» идарәсенә (редакциясенә) ачык хат язып җибәрә. Хатта Тимербайның псевдоним иясен газета битләрендә ачуы бик зур гаеп итеп күрсәтелә.

Бу вакыйгадан соң да Ф. Әмирхан әлеге имзасыннан баш тартмый. 1913 елның ноябрендә «Аң» журналы мәшһүр шәхесләрнең Яңа ел белән (һиҗридә) котлауларын урнаштыра. Арада Ф. Әмирханның – «Ташмөхәммәд»нең дә тәбрик сүзләре китерелә.

1919–1920 еллар. «Кызыл Армия» газетасында язышучылар арасында Фатих Әмирхан да бар. Монда басылган мәкаләләреннән тугызының авторы итеп «Марксист» («М-т», «Мт») күрсәтелгән. Октябрь вакыйгаларын бәяләүдә әдип баштарак шактый үзенчәлекле позициядә торса да, бераздан ул яңа чынбарлыкны яклап чыга. Ленин «буржуазия алдында бозу, җимерү, вату символы булса, бөтен җиһан пролетариаты алдында бу исем төзү, гыймран итү, яңа хәят торгызу символы» дип язган Ф. Әмирханның мондый имза алуы гаҗәпләндермәскә тиештер.

Классик язучының югарыда телгә алынган ачык һәм яшерен имзалы әсәрләре шактый дәрәҗәдә барланган һәм күбесе 100 еллык юбилеена багышлап чыгарылган дүрт томлы «Әсәрләр»енә кертелгән.

М. Һади (Мәхмүт Бөдәйли) «Псевдонимнар сүзлеге»ндә («Казан утлары», 1969 ел, 1 нче сан) тагын ике имзаны – «Имгәк» һәм «Әүлияуллаһтан бер залим»не (алар «Ялт-Йолт» журналында очрый) Ф. Әмирханныкылар итеп күрсәткән иде. Шуңа нигезлә-

неп, әдәбият галиме Үзбәк Гыймадиев «Сила сатирического слова» исемле монографиясендә бу журналда чыккан алтмышлап сатирик парчаны, рецензияне, фельетонны Ф. Әмирхан әсәрләре рәтендә тикшерә. Әмма күп кенә фактлар ул әсәрләрнең иясе мәсьәләсен хәл ителгән дип санауга, катгый фикер йөртүгә каршы килә. Бу турыдагы шик-шөбһәләребезне без «Имгәк» имзасының иясе кем?» исемле мәкаләдә язып чыккан идек («Әдәбият чыганакларын барлаганда», Казан; Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, 1994 ел). Күптән түгел генә Институт мирасханәсендә язучы Галиәсгар Гафуров-Чыгтайның шәхси фонды материаллары белән танышырга туры килде. Берничә дәфтәрдә ул үзенең тәрҗемәи хәлен тасвир итә. Казанда Тукайлар, Әмирханнар белән аралашкан чаклары турында да сөйли (кайчак алардан көлә дә). Г. Гафуров-Чыгтай «Сөембикә» журналында «Фатыйма һәм аның тәкямеле» хикәясен бастыргач, «Кояш» газетасында әсәргә тискәре рецензия чыга. Язучысы – «Гали тәхсил күрмәгән, матбугат тирәсендә йөри торган мәхдүмнәрнең берсе». Бераздан бу авторга тагын сүз алырга туры килә («Кояш»та). Бактың исә, бу имзаның да иясе Фатих Әмирхан икән...

Юк, Ф. Әмирханның барлык имзалары да табылып бетмәгән әле. Хәер, бөтенесен табу мөмкин дә түгелдер. Шулай да эзләнүләрне дәвам иттерергә кирәк.

Сүземне исә Ф. Әмирханның инде мәгълүм булган, ачык һәм яшерен имзаларының исемлеген китереп тәмамларга телим. Алар түбәндәгеләр:

Бәндәңез Ташмөхәммәт; Гали тәхсил күрмәгән матбугат тирәсендә йөри торган мәхдүмнәрнең берсе; Дамелла; Зәмзәметдинов; Казан шәкертләре; Марксист; М-т; Мт; Матбугат тирәсендә йөри торган мәхдүм; М. Зарипов (И. Нуруллин ачкан); Ташмөхәммәд; Т-д; Фатих әл-Әмирхани; Ф. Әмирхан; Ф. Ә.; Шәкертләр (И. Нуруллин ачкан).

*«Мәдәни җомга». 1996. 2 февраль*

**З. Рәмиев**

## ПСЕВДОНИМНАР ТУРЫНДА

Һәр әдип үз әсәренең башкалар тарафыннан укылу ихтималын истә тотып иҗат итә, һәм күпчелек очракта әсәр тексты, иҗатчысы күрсәтелеп, укучы хөкеменә тапшырыла. Шунлыктан без аны, шигырь яки поэмамы, хикәя, повесть яки романмы, пьесамы, авторын белеп, авторын истә тотып укыйбыз, текстны авторы белән бербөтенлектә кабул итәбез. Автор-иҗатчы иркендә – үзен ничек күрсәтү. «Мөхәммәтфатих Мөхәммәтзариф углы Әмирханов» имзасы белән чыгарамы, «Ф. Әмирхан», «Ташмөхәммәд» яки «Дамелла» имзасын куеп язамы – автор моны уйлап эшли. Менә шулчакта туа да инде имза, ягъни псевдоним мәсьәләсе. Әгәр дә исеме, атасының исеме һәм фамилиясе паспорттагыча, метрикәдәгечә күрсәтелми икән, ул чак псевдоним барлыкка килә. XX гасыр башы әдипләренең әсәрләре һәрвакыт диярлек псевдонимнар белән басылганнар. Хәтта без кайберләренең реаль тормышта кем булганлыгын да, нинди исем-фамилия белән яшәгәнлеген дә белмибез. Бу урында, псевдонимнар ни өчен кулланыла соң, дигән сорау тумый калмас. XX гасыр башында татар әдипләрен иҗат практикасында псевдонимнар ясалу сәбәпләре күптөрле. Дөрес, псевдонимнарның бер ишеләре реаль шәхесләрнең документальләштерелгән атамаларына бик якын тора, аларның яшеренлек дәрәҗәсе минималь. Мисалга Фатих Әмирхан, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Гаяз Исхакый, Сәгыйть Рәмиев кебекләрне китерергә мөмкин. Икенче төр псевдонимнар хуҗаларының чынбарлыктагы исемләнешенә һичничек тә ишарәләми. Бүген мондыйларының ялгызлык исемнәре буларак ничек ясалулары хакында сүз алып бармыйча, куллану сәбәпләрен генә күрсәтергә уйлыйбыз. Бу хакта моннан утыз еллар элек Мөхәммәт Мәһдиев бер язып чыккан иде. Әйдәгез, башта аның күзәтүләрен искә төшерик. Беренче сәбәп – авторга, язучыга бер үк журнал һәм дә газета сәхифәләрендә ике яки берничә текст белән чыгыш ясарга туры килә, һәм төрле имза куллану ихтыяҗы туа. Мәсәлән, Тукай «Уклар» журналында мәгълүм «Шүрәле» псевдонимы белән беррәттән, «Тәртә башы», «Адвокат», «Җен» кебекләрне куллана.

Икенче сәбәпкә мисалны Габдрахман Сәгъди иҗатыннан табарга була. Ул – танылган әдәбиятчы галим. Шул ук вакытта шигырьләр дә язган. Үзенең галим буларак авторитетына күләгә төшермәскә теләп, бу уртакул шигырь-тезмәләрен «Фикри», «Зәукый» дигән псевдонимнар белән генә бастыруны мәслихәт күргән. Тагын бер сәбәп, Мөхәммәт Мәһдиевнең үз сүзләре белән әйтсәк, «псевдоним куллану газета-журнал полосасын цензорны әсәртмәс өчен кирәк булган». Бу да аңлашыла. Тукайлар заманында периодик басмалардагы цензорларны сагайта торган чыгышлар мәгълүм имзаларга карап игътибарга алына торган булган. Башка бер имза күренгәндә исә, алар игътибардан читтә кала ала. Псевдоним куллануга дүртенче сәбәп авторның иҗтимагый статусына бәйле. Мал-мөлкәтле зат яки дин эшлеклесе гаиләсеннән чыккан кешеләргә, яисә «язучы яки публицистның күтәргән темасы белән социаль хәле арасында аерма зур булганда» әсәрләрне яшерен имза белән бастыру кулайрак күренгән. Мисаллары – Г. Газиз, Г. Рәхим, Г. Казаный. Аталары: Салих Гобәйдуллин – сәүдәгәр, текстиль фабрикасы хуҗасы; Мөхәммәтшакир Габдерәхимов – бай кеше; Галиәкбәр Камалетдинов исә – камчатчы мастер. Баштарак алар балаларының әдәби иҗат белән шөгыльләнүләренә риза да булып бетмәгәннәр.

Мөхәммәт Мәһдиевкә өстәп, башка сәбәпләрне дә күрсәтергә мөмкин. Шундыйлардан берсе – татар исем-фамилияләренең озын булуы, күп вакыт кушма сүзләрдән торуы. XX гасыр башында яуропалашу көчәеп китү аркасында булса кирәк, аларны кыскарту гадәткә керә. Әнә шулай Габдуллаҗан Тукаев Габдулла Тукаевка, Мөхәммәтгаяз Исхаков Гаяз Исхакыйга, Әхмәтзыя Насыйров Зыя Ярмәкигә әверелә. Моннан утыз-кырык еллар элек Фатих Хөсни үз имзасының Мөхәммәфатих Хөснетдиновтан Гомәр Гали «кисеп» ясавын язып чыккан иде.

Риза Фәхретдин – күренекле дин эшлеклесе, тарихчы галим һәм журналист кына түгел, язучы буларак та танылган шәхес. Шунысы кызыклы: ул «Сәлимә, яки Гыйффәт» һәм «Әсма, яки Гамәл вә җәза» исемле повестьларын, ачык имзасын куймыйча, «Гафил бине Габдулла» имзасы белән чыгарган. Бу турыда соңрак ул: «Духовное собрание эшләвем аркасында, шул әсәрләр хакында булачак яхшы вә яман фикерләрне ишетер өчен, әсәрләргә үземнең исемемне

куймадым, псевдоним белән яздым», – дип сөйләгән. Димәк, Риза Фәхретдин язганнары хакында объектив, авторының кемлегенә карамыйча әйтеләсе фикерләрне ишетергә теләгән, шунлыктан чын исем-фамилиясенә тамчы да охшамаган имза артына яшеренгән. Драматург Ярулла Вәли дә берара шундыйрак фикердә торган.

XX гасыр башы матбугатында демократик көчләргә каршы позициядә торучылар да булган. Аларның кайберләре «Дин вә мәгыйшәт» журналында басылып килгән, аерым китапчыклары да чыккан. Әйтергә кирәк, псевдонимнар артына качып та эш иткәннәр алар. «Таңчылар»ны сүгү белән тулы китапчыгын берәү «Мулла Ш. К.» имзасы белән чыгара. Әйтелгән журнал битләрендә «Гъ. З. Б.», «С.», «Ф. Д.», «Ф. К.», «Г. К.», «ГъФ.» кебек псевдонимнар очрап тора. Прогресс яклы көчләргә бу рәвешчә ташлануны без бу чорда шактый очратабыз. Әгәр ачыктан-ачык исем-фамилияләрен күрсәтеп язсалар, тегеләрнең үтергеч сатиралары объектына әвереләсеңне көт тә тор! Җамал Вәлиди, графоманнар, нәзымчылар, тәнкыйтьтә хурлыклы бәяләр ишетмәскә теләп, псевдонимнар астына яшеренәләр, дип язып чыккан иде.

Күптән түгел мәрхүм Рәис Сәфәров псевдоним куллануның тагын берничә сәбәбен күрсәтте: сәясәтчеләр конспирация өчен, артистлар, җырчылар реклама өчен, кайберәүләр кешеләрнең күңелен кытыклау, үз шәхесенә карата игътибар, кызыксыну уяту өчен, милләтен яшерү өчен, кайсылары үз язмышының символы итеп, яисә үз җенесен яшерү өчен. Мисаллар китерсәм, сүзем озынга китәр кебек.

Әдәби мирасыбызны тулырак күзалларга тырышсак, псевдонимлы әсәрләргә дә игътибар итәргә, псевдонимнарны ачарга омтылырга тиешбез. Моның берничә юлы бар: болар – документаль чыганакларга, әсәрнең идея эчтәлегенә, тел-стиль чараларына нигезләнү. Хәер, алай да әле байтак кына имзалар «бирешмиләр», серлелеген, табышмаклыгын югалтмыйлар. Фәнебезнең псевдономастика тармагы буенча эзләнүләрне киләчәктә дә дәвам иттерәсе иде.

*Әдәбиятчы-текстолог язмалары. (1990–2013 еллар).*
*Казан: Ихлас, 2014. Б. 126–128.*

# Кушымта

# М. БӨДӘЙЛИНЕҢ «ТӘХӘЛЛҮСЛӘР СҮЗЛЕГЕ»НДӘ УРЫН АЛГАН ИСЕМНӘР КҮРСӘТКЕЧЕ


А. Авыргазый – 39
А. Алиш – 32
А. Әхмәт – 1123
А. Б. – 562
А. Борнашев – 141
А. Влиндор – 767
А. Гайнулла – 18
А. Гомәров – 289
А. Гыйльманова – 790
А. Дәл – 323
А. Казембек – 430
А. Кудашев – 489
А. Лотфи – 20
А. М-җ – 25
А. Расих – 717
А. Сәгъди – 779
А. Таһиров – 822
А. Тәүгилде – 1020
А. Фәрхәнә – 19
А. Хәлим – 971
А. Цаликов – 747
А. Шамов – 1020
А. Яхин – 1077
Аб – 1130
Абдул – 814
Абдулла Алиш – 32
Абил – 562
Абил – 1130
Аблай – 956
Аблай М. – 1
Абнамак – 852
Абруй – 790
Абруй Сәйфи – 790
Авталиф – 158
Авыл егете – 350
Авыл кешесе – 627
Авылдан – 91
Авылчы – 299
Авыргазый – 39
Агай баш – 675
Агиев Ә. – 5
Аен – 739
Азад – 439
Азамат – 56
Азамат С.А. – 56
Азат – 928
Азат Әхмәдуллин – 1124
Аин – 1025
Аит бай – 17
Ай – 24
Айбик – 819
Айваз – 394
Айдаров Кәрамәт – 10
Айдын – 726
Айман Алтайлы – 15
Айсылу Вәлиди – 173
Акбилет – 488
Акбирдин Л. – 20
Аккобай – 84
Акмулла – 21
Акпадар – 1055
Акъегет Муса – 26
Акъегетзадә – 26
Алатавый – 435
Али – 1068
Али Ашказаров – 929
Али Зөлкарнәй – 354
Алик – 40
Алимов – 425
Алкин И – 33
Алкин С. – 34
Алкыш – 657
Аллан – 814
Аллаяр – 414
Алмай Ә. – 38
Алмас – 766
Алпир – 39
Алпуш 367
Алтай – 454
Алтайлы – 14
Алты бармак – 439
Алтынбаев – 494
Алтынбай – 26
Амурский – 591
Анкобай – 946
Аннук Самакай малае – 843
Апак – 42
Аппак – 42
Апуш – 928
Араб нажат – 562
Арамантов – 494
Асия Измайлова – 380
Астыртын? – 394
Ата шагыйрь – 814
Атави – 435
Атакай – 814
Атилла Расих – 717
Атилла Рәсүлев – 717
Атнабай – 55
Аусар – 425
Аучы – 869
Афзал Кудашев – 489
Афзал Таһиров – 822
Афзал Шамов – 1020
Афиил – 29
Ахметбек – 747

Ахунов Ф. – 60
Ашказарский-Кудашев – 487
Аяз – 291
Ә. Фәез – 885
Ә. А. – 14
Ә. Айдар – 14
Ә. Алай – 38
Ә. Атнабаев – 55
Ә. Байтурсун – 84
Ә. Бәйрәмов – 83
Ә. Бикчәнтәева – 126
Ә. Бикчәнтәй – 121
Ә. Булатов – 138
Ә. Г. – 294
Ә. Габдуллин – 216
Ә. Габиди – 211
Ә. Галиәкбәров – 445
Ә. Гомәрев – 294
Ә. Д. – 330
Ә. Давыдов – 330
Ә. Еники – 341
Ә. Ерикәй – 342
Ә. Камал – 433
Ә. Камал – 445
Ә. Каргалый – 453
Ә. Кормаши – 500
Ә. Кормаши – 501
Ә. Мирзагитов – 564
Ә. Мирсәй – 1105
Ә. Мөхетдиния – 625
Ә. Насыйбуллин – 643
Ә. Рахманкулов – 700
Ә. Рәхмәтзадә – 703
Ә.С. Хәмит – 781
Ә. Сәгыйть – 781
Ә. Сөбханкулов – 775
Ә. Таңгатаров – 821
Ә. Терегулов – 836
Ә. Түрәй – 862
Ә. Уразаев – 500
Ә. Уразай – 456
Ә. Урманчиев – 869
Ә. Усманов – 873
Ә. Шәһид – 1122
Ә. Юныс – 1057
Әбелваккас – 802
Әбелфәиз – 562
Әбелфәиз – 1130
Әбелмәних – 453
Әбелмәних-әл-Бистәви – 453
Әбелфаикъ – 820
Әбләйский – 162
Әбләминов И. – 1087
Әбмус – 597
Әбни – 739
Әбрар Мускиев – 597
Әбрар Сәгыйди – 781
Әбсәләмов – 1101 а
Әбү Сәгыйть – 781
Әбү Сәлман – 285
Әбү Танбал – 614
Әбү тигәнәк – 781
Әбү Тозгыт – 149
Әбүбакиров Хөсәен – 1089
Әбүбәкер Дашкин – 313
Әбүбәкер Терегулов – 836
Әбүбәкер Усманов – 873
Әбүгалисина – 1098
Әбүзәр Түрәй – 862
Әбүзәров Х. – 1090
Әбу Варажҗә – 786
Әгъзам Камал – 444
Әгърафи – 1029
Әдип Маликов – 542
Әдһәмов Закир – 1100
Әҗам – 693
Әзгыч – 739
Әзһәр Гобәйди – 287
Әйвар – 1062
Әйтермен әле – 158
Әйтмим – 158
Әйтмим – 607
Әйями – 1061
Әкәлим – 505
Әкмәли – 117
Әкрәм Вәли – 162
әл-Бари – 863
Әлбик – 1056
Әлиф – 844
әл-Караши – 452
әл-Каркаралы – 275
Әлмансур – 319
Әлмәшев – 1101
Әлми – 1092
Әлми Гомәр – 1092
Әлфишин – 1020
Әмили Гали – 559
Әмин – 1103
Әминә Мөхетдинова – 625
Әминә Терегулова – 1156
Әминев Бари – 1104
Әмирхан Еники – 341
Әмрулла А. – 5
Әнәс К – 445
Әнәс Камал – 445
Әнәс Кари – 1110
Әнәс Кари – 456
Әнвәр Бикчәнтәй – 121
Әнвәр Вахитов – 185
Әнвәр Давыдов – 330
Әндиҗанлы – 806
Әптери – 35

Әптери малай – 531
Әрем – 1106
Әрсез – 840
Әсгад Фәхри – 899
Әсгат Мирзагитов – 564
Әсгать Айдар – 14
Әсгать Мохтар – 592
Әскәри – 589
Әүлани – 562
Әүлани – 1130
Әүлия – 1043
Әфләтун – 178
Әфләтун – 503
Әфтәх Габдул – 216
Әхкәм – 427
Әхмәди – 593
Әхмәдуллин Фәтхи – 1112
Әхмәдуллиннар – 1111
Әхмәрова Сара – 1114
Әхмәт Булатов – 138
Әхмәт Гомәрев – 294
Әхмәт Ерикәй – 342
Әхмәт Исхак – 408
Әхмәт Исхакый – 411
Әхмәт Кормаши – 500
Әхмәт Мидхәт – 558
Әхмәт Насыйбуллин – 642
Әхмәт Сөбханкул – 775
Әхмәт Урманче – 869
Әхмәт Фәез Идел – 885
Әхмәт Юныс – 1057
Әхмәтбик Салихов – 747
Әхмәтгәрәй Хәсәни – 994
Әхмәтҗан – 38
Әхмәттаҗетдин – 700
Әхмәтһади Максуди – 536
Әхмәтшин Гәрәй – 1097
Әхнәф Кирәй – 474
Әхнәф Таңгатаров – 821
Әхнәф Харисов – 929
Әхсән Баян – 107
Әхсән К. – 501
Әхтәм карт – 1128
Әхтәмов Биньямин – 1126
Әхтәмов Ибраһим – 1127
Әһли – 643
Әюп Гәрәй – 731
Б. Б. – 113
Б. Б. – 71
Б. Бадамшин – 71
Б. Бәхетгәрәй – 151
Б. Бәхтияр – 151
Б. Бикбаев – 113
Б. Болгарский – 127
Б. Г. – 300
Б. Габдуллин – 205
Б. Гыйззәт – 300
Б. Җәмил – 79
Б. Зөлкарнәй – 77
Б. М. – 551
Б. Мансур – 551
Б. Микъдәт – 129
Б. Мирзанов – 565
Б. Мокамай – 586
Б. Мөэминова – 66
Б. С. – 769
Б. Сәлиев – 743
Б. Сибгат – 704
Б. Сирин – 769
Б. Тажи – 830
Б. Хәйдари – 905
Б. Хәмит – 434
Б. Хәсән – 932
Б. Ш. – 1034
Баба Равшан – 424
Багбостан – 66
Багис – 454
Бадамша – 71
Бадика – 439
Баембит Зөһрә – 70
Баиш – 85
Бакый Урманче – 870
Бакыр күз – 793
Балканлы – 280
Балтан Гобәй – 90
Балыкчы – 897
Бари Рәхмәти – 704
Барлас Камал – 434
Басыйр Габдуллин – 205
Батрак – 382
Баттал Салих – 96
Бату – 1082
Батыр – 232
Батыр Вәлит – 165
Батыр күз – 793
Батырбик – 1029
Батырша– 296
Бахул – 97
Бахулзадә – 97
Баһаветдин кызы – 800
Баһаветдин Максудов – 529
Башкорт – 65
Башы бозык – 414
Баязит – 794
Баязит Бикбай – 113
Баязит Дим – 317
Баязит С. – 104
Баязитов – 794
Баян – 64

Бәбәйчүп – 65
Бәдрүш Мокамай – 586
Бәкер Белоус – 108
Бәкер Усман – 873
Бәләкәй – 1003
Бәләкәй – 299
Бәхтиевский – 98
Бәшәр Хәсән – 932
Бәян Гыйззәт – 300
Без – 158
«Берәү» – 958
Бер кеше – 765
Бер кичәлек футурист – 739
Бер мосафир – 739
Бибинур Кротова – 482
Бик усал – 843
Бикзадә – 1102
Бикколов Шакир – 119
Бикмиев Ә. – 122
Бикморатов – 123
Бикморза – 100
Бикморза – 548
Биктас – 906
Бикчәнтәй улы – 234
«Бирски» – 1054
Бичура – 627
Бичура – 822
Бичура – 843
Бишәрык – 365
Богдан – 68
Богдан Г. – 67
Борис – 125
Булышлы – 844
Большевик – 158
Борис Разин – 1070
Борһан Мансуров – 551
Борһан Шәрәф – 1034
Бохарадан бер кеше – 739
Бөек – 458
Бөрчә – 1106
Бүкәнче – 1003
Бүләк – 567
Булат – 85
Булат С. – 743
Булат Сәли – 743
Буран – 538
Буранбай – 140
Буф – 145
В. Әкрәм – 162
В. Бәхтияр – 153
В. Исхакый – 402
В. Мифтах – 568
В.Н. Хангилдин – 922
В. Нуруллин – 666
В. Солтанов – 772
В. Таначев – 816
В. Х. – 170
В. Чакан – 166
В. Якуб – 181
В. Ярулла – 172
Вагапов Г. – 160
Вагыйз Нәүрузов – 651
Вазыйх Исхаков – 403
Ваккас С – 803
Вакыйф Җәлял – 1140
Вакыйф Зыя – 356
Вакыйф Нуруллин – 666
Ванька – 581
Васфи – 588
Вахитов К. – 183
Вахитов Мулланур – 186
Вахиш – 1102
Ваһһап кызы – 1150
Вәкилә – 513
Вәли Исхаков – 402
Вәли Хангилдин – 922
Вәли Шәфигуллин – 1043
Вәлидов – 1069
Вәлиев Фәйзи – 161
Вәлитхан Таначев – 816
Вәлихан Чакан – 166
Вәлишин Якуб– 181
Вәлишина К. – 180
Вәсим Солтанов – 772
Волжская Русина – 297
Вөждан – 488
Выборщик – 513
«Г». – 843
Г. Игебаев – 375
Г. Рәхмәтуллин – 518
Г. А. – 22
Г. А. – 39
Г. А. – 41
Г. А. – 435
Г. Адак – 9
Г. Айтуганов – 18
Г. Акчура – 23
Г. Акчурин – 22
Г. Аликов – 40
Г. Алмай – 37
Г. Алпар – 39
Г. Амантай – 41
Г. Афзал – 57
Г. Ахунов – 58
Г. Әлми – 1092
Г. Әмири – 1096
Г. Әпсәләмов – 1095
Г. Әфтах – 216
Г. Әхмәди – 1121
Г. Әхмәтшин – 1136
Г. Б. – 69
Г. Б. – 88
Г. Баембәт – 69
Г. Байбурин – 73

Г. Байдилде – 76
Г. Байкин – 80
Г. Бакый Урманче – 870
Г. Баруди – 92
Г. Баттал – 95
Г. Баһаветдинов – 103
Г. Бәшир – 156
Г. Бәян – 300
Г. Биги – 594
Г. Биктимирия – 124
Г. Богданов – 67
Г. Болгарская – 128
Г. Бүкәйхан – 135
Г. Буби – 130
Г. Вәлид – 168
Г. Вәлиев – 163
Г. Г. – 285
Г. Г. – 301
Г. Г. – 305
Г.Г. Дәүләт – 325
Г. Газиз – 223
Г. Газиз – 285
Г. Газиз Сакмари – 223
Г. Гали – 236
Г. Гали – 237
Г. Галимов – 58
Г. Гафуров – 271
Г. Гобәй – 288
Г. Гобәйди әл-Кыдырлы – 286
Г. Гобәйдуллин – 285
Г. Гомәр – 237
Г. Гомәрев – 290
Г. Гөлчәһрә – 269
Г. Гыйсмәти– 303
Г. Д. – 318
Г. Д. – 286
Г. Дәүләтов – 325
Г. Дәүләтшин – 326
Г. Дим – 945
Г. Динмөхәммәтов – 318
Г. Донской – 315
Г. Еники 337
Г.Җ. Сәйфуллин – 794
Г. Закир улы – 420
Г. Заһидова – 82
Г. Зәйнашева – 345
Г. И – 367
Г. И. – 361
Г. И. – 376
Г. Ибраһимов – 361
Г. Ибраһимов – 364
Г. Идриси – 376
Г. Ильяс – 994
Г. Ильяси – 383
Г. Исәнбирде – 412
Г. Исәнбирдин – 412
Г. Исламханов – 396
Г. Исхакый – 401
Г. Ишимов – 419
Г. К. – 199
Г. К. – 439
Г. К. – 467
Г. К. – 475
Г. Казани – 439
Г. Камал – 335
Г. Камал – 439
Г. Камалетдинова – 439
Г. Камилов – 1095
Г. Кандалый – 446
Г. Караш – 452
Г. Караш улы – 452
Г. Кари – 457
Г. Кариев – 457
Г. Касыймов – 464
Г. Касыймов – 463
Г. Кәрам – 518
Г. К-ва – 439
Г. Коләхмәтов – 475
Г. Котдус – 199
Г. Курсави – 504
Г. Кутуй – 505
Г. Кушай – 506
Г. Л. – 521
Г. Л. – 522
Г. Латыйпов – 522
Г. Лотфый – 525
Г. М. – 35
Г. М. – 530
Г. М. – 552
Г. М. – 572
Г. М. – 716
Г. Максудов – 530
Г. Мамай – 439
Г. Мангуш – 548
Г. Мансуров – 552
Г. Мәгази – 604
Г. Мәсгуд – 610
Г. Мәхмүдов – 555
Г. Минский – 35
Г. Монасыйпов – 618
Г. Мөслими – 622
Г. Мөслимов – 624
Г. Н. – 655
Г. Н. – 660
Г. Насыйри – 645
Г. Нигъмәти – 654
Г. Нигъмәти – 655
Г. Нур – 1145
Г. Р. – 1152
Г. Р. – 234
Г.Р. Мозаффаров – 572
Г. Разин – 156
Г. Рамазанов – 681
Г. Рафыйков – 684
Г. Рафыйкый – 685
Г. Рахманкулов – 696
Г. Рәис – 202
Г. Рәхим – 1152

Г. Рәхим – 234
Г. Ризванов – 708
Г. С. – 779
Г. С. – 811
Г. Сакмари – 223
Г. Салих улы – 285
Г. Сәгъди – 779
Г. Сәгыйдуллин – 731
Г. Сәйфи – 791
Г. Сәлимгәрәев – 799
Г. Сәлман – 285
Г. Сирай – 768
Г. Солтанәхмәт – 217
Г. Сөләймани – 807
Г. Сөнгати – 811
Г. Сөнгать – 811
Г. Т. – 833
Г. Терегулов – 834
Г. Толымбай – 833
Г. Тукай – 843
Г. Уральский – 863
Г. Утыз Имәни – 876
Г. Фәхретдин – 900
Г. Фәхри – 903
Г. Халид – 914
Г. Харис – 928
Г. Хәбиб – 958
Г. Хәбиб – 955
Г. Хәйри – 963
Г. Хәсәни – 994
Г. Хисам – 955
Г. Хөсәенов – 937
Г. Хуҗи – 954
Г. Ч. – 271
Г. Чокалый – 1006
Г. Чокрый – 519
Г. Шамук – 1022
Г. Шамуков – 1022
Г. Шәрәф – 1036
Г. Шәрәф – 1037
Габбас Сәйфи – 791
Габдебари – 39
Габделбакый сурәтче – 870
Габделгабит – 215
Габделгазиз – 285
Габделгазиз Тәфкилев – 858
Габделгалләм Фәезхан – 890
Габделгаттарлар күршесе – 561
Габделҗаббар Кандалый – 446
Габделҗәлил – 198
Габделкәрим С. – 778
Габделтатар Камбальск – 408
Габделхак Игебаев – 375
Габделхәй Динмөхәммәтов – 318
Габделхәмит Мөслими – 622
Габденнасыйр – 504
Габдерәхим Болгари – 876
Габди – 361
Габдийүш – 160
Габдрахман Вәлиди – 168
Габдрахман Гомәрев – 290
Габдрахман Кәрам – 518
Габдрахман Минский – 35
Габдрахман Рафыйков – 684
Габдрахман Рәсүлев – 719
Габдрахман Сәгъди – 779
Габдрахман Фәхри – 900
Габдүш Вагапов – 160
Габдулла Әүлани – 1130
Габдулла Әхмәт – 1123
Габдулла Әхмәтшин – 1136
Габдулла Биги – 594
Габдулла Буби – 130
Габдулла Вәли – 163
Габдулла Г. – 301
Габдулла Гомәров – 289
Габдулла Гыйсмәти – 303
Габдулла Ибраһимов– 360
Габдулла Капкаев – 449
Габдулла Кариев – 457
Габдулла Мостакай – 594
Габдулла Мөштак – 452
Габдулла Сөбханкул – 776
Габдулла Сөләймани – 807
Габдулла Уральский – 863
Габдулла Усаев – 872
Габдулла Фәхри – 903
Габдулла Шөнаси – 360
Габдуллаев Төхфәтулла – 184
Габдуллин И. – 195
Габдуллин Мөслим – 207
Габдуллин Рәшит – 206

Габиди Исмәгыйль – 209
Габидов Хәбибулла – 214
Габитов Камал – 335
Габкаһар – 158
Гадел – 220
Гадел – 318
«Гаделев» – 219
Гадел Кутуй – 505
Гает-бану – 17
Гаҗизә – 51
Гази Ибраһим – 561
Гази Кашшаф – 467
Гази Край – 561
Газиз әл-Укмасый – 344
Газиз Иделле – 377
Газиз Монасыйпов – 618
Газиз Салих улы – 285
Газиззадә – 222
Газизов Лотфулла – 224
Гай – 17
Гай – 823
Гайнан Әмири – 1096
Гайнан Хәйри – 908
Гайнан Хәйри – 963
Гайнетдин – 547
Гайн-нун – 655
Гайрәти – 192
Гайса Еникеев – 337
Гайсә Хөсәенов – 937
Гайсә Юсупов – 1059
Гай-у – 89
Гайфи Сәхи – 231
Галә Ходаяр – 945
Галәветдин Гыйрфанов – 306
Гали – 1068
Гали – 233
Гали Бирскәви – 519
Гали Гомәр – 237
Гали Зөлкарнәй – 353
Гали Ибраһим – 364
Гали Касыймов – 464
Гали Путиляков – 679
Гали Рафыйкый – 685
Гали Рәхим – 234
Гали Халид – 914
Гали Хәбиб – 958
Гали Хуҗи – 954
Гали Чокрый – 519
Галиәсгарь Гафури – 271
Галиев – 334
Галиев Габдулла – 235
Галим Максудов – 532
Галимә Рәхмәтуллина – 1158
Галимәрдан Тупчебашев – 849
Галимәтелбәнат – 124
Галимҗан Акчурин – 22
Галимҗан Баруди – 92
Галимҗан Идриси 376
Галимҗан Латыйпов – 521
Галимҗан Нигъмәти – 655
Галимҗан Сәйфетдинов – 794
Галимҗан Шәрәф – 1036
Галләм Дәүләтшин – 327
Галләмхан Ислами – 396
Гамил Афзал – 57
Гамир Насыйри – 645
Гамь – 35
Ганкәбут – 713
Гарәпша – 751
Гарби – 793
Гариф Биккинин – 116
Гариф Галиев – 236
Гариф Гобәй – 288
Гариф Латыйпов – 522
Гариф Мусин – 595
Гариф Шәрифи Чистай – 1041
Гарифьянов Н. – 1154
Гасыйм Лотфый – 525
Гата малае – 552
Гата Нуруллин – 665
Гатаулла – 1077
Гатина Хәмидә – 1149
Гауряш – 730
Гафи – 1000
Гафил бине Габдулла – 901
Гафур Голәм – 267
Гафур Коләхмәтов – 475
Гафур Төхтәмит – 855
Гаяз – 401
Гаяз Максуди – 530
Гаязов Мансур – 273
Гәрәй Рәхим – 1152
Г-җан И – 361
Г-җан Ибраһим – 361
Гизләви И.С. – 277
Гн. – 660
Гобәй Буби – 131
Гобәйдулла Әсәдулла – 944
Гобәйдулла Нигъмәти – 654
Гобәйдулла Хаджаев – 944

Голәм – 267
«Гөлҗамал» – 189
Гомәр Бәшири – 156
Гомәр Гали – 237
Гомәр Караш баласы – 452
Гомәр Мулла Иле – 1160
Гомәр Разин – 156
Гомәр Терегулов – 834
Гомәр Толымбайский – 833
Гомәр Хисаметдинов – 936
Гомдә Хәбиров – 959
Госманов Хатип – 295
Гөләй – 505
Гөләндәм – 106
Гөлгазар – 593
Гөлгыйзар – 234
Гөлҗамал – 101
Гөлсем Болгарская – 128
Гөлташ – 690
Гөлчәһрә Байкина – 82
Гөлчәһрә Гафурова – 269
Гөлшат – 345
Гөлшат Зәйнашева – 345
Гөмберт – 843
Гп – 679
Грачев – 77
Гуд – 168
Гы. Ә. – 1092
Гыг – 305
Гыйбрәт – 405
Гыйлаҗ Фәсхи – 892
Гыйлемдар Рамазанов – 681
Гыйлмуҗ – 305
Гыйльми Шәрәф – 1037
Гыймад Байгилде – 75
Гыймадиев М. – 304
Гыймат Нугайбәк – 660
Гыйнаятулла Әхмәди – 1121
Гыйниятов Х. – 284
Гыйрк – 307
Гыйрфан ахун – 302
Гыйрфан улы – 361
Гыйрфанзадә – 361
Гыйрфанов Г. – 301
Гыйсмәти – 303
Гыйсмәтуллин Г. – 303
Гыйсъян – 794
Гыйффәт туташ – 143
Д. Аппакова – 43
Д. Ә. – 323
Д. Зәйни – 346
Д. Исламов – 395
Д. Киекбай – 470
Д. Юлтый – 1051
Давытгәрәй – 919
Дамавай – 820
Даменла – 1108
Дамулла – 414
Данис Исламов – 395
Дасаев И. – 310
Дауд Юлтый – 1051
Даян Кадыйр 333
Дәврани – 362
Дәлил Әсгарь – 323
Дәмин – 324
Дәрвиш – 662
Дәрвиш – 852
Дәрдеменд – 714
Дәрҗия А. – 43
Дәүләтәли М. – 321
Дәүләтшин Гобәй – 326
Дәһри – 158
Дәһри Ибрай – 280
Демьян Фәтхи – 895
«Ди» – 1051
Дивана – 590
Ди-ди – 534
Дилбәр – 1008
Дим – 514
Дим Баязит – 317
Димский – 388
Догачы Шүрәле – 843
Домолазов Степан – 314
Дулатов М. – 322
Дулкын – 157
Думбыл дивана – 425
Думбылбай – 425
Е. Саттар – 340
Евгений – 1070
Елга аръягы төпче – 670
Емельянов Я – 336
Еникеев Нигъмәт – 339
Житель – 546
Җ. Абызгильдин – 3
Җ. Байкин – 79
Җ. Вәлиди – 179
Җ. И. – 1052
Җ. Тәрҗемани – 857
Җ. Фәйзи – 886
Җ. Юмай – 1052
Җал – 562
Җалкынбай – 808
Җамакай – 844
Җамал Вәлиди – 179
Җамалетдин Юмаев – 1052
Җамали – 152
Җан Шәрәф – 1036
Җанбай – 534
Җасур – 347

«Җәй» – 1052
Җәлалетдин
Мәннани – 198
Җәләй – 179
Җәләэтдин улы – 900
Җәнҗалов – 724
Җәүдәт Фәйзи – 886
Җәяү сәях – 711
Җигәй – 30
Җидегән – 1105
Җиргән – 1105
Җиян – 425
Җолканбай – 425
Җомагол – 904
Җүнәй Ф. – 883
Җылтыр күз – 928
З. Хибия – 143
З. Һади – 348
З. Аюхан – 62
З. Байкин – 77
З. Байчурина – 86
З. Баязитский – 105
З. Бәшири – 154
З. Бәширова – 155
З. Биги – 110
З. Биишева – 109
З. Газизова – 537
З. Гыйльман – 1035
З. Заманов – 554
З. И. – 350
З. Кадыйр – 426
З. Килбәти – 468
З. Максудова – 537
З. Маликов – 538
З. Маликов – 539
З. Мансур – 554
З. Н. – 662
З. Насыйри – 646
З. Нури – 667
З. Познякова – 672
З. Рәмиев – 714
З. Сәгыйдә – 1063
З. Сәфәргали – 762
З. Солтан – 773
З. Тулбин – 846
З. Хәбиб – 346
З. Хисмәтуллин – 939
З. Юсупов – 1032
З. Якупова – 1063
З. Ярмәки – 647
Задә – 1102
Закир – 145
Закир әл-Кадыйр – 426
Закир Сафин – 757
Закир улы – 145
Закир Һади – 1084
Закир Һади – 348
Закирә Кәримия – 1035
Закирә Шәрәф – 1035
Зариф Әмирханов –
1107
Зариф Бәшири – 154
Зариф Мозаффар – 573
Зариф Рәхмәтуллин –
706
Зариф Садыйков – 581
Зариф Сәфәргалиев –
762
Заһид Нуркин – 662
Заһид Шамил – 1015
Заһид Шәркый – 1032
Заһидә Борнаш – 143
Заһир Биги – 110
Заһит Йосфи – 1032
Зәит Мәзит – 605
Зәйнәп Камалетдино-
ва – 439
Зәйнәп Максудова – 537
Зәйнәп Познякова – 672
Зәйнәп Хөсни – 995
Зәйнәп Якупова – 1063
Зәйни Солтан – 773
Зәйнулла ишан – 718
Зәкәрия Садри – 734
Зәки Вәлиди – 174
Зәки Гыйманов – 283
Зәки Закиров – 349
Зәки Нури – 667
Зәлин – 561
Зәмзәметдинов – 1108
Зәңгәр Әхмәт – 885
Зәүкый – 748
Зәүкый – 779
Зизаг – 377
Зиһни – 640
Зөлфәкарый К. – 355
Зөлфәт – 538
Зөһрә Салихова – 744
Зыя Камал – 440
Зыя Маликов – 539
Зыя Мансур – 554
Зыя Насыйри – 646
Зыя Өммәти – 1143
Зыя Сәит – 749
Зыя Янгалычев – 1073
Зыя Ярмәки – 647
И. Б. – 117
И. Башмаков – 100
И. Бикмөхәммәдев –
133
И. Б-к. – 100
И. Богданов – 68
И. Борнаш – 142
И. Габдуллин – 195
И. Габиди – 209
И. Гази – 561
И. Гыйззәтуллин – 279
И. Гыйззәтуллин – 278
И. Еникеев – 338
И. Закиров – 351

И. Йосфи – 507
И. Казаков – 428
И. Кули – 494
И. Лиманов – 523
И. М. – 363
И. Мирза – 363
И. Надиров – 1151
И. Нуруллин – 664
И. Рахман – 695
И. Рәми – 713
И. Рәхмәтуллин – 705
И. Сәлахов – 745
И. Туктар – 844
И. Фәрид – 370
И. Хәлим – 394
И. Хәлим – 972
И. Һилал – 385
И. Шаммаси – 1017
И. Шәфиев – 1042
И. Ширванский – 397
И. Яһүдин – 1080
Иблис – 401
Ибне Хәсәнел-Болгари – 661
Ибнеямин – 794
Ибрай Гази – 561
Ибрай Кули – 494
Ибраһим Борнашев – 142
Ибраһим Гази – 561
Ибраһим Гафури – 272
Ибраһим Гомәрев – 293
Ибраһим Гыйльфанов – 280
Ибраһим Зиннәтула – 664
Ибраһим Йосфый – 507
Ибраһим Моратов – 581
Ибраһим Сәлахов – 745
Ибраһим Таһири – 826
Ибраһим Терегулов – 835
Ибраһим Ф. – 370
Ибраһим Хәлим – 972
Ибраһимов – 371
Ибраһимов Биккол – 117
Ибраһимов Нәгыйм – 1147
Ибраһимов Фәрид – 370
Ибраһимов Хәбиб – 371
Ибраһимов Шәймәрдан – 373
Игебай Габделхак – 375
Иген игүче – 145
Иделле – 377
Идрис Туктар – 844
Иҗикбатыр – 191
Ик – 428
ИК – 494
Икрамов Әкмал – 381
Икътисадчы – 583
Ил мөхбире – 593
Ил улы – 89
Илгәр – 267
Илгиз – 687
Илгиз Кәлимуллин – 432
Илгизәр – 462
Илдус Гыйззәтуллин – 279
Ильская Фатыйма – 386
Ильский – 697
Имам хатыйп – 843
Иманаев Миргаяз – 389
Иманаев Шәехгаттар – 390
Иманколый Садыйк – 391
Иманский – 582
Имгәк – 1108
Имзасыз да Яраретдинов – 843
Инан – 808
Инҗик – 559
Ирдас – 733
Ирдәс Садри – 178
Иркәбай – 425
Иркен – 691
Иртугрул – 1010
Исәнбай – 793
Исбах Таһиров – 827
Исболдов Морза Казый – 399
Исмәгыйль Кугушев – 486
Исмәгыйль Лотфый – 397
Исмәгыйль Рәми – 713
Исмәгыйль Хантимеров – 927
Исмәгыйль Һилалов – 385
Исмәгыйль Шәфиев – 1042
Исмәгыйль Ширванский – 397
Исрафил – 296
Исхак Е. – 338
Исхак Закиров – 351
Исхак Казаков – 428
Исхак малае – 409
Исхак Рәхмәтуллин – 705
Исхаков Рәхмәтулла – 596
Ихсанов Әхмәт – 416

Ихсанова Ләбибә – 415
Иш – 469
Ишан – 439
Ишан мөнкире – 843
Ишангали – 439
Ишемгулов Булат – 420
Ишетүче – 454
Ишми ишан – 320
Й. Акчура – 24
Й. Акчурин – 24
Й. М. – 1065
Й. Шәркый – 1032
Йолдыз Вәлиди – 177
Йосыф Дибердеев – 316
Йосыф Ибраһимов – 372
Йосыф Мозаффаров – 579
Йосыф солдат – 507
Йосыф Шәркый – 1032
К. – 593
К. Абрамов – 2
К. Гыйрфанов – 307
К. Армиец – 87
К. Әмири – 1106
К. Әхмәт – 593
К. Б. – 149
К. Баһман – 102
К. Биккол – 118
К. Бөдәйли – 157
К. Габидуллин Минзәләви – 275
К. Гобәй – 495
К. Даян – 333
К. Депутат – 990
К. Исхак – 428
К. К. – 495
К. Карип – 460
К. Карипов – 460
К. Катибә – 473
К. Кәримов – 510
К. Кормаши – 498
К. Кулаткый – 495
К. Мостакай – 593
К. Мотыйгуллин – 860
К. Н. – 648
К. Насыйри – 648
К. Патин – 676
К. Р. – 593
К. Рәхим – 593
К. С. – 777
К. С. – 778
К. Сәгыйть – 778
К. Тинчурин – 839
К.Үзбәк – 839
К. Х. Ф. – 918
К. Хаджаев – 941
К. Халиди – 912
К. Хәмзин – 917
К. Хәсәнов – 990
К. Шамил – 1016
К. Шамил – 466
Кабан – 414
Кави Нәҗми – 670
Кадир Хадҗаев – 941
Кадрия – 448
Кадыйр Гайнан – 228
Казакъ Г.К. – 452
Казалы казасы – 786
Казанлы – 793
Казбек – 505
Кайгыртучы – 516
Кайчылы – 627
Какра – 28
Каләм – 513
Каләм – 8
Каләм каш – 454
Калвак мәхзүм-Шаши – 425
Календарь – 806
Камай – 814
Камал I – 436
Камал II – 438
Камал III – 437
Камал Әгъзам – 433
Камалетдинов Әгъзам – 444
Камали – 445
Камали малае – 445
Камалова Фатыйма – 443
Камил – 307
Камил Кәримов – 510
Камил Мотыйги – 860
Камил Фасиев – 891
Камилә Валиуллина – 180
Кан – 670
Канәҗ – 670
Кангазәл (Кави белән Закир Гали) – 670
Канзафәров Локман – 447
Капкаев Г. – 449
Капкаев Г. – 451
Каплан – 414
Кара малай – 56
Каразадә – 607
Каракүз – 65
Карасакал – 414
Карәхмәт – 408
Кармакбай – 607
Карт студент – 158
Карт Чаян – 1106
Карт эшче – 513
Карчыга – 627
Карыйзадә – 454
Касыйм – 840
Касыйм Биккол – 118

Касыйм Вахитов – 183
Касыйм Туйбахтин – 840
Касыйм Фәтхетдинов – 895
Касыйм Халид – 912
Касыйм Хәмзин – 917
Касыйм Шакирҗан – 1012
Касыйм Шамил – 1016
Касыйм Шамил – 466
Касыймов Газим– 463
Касыймов Йосыф – 465
Касыймский – 598
Катибә Киньябулатова – 473
Качимский – 598
Кашшаф Гази – 467
Кашшаф Патин – 676
Кашшафетдин Каркаралы – 275
Кашшафчы – 738
Каюм Җулбатый – 102
Каюм Насыйри – 648
Каюм Рәхим – 593
Каюм Саттаров – 754
Кәбир Бәкер – 149
Кәбүли – 157
Кәкәмәрун – 561
Кәләй – 1106
Кәли – 1000
Кәли – 445
Кәлимулла Хәсәнов – 990
Кәлимуллин И. – 432
Кәмпер – 425
Кәрим Әмири – 1106
Кәрим Рәхим – 508
Кәрим Сәгыйть – 778
Кәрим Тинчурин – 839
Кәрими М-фатих – 513
Кәримов Хәниф – 515
Кәүкәб – 1023
Кәүкәб – 536
Кәшиф Кормаши – 498
Кәшфи Бөдәйли – 157
Кәшфи К – 460
Кәшфизадә – 158
Кәшшаф Тәрҗемани – 856
Квилд – 307
Кемий – 1024
Кечкенәкәй – 1003
Кечкенәкәй – 299
Кечкентәй – 299
Кигәвен – 158
Киекбаев Җәлил – 470
Килбәтов Зиннәт – 468
Ким Әхмәтҗанов – 1134
Кинҗәтай – 197
Кирәй Мәргән – 474
Кисекбаш – 408
Колмаери – 895
Колмөхәммәтов Я. – 492
Корбангали Әхмәтов – 1133
Корбангалиев Мөхетдин – 477
Корбанов Таһир – 489 а
Кормаши Әхсән – 501
Кормашилар – 499
Корчагин – 862
Коры философ – 414
Корыч – 463
Котбетдин – 1086
Котлы – 481
Көләр – 469
Көлемсәр – 1099
Көлке баш – 771
Кредо – 467
Кротов Рамазан – 483
Крыймов Мансур – 485
Крыймов Миргазиян – 484
Күгәй – 89
Күзәтүче – 516
Күзле ут – 1105
Күкташ – 414
Күпкински-Чүпкински – 170
Күрәзә – 299
Күсә – 267
Күсә ирсакал – 267
Кулалаев – 491
Кусинов – 961
Кучкар елы – 844
Кушаев Ибраһим – 507
Кушмый ишан – 320
Кызыл – 1068
Кызыл – 439
Кызыл җырчы – 885
Кызыл йөрәк – 1020
Кызыл солдат – 531
Кызыл солдат – 87
Кыйссасел-әнбия Рабгузи – 843
Кылыч – 488
Кылычбай – 488
Кыпчак – 357
Кырмыска – 843
Кырыкбаш Имәни – 408
Кырыкбаш Имәнлесенең бер туганы – 408
Кыям А. – 2
Кыям Юлдаш – 1050
Л. Гомәрев – 291
Л. Җәләй – 1142

Л. Мостафа – 599
Лаппаси – 50
Латыйф Гомәрев – 291
Латыйф Җәләй – 1142
Латыйф Мостафа – 599
Латыйф Хәмиди – 983
Лачын – 851
Ләбибә Ихсанова – 415
Ләйләтин – 147
Ләкләк мәхзүм – 425
Ләлин – 147
«Ләм» – 599
Локман Гыйләҗев – 282
Локман Хәким – 282
Локман Хәким – 447
Лопатинский – 639
Лотфи Гадел – 221
Лотфи Гадел – 524
Львов Михаил – 526
М. – 531
М. Аблаев – 1
М. И. – 363
М. Сөндекле – 535
М. Аблаев – 1
М. Акчурина – 25
М. Алиев – 629
М. Ә. – 1105
М. Әли углы – 629
М. Б:Мб. – 158
М. Басыйров – 93
М. Биги – 111
М. Бикбулат – 114
М. Биккинин – 116
М. Борнашев – 144
М. Борындыков – 129
М. Бөдәйли – 158
М. Бөдәйли – 159
М. Буби – 132
М. Бурангол – 139
М. Вахитов – 186
М. Вәдүд – 568
М.Г. Әхмәтшин – 1097
М. Габдрахманов – 201
М. Гайнетдин – 226
М. Гайнуллин – 225
М. Гайнуллин – 227
М. Галәү – 607
М. Гаяз – 273
М. Д. – 321
М. Давидов – 308
М. Җ. – 1141
М. Җәлил – 1141
М. Иманаев – 389
М.К. Калтай – 563
М. Кадермәти – 423
М. Калтай – 563
М. Кәрим – 511
М. Кәримов – 512
М. Конов – 476
М. Корбангалиев – 477
М. Крыйм – 485
М. Крыймов – 484
М. Курми – 497
М. Львов – 526
М. М. – 531
М. М. – 549
М. М. – 607
М. Мазунов – 527
М. Максуд – 531
М. Маннапов – 549
М. Мәкки – 606
М. Мәрҗани – 607
М. Мирвәлиева – 1153
М. Мозаффария – 577
М. Мостафа малае – 1141
М. Мөхәммәдев – 626
М. Мөхәммәдьяр – 628
М. Мөштәри – 636
М. Мөштәри – 637
М. Ногман – 658
М. Парсин – 675
М. Рәшиди – 210
М. Садри – 735
М. Сөләйманов – 809
М. Таҗи – 831
М. Таһиров – 824
М. Тимербулат – 35
М. Турагиров – 850
М. Укмасый – 344
М. Урманчиева – 871
М. Ф. – 878
М.Ф. Туктаров – 845
М. Фазлуллин – 878
М. Фәйзи – 877
М. Фәйзи – 881
М. Х. – 477
М. Х. – 997
М. Халиков – 916
М. Хәй – 632
М. Хәйдәров – 907
М. Хәмәдиев – 953
М. Хәмитов – 987
М. Хәнәфи – 431
М. Хәррасов – 953
М. Хөсәен – 997
М. Хуҗин – 953
М. Һади – 158
М. Һинди – 423
М. Ш. – 627
М. Я. – 1065
Майна – 766
Макс – 531
Максуд Сөндекле – 535
Маликов Әдип – 542
Мамли – 546
Маннур Саттаров – 812
Мансур Гаяз – 553

Мансур Мозаффаров – 578
Марат Кәрим – 511
Марат Рахманкулов – 698
Марзия Даутова – 312
Марксист – 1108
Маруз – 472
Маһри – 1029
Маһруй Мозаффария – 575
Машаяк – 627
Мәгъзави – 950
Мәдинә Ямангулова – 1067
Мәҗит Әсгать – 617
Мәҗнүн – 843
Мәзитов Зәит – 605
Мәзлум – 881
Мәйле – 1102
Мәктәпче – 945
Мәлгунь – 1055
Мәлгунь – 414
Мәлих Харис – 930
Мәмә Сабир – 191
Мәңгелек юлчы – 89
Мәргән – 414
Мәрдегаләм Мөхәммәдев – 626
Мәрдкяр – 1055
Мәрьям Бөдәйли – 636
Мәрьям Кугушева – 540
Мәрьям Мөштәри – 636
Мәрьям Рахманкулова – 702
Мәсгуд Идиятуллин – 378
Мәүла Колый – 611
Мәүләнгафур – 469
Мәфтуха Вәлитова – 1159
Мәхмүд Максуд – 531
Мәхмүдә Мозаффария – 871
Мәхмүдә Урманчиева – 577
Мәхмүдов Гали – 555
Мәхмүт Дәүләтәли – 321
Мәхмүт Мәрҗани – 607
Мәхмүт Фуат – 845
Мәхмүт Хөсәен – 997
Мәхмүт Һади – 158
Мәхубҗамал Акчурина – 25
Мәшрәб – 1029
Мәшрәб Фәрганәли – 590
Мик – 631
Миләүшә – 790
Милләтче – 840
Милләтче – 843
Мим – 406
Мим – 531
Мим – 631
Мин – 607
Мин сиңа әйтим – 607
Мин түгел – 158
Мин язмадым – 843
Минзәләви – 275
Миниев Гатаулла – 560
Минһаҗ Гыймадиев – 304
Минһаҗ Кадерммәти – 423
Минһаҗ Конов – 476
Миңнулла Вахитов – 184
Мир – 1105
Мирәк – 514
Мирвәли калтай – 563
Миргазиз Укмасый – 344
Миргазизел Укмасый – 344
Мирза – 947
Мирза Давидов – 308
Мирзагали Саинов – 737.
Мирмөхсин – 566
Мирсәит Сафин – 758
Мирсәй Әмир – 1105
Миртимер – 851
Мирхәйдәр Фәйзи – 881
Мирьякуп Д. – 322
Мирьякуп Дулатов – 322
Мисбөдәл – 159
Мискин – 1008
Мискин – 818
Мифтах Вәдүд – 568
Мишәр – 145
М-нур Вахитов – 186
Мокамай – 814
Мокамайның якын кардәше – 814
Моңсыз – 1033
Морад – 901
Морат Мәкки – 606
Мортаза Әҗимов – 1129
Мортый Я. – 1065
Мортый Якуб – 1065
Мостай Кәрим – 512
Мостафа Лотфи – 397
Мостафа Ногман – 658
Мохтаҗи – 739

Мохтар Мутин – 602
Мохтарбад – 631
Мөгаллим Гаян – 593
Мөганни – 36
Мөдәррис Сөләйманов – 809
Мөдәррис Фәйзи – 882
Мөнәвәр карый – 210
Мөнир Ибраһимов – 366
Мөнир Мазунов – 527
Мөнир Һади – 1083
Мөнир Һади – 620
Мөрәттиб – 363
Мөртәт – 844
«Мөселманин» – 771
Мөслим Марат – 623
Мөслими әл-Болгари – 621
Мөтәллид – 766
Мөфәссир – 860
Мөхәммәд Парсин – 675
Мөхәммәд Садри – 735
Мөхәммәдгали Рәхим – 234
Мөхәммәди Габидуллин – 276
Мөхәммәдша Б. – 139
Мөхәммәт Әхмәтгалиев – 1125
Мөхәммәт Галиев – 1125
Мөхәммәт карый Болгари – 585
Мөхәммәт Садыйк – 391
Мөхәммәтҗан хафиз – 1116
Мөхәммәтфатих Кәрими – 513
Мөхәммәтхан Фазлуллин – 878
Мөхәррәмов М. – 635
Мөхбир – 158
Мөхлисә Буби – 132
Мөшриб – 935
Мөштем – 425
Мулла – 1028
Мулла Казакаев – 452
Мулла монтагай һәм сәүдәгәр кулаклар оешмасы – 158
Мулла Тиртыйк – 631
Мулла Хайратый – 503
Мулла шалган – 738
Муллаҗан Халиков – 916
Муса Акъегетзадә – 26
Муса Алтынбай – 26
Муса Бигиев – 111
Муса Габдулла – 111
Муса Габдулла – 95
Муса Җарулла – 111
Муса Җәлил – 1141
Муса Юсупов – 1060
Мусин Ногман – 601
Мусин Флүн – 1144
Мусинский – 406
Мусинский – 596
М-Һ Атласи – 53
Н. Исәнбәт – 414
Н. Арапова – 44
Н. Арслан – 46
Н. Асанбай – 48
Н. Баян – 106
Н. Бәхтияров – 152
Н. Гайсин – 230
Н. Гамир – 645
Н. Гасрый – 612
Н. Гыйззәтуллин – 1145
Н. Дәүли – 332
Н. Думави – 820
Н. Еники – 339
Н. Зарипов – 352
Н. Зәки – 667
Н. Зыя – 646
Н. Ибраһим – 1147
Н. Илбарис – 1151
Н. Ишаев – 417
Н. Карипов – 461
Н. Кәрипов – 517
Н. Кизанов – 667
Н. Мәмлиев – 545
Н. Мусин – 601
Н. Надиев – 639
Н. Нариман – 641
Н. Насыйри – 644
Н. Рәхимов – 692
Н. Робтый – 417
Н. Түнтәри – 669
Н. Түрәкулов – 852
Н. Хәлфин – 979
Н. Шаһбаз – 668
Надиров Илбарис – 1151
Нажар Нәҗми – 671
Назчы – 766
Найза – 268
Намакаб – 852
Наразый – 394
Наразый – 902
Нариман Мостафин – 600
Нариманов Н. – 641
Насыйри Имай – 644
Насыйров Зыя – 647
Нәби Дәүли – 332
Нәҗип Асанбаев – 48
Нәҗип Гасрый – 612
Нәҗип Думави – 820

Нәҗип Корбангали – 478
Нәҗип мәхзүм – 669
Нәҗип Түнтәри – 669
Нәҗип Түнтәри – 848
Нәҗип Хәлфин – 979
Нәзир Түрәкулов Ю. – 852
Нәкый Исәнбәт – 414
Нәкый Шаһбаз – 668
Нәкыя – 790
Нәсими – 194
Нәүрузов В. – 651
Нәүширван Я. – 1079
Нәүширван Яушев – 1079
Нигъмәт Хәким – 969
Низам Кәрипов – 461.
Низам Кәрипов – 517
Николай – 1070
Николай Ибраһимов – 368
Нихан – 968
Нияз Колый – 533
Нияз Максуди – 533
Ногманов Камил – 657
Ногманов Сәлим – 659
Номерсыз урындык – 145
Нузад – 598
Нур – 531
Нур Баян – 106
Нур В. – 186
Нур Гайсин – 230
Нур Гыйззәтуллин – 1145
Нур Зарипов – 352
Нургали әл-Болгари – 661
Нургали әл-Хәсәни – 661
Нургали Надиев – 639
Нургаяз Гарифьянов – 1154.
Нури Арслан – 46
Нури Вафин – 167
Нури Сакаев – 740
Нурихан Фәттах – 893
Озын колак – 513
Очкын – 31
Өй анасы – 820
Өмәрбик – 1056
Өндәмәс – 562
Өндәмәс – 1130
Панфиловчы – 1161
Партави – 630
Парчинский – 662
Пәрвәз Камали – 440
Пәтәнә – 683
Перс – 235
Пиннати – 455
Позняков – 677
Полкан – 921
Пономорев Хәсән – 674
Путиляк – 781
Р. Башкур – 99
Р. Бикбай – 112
Р.Г. Габитов – 526
Р. Габдрахманов – 234
Р. Габидуллин – 212
Р. Гали – 234
Р. Гыйлемдар – 681
Р.З. Сәгъдиев – 782
Р. Ибраһим – 359
Р. Ильяс – 384
Р. Кузеев – 502
Р. Мозаффаров – 572
Р. Низамов – 653
Р. Рәкыйби – 680
Р. С. – 686
Р. Сафин – 759
Р. Сөббух – 686
Р. Төхфәтуллин – 854
Р. Фәйзуллин – 880
Р. Хәкимов – 910
Р. Хуҗа – 687
Р. Шәйхетдинов – 1009
Рабига Габитова – 1156
Равил Бикбай – 112
Равил Фәйзуллин – 880
Рамазан Кузеев – 502
Рамир – 193
Рания Ишморатова – 422
Раттас – 340
Рафаэль Төхфәтуллин – 854
Рафыйков Сөббух – 686
Рахман Ильяс – 384
Рахман Ильяс – 695
Рәисә – 296
Рәис Габдрахманов – 202
Рәис Низамов – 653
Рәкыйб Шәйхетдинов – 1009
Рәкыйп Рәкыйби – 680
Рәмог – 237
Рәмул – 786
Рәтмир – 416
Рәүф Сабиров – 725
Рәхим Кәрим – 720
Рәхмай Мусинский – 596
Рәхмәти С – 721
Рәхмәтулла Әмирхани – 1109
Рәхмәтулла малае – 704

Рәшид Фәхри – 902
Рәшит казый – 359
Рәшит Нигъмәти – 656
Ренат Харисов – 931
Риза Ишморат – 421
Ризаэтдин бине Фәхретдин – 901
Рим – 514
Робтый – 417
Рөстәм Башкуров – 99
Рузадар – 739
Руслан – 505
Рухи – 779
С. Агиш – 7
С. Айдар – 12
С. Айнулов – 16
С. Атнагул – 56
С. Аягузи – 63
С. Әдһәмова – 1099
С. Б. – 115
С. Байкина – 78
С. Баттал – 96
С. Батыршин – 769
С. Баязитов – 104
С. Бикбулат – 115
С. Булат – 136
С. Г. – 223
С. Габәши – 217
С. Гайни – 229
С. Гайфи – 231
С. Гафуров – 270
С. Д. – 1033
С. Е. – 340
С. Еники – 340
С. Җ. – 178
С. Җәлал – 178
С. Зәйнәб – 1063
С. Иманколый – 391
С. Исәнбай – 413
С. Камал – 441
С. Камский – 965
С. Корбангалиев – 479
С. Кудаш – 488
С. Кулибай – 493
С. Ләбиб – 789
С. Максуди – 534
С. Мифтахетдин – 570
С. Мифтахов – 569
С. Ногманов – 659
С. Р. – 721
С. Рахманколый – 701
С. Рәкыйп – 753
С. Рәми – 716
С. Рәхмәти – 721
С. С. – 802
С. Сабиров – 727
С. Садыйкова – 736
С. Сәгыев – 732
С. Сүнчәләй – 802
С. Таҗи – 832
С. Урайский – 613
С. Урманов – 865
С. Фәйзи – 774
С. Хаҗи Аягуз – 63
С. Хәким – 967
С. Хәсәни – 993
С. Шакир – 1011
Сабир әл-Хәсәни – 993
Сабир Имаметдинов – 387
Сабир кызы – 726
Сабиров Сафа – 727
Сабирова Ләлә – 962
Сабур – 147
Садрелҗиһанов Җәлал – 725 а
Садретдин Айни – 229
Садри Җәлал – 178
Садри Максуди – 534
Садри малае – 733
Садри Самарлы – 733
Садыйк – 391
Садыйк абзый – 1128
Садыйк Саттаров – 755
Садыйк Сәгыев – 732
Саип – 439
Сакай бабай – 741
Сакай Н. – 740
Сакалтай – 7
Салават Камский – 965
Салават Хәйруллин – 965
Салих Корбангалиев – 479
Салих Сәйдәш – 785
Салихҗан Кукляшев – 490
Салихҗан Урманов – 865
Сал-Шәф – 742
Самат Шакир – 1011
Самат Шәрәфетдинов – 1033
Сандугач – 730
Сандугач – 847
Сания Гыйффәт – 448
Сара Садыйкова – 736
Сарим Фәхри – 904
Сатиев Г. – 752
Саттаров Гомәр – 1160
Саттаров Рәкыйп – 753
Сафа Бакый – 91
Сафа Борһан – 147
Сафа Хафиз – 934
Сафин Рафаэль – 759
Сафиуллина Соня – 761
Сахибҗамал Гыйззәтуллина – 297
Сәвәл – 176
Сәгыйка – 439

Сәгыйть – 843
Сәгыйть Әбелфәрид – 802
Сәгыйть Ваккас – 802
Сәгыйть Исәнбай – 413
Сәгыйть Мифтахов – 569
Сәгыйть Рәмиев – 716
Сәгыйть Сүнчәләй – 802
Сәгыйть Таҗетдин – 832
Сәгыйть Ф. – 883
Сәгыйть Хаялин – 942
Сәгыйть Янгалычев – 1074
Сәед – 398
Сәед Исмәгыйлев – 398
Сәед Шәкүров – 1013
Сәйид Али – 875
Сәйфелмөлек – 796
Сәйфуллин Габбас – 791
Сәйях Аягузи – 63
Сәлах Атнагулов – 56
Сәлах Камал – 441
Сәләй – 56
Сәләх Кулибай – 493
Сәлим – 1119
Сәлим Вәлиди – 176
Сәлими Ф. – 788
Сәмави – 1003
Сәмави – 299
Сәмитова Газизә – 800
Сәмруг – 786
Сәнҗар – 765
Сәрвәр Әдһәмова – 1099
Сәрвәретдин Мифтахетдинов – 570
Сәүбани Г. – 801
Сәхаб Урайский – 613
Сәхи Р – 721
Сәхи Рәхмәти – 721
Сәхипгәрәй Сәетгалиев – 783
Сверигин Р. – 763
Сер – 810
Сибай – 728
Сибгат Бари – 704
Сибгат Гафуров – 270
Сибгат Хәким – 967
Сибирияле – 557
Сирин – 896
Солдат Йосфый – 507
Солтан Рахманколый – 701
Солтангалиев Мирсәит – 771
Сорокин Касыйм – 777
Сөемсез – 843
Сөендек – 1051
Сөләйман С. – 795
Сөндекле М – 535
Сөрүҗе (революциягә чаклы) – 154
Срәи – 712
Субай – 786
Субукай – 309
Сул – 1068
Сулмаш – 295
«Султанов» – 122
Сумалак әүлия – 1055
Сурати – 559
Суфизадә – 1102
Сүрәйә – 562
Сүрәйә – 1130
Сылухан Дасаева – 311
Сюрприз – 318
Т. Арслан – 47
Т. Әбүзәр – 862
Т. Г. Т. – 843
Т. Гыйззәт – 298
Т. Гыйззәт – 299
Т. Мамлин – 546
Т. Р. – 764
Т. С. – 764
Т. С. – 827
Т. Сәгъди – 730
Т. Соловьев – 770
Т. Үзбәк – 334
Т.Һ. Таш – 814
Таван тистәр – 968
Таҗетдинов Басыйр – 830
Таҗи Гыйззәт – 298
Таибә Капкаева – 450
Таймас – 95
Тайфун – 467
Талпан – 414
Танай – 147
Таналин Һ. – 815
Таң – 334
Таң – 420
Таңчы – 401
Тараканлы – 839
Таранчы – 618
Тарикъ – 296
Тарпищев Х. – 817
Татар – 460
Татар углы – 634
Татар хатыны – 86
Татарин театрал – 475
Татлы – 222
Таттеатр трест – 158
Таулы башкорт – 65
Таһиров Афзал – 822
Таһиров Индус – 825
Таһиров Мөхәммәт – 824

Ташкент Шамали – 28
Ташкентлы – 28
Ташкын – 631
Ташмөхәммәт – 1108
Тәвәллә – 950
Тәлгать – 531
Тәлгать – 928
Тәнкыйть сөюче – 843
Тәрҗеманов Җәвад – 857
Тәфкилев Котлугмөхәммәт – 859
«Т-д» – 1108
Телче – 454
Темучин – 1093
«Теоретик» – 431
Тикән – 829
Тиктормас – 178
Тиктормас – 843
Тимер ага баласы – 178
Тимер Арслан – 47
Тимер калтай – 563
Тимербай курайчы – 808
Тимери – 838
Тимерче малае – 505
Тимерша С. – 770
Тире трест – 158
Торгын – 1094
Торгынбай – 682
Точка – 814
Төкәмсез әкәм – 445
Төхфәт Ченәкәй – 1003
Төхфәт Ченәкәй – 299
Төхфәт Янәби – 1072
Төхфәтуллин Хәмит – 861
Түкә – 584
Түки – 833
Тукай түгел – 158
Туки – 842
«Туктар» – 844
Тулкын – 204
Тулкын – 710
Туран – 334
Тургай – 738
Тутай II – 157
Тутыя Якубы – 8
Үзбәк – 463
Үзе – 798
Үтәй Җ. – 1137
Уйгун – 52
Уйгур – 615
Уйгур – 196
Уйгыр – 95
Укмасый М.Г. – 344
Укытучы – 938
Уразаев Габдулла – 864
Уральский – 1088
Урманова Рауза – 868
Урманова Хәнифә – 866
Урманчиева М. – 577
Уртай – 267
Усай – 872
Усал – 845
Усбак – 88
Усман Бакир – 88
Усманов – 874
Ут малай – 505
Учитель – 546
Учитель – 938
Учитель-Тәтешле – 428
Ф. А. – 6
Ф. Агиев – 6
Ф. Алушаева – 19
Ф. Асаева – 81
Ф. Асянов – 49
Ф. Ә. – 1108
Ф. Әсгад – 899
Ф. Б – 94
Ф. Байкина – 81
Ф. Бакир – 89
Ф. Бакиров – 89
Ф. Басыйр – 94
Ф. Болгарский – 879
Ф. Борнаш 145
Ф. Булатов – 137
Ф. Вагазова – 190
Ф. Вәлиев – 161
Ф. Ибраһим – 369
Ф. Исәнкулов – 392
Ф. Исхаков – 407
Ф. К. – 513
Ф. К. – 514
Ф. Камалов – 793
Ф. Мортазин – 583
Ф. Мөхәммәдьяров – 633
Ф. Нәүрузова – 652
Ф. Нурмави – 663
Ф. Рәхимгулова – 688
Ф. С. – 774
Ф. С. – 797
Ф. Сәйфи – 797
Ф. Сәйфи Уфалы – 797
Ф. С-Казанлы – 793
Ф. Солтанбик – 774
Ф. Сөләймани – 808
Ф. Сөләймания – 805
Ф. Таипов – 813
Ф. Туйкин – 842
Ф. Туйкин (Чаян) – 369
Ф. Х. – 913
Ф. Халиди – 913
Ф. Хәйруллин – 964
Ф. Хәмидулла – 985
Ф. Хөсни – 1000
Ф. Чиркәсов – 1005
Ф. Яркимбаева – 1148

Фагыйл – 75
Фазыл Таипов – 813
Фазыл Туйкин – 842
Фазылҗан Хәмидулла – 985
Фаикъ – 1066
Фалончи – 1135
Фамирәк – 514
Фатих Әмирхан – 1108
Фатих Ибраһимов – 369
Фатих Кәрим – 514
Фатих Кәрими – 513
Фатих Мортазин – 583
Фатих Мөхәммәдьяров – 633
Фатих Сәйфетдинов – 797
Фатих Сәйфи учитель – 797
Фатих Сәйфи-Казанлы – 793
Фатих Хөсни – 1000
Фаш (?) – 145
Фаяз Дунай – 940
«Ф Ә-д» – 899
Фәез Идел – 885
Фәезбәк – 134
Фәезхан – 890
Фәезхан Даудов – 331
Фәйзи – 161
Фәйзи – 566
Фәйзи әфәнде – 131
Фәйзи Зайсанлы – 882
Фәйзи Чаган – 161
Фәйзрахман Солтанбик – 774
Фәйзрахман Чиркәсов – 1005
Фәйзулла Туишев – 841
Фәйзуллин Әхмәт – 885
Фәйзуллин Сәгыйть – 883
Фәлән – 318
Фәнил Асянов – 49
Фәрваз Миңнуллин – 576
Фәрид И – 370
Фәрид Исәнкулов – 392
Фәрид Ыргалы – 370
Фәридә ханым – 652
Фәрит Хәйруллин – 964
Фәрихат – 827
Фәррах Дәүләтшин – 328
Фәрхи Әхмәт– 1119
Фәтхи – 137
Фәтхи Альберт – 894
Фәтхул – 898
Фәтхуллин Хәлил – 897
Фәүзия Рәхимгулова – 688
Фәхрелбәнат Сөләймания – 805
Фәхретдин бине Мифтахетдин – 571
Фәхри – 6
Фәхриев – 1077
Фбикар – 680
Феакут – 843
Фидаи – 1032
Фидани – 424
Фикри – 455
Фикри – 779
Философ – 158
Фираз – 154
Фиракый – 888
Фитрәт – 689
Фитри – 566
Флора Әхмәтова – 1150
Фольклорчы Флора – 1150
Фонамсог – 377
Фурия – 155
Х. Абушаев – 54
Х. Араблинский – 45
Х. Атаев – 50
Х. Атлаши – 54
Х. Әхмәтсолтан – 957
Х. Байбиков – 72
Х. Бакири – 150
Х. Бәдигый – 148
Х. Борнаш – 146
Х. Вәгыйз – 434
Х. Г. – 208
Х. Г. – 292
Х.Г. Габәши – 218
Х. Габдулла – 956
Х. Габдуллин – 213
Х. Габдушев – 208
Х. Габиди – 214
Х. Гатина – 1149
Х. Гобәйди – 286
Х. Гомәрзадә – 292
Х.Д. Мәхмүдов – 557
Х.З. әл-Чистайлы – 343
Х. Зәбири – 343
Х. Искәндәров – 394
Х. Исхакый – 409
Х. Ишбулат – 418
Х. К. – 516
Х. Кайбышев – 431
Х. Камалов – 442
Х. Канзәфәр – 434
Х. Кәрим – 516
Х. Корбангали – 480
Х. Кунакбаев – 496
Х. Мамин – 543
Х. Мәхмүт – 557
Х. Мөҗәй – 991

Х. Мөхтәр – 587
Х. Наумов – 650
Х. Нәҗибәк – 933
Х. Нигъмәти – 650
Х. Ниязи – 968
Х. Рахман – 200
Х. Ризван – 709
Х. Сәлимов – 798
Х. Телләхан кызы – 837
Х. Туфан – 853
Х. Усманов – 295
Х. Фәйзи – 884
Х. Хәйри – 966
Х. Ямашев – 1068
Х. Янибай – 919
Х. Ярми – 1076
Хаджаев Низам – 952
Хаҗи Габдуллин – 213
Хаков Вахит – 911
Халиди Фатих – 913
Халикъ Садри – 733
Хан Җәмил – 1138
Ханзафаров – 923
Хаников Кәрим – 924
Ханиф Чыңгыз – 925
Ханская Хәдичә – 926
Хантимеров Н – 927
Харис Фәйзи – 884
Хас – 678
Хасиятулла малае – 1030
Хатыйб Пәрвәз – 1029
Хафиз Палютин – 673
Хафиз Сәйфи – 792
Хафизов Нәҗибәк – 933
Хафизов Сафа – 934
Хәбәрче трест – 1106
Хәбиб – 409
Хәбиб Зәйни – 346
Хәбиби Солтан – 957
Хәбибрахман әл-Мәсгуди – 609
Хәбибрахман Зәбири – 343
Хәбибулла Гомәрзадә – 292
Хәбирә Насыйрия – 1155
Хәбиров Гомдә – 959
Хәбра Рахман – 200
Хәдичә Әхмәрова – 1115
Хәерби – 536
Хәй Вахит – 182
Хәй Мөхәммәдьяров – 632
Хәй Хисмәтуллин – 938
Хәйдәр Сәлимов – 798
Хәйдәрова Л. – 962
Хәйретдин Вәли – 170
Хәйретдинов М. – 991
Хәйриев – 1077
Хәйрулла малае – 814
Хәйруллин Исмәгыйль – 909
Хәлим Сабит – 729
Хәлимов Айдар – 971
Хәлимов Борис – 971
Хәлфин Ибраһим – 974
Хәлфин Исмәш – 977
Хәлфин Исхак – 976
Хәлфин Мөхәммәдрәхим – 978
Хәлфин Сәгыйть – 980
Хәлфин Хәсән – 981
Хәлфин Шаһингәрәй – 982
Хәмзә – 1122
Хәмзә Хәкимзадә – 968
Хәмиди Идрис – 984
Хәмит – 781
Хәмит М. – 988
Хәмит Мөштәри – 637
Хәмит Сөләймани – 806
Хәмит Шәрәф – 284
Хәмит Ярми – 1076
Хәмитов Малик – 987
Хәнәф Наумов – 650
Хәнәфи – 431
Хәнәфи Бакири – 150
Хәнәфи Кайбышев – 431
Хәнәфи Мозаффар – 574
Хәнәфи Мөбарәкша – 989
Хәниф Кәрим – 515
Хәнифә Гыйсмәтуллина – 1157
Хәсән К. – 501
Хәсән Мамин – 543
Хәсән Мөхтәров – 587
Хәсән Ризванов – 709
Хәсән Туфан – 853
Хәсән Урманов – 867
Хәсән Хәйри – 966
Хәсәнгата Г. – 218
Хәсәнов Нургали – 992
Хәятел-хәйванаттан күчерүче – 843
Хис – 409
Хисам Камалов – 442
Хисам Тыңламыш – 955
Хисамов – 1146
Хисләт – 1131
Хисрави – 459

Ходайбирдин Ш. – 943
Хокандлы – 810
Хөжҗәтелхәким – 557
Хөршид – 1026
Хөсәен Атлаши – 54
Хөсәен Мәүлүтов – 603
Хөсәен Сахин – 949
Хөсәен Тарпищев – 817
Хөсәен Фәезханов – 889
Хөсәенов Вәли – 998
Хөснетдин малае – 551
Хөснетдинов Вәли – 999
Хөсни Кәрим – 516
Хуҗа Бәдигъ – 148
Хуҗа Рафыйков – 687
Хуҗиев Г. – 954
Хурамшин Җамалетдин – 948
Хыф – 884
«Чүкеч» – 770
Һ. Атласи – 53
Һ. Килдебәк – 471
Һ. М. – 536
Һ. Сәгъди – 780
Һ. Т. – 814
Һ. Таһири – 828
Һ. Таһиров – 828.
Һ. Таш – 814
Һ. Фәйзи – 887
Һади – 439
Һади Маликов – 541
Һади Атласи – 53
Һади Исхаков – 410
Һади Килдебәк – 471
Һади Максуди – 536
Һади Сәгъди– 780
Һади Такташ – 814
Һади Фәйзи – 887
Һаҗәр Ибраһимова – 374
Һәдия Дәүләтшина – 329
Һәдия Такташева – 814
Һәдия Хәйрулла кызы – 814
Һәмзәви – 536
Һәнүз Мәхмүтов – 556
Һәшрәб – 787
Һиббәтулла – 746
Һидаят Хәкимов – 970
Һидиятуллин Рамазан – 1085
Һиҗрәт – 562
Һиҗрәт – 1130
Һималай – 505
Һинди Минһаҗ – 423
Һөд-һөд – 843
Ч. Ханиф – 925
Чабата – 814
Чакан – 166
Чакар – 528
Чакмагыш – 69
Чакмак – 614
Чал – 1130
Чанышев Хафиз – 1001
Чанышев Якуб – 1002
Чапуринский. (1007
Чархи – 920
Чаянист – 1105
Чаянчы – 158
Чаянчы – 955
Чәпи Камали малае – 793
Чебен – 158
Челтәрле – 840
Ченәкәй – 1003
Ченәкәй – 299
Черки – 1106
Чигәбай – 562
Чигәбай – 1130
Чикәбай – 562
Чиркәсов Султан – 1004
Чистайлы – 820
Чичарә – 425
Чокалый Гариф – 1006
Чүкәй – 972
Чүмәти – 951
Чүпләүче – 713
Чулпан – 683
Чулпан – 806
Чутайлы – 955
Чыгай – 750
Чыгтай – 271
Чыгтай – 4
Чыңгыз – 401
Чытырман – 65
Ш. Мостай – 598
Ш. Әхмәди – 1122
Ш. Әхмәтҗанов – 547
Ш. Б. – 120
Ш. Б. – 87
Ш. Байчура – 87
Ш. Биккол – 120
Ш. Гауни – 274
Ш. Зәйни – 1019
Ш. Ибраһимов – 373
Ш. Измайлов – 379
Ш. Иманаев – 390
Ш. К. – 74
Ш. Камал – 74
Ш. М. – 619
Ш. Манатов – 547
Ш. Маннур – 550
Ш. Мәҗитов – 616
Ш. Мөдәррис – 619
Ш. Мөхәммәдев – 627

Ш. Мөхәммәдьяров – 634
Ш. М-яров – 634
Ш. Н. Т. – 1027
Ш. Насыйров – 649
Ш. Р – 715
Ш. Рамазанов – 683
Ш. Рәмзи – 715
Ш. Рәхмәтуллин – 707
Ш. Саттаров – 756
Ш. Сүнчәләй – 804
Ш. Усманов – 296
Ш. Хасиятуллин – 1030
Ш. Хәмиди – 986
Ш. Хөсәенов – 996
Ш. Ш. – 1038
Ш. Шамильский – 187
Ш. Шәһәр – 1047
Шагыйрь № 1 – 814
Шад – 1050
Шакир Б. – 119
Шакир Измайлов – 379
Шакир Мәҗитов – 616
Шакир Мөхәммәдьяр – 634
Шакир Насыйров – 649
Шакир Рәмзи – 715
Шакир Шамильский – 187
Шакирҗан Хәмиди – 986
Шалгай – 425
Шалпанколак – 267
Шамил Госманов – 296
Шамил Рәкыйпов – 723
Шамил Сафин – 760
Шаммаси Хәдичә – 1018
Шамун Фидаи – 1012
Шапалак – 562
Шапалак – 1130
Шаркүз – 445
Шахмай 1141
Шахтер кызы – 175
Шаһбазгәрәй Әхмәров – 1117
Шаши – 425
Шаян – 1052
Шәй агайның секретаре – 377
Шәймәрдәнов Шәңгәрәй – 1031
Шәйхи Маннур – 550
Шәмигулов Гали – 1014
Шәмсетдин Күлтәси – 520
Шәмсетдин Суфи Зәки – 1021
Шәңгәрәев Гайнелислам – 1045
Шәрә – 960
Шәрәф Мөдәррис – 619
Шәриф Биккол – 120
Шәриф Камал – 74
Шәриф Манатов – 547
Шәриф Рахманкулов – 699
Шәриф Саттаров – 756
Шәриф Сүнчәләй – 804
Шәриф Хөсәен – 996
Шәрык баласы – 781
Шәрык баласы – 887
Шәрык кигәвен – 158
Шәүкәт – 928
Шәүкәт Гали – 1086
Шәүкый – 27
Шәфигуллин В. – 1043
Шәфика Шәрәф – 1038
Шәһәр Шәрәф – 1040
Шәһид Ходайбирдин – 943
Шәһиди Рәүф – 1044
Шәһидуллин Шәрәфетдин – 1046
Шәһит Әхмәдиев – 1122
Шәһит Гауни – 722
Шәяхмәт – 700
Шәяхмәт – 833
Шимали – 318
«Шималь» корреспонденты» – 778
Ширванский – 397
Шиһаб Әхмәров – 1118
Шиһаб Мәрҗани – 608
Шиһаб Рәхмәтуллин – 707
Шиһап солдат – 550
Шөнаси – 360
Шөпшә – 65
Шөһрәт – 562
Шөһрәт – 1130
Шүрәле – 843
Э. Сәгыйтова – 784
Эзче – 1082
Эзче – 381
Энҗе Мөэминова – 638
Энҗе Сәгыйтова – 784
Эрә егете – 350
Эшче – 1055
Эшче – 803
Ю. Ахунбабаев – 61
Юзеев Илдар – 1049
Юзиев Ибраһим – 1048
Юксыл – 404
Юксыл – 358
Юлазский – 675
Юлаучы – 425

Юлдаш А. – 61
Юлчы – 1050
Юнай Г. – 1053
Юнусов Мирсәед – 1054
Юныс Әминов – 1132
Юсупов Габдулла – 1058
Я. А. – 15
Я. А. – 8
Я. Агиш – 8
Я. Айман Капаллы – 15
Я. Халитов – 915
Я. Хәлили – 973
Я. Чанышев – 1002
Ягру – 678
Якәнч – 299
Якуб Айманов – 15
Якуб Алтайлы – 15
Якуб Колмөхәммәтов – 492
Якуб Мамишев – 544
Якуб Хәлили – 973
«Якуб улы» – 1060
Якупов Әхмәт – 1066
Якупов Нургали – 1064
Яланаяк – 469
Ялганчы – 739
Ялкавайлы– 281
Ялкын – 694
Ялчыгол Т. – 1071
Янбулат Муса – 1070
Япанчы – 1075
Япанчы – 904
Яркимбаева Флюра – 1148
Ярлы Кәрим – 509
«Ярул» – 1113
Ярулла Вәли – 164
Ярулла Вәли – 172
Ярулла Морадый – 580
Яушев Н. – 1079
Яхин Таип – 1078
Яхъя Халитов – 915
Яһүдин Әзәл – 1081
Яһүдин Ильяс – 1080
Яшен – 657
Яшенче – 439

# ТЕКСТЛАРНЫ ГАМӘЛДӘГЕ ЯЗУГА КҮЧЕРҮЧЕЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘҮЧЕЛӘР

*Гомәров И.Г. – филол. фән. канд.,* Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге җитәкчесе.

*Ахунов А.М. – филол. фән. канд.,* Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Гарипова Л.Ш. – филол. фән. канд.,* Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Зәйниева Г.Н. – филол. фән. канд.,* Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

# ЭЧТӘЛЕК

**Кереш** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
**I бүлек. Тәхәллүсләр сүзлеге** . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
*М. Бөдәйли*. Псевдоним-кушаматларга аңлатма . . . . . . . 10
*М. Бөдәйли.* Тәхәллүсләр сүзлеге . . . . . . . . . . . . . . . 12
**II бүлек. Псевдонимнар турында** . . . . . . . . . . . . . . . . 235
*М. Бурнашева.* Псевдонимнар турында . . . . . . . . . . . 236
*М. Мәһдиев.* XX йөз башы татар әдәбиятында псевдонимнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 241
*М. Абдуллин.* Псевдоним кушамат түгел . . . . . . . . . . . 257
*З. Рәмиев.* Дамелла, Марксист, Ташмөхәммәд . . . . . . . 266
*З. Рәмиев.* Псевдонимнар турында . . . . . . . . . . . . . . . 270
**Кушымта** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 273
Исемнәр күрсәткече . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 274
Текстларны гамәлдәге язуга күчерүчеләр һәм шәрехләүчеләр 298

**ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ**
**поиски и открытия**
Выпуск 10

Редактор А. А. Давлетова
Компьютерная верстка Н. Т. Абдуллиной
Дизайн обложки А. Б. Шляпкина

Подписано в печать: 15.12.2021 г.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная.
Усл.-печ. л. 17,4. Уч-изд. л. 12,5. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20